# КАЗАН УТЛАРЫ

7

ИЮЛЬ · 1972

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**7**

ИЮЛЬ
1972

## Бу санда

Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Лирик шигырьләр . . . . . . 3
Ш. БИКЧУРИН. Каты токым. Роман . . . . . . 9
Ә. БАЯНОВ. Чәлтәрләргә карап. Шигырьләр . . 75
Ф. ЧАНЫШЕВА. Гомер мизгелләре. Шигырьләр . 80
Н. СӘФӘРЕВ. Каргышлы һәм өметле көн. Роман. 83
Р. ГӘРӘЙ. Туган-үскән җирләрем. Шигырьләр . 131
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Ничек онытыйм! Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 134
А. СӘФӘРЕВ. Дзержинский ордеры. Хикәя . . 137

ОЧЕРКЛАР

Ш. МОТЫЙГУЛЛИН. Яшьтәшләр . . . . . . . 146

СССР ТӨЗЕЛҮГӘ 50 ЕЛ

З. НУРИ. Янка Купала һәм аның иҗади варислары . . . . . . . . . . . . . . . 156
Я. КУПАЛА. Минем юл. Шигырьләр . . . . . 157
И. АХУНҖАНОВ. Үткәнгә сәяхәт . . . . . . . 162
И. КОЛЕСНИК. Күзге кич... Шигырьләр . . . . 168

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

М. ХӘМИТОВ. Очерк гыйбрәтле булсын . . . . 170

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ш. ӘХМӘДУЛЛИН. Иҗат үзенчәлеген расларганда 176
М. МАЛИКОВА. Тормышчанлык өчен . . . . . 180
Ш. МАННАПОВ. Шагыйрьне мин шулай ачтым... 182

ЮМОР-САТИРА

Н. ДӘҮЛИ. Тимәгез минем Гөлзадама! Хикәя. Мәзәкләр . . . . . . . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары»*.
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь—2-39-52, бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева.*

Производствога бирелде 5/IV-1972 ел. Басарга кул куелды 20/VI-1972 ел. ПФ 09021. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83846 экз. Заказ Г-237. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1972 ел.

**Равил Фәйзуллин**

# ЛИРИК ШИГЫРЬЛӘР

## Этюд-рәсем

Баласын яшь ана
йөзәргә өйрәтә.
Үзе яткан чалкан,
баласы — күкрәктә.
Биеккә-биеккә
төбәлгән карашы.
Зәңгәр күк фонында —
Кояш та баласы.
Төтенсез, шартлаусыз
аларның арасы.
Шулай күккә багып
килә гел барасы,
барасы...

Яр буе чыр-чуын
ишетми дә ана.
Баласы белән ул
эчкә кереп бара.
Сакланып, шатланып
йөзәргә өйрәтә.
Дулкыннар тибрәтә,
бәгыре — күкрәктә.

●

Нинди күзләр! Нинди буй!

Яшь чагында көн дә бәйрәм!
Көн дә уен, көн дә туй!

Ник ди исәп! Ник гамь-уй?
Дөнья бәйрәм! Дөнья туй!

Кара, кара, күрми калма —
нинди күзләр! Нинди буй!

●

Син — теләп алган сагышым.
Син — теләп алган ярам.
Туеп кем дә китәр, ә син —
яратып китеп кара!
Үз-үземә каршы килеп
мин синнән китеп барам.
Кайтмаска китеп барам,
китеп барам...

Хәлне сорама, теләсәң
үзең мин булып кара!

...Иреннәр кыймылдавына
кешеләр карап кала:
«Үзалдына сөйләнә бу,
исәр, ахры, бичара!..»
Ә мин тәүге очрашуга
рәхмәтләр укып барам.
Рәхмәтләр укып барам.

Ярамы? Анысы — минем эш.
Ул — теләп алган ярам.

●

Көндезен — кеше күзендә,
төнен — син — керфегемдә.
Бергә булган вакытларның
онытмам бөртеген дә.

Синең белән узган гомер
гел тоташ бәйрәм генә.
Алда әле андый бәйрәм
бармы, юкмы — кем белә?

●

Сөйдем аны.
Шаштым!
Җаным
күкләргә күкрәп менде!
Әйттеләр: бигрәк басынкы,
сүрән дә бала инде...

Бер заман, «гашыйк икән!» дип,
илгә сүз чыккан иде.
...Ә мин инде ул вакытта
Аны онытකан идем.

●

Курыкма, көл, елмай!
Кирәкми аһ-ваһлар...
Савапка торырлык
безнең бу
гөнаһлар!
Көл, елмай!..

●

Асылмалы тар күпердән
мин алдан чыктым микән,
син алдан чыктың микән?
Тау менгәндә үпкәнемне
инде оныттың микән?

Күк — зәп-зәңгәр, ә тирә-юнь
яшь сусыл үлән иде.
Ул елны җәй әллә ничек,
безнең мәхәббәт шикелле,
соңгарып килгән иде...

Тау башыннан караганда
Зәй — кара дегет кебек.
Ә безнең күңелләр ак, пакь! —
Мәктәпне яңа бетергән
кыз белән егет кебек.

Күңелдә җыр — куанычтан:
«Яшьлек безгә үзе килде,
алмадык ла бурычка!
Гомернең, һай, мәхәббәттән
тилергән чагы кыска!..»

. . . . . . . . . . . . . . .
Син уйнаклап таудан төштең,
күктә сайрады тургай.
Асылма күпердән кире
ничек чыктык, хәтерләмим —
без очып чыктык бугай.

## Уен

Борынгы уен дигәч,
ырымлы уен дигәч,
ләззәтле, тәмле дигәч,
уйнавы ямьле дигәч,—
нигә кермәскә, дидем,
уенга барып кердем.
Авыз ачып калмаска,
кешедән калышмаска!

Уенда юк кем генә!
Монда утлар, монда балкыш,
гүя монда көн генә.
Читтән карап торганда,
бәхетле бер гөр генә!

Үзең кергәч, күрәсең,
күргәч, бераз беләсең!
Монда әллә нәрсәләр!
Кайчак хәрәмләшәләр.
Алдаса да, юрамалый
тәмле сүз эндәшәләр.
Монда бар газиз хисләрен
ваклатып оттырган да.
Бар шомалар. Гомерләрен
гел уенга корган да.
Бар мәгънәне, бар хәйләне
аңлап бетү дә кыен.
Бу әллә кызык уен,
бу әллә бозык уен?

Бу әллә нинди уен!
Туктыйм инде, дип уйлыйм.
Үзем уйныйм, үзем туймыйм...
Бүтәннәр юри уйныйлар,
мин, юләр, чынлап уйныйм,
ихлас ышанып уйныйм.
Барысын беләсе килә.
Кайчак көләсе килә.
Уендашлар шаркылдыйлар,
миңа күз яше килә...

Бу әллә нинди уен!

●

Мин сиңа йомшак таң җиле
юллаган идем.
Чәчләреңнән иркәләр дип
уйлаган идем.

Сәфәрендә илләр кичеп,
тауларда кунып,
ул сиңа ирешкән икән
зилзилә булып.

Мин сине сагынып бер җыр
чыгарган идем.
Кешеләр аны яратып
тыңлаган иде.

Җыр сиңа ошар дип йөрдем,
ваемсыз булып.
Ә ул сиңа барып җиткән
хаин сүз булып.

...Хәзер җилләр дә юлламыйм,
чыгармыйм җыр да.
Теләсәң үзең җанымны
кил дә бер тыңла.

●

Биеккә мендем. Кояшка —
калды шундый якын!
Җиде кат күкнең быел мин
ачтым алты катын!

Берсен әле куеп тордым
алгы гомергә дип.
Бер бәхетле таңда икәү
ачарбыз бергә дип.

## Бу дөньяда

Бу дөньяда бик офтанма,
мин барын да истә тот.
Дусларның да дуслары бар,
серләреңне эчтә тот.

Бу дөньяда бер ояга
сыялмаган кош азмы?
Барыбер тартып алалмыйлар
күңелгә тулган язны!

Бу дөньяда әле алда
күп бәхетләр бардыр күк.
Күгең тутырып бер килермен
тоташ ләйсән яңгыр күк.

## Тимим күңелемә

Тимим күңелемә,
өзгәләнсен, янсын!
Кеше кайчак үзен
кичерә дә алсын.
Хисләрем ярсысын,
уйларым ташысын,
зиһенем чуалсын,
җан изрәп талсын...
Тимим күңелемә,
өзгәләнсен, янсын!
...Ә безнең бу мәхәббәт,
сагышлы мәхәббәт,
каргышлы мәхәббәт
җыр булып калсын.

Яңа таңнар атсын,
яңа гөлләр үссен.
Бу татлы газаплар
бүтәннәргә күчсен.
Яшь йөрәкләр янсын,
яшь җаннар юансын.
Сөю алар белән
киләчәккә барсын!
Тимим күңелемә,
өзгәләнсен, янсын...
...Ә безнең бу мәхәббәт,
тиңдәшсез мәхәббәт,
күз яшьле мәхәббәт
җыр булып калсын!

●

Бәхетле булып, таңгача
йөргән идек икәү без.
Кавышырга да өлгермичә,
аерылган икәнбез.

Без яраткан ул ләйсәннәр
кабатланмас микәнни?
Бу йөрәкләр өзгәләнеп
кабат янмас микәнни?

Көзге соңгы чәчәкләргә
саксыз кагылма икән.
Үзең теләп бер хушлашкач,
кабат сагынма икән.

1971

Шамил Бикчурин

# КАТЫ ТОКЫМ

РОМАН

19


Җәйләүдә Язтургай кызларын күреп кайткан көннән соң егетләрдә тәмам дәрт кабынды. Вахтага ашыгып баралар, эштән ашкынып кайталар. Кич җитә башлау белән үк чатыр тирәләре җанланып китә: егетләр билдән чишенеп ташлап юыналар да, ватык-китек көзгеләре алдына утырып, сакал-мыекларын кырырга тотыналар, кабалана-кабалана киенә-ясана башлыйлар. Кайсы чәчен тезәтә, кайсы башына хушбуй коя, кайсы таш өстендә туфлиен ялтырата. Аланга исле май исе, крем, одеколон исе тарала — яшьләр Язтургайга китәргә җыеналар.

Валентин, инде диңгезче формасын киеп алып, күптән таш өстенә чыгып утырган, егетләрне ашыктыра:

— Нигә шул кадәр тырышасыз, туйга барасызмы әллә?

Сапарбай да озак көттермәде, чатыр алдына чыкты. Казагыстаннан кайтканнан бирле ул хәзер кеше рәтеннән ашый, кеше рәтеннән киенә. Үткән айда кассир Маша түти акча урынына бик яхшы зәңгәр габардин костюм алып килгән иде — Сапарбай ведомостька кул куеп, тукланырлык кына акча алды. Рәйсә дә күптән түгел район үзәгеннән егеткә пальто алып кайтып бирде. Күлмәкләре дә күп аның хәзер, чалбарлары да. Тик менә киенеп-ясанып йөрергә генә вакыты аз тия. Нефть чыгып, ял алса, Сапарбайның әле Ык буйларына барып чыгарга, Кәримәне күреп кайтырга да исәбе юк түгел... Кәримә дип хыялланган була, бичара, тик карармы икән соң аңа Кәримә? Шаяртып кына яза торгандыр ул хатны Сапарбайга...

Ниһаять, Сергей да сакалын кат-кат кырып, тәмам шомарынып аланга чыгып басты, гармунын җилкәсенә аскан Габбас та күренде. Бераздан Нәҗип белән Михаил Кубрак та әзер булдылар.

— Мотгәрәй кая соң әле, Мотгәрәй?

— Ул әллә кайчан урманга кереп тайды инде. Шүрәле кызлары янына китте бугай...

---

Ахыры. Башы 5, 6 саннарда.

Фәрхетдин әле һаман җыена. Ике зур чемоданын актарып ташлаган да, көяз хатыннар шикелле, күлмәк сайлый. Күлмәген күп булса да кыен икән: берсен киеп карый да, ошатмыйча, салып ыргыта, икенчесен табып ала, аны төрле яклап тагын әйләндерергә тотына.

— Я инде, Гафифә түтәй, асылынасың килсә асылын ки дә, киттек, булмаса! — дип кычкыра аңа Габбас.

Бригадага эшкә килгәннән бирле Фәрхетдиннең бөтен максаты кием җыю булды. Төрле төстәге костюм алды, төрле сорттан күлмәк, төрле модельдән аяк киеме булдырды. Хәзер аның биш-алты пар костюмы, утызлап күлмәге, үзе әйтмешли, бер ротаны киендерерлек туфли-ботинкалары, аркан ишәрлек галстуклары бар. Кая булса да барырга, чыгарга булса, кайсын кияргә, кайсын салырга белми буталып ята...

Шул киемнәре аркасында бик күп отты да ул. Барган җирдә ыспайлыгы белән иптәшләре арасында аерылып торды, һәрвакыт чит кешеләрнең игътибарын үзенә тартты. Белмәгәннәре аны буровойның хуҗасы итеп күрәләр, мастердан да алда аның янына килеп сөйләшә башлыйлар. Мондый вакытта да Фәрхетдин югалып калмый, Зөбәеровны күрсәтеп: «Ошбу мәсьәләдә әнә минем заместительгә мөрәҗәгать итегез!» — дип кенә җибәрә.

Кызлар чат ябыша Фәрхетдингә. Кеше белән тиз аралашучан, житез хәрәкәтле, шаян, жор телле егет тирәсендә сырышып йөриләр. Күрәсең, кызларны бары тик матурлык кына тарта дигән сүз дә дөрес түгелдер, аларга ярау өчен чиста-җыйнак булу да, сөйләшә-аралаша белү дә кирәктер.

Язтургайга баргач та кызлар белән бик тиз уртак тел тапты Фәрхетдин. Яшьләр клубка түгел, Сагындык елгасы буена җыелганнар булып чыкты. Түгәрәкләнеп, җырлап-биеп уйныйлар иде:

Хаткайларыңны язасың
Кара каралар белән,
Төннәренче уздырасың
Бала-чагалар белән.

Фәрхетдин килеп җитү белән үк түгәрәкнең уртасына кереп басты, җырлап та җибәрде:

Кара кара булса ни,
Ала кара булса ни,
Мин үзем дә бала-чага,
Бала-чага булса ни...

Шуннан соң дилбегәне ычкындырмады да бугай үзе. Һәр төртмәле сүзгә, һәр җырга җавабын биреп кенә торды.

Тегене дә килеп кысты,
Моны да килеп кысты.
Сез кайлардан буласыз соң,
Әйтегез, пожалысты? —

дип җырладылар аңа.

Фәрхетдин шундук тегеләрнең авызын томалады:

Ал биргәннәргә ал бирәм,
Гөл бирел тормыйм әле,
Гөрбияннарга гөрбиян,
Сер биреп тормыйм әле.

Кызлар йомшадылар:

Аргы урамнан килдеңме,
Бирге урамнан килдеңме?
Без сагынганны белдеңме,
Үзең сагынып килдеңме?

Аргы урамнан килмәдек,
Бирге урамнан килдек без,
Сез сагынганны белмәдек,
Үзебез сагынып килдек без.

Кара-каршы әйтешеп җырлаулар, такмаклар, бер-берсен биюгә чакырышулар, кул сугышулар, бөҗра өзешләр, күпер чыгышлар һәм тагын әллә нинди уеннар бу көнне таңга тикле диярлек барды. Тел белмәү аркасында уенга катнашмый бер читтә торган Валентин да, Сергей белән Михаил да, сокланып, бу уеннарда үз милләтләренең яраткан уеннарына хас охшашлык, якынлык тоеп тордылар. «Кызлар белән егетләрнең кара-каршы такмак әйтешүләре һәм тыпырдап биеп китүләре бездән — руслардан керде микән әллә? — дип уйлап куйды Валентин.— Тик бездә дәртлерәк җырлыйлар, гайрәтлерәк биниләр төсле».

Түгәрәк ясап, кулга-кул тотынып әйләнеп биюләрне Кубрак кайсы ягы беләндер украинның «Гопаг»ына охшатты. Охшатты, ләкин килештереп бетермәде. Гопак житезрәк, җиллерәк биелә...

Әрмән кызлары да кич уенга чыгалар, әйләнеп җырлыйлар һәм кыз белән егетне уртага алып биетәләр. Анда егетнең хәрәкәте ярсу, кискен була, ә кызлар мөмкин кадәр салмаграк, нәзакәтлерәк булырга тырышалар; йомшак дулкыннар эчендә йөзеп барган аккошларны хәтерләтеп, егетләргә булган мөнәсәбәтләрен күз карашлары белән җиткерәләр...

Ялгыз җырларда, ялгыз биюләрдә, кемнең нинди милләттән булуына карамастан, бораулаучы егетләрнең барысы да катнашты. Тора-бара Язтургайның оялчан, тыйнак һәм беразгына кыргый кызлары да «кулга ияләшә» башладылар. Тартынусыз гына чыгып биниләр, җырлыйлар, чылбыр өзеш, арка сугыш уеннарында йомшак куллары белән сугып, егетләрне сызланып алырга да мәҗбүр итәләр иде.

Егетләр арасында уен башлыгы Фәрхетдин булса, кызлар ягыннан сыер савучы Саймә иде. Үткерлегеннән, чаялыгыннан бигрәк, бораулаучыларга аның матурлыгы ошады — ул күз сирпеп елмаеп торган түгәрәк йөзле, куе кара чәчле, озын толымлы. Уен вакытында Саймә һәр егеткә кыю карап команда бирә, хәтта, әрсезләнеп, беләктән дә килеп тота. Биш малай арасында үскән кыз диләр аны.

Язтургайга егетләр белән берничә көн рәттән барып, уеннарга катнашып йөргәннән соң, Валентин бер көнне мондый тәкъдим кертте:

— Болай читтән генә кызынып йөрү эш түгел. Язтургайның клубы бар, әйдәгез, кызлар белән концерт өйрәник тә концерт бирик халыкка!

— Бик яхшы! — дип хупладылар аны яшьләр.— Гөрләтик әле бер Язтургайны! Янсын бер кызлар йөрәге!

Хәзер егетләрнең телләрендә «клуб»та «концерт», «репетиция», ләкин ул сүзләр астына әле күбесенең яшерен уйлары, хыяллары, өметләре ята. Һәм шунысы кызык: Тин-Тинычтан калганнарының бу уй-хыяллары бер кызга — бары тик Саймәгә генә юнәлгән иде. «Болында Саймә миңа гына карап көлде, миңа гына карап җырлады,— дип фикер йөртте Сергей.— Димәк, ул мине ошаткан». Сапарбай да кичке уеннарда булганнан соң Кәримәсе турында онытып, күңелен Саймәгә күчергән иде: «Саймә кашын-күзен миңа карап сикертте. Җитмәсә, кулымнан да килеп тоткалады».

Егетләрнең күзләре Саймәгә төшкәнен Фәрхетдин шундук сизенде, ләкин сер бирмәде. «Язган булса, миннән качмас әле»,— дип йөри иде ул эченнән генә.

Менә бу «концерт» дигәннәре генә эшне бозып куйды бит әле. Харап итте Тин-Тиныч. Барысы диярлек җырлый белә, бии белә, гармун тарта, баян уйный, шигырь сөйли... Ә Фәрхетдин нинди һөнәр белә? Күп булса, барлы-юклы тавышы белән кешегә кушылып такмак әйтә ала.

Сәхнә диганенә гомеренә аяк басканы юк. Халык алдына чыгу бит ул сиңа болында кызлар көлдереп йөрү генә түгел. «Булмый, җәмәгать, миннән, кыстамагыз да, бармыйм да!» — дип карышып та караган иде, ләкин яшьләр аның өстенә болыт булып ябырылдылар. Юкны сөйләмә, катнашасың. Шигырь сөйлисең! Иң кызыгын! Синдәге тел бездә булсамы?! «Җаным-бәгырем» дия-дия, Саймә дә килеп ялынгач, каршы тора алмады Фәрхетдин, биреште.

Менә бүген Фәрхетдин Язтургайга репетициягә барырга җыена һәм үзе тумбочкасына сөяп куйган китаптан карап сәхнәдә сөйләячәк шигырен ятлый. «Егет илә кыз». Тукай язган. «Нәкъ инде менә сиңа гына бара!» дип, моны кызлар тәкъдим иткәннәр иде. Кыз булып сәхнәгә Саймә үзе чыгачак, ә түбәтәйле, камзуллы егет ролен атказанган, аттан егылып кадалган, шуның өчен каз алган артист Фәрхетдин башкарачак, ягъни.

Сөям чүмеч кебек борыныңны, җаным.
Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалем!
Җанашым, аһ, иләк авызыңны үпсәм!
Ни кайгы инде шул чакта үлсәм...—

дип әйтәчәк Фәрхетдин Саймәгә. Саймә үпкәләгән булачак, рәнҗеп егет яныннан китеп барачак.

Мәхәббәтсез, лыгырдый шунда җукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә җукмы? —

диячәк, кечкенә авызларын бөреп.

Фәрхетдин йөгереп килеп кызның кулыннан тотып алырга тиеш, ялынырга тиеш:

Ачуланмасана инде, Гайнижамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным,
Синең төсле матур кызлар сирәк бит,
Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит...

Шәп әйткән дә соң Тукай абзаң! Тик менә, каһәр суккыры, шигырьне ятлап кына булмый бит! Бары тик җиде генә юл, әмма башка кермәсә керми икән!

«Кая китте синең телең? Кая китте синең уендагы җорлыгың? — дип тирги аны репетиция вакытында Саймә. Чыннан да, кая китте икән соң ул тел? Күрәсең, ул, буровой бияләе, юкны бушка аударырга гына оста!..

Ниһаять, киенеп-ясанып, Фәрхетдин чатырыннан чыкты. «Сөям чүмеч кебек борыныңны, җаным»,— дип, авыз эченнән һаман шигырьне кабатлый иде әле ул.

— Ну, туган, бара башласаң, сине ике сәгать көтәргә кирәк! — дип, ду килеп каршы алды аны иптәшләре.

Язтургайга юл тоттылар.

— Ул бит, бораудашлар, сез диганчә генә түгел. Кием белән генә булышмыйм бит мин, бер үк вакытта репетиция дә ясыйм,— дип акланып барды Фәрхетдин.

— Биш-алты юллык шигырьгә атна буена нинди репетиция инде ул! — дип кычкырды Тин-Тиныч.

Ләкин концертта Фәрхетдин «артистлыгын» күрсәтә алмады. Күрсәтә алмады гына түгел, бөтенләй хур булып сәхнәдән чыгып китәргә, клубтан ук качарга мәҗбүр булды.

Концерт башта яхшы гына барды. Программада кызлар биюе, егетләр биюе, ялгыз җыр, нәфис сүз белән бергә Язтургай халкы өчен моңача күрелмәгән, ишетелмәгән номерлар да күп иде. Мәсәлән, Михаил

Күбрәк бик матур украин җырларын җырлады. Миргазиян белән Саакян икесе бергә чатырда өйрәнгән әрмән дуэтын башкардылар. Тин-Тиныч үзе язган шигырьләрен сөйләде, дингезче киеменнән «чечетка»га биеде, Габбас баян уйнады. Таныш булмаган бораулаучы егетләрне халык кат-кат сорады, янадан биетте, янадан җырлатты. «Менә, ичмасам, егетләр! Бар якка да булдыралар, авылга ямь алып килделәр, рәхмәт төшкерләре»,— дип кул чаптылар. Фәрхетдин булмаса, бөтенләй дә яхшы фикердә каласылар иде!

— Хәзер буровойның атказанган артисты Фәрхетдин һәм Язтургайның атаклы сыер савучысы Саймә «Егет илә кыз»ны башкаралар, дип игълан итте концертны алып баручы Нәсимә. Гөж китереп кул чаптылар залдагылар.

Бу вакытта Фәрхетдин, кемнәндер алып килгән читекне аягына сыйдыра алмыйча, сәхнә артында азаплана иде. Ашыгычлык белән уңын сулына кигән икән.

Халыкны көттереп булмый бит, Фәрхетдинне бер аягы ялан килеш сәхнәгә төртеп чыгардылар. Түбәтәй белән камзул, аягына сыңар читек кигән мыеклы егетне күреп, тамашачы рәхәтләнеп бер көлде. Җитмәсә, Саймә чүмеч борынлы булам дип танавына йодрык кадәр балавыз ябыштырган, иләк авыз ясарга теләп иреннәрен колакларына кадәр кызылга буяган иде.

Онытты бит башлап җибәрәсе сүзен Фәрхетдин. Саймәгә карап катты да калды. «Иләк» дип карады, «чиләк» дип карады, тотлыкты, кузгатып җибәрә алмады шигырьне. Көлгән булды — бер як мыегы кубып төште. Язтургайның мунча ләүкәсе кадәр генә сәхнәсе тагын да тараеп, эсселәнеп китте...

Сәхнә артыннан, сәхнә кырыйларыннан аңа кайсы «иләк», кайсы «чүмеч» дип кычкырдылар, ләкин Фәрхетдин үтә каушаган иде, ул сүзләрен ишетерлек, чүмеч белән иләкне аерырлык хәлдә түгел иде. Кул селтәде дә бер аягындагы читеген сөйрәп чыгып китте.

— Юк икән, Фәрхетдин, синнән! Коры телең генә икән! — диде аңа Саймә, сәхнә артына чыккач.

Фәрхетдин, кызны тынычландырудан бигрәк, үзен акларга маташты:

— Соң инде, җаным Саймә, ничек итеп синең уймак кадәр авызыңны иләк дип, бал кашыгы кадәр борыныңны чүмеч дип әйтә алыйм? Телем бармады! Юк, теләсәң ни эшләт!

Шуннан соң Фәрхетдин әкрен генә киенде дә клубның арт ишегеннән чыгып сызды. Әйтте бит ул аларга уйный белмим дип, ышанмадылар. Уйный белсә, буровойда да эшләп йөрмәгән булыр иде...

Чатырына кайтып ут алуга, Фәрхетдин тумбочкасы өстендә өч хат күрде. Берсен алып карады — Бөгелмәдән. Димәк, теге сары чәчле кыз язган. Исеме дә онытылып бара инде — Зарифамы, Закирәме шунда, Карабаш мәйданында эшләгәндә танышкан иде. Икенче хатны алып адресына күз салды — Ташлыярдан. Юан чәлтерле Әкълимә яза инде. Китәр алдыннан гына танышып калган иде аның белән Фәрхетдин. Өченче хат зәңгәр конвертыннан ук танылып тора — Гөлнисадан. Җүләр кызлар, нигә дип инде берьюлы язарга уйлаганнар. Фәрхетдинне писарь дип уйладылармы көн-төн җавап язып утырырга?

Беренче булып Фәрхетдин Гөлнисаның конвертын ачты.

«Фәрхетдин, түбәтәең бәрхетдин! — дип шаянланып башлаган Гөлниса.— Ыкка барып таяк тыгып карыйм да, суларның артулары бер дә сизелми. Димәк, сагынып еламыйсың, күз яшьләрең елгага агып төшми. Ник оныттың, ник хат язмыйсың?..» Зөбәеровтан башлап бөтенесенә күп сәламнәр тезгән. Барысын да берәм-берәм сораша киткән. «Мине мастер иска аламы?» — дигән. Шакката монда Зөбәеров! «Тин-Тиныч ничек соң, һаман Валясын эзләп йөриме? Монда безнең янга Валя исемле агроном кыз килде, чәчен баганасы кебек озын, нечкә

билле, килеп күрсен, бәлки, шул үзедер»,— дип тәрттерергә дә онытмаган. «Сапарбай әле дә булса калымга акча җыямы?» — дип сораган.

Хатында Мотгәрәйнең янтыгына да шактый тәрттергән кыз: «Язгургайда катык бармы? Мотгәрәй әйрән эчәргә авылга баргалыймы?» Шунда ук Габбаска, Нәҗипкә, Еланскийга карата әйтелгән тәртмәле сүзләр дә күп.

Фәрхетдин, башын тота-тота, бер ялгызы рәхәтләнеп көлде. Усал кыз бу Гөлниса!

Соңга табарак җитдиләнеп киткән кыз:

«Көз җитә. Чакырсагыз быел да эшкә сезнең бригадага килергә идем. Зөбәеров ни әйтер икән, белеш әле шуны, дустым»,— дигән.— «Сагынам сезләрне» — дип өстәгән. «Тиз арада җавап яз, юкса, үтерермен!» — дип тәмамлаган.

Фәрхетдин елмаеп куйды. «Үтерермен» — Гөлнисаның яраткан сүзе иде бит.

Хатның иң азагына бер-берсенә томшыкларын терәшеп торган ике күгәрчен ясап куйган. Аңласаң аңла, аңламасаң юк.

Бер караганда тавыкларга, икенче караганда күгәрченнәргә охшаган рәсемнәргә карап Фәрхетдин уйга калды. Ык буенда эшләгән чаклар, буровойның пар казаннары тирәсендә чыр-чу килеп йөргән кочегар кызлар, шулар арасында зәңгәр шәлъяулыгын муеныннан ук урап бәйләгән Гөлниса күз алдына килеп басты. Аның кара чәчләре тыңлаусызланып яулык астыннан бәреп чыга һәм һәрвакыт тузгып йөри иде. Фәрхетдин беренче күрүдә үк кызның күзенә бәреп: «Каты чәчләр усал кызларда гына була»,— дигән иде. Җавап та соңламады: «Көрәк тешләр телдәр егетләргә генә чыга!»

Кызга биргән бәясендә Фәрхетдин ялгышмады. Кочегар булып килгән иптәшләре Разия белән Кәримә арасында Гөлниса аерылып тора иде. Горур караш, тәкәббер йөз, бөгелү-сыгылусыз туры йөреш... Аңарда ирләр холкы»,— диләр иде бораулаучы егетләр. Шуңа күрә Гөлниса янына килергә, аңа сыенырга батырчылык итүче булмады. Аның тирәсендә койрык болгарга хәтта Фәрхетдингә дә киңәш итмәделәр.

— Ялгыш кына кочакласаң да күзеңне чукып алыр, билләһи! — диештеләр.

— Миңа карамаган кыз әле дөньяга тумаган! — дип масаеп кычкырды Фәрхетдин.— Менә, күрерсез, ул миңа үзе килеп сыланыр.

— Булмый!

— Нәрсәдән бәхәс?

— Американкадан. Нәрсә телим, шуны бирәсез!

Бәхәсләшүен бәхәсләште Фәрхетдин, ләкин Гөлнисаның йөрәгенә һич кенә дә ачкыч таба алмады. Кызның сменасында төннәрен котельныйга да барып карады, эшләр ничек соң, авыр түгелме, фәлән-фәсмәтән, дип тә сорашты. Ярдәм кирәк булса, миңа гына әйтегез, мин пар казаннары буенча зур белгеч дип тә шапырынды, ләкин берсенә дә Гөлниса шаккатмады. «Ярый, ярый, ватылса үзебез дә төзәтербез»,— дип кенә җибәрде. Шаян сүзләр дә, көлке анекдотлар да, кичләрен кызның фатирына барулар да ярдәм итмәде. Кыз һаман һавалы, кырыс, күнмәүчән иде.

Гөлниса кебек «тип» чыннан да Фәрхетдинне борчып-борчып кызыксындыра башлады. Ул бит егет дәверендә таш бәгырьле кызларны да күрмәде түгел. Ләкин ныклабрак тотынгач андыйларны да эретә ала иде бит Фәрхетдин.

Гөлнисага карата запастагы бөтен сүзләрен әйтеп, резервтагы барлык кыланышларны, аһ оруларны, авыр сулауларны сарыф итеп бетергәч, Фәрхетдин ахырда мәсьәләне кызга ачып салырга булды.

— Бетәм мин, Гөлниса, коткар. Егет булып каласым килә, бәхәсләшкән идем...

Гөлнисаның беренче мәртәбә яңгыратып көлүен шунда гына ишетте Фәрхетдин.

— Куптән шулай диләр аны, хәсрәт! Я, нәрсәдән бәхәсләштең? — диде кыз.

— Америкаикадан.

Гөлниса кинә башлады.

— Алайса, култыкла мине, киттек буровойга. Ләкин кара аны, без бәхәсне чишкәнче генә дус!

Фәрхетдин белән Гөлниса ул көнне буровойга култыклашып кына түгел, хәтта кулга-кул тотынышып килделәр. Күзләре шар булды егетләрнең. Бәхәстә җиңелүчеләр, Гөлниса кушуы буенча, берәм-берәм верховой сәндерәсенә менеп, әтәч булып кычкырдылар.

Фәрхетдин белән Гөлнисаның дуслыгы да шул кызыкны уртаклашудан башланып китте бугай. Кыз, үзе дә сизмәстән, Фәрхетдин янында урала башлады...

Ә Ык буеннан киткәндә исә Гөлниса Фәрхетдиннән аерыла алмас хәлгә килеп җиткән иде инде...

Хатны укыгач, Гөлнисаның үзен күреп сөйләшкәндәй булды Фәрхетдин. «Ну, кызый, нәрсә дигән сүз ул үбешеп торган күгәрченнәр? Кая горур күтәреп йөргән башың?» — дип әйтәсе килде аның.

Адым саен кызларга гашыйк булып, аларны кулга төшерү өчен көнтөн чабып йөргән элеккеге Фәрхетдин юк иде инде дөньяда. Арыды, ахры, егет бу «кәсептән». Язтургайга килгәч, ул блокнотына бер генә яңа исем дә терки алмады. Күрәсең, кеше дигәнең утызга җиткәндә олыгая, төпкә утыра башлый...

Тукта әле, моңа шушы ук Гөлниса, аның хатлары гаепле түгелме? Фәрхетдин бит, Язтургайга килгәч, дөресен әйткәндә, Гөлнисадан хат көтүдән, аны уйлаудан арына алмады.

Дөрес, концерт хәзерләгәндә Саймәгә күзе төште төшүен, ләкин бит матур кызга кемнең күзе төшми? Бу концерттан соң хәзер Саймә әйләнеп тә карамас инде...

Фәрхетдин тумбочка өстендә яткан тагы ике хатны алды. Кулында әйләндерде-әйләндерде дә ачмыйча гына ертып идәнгә ташлады.

— Җитте шаярырга! Тәмам!

Гөлнисага хат язарга утырды. Карага манган таракан йөргән кебек кыек-мыек, салулы-солулы юлларында аның Гөлнисага беренче тапкыр әйтелгән матур сүзләре коелды:

«Бездин сезләргә, кара күзләргә, кара кашларга, сандугачларга...»

## 20

Иген басуларының шәрәләнеп калулары гына түгел, көз киләсен Сагындык елгасыннан күтәрелгән аксыл куе томан да, урманның шомланып шаулавы да әйтеп тора иде. Иртә-кичләрен аланга төшкән салкын кырау җинел киемле кешеләрне өтеп ала, төньяктан искән ачы җил чатырга куып кертә.

Юка одеял астында, саф һавада, сайрар кошлар бәллүе астында иркен киерелеп йоклаган чаклар үтте — бораулаучылар өсләренә каткат ябынып, бишкә бөгәрләнеп яталар. Төннәрен алай да өшетә.

Кичә кич урман буендагы чатырлар өстенә кояш баешыннан вак спас яңгыры килде. Бу инде разведчикларның Баланлы тәбәктә көннәре саналулы калганын хәбәр итә иде.

Иртән торып һавага чыккан саен егетләр, физзарядка ясый-ясый, Зебаеров чатыры тирәли чабып йөриләр һәм карга буялып: «Мастер-р-р, квартир-р! Коткар-р!» — дип карылдыйлар.

Зөбәеров үзе дә Рәйсә алып килгән мамык юрганын ачарга куркып, бөрешеп ята, ялгыш селкенү белән үк муенга салкын елан шуышып кергәндәй була.

— Әйе, авылга күченергә дә вакыт шул,— дип уйлый. Аннан:— Унунбиш көн яшәргә мөмкин әле, үлмәбез!

Өстеннән юрганын атып бәреп, егетләр янына физзарядкага чыга.

— Кайтыйк авылга, зинһар, интектермә безне! — дип каршы алалар аны.

— Нәрсә кытаклыйсыз? Әбиегезнең бозавын сагындыгызмы, кәҗә бәрәннәренме? Әллә кандала ямансулатамы?

Әгәр чегәннәр килеп чыкмаса, тагын күпме нужа кудырган булыр иде икән бу Зөбәеров?

Ул көнне кунарга Зөбәеров Язтургайга киткән иде.

Сапарбай ат пошкырганына уянып китте. Әллә кай җирләрдән куптарылып, үзәкне өзеп, даланы, җылкылар көтеп йөргән чакларны искә төшерде бу тавыш. Торып чатыр ишеген күтәрде, тышка чыкты. Караса ни күрсен: аланда, урман буенда кемнәрдер атлы арбалары белән туктаганнар. Шунда ук ике-өч зур чатыр корылган, төрле урыннарда учаклар ягылган, ир-атлары, хатын-кызлары, бала-чагалары, түгәрәкләнеп, учак янында кызынып утыралар.

— Болар кемнәр? Әллә яңа разведка килгәнме Язтургайга?

Кереп тиз генә Валентинны уятты Сапарбай. Тин-Тиныч одеялын бөркәнгән килеш кенә тәрәзәдән карады да: «Чегәннәр!» — дип кычкырды. Аягы белән төртеп Фәрхетдинне уятты.

— Кара әле, төнлә чегәннәр килеп урнашкан бит безнең лагерьга!

— Һе, чегәннәр! Туганнар диген, дивана баш! Безне эзләп килгәннәр алар...

— Яхшы түгел бит бу, бөтенләй шәп түгел!

— Нәрсәсе начар? Бергә-бергә күңеллерәк булыр, тиле!.. Чегән кызлары күренмиме анда?

Фәрхетдин торып, суыктан калтырый-калтырый, тәрәзәгә килде.

— Да, Тин-Тиныч, болар бездән баерак яшиләр. Иш түгел без аларга. Атлар, арбалар... җитмәсә, хатыннары яннарында. Билләһи, шалашлары да безнең чатырдан зуррак. Җылырактыр да әле ул...

Тин-Тиныч чатырындагылар килгәндә аланга Кадермәтнекеләр чыгып баскан, гаҗәпләнеп, бер читтән чегәннәр таборын карап торалар иде.

Фәрхетдин Кадермәтне култыклап алды.

— Нәрсә куркып калдыгыз, канатларым? Әйдәгез әле, яннарына барыйк, танышыйк туганнарыбыз белән. Кайдан килделәр икән, бик ерактан микән, хәл-әхвәлләрен сорашыйк.

Разведчиклар шактый ук якын килеп, чегәннәрнең зур-зур арбаларына, ул арбага тау кебек итеп өелгән йөкләренә, җәһәннәм уты кадәр итеп яккан учакларына карап хәйран калып тордылар. Учак тирәсендә йөзләрен сакал-мыек баскан ир-ат, өсләренә кат-кат киенгән хатын-кыз кайнаша, үлән өстендә эреле-ваклы бала-чага аунап йөри.

Килеп, авыз ачып, тамаша кылып торган кешеләргә алар игътибар итмәделәр, утка бер-бер артлы агач ташлап учак дөрләттеләр, аның өстенә казан астылар, дугалары белән күтәртеп куйган тәртә башларына, кадап куйган таякларга киемнәрен, ятакларын җилләтергә элеп куйдылар. Табордан җил уңаена төтен исе килә иде.

Инде китәргә дип кенә торганда, бораулаучылар янына эре-эре атлап, сарафан итәкләре белән үләннәрне егып, яшь кенә чегән кызы килде. Янып торган шомырт кара күзләрен башта Кадермәткә, аннан Валентинга төбәде, таныш кешесен эзләгәндәй, Фәрхетдингә борылды да, юмартрак йөзлесен сайлап, Сапарбайның кулын тотып алды.

— Бир, егет, кулыңны, киләчәгеңне юрыйм! — Чегән кызына рөхсәтмазар кирәкми иде, күрәсең, ул тезеп тә китте:— Бәхет эзләп ерак илләрдән килгәнсең, чибәр егет, ә син...

Киләшчә урынына беләгеннән каптырган чегән кызыннан коты алынып, Сапарбай артка тартылды:

— Кирәкми!..

— Юрасын, җүләр, курыкма! — диештеләр разведчиклар. Сапарбайның киләчәгеннән бигрәк, чегән кызының туп-туры күзгә карап сөйләп торуы кызык иде.

— Син бәхет эзләп җиде җир читеннән килгәнсең, бәхетең синең баш очыңда очып йөргән, ләкин син аңарга игътибар итмәгәнсең... Син, егет, казна йортында яшисең икән һәм бәхетең дә синең казна йортында табыла... Ничек, кайчан табылуын беләсең килсә, кулымны алтынга ман, аннан ишетерсең...

Сапарбай чегән кызыннан кулын тартып алды.

— Акча сорый ич бу!

— Нәрсә син, әллә аны бушка эшли дисеңме?

— Кызганма ун тәңкәңне, дивана баласы! — Фәрхетдин иптәшләренә күз кысты.— Өстенә баса бит! Хәтта Ык буенда чакта синең янда Кәримәнең очынып йөргәненә кадәр әйтте!

Чегән кызы шул арада Фәрхетдиннең кулын үрелеп тотты:

— Бир, синең язмышыңны әйтим!

— Әйдә! Каян килеп кая китмәгән ун тәнкә!

Чегән кызы Фәрхетдиннең күзенә текәлгән килеш сайрады да сайрады: син казна йортында яшисең, казна кешесе икәнсең, диде, синең малың да юк, семьяң да юк, бала-чагаң да юк, өмет тә итмә, киләчәктә дә булмас, диде, шуңа карамастан, син бай яшәрсең, зур урыннарда эшләрсең, мөлкәтең күп булыр, диде.

Бу сүзләр Фәрхетдиннең бер колагыннан керсә икенчесеннән чыга тордылар. Аның игътибары «казна йортыннан» бөтенләй читтә иде әле.

— Эх, куллары да куллары, егетләр! Күптән мондый кул тотканым юк иде...

Багучы кыз тагын-тагын кайтып «казна йорты» турында, ул йортта егетне көтелмәгән бәхет сагалап торуы турында, ләкин тотам дигәндә генә ул бәхетнең очып китүе турында такмаклады. Шуның белән түгәрәкләнде дә бугай Фәрхетдиннең «язмышы».

— Тукта әле, чегәнкәй, китми тор, мә тагын ун тәңкә...

— Нәрсә багарга боерасың, князь?

— Теләсә нәрсә бак, тик озаграк бак... Әй, егетләр, белмисез!..

Учак янында утыручылар акча тавышын гына көткәннәр, күрәсең — күз ачып йомганчы чегән хатыннары сырып алды бораулаучыларны. Болары киләчәк язмышны кәрт ачып та, маңгай сырларына карап та, кулдагы эзләр буенча да әйтеп бирә алучы «белгечләр», имеш.

Егетләр көлә:

— Әйдә бер алдатыйк инде туйганчы! Я, алайса, әйтегез: нефть бармы монда, юкмы?

Фал базарының нәкъ кызып барган чагында Зөбәеров кайтты.

— Нәрсә бу? Монда кемнәр килгән тагын? — Мастер ерактан ук тавыш күтәреп таборга килде.

Рапорт бирергә җыенгандай, Фәрхетдин Зөбәеровның каршысына басты:

— Кардәшләребез килгән, мастер!

— Ну-ка, укчаләрегезне күтәрегез моннан! — дип кычкырды чегәннәргә Зөбәеров. Шунда ук сакаллы ике-өч чегән йөгереп килде, күкрәкләренә кулларын куеп, баш иеп күрештеләр.

— О, мәрхәмәтле хуҗа, алай димәгез! Алланың күңеле киң, күк асты иркен — сыярбыз!

— Бу — чегән таборы түгел, нефтьчеләр лагеры, аңладыгызмы?
— О, шәфкатьле хуҗа, без сезнең лагерьга кагылмыйбыз! Безнең тормыш үзебез белән!

Җитмәсә, ачу китереп берничә чегән хатыны килде дә, бушлай гына киләчәгеңне әйтәбез дип, төрлесе төрле яктан Зөбәеровның беләгенә ябыштылар.

Зөбәеров гарьләнеп кулын селтәде дә китеп барды.

— Чегәннәр белән күрше яшәп булмас, авылга күченергә кирәк,— диде.

Язтургайда кешеләрне урнаштыру мәсьәләсе Карабашта яки Ык буендагы авыллардагы кебек ансат булмасын Зөбәеров белә иде инде. Авыл олы юлдан читтә утырган, кешеләр гомерләрендә узгынчыларны күрмәгәннәр, юлчыларны фатир кертеп өйрәнмәгәннәр.

Авыл Советына кереп бораулаучы табу мәсьәләсен сөйләшкәндә, тиздән разведчикларга фатир кирәк булачагы турында да житәкчеләрнең исләренә төшергән иде Зөбәеров. Күңел юатырлык нәрсә әйтмәделәр. Авыл Советы председателе Хафизов кайчандыр бу авылга укытучы булып килгән кеше икән, заманында интегеп фатир эзләп йөргән. «Язтургайларнын гадәтен яхшы беләм мин,— ди.— Мондагы халык гаҗәп тискәре, үҗәт халык, уртак тел табуы кыен булыр»,— дип куркытты. Хәтта ул якын-тирәдәге башка бер авылга барып урнашу яхшырак булыр дип киңәш иткән иде.

Партоешма секретаре Дәминов та авылдашларының кыргыйрак булуын инкарь итмәде. Ләкин Хафизов сөйләгәнчә ук Язтургайларның кире беткән халык түгеллеген, җаена ятсаң яхшы, хәтта бик яхшы була белүләрен әйтте.

Сөйләшә торгач шул кадәресе ачыкланды: фатир табарга мөмкин. Тик, Зөбәеров таләп иткәнчә, кешеләрне вахталап түгел, берәр-икешәр итеп кертергә булдылар. Язтургайда куелган шартлар белән күнәргә туры килде мастерга.

Бу баруында инде күп сүз куертып тормаска, фатир мәсьәләсен авыл җитәкчеләре каршында конкрет куярга дип килде мастер. Чөнки тышта сизелерлек суытты, яңгырлар төшә башлады, җитмәсә, аланга чегәннәр тулды, чатырларда яшәү хәзер мөмкин түгел иде.

Хафизов бу юлы ачык чырай белән каршылады Зөбәеровны. Мастер керүгә урыныннан торып ишек катына ук килде, аеруча сизелерлек итеп Зөбәеровның кулын кысып торды, түрдән урын күрсәтте.

— Ну, эшләр яхшы барамы, нефть короле? — дигән булды.

«Теге операциянең хикмәте,— дип уйлады Зөбәеров.— Кешеләр шул алар үзләренә авырлык килгәндә генә...»

— Хезмәтегез турында ишетеп торабыз, куанабыз. Үзебез шунда эшләгән кебек. Кем уйлаган безнең Язтургай да телгә керә башлар дип! Иртән торып радионы борасың — Язтургай мәйданы, газета алып карыйсың — Язтургай мәйданы, Зөбәеров бригадасы... Менә егерме ел яшәдем Язтургайда, авылны радиодан ишетү түгел, газетада да күрмәдем:

— Нефть чыкса, әле болай гына булмас...

Председатель кызыксынып мастер янына килеп утырды:

— Ничек соң, чыгардай күренәме? Имеш, нефть урынына газ бәргән дип әйтәләр...

— Газ коесына юлыктык... Ләкин ул кечкенә. Андый гына урыннар бу... жир астында. Ә нефть дигәндә... Әле аңа ерак. Алдан әйтүе кыен...

— Бораулаучыларның газга исерүләре дөресме? Монда бөтен авыл гөж килә, имеш, разведчиклар газга тончыгып беткәннәр...

Зөбәеров көлеп җибәрде:

— Бетүен бетмәдек тә, шулай да куркытып алды... Үттек инде хәзер ул урынны...

Хафизовның сүз куертырга бик оста кеше икәнен исәпләп, Зөбәеров мәсьәләгә якынрак килергә булды.

— Ничек соң үзегезнең хәлләр?

— Лично минем дисеңме? У-у, үкертеп йөрим! Корсакны тегәрҗеп белән ямаганнан бирле ун елга яшәреп киткәндәй булдым! Җен икән ул синең Рәйсә, беләсеңме!

— Квартир мәсьәләсе ничегрәк соң? Өскә янгыр үтә башлады бит...

— Фатир мәсьәләсеме? Хәл ителгән!

Хафизов өстәл тартмасыннан исемлек чыгарып Зөбәеровка тоттырды.— Менә, Зөбәеров иптәш, үзегез чамалап кертегез. Бер кеше кирәргә мөмкин, ике кеше... Ә менә үзегезгә лично... әлегә таба алмадык... Семья белән кеше кертмибез диләр.

Шул вакытта авыл Советына Дәминов белән колхоз председателе Галләм килеп керделәр. Баш кагып кына күрешкәннән соң:

— Тагын сораңырга килгәннәрме? — диде Галләм тупас кына.

— Без, урындагы власть кешеләре, ярдәм итәргә бурычлы.— Моны Хафизов әйтте.

— Бурыч, бурыч! Без генә барысына бурычлы: җирен бир, суын бир, көтүлегенне бир! Аның өстәвенә, буровой өчен кешеләреңне бир, фатир белән тәэмин ит!..

Галләм, кулын селки-селки, Зөбәеровка борылды.— Үзегез соң, үзегез нәрсә бирәсез?

— Бирер нәрсәбез юк бит!..

— Менә шул шул! Монда сезнең кебек хәерче туганнар бетмәс!

Каты гына бәрелешеп алдылар.

Нервылар тынычлана төшкәч, Зөбәеровның да бирер нәрсәсе табылды: ул буровой движогыннан клубка, мәктәпкә, авыл Советына, колхоз идарәсенә, почтага һәм тагын берничә йортка электр кертә ала икән.

Бу сүз авыл Советындагыларның йөзен ачып җибәрде. Галләм авызына тәмәкесен кабызып, Зөбәеров янына ук килеп утырды.

— Теге вакытта торбаларыгызга кызыгып кайттым. Сез фермага су кертү өчен бер-ике километр озынлыгында торба тапмассызмы икән?

— Табарбыз. Безнең конторада иске торбалар күп.

— Китертергә машина да табасызмы?

— Табарбыз. Контора рөхсәт итсә...

— Сездә тракторлар да, бульдозерлар да бар бит инде...

— Сез нәрсә... Хәерчегә якты чырай бирсәң, ямаулык сорар, ди. Башта торба, аннары машина, аннары бульдозер. Аппетит зур сезнең, ә? Ләббәйкә дип торсаң, буровойны сүтеп бирегез диярgә дә күп сорамассыз,— дип, кинәт бик хәтәр кутәрелеп бәрелде Зөбәеров.— Кешеме сез, җаныгыз бармы сезнең? Рабочий класс суыкта дер калтырап утыра, аларга тегесен бир дә монысын бир. Кеше булсагыз, сез иң элек фатирга кертегез, аннары сорасыгызны сорагыз, японский городовойлар!..

## 21

Иртән Саакян вахтасын алыштырырга килгән Тин-Тиныч бораулаучылары буровойда «алдым-бирдем» ясаган вакытта яңа фатирдагы беренче кичләрен, анда алган тәэсирләрен сөйләштеләр. Җылынганнар, кырынганнар, мунча кергәннәр — чын егет булып күренәләр. Һәркем үзен бәхетле итеп сизә.

Сапарбай ялгызы гына ишле семьяга эләккән һәм аңа хуҗаның балалары «бай абзый» дип кенә дәшәләр икән. Ķече малайлары исә бер кич эчендә шул кадәре иялəшеп алган, моның яныннан да китми, кулыннан да төшми икән. Сапарбайга төне буе диярлек аның белән бергә идәндә мүкәләп йөрергә туры килгән.

Валентин белән Фәрхетдин бер әби белән бабайга кергәннәр. Фәрхетдиннең әйтүенә караганда, өйләре иркен, тыныч, җылы икән. Киерелеп сәкедә йоклаганнар, тик яшь бозау белән кәҗә бәрәннәре генә тынгылык бирмәгән.

— Бер вакыт төнлә уянып китсәм,— дип сөйли Фәрхетдин,— Тин-Тиныч торып утырган. Ķараңгыда күзләре утлы шар кебек. «Нәрсә булды?» — дип сорыйм моңардан әкрен генә. Күреп торам, саташып уянган. «Беләсеңме, Фархутдин,— дип пышылдый бу миңа,— күзләремне ачып җибәрсәм, өстемә бер нәрсә менеп атланган да «бә-бә» дип кычкырып тора... Ул күзләрен күрсәң, ул тырпайган мөгезләрен!» Йокла, мин әйтәм, бәбкәм Тин-Тиныч, борчылма, ул кәҗә бәрәне генә!

Тынычланып яткан булды булуын, шулай да һаман калтырый: «Ә мөгезләре, мөгезләре?» — ди. Ķолак ул җаным, мөгез түгел, дим.

Шуннан йоклап киткәнбез. Торсак, Тин-Тинычның чөйгә элеп куйган безкозыркасы юк!

Бораулаучылар алдан ни буласын сизенеп хахылдап көлешәләр, ә Тин-Тиныч Фәрхетдиннең авызын тотарга теләп, кулын суза:

— Я инде, лыгырдама! Тапты сөйләр нәрсә!

Фәрхетдин читкәрәк тайпылып сүзен дәвам итә:

— Чын менә! Кичтән чистартып, каккалап чөйгә элеп куйган безкозыркасы юк! Дөнья бетереп эзлибез, таба гына алмыйбыз бит. Шуннан почмактагы ләгән артына күзем төште. Ķарасам — көләргәме, җыларгамы — Тин-Тинычның мунчалага әверелеп беткән кәпәче! Ķаһәр суккан бозау, муенчакта булса да үрелеп җиткән бит, баш киеме кадәр баш киеменнән «Тихоокеанский флот» дигән лентасын гына калдырган!

Шау килеп көлешкән разведчиклар арасыннан чыгып, Тин-Тиныч бер читкә барып утырды.

— Черт с ним иде безкозыркасы, бу хәлдә менә Валя очраса ничек күренермен?

— Танымас инде Валя сине!

— Син дип белеп, түбәтәйле Мотгәрәйгә килеп асылынмаса инде! — дип үртиләр Тин-Тинычны.

— Ну, синең фатир ничек, Нәҗип?

— Ярыйсы. Ķандала юк...

Бар да Фәрхетдингә таба борыла, Нәҗип фатиры турында бәяне аннан көтәләр. Фәрхетдин фуражкасын колагына таба этеп куя да хикәясен башлап җибәрә.

— Нәҗип тора алмас, егетләр, ул фатирда, түзә алмас. Сез уйламагыз анда начар икән дип. Киресенчә, артык яхшы! Кердем кичтән боларга. Беләсезме, хуҗалары ачыклар инде менә! Өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар. Ашаса — өстәлдә Нәҗипкә коймак, бәлеш, ятса — пружиналы караваt. Һич инде сөйләргә дә түгел. Ләкин Нәҗип бәхетсез!

Нәҗип җилкәләрен җыерып куйды:

— Ни эшләп инде мин бәхетсез?

— Син бәхетсез, туган! Күрдең бит кызлары бар!

— Булса соң?

— Менә бөтен бәла дә шунда шул. Их, егетләр, күрсәгез кызларын фатир хуҗасының! Инде дә сылу, инде дә гүзәл булса булыр икән! Ķашыкка салып суырып йотарсың менә! Шуннан соң мин Нәҗипне кызганып куйдым: Нәҗип анда йоклый алмаячак, ул кызны күз алдына китереп керфек тә какмаячак. И һәм эштә аягүрә йоклап йөриячәк,

тора-бара йөрәк чиренә әверелеп бетәчәк... Дус итеп әйтәм, андый-мондый хәлгә юлыкканчы күчерсен мастер ул фатирдан!

Шунда ук Нәҗип урынына керергә теләүчеләр дә табылды, ләкин Фәрхетдин телен генә шартлатты:

— Юк инде, җәмәгать, Нәҗип фатирын минем белән алышачак!

Буровойда эшне тапшыргач, Саакян вахтасы туп-туры Язтургайга китте. Зөбәеровның әйтүенә караганда, аларның дүртесенә дә фатир табылган, тик авыл Советына барып ул йортлар кемнеке, кайда икәнен генә беләсе бар икән...

— Тагын күпмегә сузылыр бу әби-бабайда торулар! — дип, Мотгәрәй юл буена сукранып барды, аннары авылны кергәч туктады да:

— Бармыйм мин авыл Советына,— диде.— Алардан башка да табармын әле...

Иптәшләренең хәтере калды.

— Кешедән аерым яшәмәсәң, эчең күбә инде синең! — диде Саакян җенләнеп.— Сәер кеше, билләһи!

Мотгәрәй борылып та карамады, тиз генә урам аркылы чыгып, тар һәм пычрак тыкрыкка кереп китте.

Фәриданең әйтүе буенча, өе әнә шунда, тыкрыкның елгага барып терәлгән урында булырга тиеш. Тик нәрсә әйтер, кертерме? Кертер. Узган очрашуда Фәридә үзе әйткән иде бит: авылга кайтсагыз, туп-туры үзебезгә генә кил, әллә каян фатир эзләп йөрмә, диде. Аннан болай дип тә өстәп куйды: «Хәер, сез инде безнең кебек ярлы-ябагайның мунчасында яшәмәссез. Сезгә йортның зуррагын табарлар».

Киртә буйлап барып, чылтырап ага торган елгага барып чыкты Мотгәрәй. «Шулдыр инде». Сулдагы тәбәнәк ялгыз йортка карап торды. Чыннан да мунча гына икән. Өй шулай кечкенә, тәбәнәк булган өчен авыл күзеннән качып утырган кебек.

Урам якка караган кәрәз рамы кебек кенә тәрәзәдә ут күренә иде. Мотгәрәй читәннән үреп ясаган капканы барып ачты.

Эчкә атлауга пырылдап бер төркем сарык читкә атылды, куркып сыер сикереп торды, кайдадыр лапас эчендә тавыклар кыткаклый башладылар.

— Ялгыз булса да малы күп икән,— дип бәя биреп алды Мотгәрәй. Шунда ук читән буена өелгән юан-юан бүрәнәләргә күзе төште.— Моныcы өйләк. Ире мәрхүм кисеп калдыргандыр...

Өйалды ишегеп шакуга ишек ярыгында ут ялтырап китте, эчтән таныш йомшак тавыш ишетелде:

— Кем бар?

— Мин бу, Фәридә.

Фәридә тавышны танымады — Мотгәрәй килер дип уена да китермәгән, күрәсең...

— Кем соң син? — дип сузып сорады Фәридә яңадан.

— Кергәч күрерсең!

Шикләнә-шикләнә генә килеп, хуҗа хатын өйалды ишеген ачты, тиз генә өйгә узды. Ашыгып, аның артыннан Мотгәрәй керде.

Бер мәлгә карашып тордылар. Менә шундый чакта җай гына әйтер сүзе дә табылмый бит.

Кем икәнен танығач, Фәриданең йөзе ачылып китте:

— Уф, котымны алдың... Син икәнсең, Мотгәрәй!

Фәриданең еш-еш сулавыннан калку күкрәкләре бер менә, бер төшә иде.

— Ачуланмасаң, сиңа фатирга килдем,— Мотгәрәй, Фәриданең йөзенә текәлгән килеш, ни әйтер дип, һаман ишек төбендә басып тора бирде.

— Нинди ачулану ди! Килештерсәң кара, тик бездә бик кысан...

— Күнелең генә иркен булсын! — диде Мотгәрәй, батырая төшеп. Өй эченә күз салгач, аның чыннан да кечкенә икәнен күрде. Инә-бүе дүрт-биш адымнан артмаган бу өйдә яшәү-тору, көнкүреш өчен бөтен кирәкле нәрсә бар иде. Түрнең яртысын диярлек алып зур гына агач караватт тора. Аңа каршы стена буенда рәшәткәле янә бер караватт бар — анысында аяк-кулларын ташлап бала йоклый. Шулдыр инде Фәридәнең кызы. Ишеккә табарак кечкенә өстәл белән калай бизәкле сандык куелган.

Өйнең икенче яртысын мич һәм аш ягы били. Андагы кечкенә сәке кисмәк, савыт-саба белән тулган. Турысын әйткәндә, өйдә ятарга түгел, утырырга да урын юк.

Фатир сорап мондый йортка кергәненә дә читенсенә башлады Мотгәрәй. Инде чыгып китсәң дә уңайсыз...

Фәридә дә моны сизде, өйдәге бердәнбер урындыкны күрсәтте.

— Утыр, Мотгәрәй,— диде шактый моңсу тавыш белән, көрсенеп.— Чишен дип әйтмим, үзең кара.— Кулларын күкрәк турысына чалыштырып, мичкә терәлде.— Менә шулай яшибез инде. Ялгыз кешегә җитеп тора...

Фәриданең күңеле өчен генә утырды Мотгәрәй, шулай ук сүз юктан сүз булсынга гына шаярып әйтте:

— Ну, тормышлар ничек, Фәридә? Кайчан тагын урак урырга барабыз?

— И-и, хәзер инде бәрәңге алырга вакыт!

— Бәрәңге алышырга барсам тагын куып җибәрмәссезме?

— Галләм абзыйдан булыр!

— Җуләр ул сезнең Галләм абзагыз.

— Бер дә җуләр түгел! Әнә, хәзер Камил буровойга качты!

— Мин котыртты дип уйлыйсызмы Камилне? Беләсегез килсә, бармаска үгетләдем буровойга! Юкка кызыкты!

Мотгәрәй үзе дә сизмәстән кызып бара икән, аны Фәридә туктатты.

— Ярый, Мотгәрәй, күрешү белән талашмыйк әле, лутчы мин сиңа чәй куйыйм. Эштәндер бит син?

— Бәрәңге пешерсәң икән, Фәридә. Эх, белмисең ничек бәрәңге сагынганымны! Төшләремә кереп интектерә шул яңа бәрәңге!..

— Бәрәңге икән бәрәңге! Мин сиңа аның иң симез җирен — билдәмәсен генә салыйм әле! — Шаярып сөйләнә-сөйләнә, Фәридә чиләк алып өйдән чыгып китте.

Фәриданең казан тирәсендә йөгереп бәрәңге пешереп йөрүләреннән дә, җәһәт кенә өстәл ашъяулыгы алыштырып куюларыннан да һәм шул арада ялт итеп йоклап яткан кызын карап килүләреннән дә Мотгәрәй бу хатында гел яхшылык, тоташ изгелек, самимилек күреп тора иде.

Бәрәңге пешеп чыкканчы ук инде Мотгәрәй бу фатирда калырга дигән карарга килде. Йоклар урынын да чамалап куйды. Менә бу өстәлне ишек төбенәрәк этәсең дә сандыкны аның астына тыгып куясың, һәм идәндә менә дигән урын була. Ни әйтсәң дә, кырда, чатырда, суыкта түгел.

Фәриданең кызы уянмаган булса, бәрәңгене икәүдән-икәү кара-каршы гына утырып ашыйсылар иде. Ләкин бала торды да, үз өйләрендә чит кеше күреп, ятсынып елый башлады.

— Чү, чү, кызым Фатыйма, абый бит ул, абый килгән безгә.

Әмма кечкенә Фатыйманың нindидер кызыл йөзле, табак битле абый белән килешәсе килмәде, юаткан саен кычкырыбрак, әнисенең муенына сарылып, изүләренә ябышып еларга тотынды.

— Шулай инде менә, нинди кыргый баладыр, өйдә ир-ат күренергә ярамый! — диде Фәридә, кызын юата-юата.

— Алайса, синең сакчың ышанычлы икән! — дип көлде Мотгәрәй.

Баласы бар икәнен белә торып та конфет-мазар алып килергә онытканына үкенде. Соң бала күргән кешемени ул!

Көч-хәл белән Фатыйманы юатып йоклатканчы шактый гомер узды, өстәлдә бәрәнге суынды, бәрәкәте китте.

Фәридә аны кыстап та карады, ләкин вакыт соң иде инде.

— Булмаса мина да ятарга кирәк,— диде Мотгәрәй. Өстәлне этеп, үзенә урын әзерли башлады.

— Син монда ят, сандык өстендә — үзем.— Фәридә караваттагы җәймәләрне туздырып ташлады.

— Юк инде, алай булмый,— дип каршы төште Мотгәрәй.— Мин үземә урын таптым. Менә бу сандыкны гына күчерәм дә...

— Килешмәгәнне! Син кунак кеше...

— Кунак кеше — тыйнак кеше.— Мотгәрәй җилтерәтеп сандыкны өстәл астына тыгып куйды.— Күп сөйләнмә, бир мендәреннең берсен...

— Кара аны, урын каты дип үпкәләштән булмасын...

Бер мендәр урынына күпереп торган ике мендәр, бер җәймә сорап та калын гына түшәк китгәч, кенозын буровойда эшләп арыган егет яту белән май урынына эреде дә китте.

Анын караватын, төн буе Фәриданә йокы алмады. Арада бер-берсен бүлеп торган чаршау бар, әнисенең сизгер сакчысы Фатыйма бар, шулай да ирсез хатын өчен бер өйдә, бары ике-өч адымда гына иратнын йоклап ятуы әллә ничек ят, бизелгән, килешми торган нәрсә икән...

— Йа аллам, кешеләр белсә ни дияр, яман сүз ишеттермәсләрме?

Вакыт-вакыт Мотгәрәй каты мышнап селкенеп куя, икенче ягына әйләнеп ята, Фәридә өчен шунысы да җитә кала иде.

— Торып янына килә башласа ни эшләрсең! Күрер күзгә үзе болай әйбәт, тыйнак кебек тә... ләкин бит кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый...

Фәридә үкенә башлады. Нигә дип кунарга калдырды соң әле ул аны? Ярый, бүгенгә йокласын, ә иртән иплән-җайлап кына әйтергә кирәк үзенә. Мотгәрәй, гаеп итмә инде, диярга кирәк, өй тар, бала курка, башка фатир эзлә...

Иренең урмандагы фаҗигале үлеменнән соң йорт та сала алмый шушы иске мунчада ялгыз калган Фәриданең ишеген шакучылар аз булмады. Исереп тә килделәр, йомыш тапкан булып хәйләләп тә, утынпечән вәгъдә итеп тә килделәр, ләкин яманатын чыгарудан курыкты хатын, берсен дә аяк бастырмады. Алай гына да түгел, ишек алдыннан я табагач, я кисәү таягы белән сөреп чыгарган чаклары да булды.

Ихлас күнелдән кияүгә сорап килүчеләре дә булмады түгел. Фәриданен үз әти-әнисе юк иде, монда авылнын югары очында яши торган кайнатасыннан рөхсәт-фатиха алып, яучылары, башкодалары белән килделәр. Тиешле җавабын биреп андыйларын да борып чыгарды Фәридә. «Юньле кеше балалы хатынга өйләнәме? Я юлдан язган исеректер шунда, я эшкә буллыксыз сантыйдыр. Һич булмаса, ирлеккә ярамаганга хатыны куып чыгарган бер бәндәдер»,— дип уйлый иде ул.

Шуннан соң инде Фәридә өе тирәсендә чуалучылар азайды, торабара бөтенләй бетте. Инде менә бер ел бар, әлек узганда тәрәзәдә ут күреп шакый торган исерекләр дә килми.

Дөрес, быел яз күрше авылдан Фәридәне димләргә килгәннәр иде. Әллә чынлап, әллә мыскыл итүләре — кияү буласы кеше житмеш яшьлек карт икән. Үләрсең гарьләнеп, «карагыз, белеп сөйләшегез, кызнын якасын кеше испәгән булмасын» дип әйтеп җибәргән, имеш, карт тәре. Алар киткәч иләндә ауный-тәгәри елады Фәридә. Шулай инде бер кадерен беткәч...

Менә ни галәмәт, шул көннән соң ир-ат, кияү дими тып-тыныч яши торган хатынны коточкыч күңелсезлек били башлады. Ирсез калудан

курку түгел, гомер юлдашы булмау, ялгыз калу җәберләргә керештe. Ярый ла, әлегә аның янында юанычы — кызы бар. Үсеп буйга җитсә, торамы ул әнисе янында? Һәм аның китеп баруы да хәерле. Ә әнисе? Кырыкка да җитмәгән Фәридә шушы тәбәнәк иске өйдә япа-ялгыз калачак бит. Язмышың алдан маңгаеңа язылып куелган кебек!

Фәридә үзен сорап килгән яхшы ниятле кешеләр белән сөйләшмәгәнгә, аларны усал сүзләр белән борып чыгарганга бик үкенде. Кем дә булса ишегеп шакыса, ул кеше исерек булса да, елмаеп ишек ачар төсле иде... Тик килмәделәр...

Ә бүген, менә, яңадан акыллыланып ята Фәридә, нужасы төшкән кешене фатир керткәнгә үкенә, шушы кысан өен, каты идәнен күпсенә...

— Юк, җайлап кына әйтергә кирәк үзенә, чыгып китсен...

Иртән торып чаршауны ачып караса, өйдә Мотгәрәй юк. Йөрәге «жу» итеп китте Фәридәнең: «Шулай ук китүе булдымы? Миңа әйтмичәме? Әллә уйларымны сиздеме?»

Бәгырь түреннән ниндидер әрнеткеч җеп суырылып чыккандай булды. Куркрәген тотып караватка утырды да Мотгәрәйнең җыештырылмаган урынына карап тора башлады.

— Үзем гаепле,— дип пышылдап куйды аннан.— Кешегә кырын торгач шулай була инде...

Эшкә барышлый баласын кайнанасына илткәндә дә, кырда кукуруз силослаганда да, ял итеп алган арада да Фәридә Мотгәрәй турында гына уйлады. Уйламаска тырышты, тик аның саен бу исем гел аның тел очына килеп торды, башында айкалып йөрде.

— Эчкерле бәндә икән. Әйтми-нитми китеп баруын гына кара син аның... Шулай инде, өйне тарсынгандыр. Алай дисәң, кичтән риза төсле иде. Минем үземне ошатмагандыр. Алай дисәң, нигә урак өстендә шаярып сөйләнде, миңа карап күзен әлҗе-мөлҗе китергәләде? Кызым булганга киткәндер. Егет кешегә балалы хатын янында нәрсә калган?

Тукта әле, тиле җан, нигә тырышып-тырышып үземнеке итмәкче булам мин аны? Ул бит миңа андый-мондый тәкъдим ясамады. Фатир сорады, мин риза булдым — шул гына! Аңа фатир ошамаган, миңа турысын әйтергә читенсенгән дә таң белән чыгып сызган!

Көн буена төрле уйлар белән изелеп, талчыгып эштән кайтып керсә — Мотгәрәй ишек алдында утын ярып маташа. Капканы ачканда кулы калтыраганны сизгән иде аны. Юкка түгел икән. Иртән мыштым гына чыгып китүе өчен Мотгәрәйне шелтәлисе килде. Ләкин моңа бернинди хакы юклыгын тоеп, тыелып калды.

— И Мотгәрәй, ачкычны калдырырга оныткамнын бит! — «Синең аркада» дип чак әйтеп җибәрмәде.

— Монда миңа эш табылды әле...

Ярып, биек итеп өеп куелган пүләннәренә караганда Мотгәрәй күптән кайткан булырга тиеш. Күрәсең, өйгә керә алмый аптыраганнан, вакыт уздыру өчен эшкә тотынган, бичара...

Фәридә кесәсеннән ачкыч алып ишекне ачып җибәрде.

— Әйдә, ташла, керик!

Шулай катырак әйтмәсә егет кермәс, хәзер балтасын атып бәрер дә ишек алдыннан чыгып китәр төсле тоела иде аңа.

Ләкин Мотгәрәй китәр өчен килмәгән иде. Әнә агачлар өстендә аның бердәнбер байлыгы — чемоданы ята. Шуны алып килү өчен барды ул Баланлы төбәккә.

Балтасын иплэп кенә бүкәнгә чабып куйды да, фанер чемоданын күтәреп, Фәридә артыннан өйгә керде. Икәүдән-икәү генә калгач, ничектер кыен булып китте сыман.

— Юынып алыйм әле булмаса, Фәридә.

Мотгәрәй кыенсынып кына өстен чишенде, күлмәген салып майкадан калды. Фәридәнең борынына тир исе, сүз белән әйтеп булмый торган

ир-ат исе килеп бәрелде. Йа ходаем, бизенсә дә бизенә икән күнел ир-ат затыннан...

Кулына комган тулы жылы су, исле сабын, чигүле ап-ак сөлге килгәч, Мотгәрәйнең шатлыгы эченә сыймады. Жылы су белән юынып, ак сөлгеләргә сөртенер көн дә бар икән! Тик аның мазут сеңгән кытыршы кулларына чәчәкле-чуклы нәфис сөлгеләр килешеп бетәрме?

Юынып кергәч, Мотгәрәй чемоданыннан кайчандыр ак булып та хәзер сары төскә кергән, шадра «казна» сөлгесен чыгарды.

— Моны юарга кирәк булыр.— Фәридә аны тартып алды.

— Синекен каралтам ич мин!

— Каралтсаң, юарбыз!

Күптән ачык йөзгә, игътибарга сусап йөргән егетнең йөрәгенә сары май булып ята иде Фәридәнең сүзләре.

Мич артына кереп яшеренә-яшеренә, өс-башын алыштырырга кереште Мотгәрәй. Искерәк булса да кадерләп чемоданында гына саклана торган зәнгәр костюм-чалбары, ак күлмәге һәм хром итеге бар иде аның. Ничә ел буровойда йөреп ике-өч тапкыр киде микән ул аларны? Ничектер кәефе булмады, кәефе булса, вахтасы туры килмәде, бәйрәмял вакытларында да эшләде.

Хәтерли, бер тапкыр Карабашта эшләгән чакта киенеп клубка чыгарга уйлаган иде, анда да кире уйлады. «Бер сәбәпсез нәрсәгә дип кеше көлдереп киенеп-ясанып йөрергә, болай да куып кайтармыйлар ич аннан»...

Ык буйларында эшләгәндә дә бер көязләнеп алырга булды. Мотгәрәйне язгы чәчүдә катнашканы өчен механизаторлар бәйрәменә чакырганнар иде. Уйлады-уйлады да көн дә киеп йөри торган җиләненнән китте. «Дус-иш, таныш-белеш гаеп итмәс әле»,— диде.

Бүген исә ни бәйрәм, ни ял дигәндәй, тора салып кием алыштырып ята Мотгәрәй һәм нигә икәнен үзе дә белми.

Менә ул хром итекләрен шыгырдатып мич артыннан чыкты, стенада эленеп торган кечкенә көзге каршына килеп басты. Чистарып, яшәреп, матурланып киткән егет. Әле Фәрхетдин көлгәнчә, төскә-биткә дә ямьсез түгел икән ләбаса болай. Шул каһәр суккан табак бит булмаса, бит уртасында борыны да чак кына калкыбрак торса, тагын да чибәррәк буласы икән дә... Ни хәл итәсен танавыңны песи ялагач! Аның каравы, чәчләре ни тора бит аның! Әйдә, кешеләр жирән дисен, бакыр баш дисен, әмма ялкынланып торган чәче Мотгәрәйнең үзенә ошый.

Аның көзге алдында көязләнеп боргалануын аш пешереп йөрүче Фәридә үзалдына астыртын гына елмаеп карап торды.

«Кызлар янына чыгарга жыена бит бу...»

Эсселе-суыклы булып китте, әллә кайлардан чыккан көнчелек, ачу, үпкә барысы бергә эчендә кайный башлады. Кулы тиеп ялгыш он савытын аударды, токмач кискәндә пычак белән бармагын эләктереп алды.

«Дивана хатын! — дип тиргәде Фәридә үзен эченнән генә.— Тәмам котырдың ир-ат күргәч!..»

Шулай да егетнең кылын тартып карамыйча булдыра алмады:

— Бик киендең-ясандың, артыңнан берәр кыз ияреп кайтмаса инде...— Фәридә көлгән булды.

— Нигә, майга батып утырыргамыни? — Гүя Мотгәрәй бу киемнәрен бүген генә түгел, һәр көн кигән!

Фәридә кызын кайнанасыннан алып кайтканда, Мотгәрәй өйдә аның герле иске сәгатен сүтеп утыра иде. Фәридә иркен тын алып куйды: «Бу егет төнлә буталып йөрүчеләрдән түгел икән».

— Нигә клубка чыкмыйсың? — дигән булды Фәридә.— Анда хәзер иләннәр дер селкенә! Жанланды авыл, бораулаучылар килгәч!

— Клубка чыгар идем дә, сәгатен ундүртне суга! Менә акылга өйрәтим дим үзен!

Фәридә рәхәтләнеп көлеп җибәрде. Аның сәгате саташып кай вакытта өч урынына җидене, җиде урынына унդүртне сугып куя иде шул. «Хуҗасыз йортка җен ияләшә» дип белмичә әйтмиләр!

Ләкин Мотгәрәй клубка иртәгәсен дә, аннан соң да чыкмады. Вахтадан кайта да я пычкы, я балта, яисә чүкеч-кадак тотып ишек алдында, йорт тирәсендә кайнаша.

Фәридәгә рәхәт тә, читен дә. Эштән буш көннәрне Мотгәрәй ничә ел ир-ат кулы тимәгән зур-зур бүкәннәрне ярып ташлады, кыш җил-буран куптарган өйалды такталарын кадаклады, тәрәзә рамнарын ныгытты. Ул гына да түгел, җиң сызганып тотынып былтыр ишелеп төшкән бәрәңге базын рәтләде, җимерелергә торган лапаска терәү салды.

Читтән бернинди ярдәме булмаган (кайнатасы карт иде) хатынга моны күрү күңелле, тик эштән арып кайткан Мотгәрәйне кызгана да, авылдашлары сүзеннән дә курка иде. Аннан түләргә кирәк бит эш өчен...

Бер көнне түзмәде, ишек алдында мәж килеп йөргән егет янына килде.

— Мәшәкатьләнмәсәң икән, Мотгәрәй. Син эш кешесе, сиңа ял итәргә кирәк...

— Нинди ял ул? — дип гаҗәпләнде Мотгәрәй.— Мин болай да аллага шөкер, бер көн эшлим, ике көн тик ятам! Үләм эшсез, кулым кычыта!

— Син эшләрсең дә бит... Мин түли алмасам?

Егетнең хәтере калды:

— Ни сөйлисең, Фәридә!.. Кем синнән хак сораган?

— Шулай да кешене бушка эшләтү килешмиме инде...

— Һо, беләсең килсә, Карабашта торганда мин фатир бабайга нинди мунча салып бирдем! Чын! Кул кычытканнан гына тотынган идем, минә диген мунча булды!

— Мунча, мунча! Бар әле алай булса мунчага! Әнә кайнатайлар бүген бик шәп мунча ягып куйганнар. Ераксынма, бар...

Мунча дигәндә бара инде Мотгәрәй, җир читенә дә бара... Килгәч үзе үк бу турыда әйтмәкче иде, читенсенде. Фәридәнең мунчасы юк ич...

Фәридә, ашыгып-кабаланып, кайнаталарының өен өйрәтә башлады:

— Ерак дигәч тә бик үк ерак та түгел. Тыкрыкны менәсең дә уң якка борыласың. Урам буйлап күпергә кадәр барасың да тауга таба күтәреләсең. Тау очында почмакта гына алар. Үрдәк Дәүләтбай дип йөртәләр. Мин үрдәк килене булам инде, ягъни. Урыс капкалы, зур гына алты почмаклы йорт булыр. Әтләре юк, туп-туры бар да кер үзләренә...

Мунча дигәндә бара инде Мотгәрәй, җир читенә дә бара. Әй, Кадермәт ясаган җир мунча мунчамыни ул! Менә, ичмасам, авылда бар иде Мотгәрәйләрнең мунчасы! Ут кебек кызган ташына бер чиләк салкын су томырып җибәрсәң — ләүкәдә түгел, идәндә дә чыдар хәл калмый иде. Әмма Мотгәрәй идәнгә иелми иде. Җәһәннәм кебек кызуда башына бүрек, кулына бияләй киеп ләүкәгә менеп китә дә, таш өстендә каен миннеген пешереп, хәле беткәнче чатырдатып чабына иде. Аннан йөрәге дөп-дөп типкән хәлдә, ләүкәдән төшә, сап-сары арыш саламы түшәлгән салкын идәнгә сузылып ята. Тән гүя тән түгел, ә камыр булган, синдә инде атна буе кырда җыелган тузан-кер дә юк, арыганлык та калмаган, син бишектә ята торган бер гөнаһсыз сабый...

Мотгәрәй, Фәридә өйрәткәнчә китеп, бик тиз тапты Үрдәк Дәүләтбайларны. Нәкъ Фәридә әйткәнчә, туп-туры өйләренә барып керде, ишек төбендә туктап олыларча сәлам бирде, килеп, карт белән ике куллап күреште.

Бик ачык каршыладылар. Карт белән карчык Мотгәрәйне үз балалары кебек күреп йөгерешеп йөрделәр. «Әйдә, чишен», «утыр», «түрдән уз»лар һәр икесе тарафыннан явып торды. Әйбәт йортка эләккән булган икән Фәридә, төпле семьяга төшкән.

Өйдәге чисталык, пөхтәлек кешенең хәтта мунчасына да күчкән. Стеналар ап-ак итеп агартылган, ләүкәләренә кадәр сап-сары итеп юылган. Мунчада кайнар пар белән бергә мәтрүшкәле себеркенең хуш исе таралган.

Авыл мунчасын Мотгәрәй кебек ләззәтләнеп керүче юктыр инде. Ташка эссе өсти-өсти, себеркене кат-кат пешереп, пошкыра-пошкыра чабынды ул. «Юк, каламмы соң разведкада! Авылдагы мунчага житәме соң!» — дия-дия чабынды. Куе пар эчендә күмелеп калган кеше өстендә ут уйнатып торды себерке, сыртына, жилкәләренә менеп төште, аяусыз рәвештә корсагына, янбашларына сыптырды. Тирә-якка кайнар су тамчылары чәчрәде, себерке яфраклары өзелеп очты, әйтерсең мунча чабынучы, нәрсәгәдер ачуланып, үз-үзен тукмый иде.

Үрдәк Дәүләтбайларга Мотгәрәй тәмам хәле бетеп кайтып керде. Киң бите аның йомшап, бүртеп чыккан, болай да кызыл йөзе кызыл борыч кебек янып тора. Күлмәге юешләнеп тәненә ябышкан, борын очларыннан алып колак яфракларына кадәр су тама.

Хужаларга рәхмәт әйтергә генә дип кергән иде Мотгәрәй, аны чәйгә кыстадылар. Карышмады егет. Карлыган кагы, жир жиләге вареньесы белән мунчадан соң чәй эчү үзе ни тора бит!

Чәй янында сүз, гадәттәгечә, хәл-әхвәл сорашудан башланып, Мотгәрәйнең кайсы яктан булуы, өйләрендә кемнәре барлыгы турында китте. Дәүләтбай карт аннан сүзне әкренләп нефтьтә эшләрнең ничек баруына, фатир мәсьәләләренә күчерде.

— Алла ярдәм бирсен инде үзегезгә. Кыендыр читтә яшәүләре. Фатирда тору да бик жайсыздыр инде... бигрәк тә безнең Фәридә килеңнең тар өендә...

— Бер өйрәнгәч, әллә ни түгел инде ул, бабай,— дигән булды Мотгәрәй, сер бирәсе килмәде.— Аннан бит мәсьәлә тарлыкта-кысанлыкта түгел, кешенең киң күңеллелегендә...

— Анысы шулай инде, Фәридә килен якты йөзле, рәхмәт төшкере... Тик менә бәхете генә булмады үзенең...

Шунысы гажәп: мәрхүм уллары турында бер сүз дә кузгатмыйча, карт та, карчык та гел киленнәрен генә мактадылар. Фәридә уңган, Фәридә булган, Фәридә эшчән. Кайнатасын-кайнанасын караган да Фәридә, ашаткан-эчерткән дә Фәридә. Кеше арасында Фәридә ирдән калса да йөзенә кызыллык китермәгән, яманатын саттырмаган, абруен төшермәгән... Тик менә шушы инсафлы баланың бәхете генә юк...

Кайниш тарафыннан мондый сүзләрнең чыгуы бик сирәк булгангамы, Мотгәрәй аларның тел төпләрен аңлады. Картлар ихлас күңелдән киленнәренең ялгыз калуына борчылалар һәм аның язмышын хәл итү өчен тырышалар иде.

Ләкин Фәридәгә игътибар итәргә кушылган ишарәләрне аңламаганга салынып, картларның кунакчыллыгына рәхмәт әйтеп, фатирына кайтып китте.

Мунчадан кайткач, Мотгәрәй тагын бер тәкъдим ясады Фәридәгә:

— Кара әле, Фәридә, минем монда вакыт житәрлек, нефтьнең тиз генә чыгасы юк, әллә, мин әйтәм, шушы бүрәнәләрдән сиңа өйлек бура бурап биримме?

— Кит, булмаганны сөйләмә!

— Юкка карышасың, Фәридә. Чамалап карадым: монда синең алты почмак куярлык бүрәнәң бар. Тотынныйм булмаса, тәвәккәлләп!

— Кирәкми, кирәкми! — Фәридә тыңларга да теләмәде.

— Ышанмыйсынмы? Мин берне генә түгел, гомеремдә йөзне бурагап кеше! Әйе, әйе, көлмә! Һөнәр мәктәбендә өйрәттеләр. Себердә шахтерлар өчен бүрәнәләрдән озын-озын бараклар сала идек. Армиягә дә алмадылар шуның аркасында...

Соңгысын әйтү Фәридә өчен нигә кирәк булгандыр, әмма яшьли һөнәр мәктәбенә алынып армиядән калганына Мотгәрәй әле булса да әрни һәм кимсенә иде. Үзенең буйга бәләкәй калуын да шул «солдат шулпасы» эчмәүдән күрә иде хәтта.

Фәридә ризалык бирмәсә дә, Мотгәрәй карар кылды: иртәгәдән бура бурый башларга!

## 22

Бораү инде дүртенче сәгатен диярлек бер урында таптана. Ул инде ашалган, тузган булса кирәк. Аның инде, бәлки, тешләре дә җимерелеп чыккандыр. Бораүны күптән алыштырырга вакыт булса да, Кадермәт инструментны күтәрергә ашыкмый, мастерның нәрсәдер әйткәнен, күрсәтмә биргәнен көтә.

Бик тә хикмәтле булып чыкты бу Язтургай скважинасы. Инде проект тирәнлегенә җитеп продуктлы горизонтны да ачтылар, аннан соң да шактый күп метрлар үтелде, нефть күренми дә күренми. Нефть сеңгән комташ катламын үтеп, менә хәзер бораү яңадан каты токымга килеп керде.

Бораү инде бармый — алдыра алмый. Бу нәрсә, разведчиклар кристаллик фундаментка килеп төртелделәр түгелме? Моннан соң эшне дәвам итүдә, бернинди җир асты байлыгы булмаган гранит нигезне җимерүдә хасият бармы?

Скважинаның мондый хәленә бигрәк тә яшь бораулаучы Камил борчыла иде. Вахтага килгән саен ул: «Нефть чыкмадымы?» — дип сорый, эштән киткәндә: «Мин юкта кинәт чыгып куймаса ярар иде»,— дип хафалана. Үз куллары белән аттырасы килә аның нефть фонтанын, аның ташкын кебек ургып биеккә-биеккә күтәрелүен үз күзләре белән күрәсе һәм авылга кайтып иптәшләренә мактанып сөйлисе килә.

Ләкин, ни сәбәп, тирәндә яткан могҗизалы нефть тә, өскә ургый торган хикмәтле фонтан да күренми. Инде ике чакрымнан артык җир төштеләр, тирәндәге бөтен токымнарны актарып чыгардылар, балчыгын, комын, акбурын, доломит ташларын тишеп үттеләр, «кара алтын» шунда дигәч, девон катламына барып җиттеләр. Хәзер инде чуер таш, гранит, магма катламнарын кимерәләр, ә нефть юк та юк.

Бораулаучыларның кәефләре сүрелде, эшкә дәртләре калмады. Тик болай гына, бушка гына әйләндерәләр, ахры, алар бораүны.

Зөбәеров җир астыннан килеп чыккан токымны карап килә дә Кадермәттән сүзсез генә рычагларны үз кулына ала, бераз гына бораулап карый да, түземсезләнеп, улаклар янына китә, лай белән уйнаган балалар шикелле, балчык актара башлый. Хәзер инде скважинадан ком да, балчык та килми, ярма урынына вакланган гранит кына менә. «Бер читтә калды булса кирәк нефть»,— дип уйлый мастер.

— Күренмиме?

Зөбәеров дәшми генә Кадермәт алдына килеп басты, күзен чекерәйтеп, бораулаучысына карап тора башлады. Кадермәт кнопкага басып бораүны туктатты.

— Әллә югыйсә... скважина кысырмы?

— Әйе, шуна охшаган.

Разведчикларның айлар буе интегүе бер сүз белән кинәт юкка чыкты.

Яман хәбәр, шомлы җил булып, буровойдан Язтургайга килеп житте, бораулаучылар урнашкан фатирларга бәреп керде. «Нефть табылмады!»

Бригадада булган кешеләрнең барысы да тиз арада Баланлы төбәккә, җансыз булып туктап калган буровой тирәсенә җыелдылар. Төшенкелек, ачу, үкенеч — теләсә нинди билгеләр күрергә була иде аларның йөзендә.

Зөбәеров бораулаучыларына карамаска тырышты. Күрмәде дә бугай ул аларны. Бу араларда үткәргән йокысыз төннәрдән тонып калган күзләрен каядыр буровой ягына, вышка башына текәгән килеш басып тора бирде. «Булмаса булмый икән бригаданың бәхете...»

Җәй буе эшләгән, көч түккән буровоен кызганудан йөрәге кысылып куйды Зөбәеровның. Чын-чынлап урнаштылар гына бит әле, бер уйласаң. Егетләр дә фатирлы булды, Рәйсә дә матур гына эшләп йөри, Фазыл үзе дә Язтургайга ияләшә башлады кебек... Аннан шунысы да бар: булдыра алмый китсәләр, авыл кешеләреннән оят!

Зөбәеров каш астыннан гына разведчикларга карап алды. Болай да шартлап өзелергә торган бу киеренке тынлык озакка бармас, мастерга берәр акыллы сүз әйтергә кирәк иде.

Ләкин ул кешеләрне юатырдай акыллы сүз тапмады.

Сергей Саакян уртага чыгып, Зөбәеровны үртәгәндәй, чаңгылдатып бораулау торбасына типте.

— Нәрсә, мастер, таш чыктымы скважинадан? Шулай булмыйча! Таш тутырдык бит забойга.

— Минемчә, йомыркаларны күбрәк тондырып ташладык бугай,— дип, Фәрхетдин төрттереп алды.

— Буровойны теләсә нинди түмгәк өстенә утыртып кеше җәфалыйлар бит, аналарын!..— Еланский берсе-берсе кечкенә капчык кадәр бияләйләрен салып җиргә атты.— Нәрсә эшләп торабыз? Җыештырырга кирәк кармакларны, таралырга кирәк!..

Каяндыр кешеләр арасыннан Мотгәрәй дә песи танавын сузды:

— Дөрес әйтә Еланский! Онсыз тегермән әйләндерүдә ни файда? Сез теләсәгез ни эшләгез, мин, мәсәлән, киттем бригададан!

— Бар, үкчәңне күтәр! — дип җикеренде Кадермәт.— Синнән ни он суы, ни тоз суы!

Үзенең күптәнге сүзләренә дәлил табып, алга Миргазиян чәчрәп чыкты.

— Менә, әйттем, мастер, буровойга килде-китте крестьян җыймыйк, дидем. Күрдеңме, кая тәгәри алар? Алар бит беренче авырлык килгәнче генә эшче! — Миргазиян башыннан алып аягына хәтле кулы белән һаваны ярып төште.— Китәсе кешеләр китсен, мастер. Әмма мин бригаданы бу хәлдә ташламыйм! Кирәк булса табарбыз нефтьне!

Кешегә күп кирәкмени. Миргазиянның шушы ордым-бәрдем генә әйтелгән сүзләренә дә күңеле булды Зөбәеровның. «Рәхмәт, туган!» — дип әйтәсе килде бу эшче нәселенә. Тик кулы белән Миргазиянның җилкәсен генә кысып алды. Бер адым алга атлады. Уч төбе белән маңгаен сөртте.

— Сезнеңчә, нәрсә: разведка ул нефть кенә табып йөрергә тиешме? Безнең максат эзләнү, эксперимент икәнен дә онытырга ярамый.

— Эксперимент ясыйм дип, файдасыз урыннарны чокып йөре инде син!

— Мин каршы түгел: китәргә теләгән кешеләр китсен. Я, кайсыгыз китә? Синме, Мотгәрәй? Еланский, синме? Бәлки, Сапарбай җыенадыр?

Мастер кулы белән берәм-берәм төртеп сорап чыкса да, җавап бирүче, урыныннан кузгалучы булмады.

«Китеп кая барам инде мин хәзер? — дип уйлап алды Сапарбай.— Кайтсам, хәзер анда Рәйхана да юк, торырга урын да калмады...»

Я, әйтегез, бораулаучы һөнәреннән башка эш белмәгән Еланский кая китсен? Тин-Тиныч та, Валясын таба алмагач, киту уйларыннан арынып бара бугай. Кадерматләр, Миргазияннар, Фәрхетдиннәр буровойга ябышып яталар инде алар. Хәтта Сергей Саакян да Бакуга кайтып киту турында уйламый башлады. Китсә шул бер Мотгәрәй китәр инде...

— Шулай да әйт әле, мастер,— дип сорау бирде Сапарбай,— безне приборлар алдаган булып чыгамы, әллә үзебез ялгыш юлга кердекме?

Зөбәеров моңсу гына елмайды:

— Нефть чыкса, приборлар белән геологларны мактыйлар, Сапарбай, чыкмаса — без гаепле... Ярый, егетләр, борыныгызны салындырмагыз, торбаларны әйләндерә торыгыз. Ябышып катмасыннар. Мин конторага киттем...

Язтургай мәйданындагы хәл контора директорын, баш инженерны һәм алар белән бергә баш геологны да тиз генә Баланлы төбәккә килергә мәҗбүр итте. Аптырарлык, бәхәсләшерлек нәрсәләр күп иде. Моңа кадәр разведчиклар Татарстанның көнчыгыш районнарында кайсы гына ноктага барып скважина салсалар да ялгышмадылар — аннан искиткеч күп нефть чыкты. Ромашкино ятмасының мәйданы киңәя, үсә барды. Башта көньяк чикләре, аннан көнчыгыш чикләре мәгълүм булды. Бу елларда төньякка таба, төньяк көнчыгышка таба шактый гына зур адымнар ясалды. Бүгенге көндә Чияле таудан башланган юллар алтмыш-житмеш километрларга сузыла — ул Кама елгасына кадәр барып тоташа. Шулай итеп, разведка-эзләнү эшләре галимнәрнең, геологларның алдан исәпләүләрен, фараз итүләрен раслады. Ромашкино нефть ятмасы моңа кадәр илдә күрелмәгән иң зур, уникаль ятма икәнлеген ачыкланды.

Ромашкино нефть ятмасының сурәте геологик карталарда да бикләнмәгән йозак рәвешендә төшкән. Менә шушы гигант йозакның Язтургайга караган дугасын — көнбатыш чикләрен нәкъ менә Зөбәеров бригадасы бикләргә тиеш иде.

Конторадан килгән хуҗалар, буровой күрмәгән кешеләрдәй, скважина тирәсен әйләнеп чыктылар да улак янына килеп иелделәр. Астан юдырылып чыккан шламны карарга тотындылар. Әйе, девон тирәнлегеннән күтәрелгән кристалл бөртекләре бораунын нигезгә килеп төртелгәнен күрсәтеп тора иде.

Һәр нәрсәне төпченергә яратучы Камил, кызыксынып, аларны читтән генә күзәтеп торды. Берсе, арада иң зур хуҗа булса кирәк, кулындагы шламны иснәп-иснәп торды да җиргә бәрде.

— Ташларга кала бу урынны! — диде.

— Ташлау ансат! — дип каршы төште икенчесе.— Ә бит бу тирәдә нефть бар!

— Кайда соң ул нефть? — дип кычкырды хуҗа.— Я, күрсәт, табып бир син геолог булсаң!

— Алынган анализлар шул турыда сөйли: нефть бар! Без аз гына читкәрәк киткәнбез булса кирәк,— ди геолог. Үзе хуҗадан курыккандай бераз читтәрәк тора.

— Тагын яңа скважина салдырмакчы буласыңмы? — дип җикерена хуҗа.— Юк инде, туганкай, андый юмартлыкны эшли алмыйм!

— Бу як чикләрне ачык калдырып булмый, разведка таләп итә,— ди геолог. Бик үҗәт кеше икән үзе: кесәсеннән зур гына блокнот чыгарып әле дәфтәренә, әле җиргә сыза-сыза, бу тирәләрдә нефть чыгу ихтималын исбат итә башлады. Хуҗа аны бүлдереп, кулыннан карандашын тартып алды да нәкъ аяк астына бер түгәрәк сызып куйды.

— Безгә яңадан Ромашкинога таба кайтырга кирәк,— ди.— Ә сез, геологлар, тоттыгыз да менә кая китереп ташладыгыз буровойны. Уни-

каль нефть ятмасы дигәч тә, ул бит нефть океаны түгел, аның да бер чиге бар,— дип шелтәли геологны.

— Бу тирәдә нефть барлыгына иманым камил! — ди геолог, һаман да үзсүзләнеп. Дәфтәренә нилләрдер сыза-сыза яңадан исбатларга керешә.— Катламнарның киселеш схемасы, скважинадан алынган керн үрнәкләре, бигрәк тә нефть сеңгән комташ катламының чыгуы бу мәйданның продуктлылыгы турында сөйләмиме? Ниһаять, скважинада күмер катламы булуы, газ бәреп чыгуы нәрсәне аңлата? Әйтәм бит, бар ул нефть! Минемчә, без аны бераз читләтеп үттек...

— Кайсы яклап читләтеп үттегез? Уңнанмы, сулданмы? Ничә метр? — дип, усал елмая хужа. Ә геологы, ай-һай, гыйлемле кеше икән! Бер дә аптырап тормый, җавабын табып кына тора:

— Минемчә, шушы урыннан үзәккә таба авыш скважина салырга кирәк. Авыш скважина салу безнең өчен ярты бәягә дә төшми ич!

— Тагын нефтькә туры китерә алмасак? Бер ярым бәягә төшмәсме?

Хужа, геологы белән ризалаша башлап, инженерына карады.

— Кырыйга без ничә метр керә алабыз?

— Нинди авышлык бирәсең бит. Йөз метр, ике, өч йөз метр, аннан да күбрәк...

— Кыек борауларга дигәндә бу бригаданың тәҗрибәсе бар! — дип, хужа Зөбәеровка төрттереп алды.— Адашып читкә керергә яраталар алар...

Хужаның шаярып сөйләшә башлавы геологның фикеренә кушылганын белдереп тора иде.

— Әйдәгез әле, уйлашыйк, киңәшик,— дип, җыйнаулашып бригада вагонына кереп киттеләр. Димәк, бригада бер кая да китми, Язтургайда кала.

## 23

«Рәйсә — әйбәт духтыр», «Рәйсә — кырыс хатын», «Рәйсә — җен» — уены-чыны белән әйтелгән бу сүзләр медпунктка да юл ачты. Хәзер инде авыруларның һәм йөкле хатыннарның күбесе, бигрәк тә яшьрәкләре, имтомчыларны, күрәзәчелекне һәм кендек әбиләрен читләтеп үтәләр.

Кич бик соң һәм арып кайта башлады Рәйсә. Кайта да, өстен дә чишенмәстән, зур канәгатьлек белән урындыкка ава, иренә мактана: «Бүген алты авыру кабул иттем». «Бүген авыруларның саны унга житте». «Уйлап кына кара, бүген медпунктта егерме өч пациент!» Шунысы кызык, көннән-көн арта бара пациентларының саны.

Зөбәеров астыртын гына көлә:

— Молодец, болай булгач бу айда авырулар планын арттырып үтисең икән!

Иш өстенә куш дигәндәй, фатирдан да уңмадылар Зөбәеровлар. Бораулаучыларның барысын да урнаштырып бетереп, мастер берүзе калгач, буровойдагы Камил үзләренә чакырды Зөбәеровны. Безнең өй алты почмаклы, иркен, диде, әти-әни карт, йортта бала-чага юк, килегез Рәйсә апа белән безгә торырга, диде. Күктән көткәнне җирдән тапкан төсле булды бу, чөнки укытучылар квартирында Рәйсә актык көнен яши, менә-менә иске хуҗалары кайтып төшәргә тиешләр иде. Тиз генә яңа фатирга күченделәр.

Калтыравык Сабирҗанның йорты зур, алты почмаклы икән. Балалары үсеп, кайсы кая таралып бетү сәбәпле, өйнең алгы ягында бөтенләй тормаганнар, ул ташландык хәлгә килгән. Шулай да фатир кыенлыгы булган Язтургайда аерым семьяга мондый иркенлекне табу үзе бер могҗиза булып тоелды Зөбәеровларга. «Камилгә рәхмәт инде,

безне зур бәладән коткарды»,— дип куаныштылар Рәйсә белән Фазыл. Тик шунысына гаҗәпләнделәр: ни өчен мондый фатирны авыл Советы күрмәгән дә ни өчен бораулаучыларның берсенә дә тәкъдим итмәгән?

Кеше өстендә торуның нәрсә икәнен фатир кергән кеше үзе генә белә. Урнашкан көнне алгы якның стеналарын агартып, идәннәрен юып, ничә еллар ягылмаган өйне җылыту өчен күп кенә итеп мичкә ягып җибәргән иде Рәйсә. Иртәгесен Сабирҗан Рәйсәнең күз алдында әрдәнә итеп өеп куелган утыннарга тамга салып чыкты: бу безнең милек, янәсе, кагыласы булмагыз. Аннан пычкы, балта, сәнәк кебек эш кораллары рын келәтенә кертеп куйды да ишегенә түбәтәй кадәр йозак салды. Монысы да тотынмаска кушкан ишарә иде.

Күчену мәшәкате белән өйдә ду килеп йөргән Рәйсә янынарак килеп, хуҗа кеше, йөткерә-йөткерә, тагын шундый күрсәтмәләр дә бирде: кергәндә-чыкканда капканы яхшылап ябып йөрергә, эчке яктан һәрвакыт биген төшереп куярга, аяк киемен баскычка менгәнче үк, ишек төбенә җәйгән ташта салып керергә; ул авыру, ишекне каты итеп ябып йөрмәскә, келәсен чылтыратмаска, өйдә баланы йөгертмәскә, тавышландырмаска, елатмаска, тагын әллә нәрсәләр...

Өйне юганда су ташырга кирәк булгач, Рәйсә аларның көянтәчиләкләрен сорап алып торган иде, аның өчен дә үкенде. Йомышны кертүкәч, Сабирҗан тикшереп алды: чиләкләр яньчелмәгәнме, көянтә сынмаганмы?

— Ошамый миңа бу кешеләр! — диде Рәйсә, Фазыл эштән кайту белән.— Беткән идеме Язтургайда башкалар...

Фатир хәлләрен сөйләп биргәч, Фазыл үз-үзенә яңалык ачкандай булды. Менә ни өчен тәкъдим итмәгәннәр икән бу фатирны! Күченгән чакта күршеләреннән берәү әйткән иде шул: «Тапкансыз керер кеше! Калтыравык Сабирҗан белән тапма да, бүлешмә дә, диләр бездә».

Кая егыласыңны алдан белеп булмый. Әнә Сабирҗанның улы Камил бөтенләй башка бит. Акыллы, хыялый, зирәк малай. Буровой эшенә дә яхшы гына төшенеп килә. Кешеләргә дә бик ихтирамлы. Ул якын итеп, хәлгә кереп үзләренә чакырып торгач, ничек каршы киләсең? Зөбәеров аның мондый үтә саран, карун кеше баласы икәнен дә белми иде...

— Түз инде, Рәйсә, мәңге торасы түгел бит...

Рәйсә үпкәләп аш ягына кереп китте. Менә шулай инде ул Фазыл, гомер буе вакытлыча гына яши. Вакытлы гына буровойга күченеп китә, вакытлы гына чатырлар кора, өстенә яңгыр ява башлагач, вакытлыча гына авылга кайта. Гел вакытлыча. Ә кешеләр дөньяга вакытлыча гына дип тумаганнар бит. Кеше мәңгелеккә дип йортлар төзи, мәңгелеккә дип юллар сала, мәңгелеккә дип агач утырта... Кайчанга кадәр барыр Фазылның бу вакытлы тормышы? Берәр чиге булырмы моның?

Фазылның үзенә дә күп мәртәбәләр биргәне бар мондый сорауны, ләкин ул андый чакта җавап бирүдән баш тарта яки ниндидер җай табып сүзне икенче якка таба борып җибәрә иде.

Зөбәеров үзе дә киләчәк көнен анык кына күз алдына китерә алмый иде бугай, шуңа күрә эченнән генә көрсенеп:

— Юкка гына өйләндем,— дип куя иде.— Уйлап карасаң, семья — разведчик өчен чын имгәк.— Зөбәеров үзенчә фәлсәфә кора.— Өйләнгәч, әлбәттә, хатын белән яшәргә кирәк. Яшәр идең, нефть эзләп чыгып китмичә булмый. Үзең белән хатыныңны алсаң, ул бит Рәйсә кебек «нормальный тормыш» таләп итәчәк. Аңа яслесе кирәк, бакчасы кирәк. Хәер, чатырда да үстереп булыр иде, ә менә ничек укытырга? Авыл саен мәктәптән мәктәпкә йөрепме? Димәк, разведчик булам дигән кеше өйләнмәскә, семья кормаска тиеш булып чыга. Бу хакыйкатьне элегрәк белгән булса, Рәйсә белән танышмаган да, өйләнмәгән дә булыр иде...

Инде эштән кайтуына ак эскәтер ябылган өстәл уртасына таба белән кыздырылган бәрәңге килеп утыргач, аның тирә-ягына вак тарелкалар-

гә турап салынган кыярлар, помидорлар тезелгәч һәм бары Фазыл гына ярата торган тозлы гөмбә дә куелгач, Зөбәеровның ялгыз тору фәлсәфәсе әкренләп җимерелә башлый. «Болай үзе бергә яшәгәндә дә ярыйсы төсле икән... Ялгыз булсаң, кем сиңа суыктан кайтуыңа аш әзерләп куяр иде, каралса кем күлмәгеңне юар иде? Аннан бит әле кайтып керүеңә куышыңның бушлыгы, күңелсезлеге йөрәгеңне телә! Кайгы-шатлыкларыңны уртаклашырга, дөнья хәсрәтләрен бүлешергә дә кеше тапмый интегәсең... Шунда хатыныңның булып бер җылы сүз әйтсә, балаң килеп муеныңа асылынса, күңелләрең эреп китә».

Аштан соң Зөбәеров нәрсәдер уйлап сикереп торды:

— Мин бу Сабирҗанны кызык итим әле! Әйе, әйе, разведчиклар ярлы яши димәсеннәр!

Икенче көнне төштән соң Сабирҗаннарга әрҗәсе түбәләмә агач төяп зур машина кайтып керде. Ул агачын бушатып чыгып китүгә, утын төяп, буровойга балчык ташый торган тагын шундый ук «МАЗ» килеп туктады.

Бу хәлгә башта кулын каш өстенә куеп тәрәзәдән карап торган Сабирҗан да түзмәде, авыру икәнен онытып, күлмәкчән генә ишек алдына чыкты. «Алла, берсе-берсе бер кышлык бар!» Карт, үз күзләренә үзе ышанмыйча, кабинада утырган Зөбәеров янына килде.

— Кемгә болар?

— Сиңа, бабай.

— Бушкамы, акчагамы?

— Бушка!

— Бөтенләйгәме?

— Әлбәттә!

Әле монысы да соңгысы булмаган икән. Бу машина китүгә, Сабирҗаннар йортына аллы-артлы тагын ике машина утын кайтты. Ходай бирсә дә бирә икән, шыңгырдап торган эре имән агачлары. Кайдан кайтарткандыр мастер, мондыйлар Язтургай урманнарында да, ерак Шәмәрдән делянкаларында да юк.

Баштарак кулын артка куеп, агач өемнәренә сокланып, башын кыегата-кыегата карап йөргән карт, соңгы ике олау килгәч, хәрәкәтен кискен арттырды: авыр агачларның әле бер башына, әле икенче башына килеп тотынды, аларны өстерәде, йолкыды, каядыр илтеп яшереп куймакчы булып азапланды. Гомерендә агач заты күрмәгән кеше кебек кылана иде Сабирҗан.

Беренче кичне лампа өчен буровойдан керосин алып кайтырга оныткан иде Зөбәеров. Ул көнне Рәйсә Сабирҗанны зарландырып бер стакан керосин алып чыккан иде, «өемне хәерчеләр басты» дип каргаңып калды карт. Бүген бер буйдан аның ачуын да алды, утыннар белән бергә, Сабирҗаннар ишек алдына бер мичкә керосин тәгәрәтеп төшерде. Бер атнадан бу керосинның кирәге калмаячагын белә торып эшләде Зөбәеров.

Колхоз һәм авыл җитәкчеләре белән болай сөйләшкәннәр иде бит: багана алардан, чыбык разведчиклардан. Баганалар утырту һәм авылга чыбык сузу колхоз ягыннан, ә электр бирү буровойдан.

Разведчикларның бу мәсьәләдә тәҗрибәләре бар иде инде. Кайда гына туктасалар да, кайсы гына авылга торырга килсәләр дә, беренче чиратта фатирларына электр кертәләр. Шушы ук электр авылның үзенә күрә булган учреждениеләрен яктыртып тора.

Разведчиклар киткәннән соң да бу утлар сүнми, бораулаучылар урынына нефть чыгаручылар килә. Алар чыбыкны үз двигательләренә ялгый. Авыл тулысы белән электр утына күмелеп кала.

Сабирҗанны ут белән дә кызык итмәкче булды Зөбәеров. Чыбыкны урамдагы баганадан туры үзләренә суздзы, аннан картның чыгып киткән вакытында гына, яшерә-яшерә ишек ачып, хуҗалар ягына кертте.

Сабиржан аны-моны искәрмәгән иде, кайтып кергәч, түшәмдә асылынып торган пыяла куык тирәсендә озак таптанып йөрде, тотынырга курыкты һәм нәрсә дип әйтергә дә белмәде. Кичтән йортның һәр ике ягында да электр уты гөлт итеп кабынып киткәч, карт, яктыда калган сукыр тычкан шикелле, куләгә эзләп арлы-бирле чаба башлады, кая да кереп посар урын тапмагач, ләхәүләсен укып, мич башына менеп китте.

Бу минутта бер үк вакытта тарихта беренче мәртәбә Язтургайның караңгы урамнарында, бораулаучылар яшәгән йортларда, авыл Советында, колхоз идарәсендә, мәктәптә, клубта, медпунктта ут балкый иде.

## 24

Бу көнне буровойда эш аеруча тыгыз булды. Бер мең метр тирәнлектә кырыйга таба юнәлдерелгән скважинадан торбаларны күтәреп җир астына махсус борау төшерергә, аның белән лабораториядә тикшерү өчен бик мөһим булган токым үрнәкләрен алырга кирәк иде. Геологлар аны керн алу дисәләр, бораулаучылар гүр газабы диләр.

Керн алу белән бигрәк тә Камил кызыксына иде. Разведчиклар кернны йөз-ике йөз метр төшкән саен алалар. Бу вакытта мастер буровойдан бер генә адым да китми, конторадан килгән геолог та, мәче тычкан саклаган кебек, җир астыннан менгән токым үрнәген сагалап ята. Алар рөхсәтеннән башка токымның бер генә валчыгына да тотынырга ярамый бораулаучыларга.

Камил эшли башлаган беренче көннәрдә скважинадан ниндидер яшькелт-көрән балчык кына чыга иде. Кадермәт абыйсы моны яңа эра балчыгы — кайназой эрасы катламнары дип аңлатты. Аның яше кимендә бер миллион ике йөз илле мең ел икән. Бу чорда әле җир өстен дингез генә каплаган, анда бары тик суүсемнәр генә булган да диңгез җанварлары гына яшәгән, имеш. Бераз вакыттан соң кернны тагын да тирәнрәктән алдылар. Монда Камил катламның сары-аксыл төскә кереп ташка әверелә баруын күрде. «Менә монысы инде, энем, тагын да борынгырак катлам»,— диде Кадермәт. Бу катлам мезозой эрасыннан икән. Ул гади суүсемнәрдән, кабырчыклардан, медузалардан һәм башка төрле дингез хайваннары калдыкларыннан ясалган, известька һәм акбурга әверелгән. Катламның яше дә шаккаткыч: кырык миллион елдан артык икән.

Бу скважинаны бораулаган чорда токымнарның төрле үрнәкләрен күреп үтте Камил. Ком чыкты, известьташ, балчыклы ком, комлы балчык — барысы да чыкты. Бөтен бер җир асты патшалыгының шаһиты булды ул. Ә менә бүген Камил иң борынгы палеозой эрасы белән танышa. Бу эра үзе генә дә берничә чорга бүленеп, пермь чоры, ташкүмер чоры, девон чоры, силурый чоры, кембрий чоры дигән исемнәр белән йөртелә икән. Әйтә башласаң телеңне сындырырсың!

Камилләр бригадасына девон чорына кадәр төшәргә, шунда ята аларга дигән хәзинә. Бу токым иң карт токымнарның берсе, аңа илле миллион елдан артык икән. Ләкин, күрәсең, нефть девонның һәр катламында да булмый. Мең метрдан башлап тагын каядыр кырыйга кереп киттеләр.

Җир астында илле миллион яшәгән менә шушы катламны яңадан кистереп югары чыгарганчы һәм аны геологлар кулына тапшырганчы шактый вакыт узды. Торбаларны бер сүтеп, бер ялгап, борау артыннан борау алыштырып азаплана торгач, кешеләр тәмам ялыктылар. Иң беренче булып, мускуллары белән мактанып йөрүче Геннадий Еланский арыды — кулыннан торба бора торган ачкычлары төшеп китә башлады. Әйе, бу сиңа гер күтәреп уйнау гына түгел! Аннан, өстә верховой Миргазиян йомшады — җир астыннан күтәрелгән торбаларны ыргагыннан

ычкындырып җибәргәләде. Әш бетәр алдыннан гына Камилнең дә тез буыннары бушый башлады — торбалар китергәндә ике мәртәбә буровойның юеш идәненә таеп егылды. Ул һаман саен борылып яна вахта килүен көтә иде.

Тик какча янаклы, арык гәүдәле кеше — вахта җитәкчесе Кадермәт кенә һаман буровойның идарә пультендә дикъкать белән әле приборларга карап, әле бораулаучыларның эшләрен күзәтеп, элеккечә нык һәм төз басып тора бирде. Аның ару-талуны белмәс куллары бертоташтан тормоз рычаглары һәм кнопкалар тирәсендә хәрәкәтләнде, аяклары алмаш-тилмәш педальләргә басып торды. Бораулаучыга бер генә минутка да туктарга ярамый, юкса, торбалардан бушанып калган урынга балчык ишелеп төшү һәм скважинаны томалау куркынычы бар иде.

Ажгырып, торба артыннан торба җир куеныннан чыга торды, вышка эчендәге платформада озын-озын «шәмнәр» тезелә торды. Ниһаять, җиде кат җир астында бораулны ут уйнатып әйләндерүче турбобур күренде, аның артыннан каты чуер ташларны кимереп баручы борау үзе пәйда булды.

Буровойдагылар җир астыннан шома стакан рәвешендә киселеп чыккан токымны карарга керештеләр.

— Менә шушы инде ул, энем, чиклэвек кабыгы,— диде Кадермәт. Камилгә доломит ташларын тоттырып.— Доломит Камил кулында, кояшка чагылып, асылташ урынына ялтырады. Егет аның бер кисәген алып тешләп карады — ватылмады таш. Пыялага сызып карады — пыяланы алмаз урынына кисә. Доломит ул чакма таштан да, иң каты мәрмәрдән дә катырак икән.

— Фью-у,— дип сызгырып куйды Камил.— Ничек шул кадәр каты токымны борау ала?

— Борау алмый аны, энем, кешеләр ала! — диде геолог.

Зөбәеров белән геолог катлам үрнәкләрен кулларында әвәләп, күзләренә якын китереп бик җентекләп карадылар.

— Әйе, токымның асылына эләккәнсез! — диде геолог, Зөбәеровка игътибар итмичә генә.

Зөбәеровның үз хәсрәте бар иде.

— Ну, ничек, булырга охшыймы нефть?

— Ни әйтсәң дә тегесенә караганда өметлерәк.

Геолог кулындагы ташларны югары күтәрде.

— Бу кернн нәрсә турында сөйли? Беренчедән, девон кабыгы өскә күтәрелә бара. Димәк, продуктлы горизонт якынрак. Икенчедән, менә кара: доломит эзлекле рәвештә комташка күчә бара. Ә комташ ул — нефть сеңгән таш...

Камил аларга карап торды: читкәрәк китеп, мастер белән геолог тагын нәрсәдер серләштеләр. Ахры, монысында да нефть юк, шул доломит кына чыга. Ахры, бораулаучыларның күңеле төшмәсен өчен генә эшләтәләр... Их, бер үргылып нефть фонтаны аттырган чакларны күрер көннәре булыр микән Камилнең?!.

Авыш юнәлештәге скважинаны бораулаларга наряд бирелгәч, разведчиклар бер нәрсәне аңламый аптырадылар: ярый, скважина теге юлы арырак та бораулаган булсын, ди. Ә хәзер ни өчен соң геологлар үзәктән тагын да читкә, кирегә таба борырга ясадылар? Бу бит нефтьтән тагын да, элеккесенә караганда да ераклашу дигән сүз!

Зөбәеров бу мәсьәләдә үзе дә икеле-микеле йөри иде, сөйләп-сөйләп, күңелләре төшкән бораулаучыларны ышандыра алмый иде, шуны аңлатуны сорап, ул баш геологка мөрәҗәгать итте:

— Моны бораулаучыларның үз авызыгыздан ишетәселәре килә.

— Рәхим итсеннәр!

Зөбәеров бораулау эшен чак кына туктатып торырга кушты, югарыдан верховой Миргазиянны чакырып төшерде.

— Димәк, нефть булуына шикләнәсез? — диде баш геолог, бораулаучылар җыелып беткәч.— Бу турыда безнең арада да бәхәс күп булды. Әнә, аны мастерыгыз белә инде. Геологлар белән администрация арасында чын сугыш булды диярлек. Без, геологлар, үзебез дә, дөресен әйткәндә, артык тәвәккәлләдек булса кирәк: нефть чыкмаса, кулыбызны да, башыбызны да кистерергә вәгъдә биреп бетердек... Ни өчен үзәктән читкә бораууларга булдык дисезме? Логика шуны таләп итә. Соң, уйлап карагыз: эзләнү-тикшерену нәтиҗәләре, приборларның күрсәткечләре, аларның әле бер якка, әле икенче якка авышулары һәм менә керн үрнәкләре барысы да нәрсә турында сөйли: без бер-берсеннән якын торган ике нефть чыганагы арасына кергәнбез, скважинаны шунда салганбыз. Бу — көтелмәгән кызыклы хәл! Аңлыйсызмы сез? Әгәр без хәзер менә бу авыш скважинадан нефтькә юлыгабыз икән — бу бит яна нефть чыганагы ачу дигән нәрсә! Версия шундый: Ромашкино чыганагы күршесендә яңа чыганак бар!

— Оһо! — дип куандылар бораулаучылар.— Димәк, без аның беренче разведчиклары?

Баш геолог, елмая төшеп, бораулаучылар белән сүз тәмам икәнен аңлатты:

— Ну, егетләр, зинһар, безне баштан мәхрүм иттермәгез! Тырышыйк, табыйк ул нефтьне!

— Болай булгач, җир астыннан булса да табабыз инде!

## 25

Улына армиягә китәргә хәбәр килгәч, Галләм абзыйның бердәнбер теләге — улын бик шәпләп, авылны гөр иттереп озату иде. Шул көнне үк ул, күрше-күләнне гаҗәпләндереп, нәселгә дип калдырган кышлау танасын егып суйды, урам буенча шешәләрне шалтырата-шалтырата, әрҗәсе белән аракы күтәреп кайтты.

Инде өендә шул шешәләрнең берсеннән авыз итеп тә алгач, Галләм абзый сандыкны актарып, аннан улына дип аталып та тектерергә өлгерә алмый калган костюмлык материалны эзләп тапты, аны газетага төрде дә, алпан-тилпән килеп, югары очның калтыравык Сабирҗаннарга менеп китте.

Әйе, егеткә солдатка китәргә хәбәр килде, ә Каюмның кеше арасында киеп чыгарлык юньле костюмы да юк. Тектерә алмады Галләм, һаман вакыты табылмады, һаман эш дип чапты. Йортта хуҗа хатын булмау, Каюмның әнисе үлү дә бик тотты кулны... Соңгы көннәрдә генә булса да бер рәхәтләнеп киеп калсын егет. Сабирҗан малае Камил белән китәчәк бит әле солдатка. Монысы икеләтә җаваплы. Кем улы дигәндә Галләм улы дигән сүзе ни тора бит әле аның. Пускай дуамал дисеннәр, бу көнгә кадәр дуамал Галләмнең сынатканы булмады кешеләр алдында, моннан соң да сынатасы юк!..

Галләм урыс капканы ачып җибәрүгә үк ажгырып аякка ташланган сары этне тибеп җибәрде, аның ярсу белән чинавына исе китмичә генә өйгә узды.

Болай да кемнәндер курыккан шикелле гел калтырап торучы Сабирҗан, шактый төшереп алган Галләмнең өйгә килеп керүен күргәч, шүрләп калды. Кабаланып машина астындагы ситсы-мазарларын җыештырырга кереште, өстәлендәге кайчысын алып аска яшереп куйды.

— Әйдә, түрдән уз, Галләметдин кордаш,— дигән булды карлыккан кәҗә тамагы белән.

Галләм пычракка баткан итекләрен лачтор-лочтыр китереп түргә узды, кулындагы төргәген Сабирҗанның өстәленә ыргытты.

— Сина ике көн срок,— диде ул тегүчегә,— или син шул срокта малайга костюм өлгертәсең, или мин сине җәһәннәмнең нәкъ төбенә ук җибәрәм!

Сабирҗан ашыгып төргәкне кулына алды. Тагын да ныграк калтырана төшеп:

— Син нәрсә, кордаш, ул кадәр... әллә малаеңны өйләндерергә җыенасыңмы? — дип сорады.

— Өйләндерү сиңа! Солдатка җибәрәм, солдатка, аңладыңмы! Синең малаең белән!

— Соң анда кием бирәләр түгелме?

Галләм Сабирҗанның кулыннан төргәкне тартып алды, нәкъ машинаның астына, энәсе янына ук ташлады.

— Анысын, кем, солдатта булган кешеләр — без үзебез беләбез. Ә син тикшереп торма, тегә башла, менә шул!

Сабирҗан, дуамал Галләмнең гадәтләрен яхшы белгәнгә, каршы сүз әйтергә базмады, төргәкне алды да калтыранган куллары белән кәгазьне сүтте. Төргәк эченнән елкылдап торган шомырт кара бастонны алып, бармаклары белән капшап торды. Моңарчы мондый материалдан беркайчан да костюм тегәргә туры килгәне юк иде әле аңарга.

— Соң, син, кордаш, ике көндә өлгертергә дисең... Бу материалның нәрсә икәнен беләсеңме соң син? Бастон диләр моны, бастон!

Моның белән бу дуамалны бераз өркетеп, аның тузга язмаган таләпләреннән котылмакчы булып караган иде, ләкин Галләм мыегын да селкетмәде:

— Булса соң, бик әйбәт! Аны Галләмнекеләр киярга тиеш! — Чыгып китү өчен ишек тоткасына тотынды.— Менә шулай, Сабирҗан, безнең нәсел гомер буе солдат бирде, ә син әле бер улыңны гына озатасың!

Сабирҗан биленә таянып торып басты.

— Нигә озатыйм?! Минем Камилем янымда кала.

Галләмнең башына таш белән ордылармыни — күзләрен зур ачып, ишек төбендә катып калды.

— Ничек янында кала?

— Шулай. Алмадылар аны... Монда кирәк ул...

— Ничек монда кирәк? Китмимени?

— Китми... Нефтькә кирәк...

— Тукта әле, тукта...

Галләм ишектән арты белән диярлек чыгып, Зөбәеровларның карават почмакларына килеп орынды.

Зөбәеров эштән кайтып ашарга утырган, Рәйсә чаршау белән корып куйган мич тирәсендә табак-савыт белән мәж килеп йөри иде. Күзләре тәмам ачу белән киерелгән Галләмне күреп, Зөбәеров кашыгын өстәлгә куйды. Галләм аның янына килде.

— Тукта әле, тукта, ничек әле бу, Сабирҗан малае Камил китмимени армиягә?

— Китми.

— Ничек китми?

— Шулай. Отсрочка бирделәр. Нефтьтә кеше кирәк.

Галләм изүен чиште:

— Ә кайда дөреслек? Минем ике малай фронтта үлеп калырга, өченчесе китәргә тиеш, аның бөтен нәсел-нәсәбеннән бердәнбер улы да хезмәткә бармаска тиешме? Кайда акыл?

— Ул бит, абзый кеше, бездән тормый. Җибәрмиләр икән, димәк, шулай кирәк тапканнар...

— Кирәк тапканнар...

Галләм, хәлсезләнеп, якындагы урындыкка килеп утырды.

— Кирәк тапканнар дисең инде, мәчтыр? Ә син беләсеңме соң Сабирҗанның бөтендөнья сугышыннан качканын? Әйе, әйе, качты, мәр-

тәт, минем белән солдатка алынгач качты. Ә бу Гитлер белән сугышта нишләде дисең? Тоже качты!

— Авызыңны чамалап ач, Галләметдин. Абзаң дүрт ел буена стройбатта эшләде. Так шту син...

Галләм аңа кул гына селтәде. Фуражкасын алдына салып куеп, Зөбәеровка Сабирҗан белән икесе арасында булган тарихны сөйләп китте. Галләм белән Сабирҗан арасындагы киеренке мөнәсәбәт элек-электән, малай чакларыннан ук килә икән. Икесе ике очта яшәсәләр дә, алар дүрт ел буена авылның бер үк тыңкыш мулласыннан сабак алганнар, шунда бергә аунап үскәннәр.

Ел саен кар ачылып җир кибәр-кипмәс вакытта икесенең дә этисе, чажын таяклары тотып, ызан үлчәргә киткән, үлчәгәндә ни сәбәпледер икесе арасында гел менә гауга чыга торган булган. Бу гауга ике эти арасындагы якалашуга, сугышуга кадәр барып җиткән һәм авыл старостасы килеп яңадан үлчәп, җирнең баш-башларына чөйләр кагып биргәнчегә кадәр дәвам иткән. Ә Сабирҗан белән Галләм шушы чөйләр аркасында бервакытта да тыныша алмаганнар. Җир сукаларга иртәрәк килгән Сабирҗан чөйләрне болар ягына күчереп кага торган булган... Бу явыз уен ике малай үсеп буй җиткәнче диярлек барган. Ундүртенче елгы Герман сугышы чыккан хәбәрне дә Галләм белән Сабирҗан кырда, уракта чакта ишеткәннәр. Кемдер атка атланып кычкырып узган, ызандашлар шунда ук якындагы көлтә чүмәләсе янына килеп утырганнар. Сабирҗанның этисе Нигъмәтҗан кулындагы урагын җиргә атып бәргән дә: «Безгә түгел икән бу икмәк!» — дигән. Галләмнең этисе, еракка, Сагындык елгасы буендагы тауларга текәлеп караган килеш, кайгылы гына әйтеп куйган: «Малы чукынып китсен, менә малайларны алалар». Нигъмәтҗан үз малае турында ник бер аһ корып карасын икән! «Тизрәк җыештырып куярга кирәк бу икмәкне»,— дип, урагын алып, кызу-кызу үз кишәрлегенә китеп барган.

Биш-алты көннән соң Галләм белән Сабирҗанга һәм униҗиде яшькә чыккан тагын берничә егеткә солдатка каралырга язу китереп биргәннәр.

— Китте дип уйлыйсызмы аны хезмәткә? Тот койрыгын! Шул төнне Нигъмәтҗан улы Сабирҗан каядыр юкка чыкты.

Алынып кайтканнан соң ике ай дигәндә без никрутларны солдатка озаттылар. Мин сугышка керер алдыннан авылдан алынган бердәнбер хаттан шуны белдем: әле Сабирҗан һаман табылмаган, малаеның кайда икәнен әйттерергә теләп Нигъмәтҗанны көн саен старостага чакыртканнар, алай да булмагач, авылга урядник китертеп, бөтен җыен алдында Нигъмәтҗанның ыштанын төшереп йөз чыбык суктырганнар. Ә инде улы аркасында җир өлешеннән атасын мәхрүм итүләрне, ахырда хәер сорашырга чыгып китеп картның бер авыл башында туңып үлүе турында мин соңыннан, берничә ел үтеп, гражданнар сугышыннан кайткач кына ишеттем...

Шул китүеннән Сабирҗан авылга егерме биш елдан соң буранлы февраль аенда гына кайткан. Башына чигүле түбәтәй, аягына читек, өстенә буй-буй ситсыдан тегелгән чапан кигән бу кешене Сабирҗанның үз чамасы яшьтәгеләрдән башкалар танымаганнар. Ул үзе дә инде авылның күп кешесен белмәгән. Шул сәер киемнәре белән авыл халкын гаҗәпләндереп, малай-салайны көлдереп, очраган кешеләргә үзбәкчәсен-татарчасын кушып сәлам биргән, ниндидер таныш-белешләрен эзләп өйләргә кергәләгән. Әллә якты чырай бирүче булмаган, әллә урамда суык өшетеп, этләр кузгатып йөрү туйдырган, бераздан соң Сабирҗан бөтенләй чыкмас булган, этисеннән калган җимерек иске өйгә кереп бикләнгән. «Сабирҗан гади кеше генә түгел икән, тегүче, зур һөнәр иясе икән»,— дигән хәбәр таралган. Аның иске, тәбәнәк өе турыннан үткәндә авыл кешеләре кызыксынып машина текелдәвен

тынлап торганнар. Аннан соң тегә торган аяклы машинаның үзен күрү өчен Сабирҗанның өйләренә керә башлаганнар. Тиз арада Сабирҗанның абруе үскән, заказлары күбәйгән...

Боларны Галләм бик җиренә җиткереп, тәмләп сөйләде, кухня тирәсендә игътибарсыз гына йөргән Рәйсә дә түр якка чыгып утырмый булдыра алмады.

— Мин ул елны авыл Советында секретарь булып эшли идем,— дип дәвам итте Галләм.— Безнең күз алдыбызда Сабирҗан кара байга әверелде дә куйды. Алты почмаклы шә-әп йорт салдырды, ишек алдын тутырып каралты-куралар булдырды, көтү-көтү мал асрый башлады. Кем хисабына дисең? Халык хисабына! Авылда тегүче юктан файдаланып биш бәясенә эшли иде бит ул! Кешеләрнең тиреләрен салдыра иде!

Кеше хәтере, күрәсең, күп еллар үтсә дә, яман нәрсәләрне хәтерендә саклый, кичерә алмый. Галләм бу вакыйгаларны ачынып, йөрәге әрнеп сөйли, гүя бу хәлләрне чит кешеме, якыннармы — барысы да белеп торырга, онытмаска тиешләр.

— Бу сугышта минем бердәнбер теләгем — Сабирҗан белән сугышка китү, ана дары исе иснәтү иде. Тик барды дип уйлыйсызмы сез аны сугышка? Юк, Сабирҗан кебекләр ил сакларга бармый! Комиссия буласы көнне генә тап-таза, кырык биш яшьлек Сабирҗан авыруга сабышты да куйды. Бума чире тота башлады үзен...

— Бәлки, аның чире электән булгандыр? — дип, фатир хуҗасын яклагандай әйтеп куйды Рәйсә.

— Соңыннан белделәр. Бума өянәге вакытында әйтеп кычкырган. «Үземне үзем боздым, әгъзамны агуладым, тиле бәрән орлыгы белән аксыргак төеп эчтем»,— дигән. Хезмәт итмәс өчен мена бит нинди этлекләргә бара кешеләр... Хәзер инде калтырап йөри...

Галләм бу хәлләрне Сабирҗан карт белән аның малае Камилне бериш итеп күрсәтү өчен, бер арбага утырган, бер-берсеннән ерак китмәгән кешеләр икәнен расларга тырышып сөйләде, әлбәттә. Ләкин Зөбәеров ата белән улы арасында бик зур аерма, ачыктан-ачык үзгәлек барлыгын күреп тора иде.

— Ләкин бит Камил Сабирҗан түгел,— диде, Галләмнең мисалларына һәм дәгъваларына каршы төшеп.— Камил — чын Совет кешесе...

Галләм кисәк кенә торып басты.

— Мин, аның урынында булсам, добровольно китәр идем армиягә!

— Мин дә шулай итәр идем. Ләкин бит җибәрмиләр аны, аңлыйсынмы, җибәрмиләр!.. Ул үзе минем янга елардай булып килде!..

Галләм башка сүз куертуны кирәк тапмады булса кирәк, фуражкасын киде. Чыкканда Сабирҗанның ишеген ачты да:

— Мена шул, ике көннән соң килеп алырмын, костюм әзер булсын! — диде.

— Соң, тукта әле, кордаш, аңлашыйк әле,— дип, Сабирҗан аңа ялынса да, Галләм сөйләшеп тормады, китте. Ашыгып чыккан тегүче ишекне ачып аның артыннан кычкырды:

— Соң, ичмасам, малаең үлчәтергә килсен!

## 26

Сабирҗаннардан кәефе кырылып, авыр уйлар белән кайтып керде Галләм. Өйдә көндәгечә тынлык, күңелсезлек, шырлык. Булачак солдаты да эштән кайтмаган. И балакай, армиягә китәр алдыннан да тырышып эшләп йөргән була. Шофер. Карангы төнгә кадәр станциягә бәрәңге ташый. Өч улыннан исән калган бердәнбер улы, төпчек улы Галләмнең. Шулай язгандыр инде, Галләм бөтенесен югалтып бетерде: хатынын да, балаларын да. Инде мена өйдә япа-ялгызы кала...

Өйдәге эчпошыргыч тынлыкка түзә алмыйча, Галләм тәрәзә каршына килеп тәмәке кабызды, бакчадагы саргайган шомырт яфракларының тынгысыз җилдә чәбәләнүләрен күзәтеп торды. Көз. Борын-борыннан кешеләр көзне көткәннәр. Язга сокланганнар, җәйне мактаганнар, әмма көзне зарыгып, хыялланып көткәннәр. Үзенә хас моңы, матурлыгы, яме булган өчен түгел, ул алып киләсе байлык, муллык, иминлек өчен көткәннәр көзне. Әүвәл-әүвәлдән кеше хыялын көзгә төбәгән. Уздырасы бәйрәмнәрен дә, ясыйсы туйларын да ул көзгә калдырган. Көз көне кыз ярәшкәннәр, көз көне килен төшкән, көз көне ярминкәләр ачылган, базарлар шаулаган. Хәтта яз чыккан чебешләрне дә көз санарга кирәк, дигән халык.

Башка җирләрдәге кебек үк, Язтургайда да көзне тилмереп көткәннәр. Ярлы-ябагай үзенең ашъяулык кадәре генә җир кисәгеннән иген өмет итеп тә булмагач, я капчык асып хәер эстәргә, я эш эзләп ерак җирләргә сәфәргә чыгып киткән.

Җир кояш тирәсен әйләнеп чыккан саен, теләсә-теләмәсә дә, көз килгән. Иртәләп тә килгән ул, соңлап та. Ачлык булып та килгән, чирүләт булып та, дәһшәтле сугыш булып та. Ләкин кешеләр барыбер көзне көткәннәр. Көз кешеләрнең өмете, уе, хыял канаты булуында дәвам иткән.

Галләм уздырган көзләр дә бер төрле генә булмады. Һәр көз саен, гадәттәгечә, яфраклар саргайды, үләннәр корыды, ачы җилләр исте, салкын яңгырлар яуды, ләкин көзләр һаман да бер-берсенә охшап килмәделәр.

Галләм көзнең төрле вакытларын хәтерли. Икмәк яшереп Рәчәйне ач калдырган кулаклар көзен дә, күмәк хуҗалык булып бер табында уңыш бәйрәмен уздырган тәүге колхоз көзен дә, каты буразналарны тирән һәм ышанычлы сөргән беренче тракторлар көзен дә нык истә тота.

Галләмнәр буыны дәһшәтле 1941 ел көзен дә күңелләреннән җуя алмыйлар. Бомба, снарядлар белән чокылып, окоп, траншеялар белән казылып беткән иген кырларын, тук башакларын җиргә иеп басуларда утырып калган ятим ашлыкларны күреп уздырдылар алар. Хәвефле, сагышлы, хәсрәтле көз иде бу.

Кан коюлы сугыш барды. Ничә көзләр халык ипигә туймады, бөртекләп җыеп алган актык икмәкләрен ил өчен, фронт өчен, җиңү өчен бирде.

Сугыш бетте. Көзләр һаман кешеләргә елмаймады. Буш кырлар, җимерек авыллар, янган йортлар, арык атлар мәшәкате белән тагын әллә ничә көзләр уздырды халык. Уңышның илгә дигәнен бирергә тырышты. Машиналарга төяп тә, атларга салып та, арбалар тартып та илтте ул икмәкне. Үзләренә дигәнен көшел чүпләреннән җыйды, бура төпләреннән кырды, граммнарга салып үлчәде. Шунда да кешеләр өмет, ышаныч, иман белән һаман көзне — икмәкле көзне, тыныч көзне, бәхетле көзне көттеләр.

Менә, ниһаять, килде ул көзләр, чын-чыннан алтын көзләр килде. Юмарт җиребез үзенә йөрәк җылысын, көчен, мәхәббәтен салган кешеләрдән уңышын кызганмады. Басулардан игенчеләр мул уңыш җыеп алдылар, табыннар бай, күркәм ризыклар белән тулды. Язтургай авылы көзне куанычлар белән каршы алды: колхоз сугыштан соң беренче мәртәбә икмәк тапшыру планын арттырып үтәде.

Бу көздә Язтургай кырында яңа вышка — нефть вышкасы утыра. Бу көздә авыл тулы нефть эзләүчеләр һәм Язтургай урамнарын яктырткан электр утлары.

Бу көз Галләм өчен икеләтә ялгызлык алып килгән көз булды. Яз аенда хатыны үлеп тормыш иптәшеннән мәхрүм булды, инде хәзер карап торган бердәнбер улы армиягә китә...

Улы өчен хафаланмый, киресенчә, горурлана Галләм: шулай тиеш. Ир-егет хезмәт итәргә, ил каршындагы мактаулы вазифасын үтәргә бурычлы. Алар нәселе — гомер-гомергә солдат нәселе. Бабалары солдат булган, атасы солдат, өч улы солдат...

Сабирҗан вакыйгасе, аның улы Камилнең колхоздан рөхсәтсезнисез нефть эшенә китеп баруы, инде килеп армиядән калуы яңадан Галләмнең йөрәген тырнап узды. Җитмәсә, шушы мәлне генә авылда электр утлары кабынып китеп, клуб, авыл Советы, колхоз идарәсе белән беррәттән, еракта, тау очындагы Сабирҗаннар өен дә яктыртып җибәрде. «Яши белә бит дөньяда кеше!» — дип төкереп куйды Галләм. Эшкә, колхоз идарәсенә кузгалды.— «Һич урынлы түгел Сабирҗанны яктырту...»

Шушы кичне үк разведчикларның ферма ишек алдына өч машина торба китереп аударганнарын ишетте. Ишетте, ләкин ышанмады. Барып караса, чыннан да, терлекчеләр өе каршында озын-озын торбалар өелеп тора.

— Маладис икән үзе мачтыр, сүзендә торган,— дип куйды.— Димәк, иртәгә фермага су кертә башларга...

Шул ук минутта председатель Галләмнең бораулаучыларга карата булган күптәнге ачуы юып ташлагандай юкка чыкты.

Күңеле хуш килеп, кайтышлый Фәридәгә кереп чыкмакчы булды. Менә ничә айлар инде (хатынының кырыгы да тулмаган иде бугай), Галләм Фәридәгә күз төшереп йөри. Ире үлгән бер балалы хатын. Үрдәк Дәүләтбай килене. Төскә-биткә чибәр. Эшкә уңган. Тик шунысы бар — яшь. Хәтта кирәгеннән артык яшь. Аңа сүз салып караса, «бабай» дип көлмәс микән Фәридә? Ир-атка карата үзен бик усал тота дип сөйлиләр, табагач белән пышкыртып чыгармас микән өеннән? Әйдә, ни булса шул, сөйләшеп карарга кирәк. Яшең илледән узгач, буйдак булып йөреп булмас, тәкъдим ясап карарга кирәк... Син дә ялгыз, Фәридә, мин дә ялгыз, дияргә кирәк. Малайның бүген-иртәгә солдатка китәсен дә әйтергә кирәк, өем зур, иркен, әйдә бергә торыйк, дияргә кирәк... Юк, бергә торыйк дип әйтү килешеп бетмәс. Фатирда гына бергә торалар. Хатыным бул, кызыңны рәнҗетмәм, үз балам кебек итеп тотармын, дип әйтергә кирәк.

Иман укыгандай авыз эченнән мыгырдана-мыгырдана, әкрен генә тыкрыкка борылды Галләм, елгага таба төшеп китте.

Килеп җитәрәк, Фәридә өендә электр уты күреп туктап калды.

— Нәрсә булып чыкты соң әле бу? Шул умарта оясына да бораулаучылар фатир кергәннәрме?

Аяк очларына гына басып, тәрәзә янына килде. Бер кырые ябылып бетмәгән пәрдә почмагыннан өстәл янына утырган Фәридәнең түгәрәк бите күренеп тора иде. Фәридә чәй эчә, елмая. Кем белән чәй эчә ул, кемгә елмая?

Ничаклы гына тырышып караса да, Фәридәнең кызарып чыккан битеннән, киң итеп елмайган авызыннан башканы күрә алмады Галләм.

— Нигә болай кояшы балкыган соң әле бу хатынның? Нәрсәгә дип шул кадәр авыз ера?

Каракларча сак атлап, капкага якынлашты. Галләмнең күпне күреп таушала башлаган йөрәге түзмәде, үзен сиздереп дөп-төп тибәргә тотынды. Кара син аны, каһәр, чаптар ат кебек ярсый бит... Егет чакларны, шушылай яшеренеп кенә Миңлебикәсен күзләргә килгән вакытларны искә төшерде бу йөрәк... Егерме биш елдан соң да бер чама тибә икән үзе. Юк, картаймаган икән әле Галләм...

Ишек алдына караган ике тәрәзәнең иксендә дә пәрдә төшерелмәгән иде. Шунда ук түбәтәйле кабак баш чалынып китте Галләмнең күзенә. Кабак баш табыннан торып килә. Бу бит шул үзе, комбайн

янына килгән кабак баш! Әйе, аңлашыла... Тикмәгә генә Фәридә янына барып йөрмәгән икән...

Галләм, өметләре челпәрәмә килеп, капка төбендә бераз басып торды да, кыйналган кеше кебек аякларын көчкә сөйрәп, тыкрыктан менеп китте.

— Шулай була инде ул алданрак тәвәккәлләмәгәч...

Менә сизденме инде картлыгыңны, Галләм?..

## 27

«Йорт салуның ние бар — мүклисе дә чутлыйсы»,— дип, борынгылар тикмәгә генә әйтмәгәннәр. Беренче көндә үк нигез бүрәнәләрен салып, эшкә бик жинел генә керешеп киткән Мотгәрәй өчен бура биеккәрәк күтәрелгән саен авырлаша барды. Балта тота белүчесе димә инде, ботак юынганда яки каеры каезлаганда агачны әйләндереп торучысы, я күтәреп куйганда бүрәнә башын тотучысы булсын иде аның. Япа-ялгыз йорт тергезергә кереште бит, җүләр.

Үткәндә-сүткәндә туктап, кешеләр дә гаҗәпләнеп китәләр: «Фәридә оста яллаган яллавын да, эше бик сүлпән бара. Тапмады микәнни адәм рәтлерәк балта остасын?»

Мотгәрәйнең башы-аягы белән чумып бура бурап ятуын бораулаучылардан беренче булып Сапарбай күреп кайтты. Кадермәт үз йомышы белән район үзәгенә киткәч, аның урынына вахтага Мотгәрәйне чакыртырга җибәргән иде мастер.

— Ба-а, адәмнәр вакытларын заяга уздырмыйлар гой! — дип, кулында балта уйнатып эшләүче Мотгәрәйгә исе китеп карап торды Сапарбай.— Бак, нинди җакшы тирмә корып ята!

— Буш арада маташкан булам. Ничек уздырмак кирәк көнне?

— Син тик тора алмыйсың инде, улсы мәгълүм. Ә сәмән ягы ничек соң, күпме түлиләр?

Мотгәрәй балтасын бүкәнгә чабып куйды да, нәрсә дип җавап бирергә дә белмичә, аптырабрак калды. Бик рәнжетте Сапарбайның бу сүзе.

— Син, энем Сапарбай, мине үз аршының белән үлчәмә инде! — диде.— Акчаны калымга жыясым юк, бездә кызны сатып алмыйлар!

Балта астыннан очкан йомычкалар чәчрәп туп-туры Сапарбайның битенә бәрелә башлагач, казакъ егете йомышын әйтте дә китеп барды.

Сапарбайны да рәнжетте Мотгәрәйнең сүзе. Ул бит инде калым жыюны күптән ташлады. Мотгәрәй үзе дә белеп тора лабаса моны. Әллә ял вакытында Кәримә янына барырга жыйган акчаны әйтәме ул?

Нефть чыгып ял алса, Сапарбайның Ык буйларына барып кайтырга да исәбе юк түгел... Их, шул татар кызын кулга төшерә алса Сапарбай!.. Юри генә хат яза торгандыр ла ул Сапарбайга...

Вахтадан бушагач, Мотгәрәйнең бура буравын үз күзләре белән күрү өчен икенче көнне Фәрхетдин килде. Сапарбай кайтып сөйләгән иде: имеш, Мотгәрәйдә буровой кайгысы түгел, эше тыгыз, фатир хуҗасына патша сарае зурлыгында тирмә кора.

Мотгәрәй ишек башына кадәр күтәрелгән бура өстендә осталанып ята иде. Фәрхетдинне күргәч каушады, янтыгына без белән төрткәндәй, бөгелеп төште. «Көлке эзләп йөри, имансыз,— дип уйлап алды.— Кайтып берәр нәрсә чыгара инде хәзер». Әнә бит житди кешедәй кыланып, әдәпле генә сорашкан да була, житмәсә: «Ничек әле мондый зур эшкә тотынырга җөрьәт иттең? Шул инде, аңлыйм, тик тора алмыйсың. Әйе, тик торулар яман нәрсә...» Ә күзләре үзенең! Май ашаган мәчемени — бура тирәсендә йомычка җыеп йөргән Фәридәдә. Ул өйгә кереп киткәч, чишелеп китте Фәрхетдин:

— Өй хуҗасы ялгыз хатын дип әйтәләр, дөресме? Әйе, мондый күркәм хатын булганда нәрсә тора һөнәр белгән кешегә өй салып бирү... Шәт, буш итмәс, тамак ялына түгелдер...

Теленә тилчә чыккан Фәрхетдин белән сүзгә килүдән файда юк, ул барыбер үзенекен лыгырдаячак. Шуңа күрә Мотгәрәй сүзсез генә агачны киртләвен белде.

Буровойда аның ниләр сөйлисен пошынып юравы дөрес булып чыкты Мотгәрәйнең.

— Яңалык ишетәсегез киләме, җәмәгать! — дип кычкырды ул, вахтага килү белән.— Безнең Мотгәрәй бит йортка кергән!

— Йортка кергән?

— Чынмы?

— Үзе әйттеме?

— Соң, башыгыз булса уйлап карагыз, хозяйкасы яшь, чибәр һәм тулы тәнле. Бу булдымы бер. Икенчедән, ирсез. Янәдән килеп, умарта кадәр өйдә икәүдән-икәү. Бусы булдымы өч. Дүртенчедән, ни өчен Мотгәрәй газиз йокыларын калдырып, буровойдан арып кайтканнан соң да өй сала дип уйлыйсыз? Эх, мисезләр!..

— Сөйләмә, аның рәхмәткә эшләп йөрүе бер бүген генәмени!

— Менә күрерсез, башымны кисәргә бирәм, Мотгәрәй кала бу авылда йортка кереп! Тик шунысы бар: «Йортка кергәнче утка кер», дигәннәр...

Фәридә исә, эштән кайтып кергән саен, бер-ике бүрәнә күтәрелә барган бураны күреп исе китә, аңа куанып бетә алмый иде. Куана һәм шул ук вакытта баш күтәрми эшләүче Мотгәрәйне битәрли:

— Шушы кадәр җәфаланырга ярыймы соң! Ташла! Ташла! Әйдә, керик әле. Ачыгып беткәнсең инде, канатым! Куй балтаңны, җитәр бүгенгә, каурыем!..

Буровойдан бик талчыгып кайтса да, сер бирми Мотгәрәй, янында ана каз кебек кыйгаклап йөргән Фәридәнең авызын бөрә төшеп тагын бер-ике тапкыр «каурыем», «канатым» дип әйткәнен, хәтта соңгы вакытлардагы кебек батырланып, кулдан тотып алуын да көтә. Ә Фәридәнең кулы йомшак, иркә...

Тарткалаша-тарткалаша өйгә керәләр. Юл уңаеннан каенанасыннан алып кайткан кечкенә Фатыйманы караватына куеп, ашыга-ашыга чәй хәстәрләргә керешә Фәридә. Хәзер инде бала да элеккеге кебек Мотгәрәйне күргән саен куркып еламый — әнисенеке кебек зур соры күзләрен бер дә алмыйча, кызыл йөзле, табак битле абыйсына карап кына тора. Ник еласын — Мотгәрәй абыйсы ике көн элек кенә аңа кибеттән сары түшле, зәңгәр койрыклы бик матур чыпчык алып кайтып бирде. Борсаң өстәл өстендә чыкы-чыкы килеп йөри. Аннан алдарак төймә күзле куян, корсагына баскан саен «бак-бак» итеп кычкыра торган үрдәк бүләк итеп бирде.

Инде бүген аның ике як кесәсе тулы кызыл, зәңгәр кәгазьле конфетлар. Учлап-учлап Фатыймага да бирә ул аны, Фатыйманың әнисенә дә, өстәлгә дә күп итеп сала. Нигә еласын Фатыйма, акыллы бит ул, үскән кыз бит ул...

Тик вакыт-вакыт Фатыйма да көйсезләнеп куя. Караватта утырмыйча, кич буена әнисенең итәгенә тагылып йөри, ятканда әнисе янына сорый.

— Нинди кыргый баладыр бу! — дип тирги аннан кызын Фәридә.— Чыгып качаммыни: төн буе итәккә тотынып ята!..

Бәләкәй Фатыйма гына түгел, Фәридә үзе дә Мотгәрәйгә шактый гына ияләшә төште кебек. Элегрәк беренче көннәрдә Мотгәрәй белән табынга утырса, авызы ояла төсле иде Фәридәнең. Шуңа күрә йөрәгенә ятып туйганчы ашаганы да булмады, эшкә баргач, тамак ялгый иде.

Ятканда күлмәк салырга читенсенеп, ай буена чаршау артында чишенмичә йоклады. Иртән торып бит-кул юа башласа да, чәч тарарга тотынса да, Мотгәрәйдән яшереп, кача-поса гына эшли иде.
Хәзер алай түгел, ул өйдә үзен бик иркен тота, бер хәвефсез ялан баш, җиңсез күлмәктән йөри, кыю сөйләшә, көлә, елмая. «Бер өйрәнгәч, тфу, тфу, чит ир-ат та күнелгә якын була икән...»
Соңгы атналарда Фәридәнең яшь кызлар кебек очынып-очынып йөрүен Мотгәрәй һаман да шул бура бурала башлаудан күрә иде. Сөенечен кая куярга белми бичара хатын. Элек табынга да урындыгын этеп, ераклашып утырган Фәридә хәзер Мотгәрәй янына ук сыена, бөтен ризыкны аның алдына өя, бөтен ягымлылыгын, нәзакәтлелеген биреп сыйлый. Шунда самоварга яки чәшкә-чынаякларга үрелгән вакытта кайчагында Мотгәрәйгә Фәридәнең юан беләкләре орынып китә.
Бүген Фәридәнең кәефе аеруча яхшы иде. Үзе мич алдында табада нәрсәдер чаж-чож кыздыра, үзе уенчыклары белән уйнап утырган кызы белән сөйләшкән була:
— Менә шулай инде без, кызым. Үзебез йорт эшләтәбез синең белән, ә останың әле ашаганы да юк. Оятсыз хуҗалар инде без, тәмам вөҗдансыз хуҗалар. Боерган булса, без дә тырышырбыз әле, яхшы абыйга бурычлы булып калмабыз, әйе бит, кызым?
Табынга төрле нигъмәтләр килеп беткәч, һич уйламаганда, Фәридә ярты литр аракы чыгарып куйды.
— Нигә инде, Фәридә?
— Син теләсә ни диген, Мотгәрәй канатым, монсыз булмый.
— Юкка мәшәкатьләнәсең бит.— Мотгәрәй йөзенә ризасызлык һәм үпкә билгесе чыгарды. Моны сизеп Фәридә сүзне шаяртуга борды:
— Электән килгән йола. Яхшы итеп эшләсен өчен останы шулай сыйлыйлар.
— Болай сыйлый башласаң, мин аны ун елга сузармын!
— Ун ел тормассың шул.— Фәридә үзе дә сизмәстән көрсенеп алды.— Нефтькә житеп киләбез дисең түгелме соң?
Мотгәрәй җавап бирмәде. Әйе, разведчиклар нефтькә җитеп киләләр. Мотгәрәйнең дә монда актык көннәре, актык буровое булыр, ахры. Бүтән эшләмәс инде ул разведкада. Башка бер җиргә китәр, кызыклырак башка эшкә күчәр... Я комбайнына кайтыр, я төзелешкә... Тик менә тәмамланмаган бурасы кала, аны ничек ташлар? Бераз гына нефть чыкмый торса да, өйле итәр иде Фәридәне...
— Я, салып эч әле, Мотгәрәй,— диде Фәридә, егетнең нәрсә турындадыр тирән уйланып китүен күргәч.
— Алайса, икәү, булдымы?..
— Минем бер дә эчкәнем юк бит, канатым.
— Эчмәсәң эчеп кара! Өйне тизрәк өлгертик дисең икән — салып бетерәсең шушы стаканны...
Мотгәрәй шешәне ике стаканга тутырып аударды да берсен Фәридәгә тоттырды.
— Өлгергән өйгә кереп утырырга язсын!
Мотгәрәй стаканындагы аракыны ялт иттереп каплады да ашыгып ашамлыкка үрелде, Фәридә исә, авызына ут капкандай, су эчәргә йөгерде.
— Уф, уф, үләм!..
Бераздан барысы да үз урынына утырды. Фәридә сүзчәнләнеп китте:
— Син йорт дисең, Мотгәрәй канатым. Уйлап кара: тормышында бәхетең, киләчәккә өметең булмагач, нәрсәгә кирәк соң ул йорт? Аның нинди шатлыгы, нинди куанычы бар минем өчен? Мин аны, Мотгәрәй кауреем, беләсең килсә, әллә кайчан салдырып куя идем. Аннык кына рәтем дә бар минем. Тик син кулым кычыта, фәлән-төгән дип сорагач, ярар инде, кашысын бу кулын, дип кенә риза булдым... Ярый, алай

гайрәтен булгач, һөнәрсез тора алмагач, күңелең туйганчы эшлә инде, бизгәч ташларсың. Утырсын ул шунда төгәлләнмәгән бура булып ишек алдында. Син китәрсең, онытырсың безне, ә ул синең истәлегең булып калыр...

Күрәсең, Фәридәнең күңеленә җыелган уйлары бик күп, әйтер сүзләре бихисап булган, хәзер терсәкләре белән өстәлгә таянган хәлдә, караңгы тәрәзәгә караган килеш, шул уйларын, шул сүзләрен әкрен генә, агымлы итеп кенә тезә:

— Миңа нәрсә? Ничек тә кызымны,— ул караватта уенчыклары белән йоклап киткән Фатыймага карап алды,— шушы тәбәнәк мунчада үстерермен дә очырып җибәрермен. Аннан нәрсә? Аннан кереп бикләнермен дә яшәрмен үлгәнче моңаеп берүзем... Шул инде ул ялгыз хатынның язмышы, канатым...

— Син төшенкелеккә бирелмә әле, Фәридә.

— Бирелеп торасы юк, каурыем. Ул инде безнең маңгаебызга язылган. Бәхетле кеше бала белән яшьли иреннән калмый!..

Фәридә, өстәлгә ятып, сулкылдап елый башлады.

Мотгәрәй каушады, аны ничек юатырга белмичә, урыныннан торып, ишекле-түрле йөреп килде, ник эчерткәненә үкенде.

— Менә син, ә? Юкка кыстадым бит эчәргә... Ярый әле, бала йоклаган, анысы да елый башласа, ни эшләр идең?

Фәридә бераздан тынычланды, бер-ике тапкыр мышкылдап борынын тартып алды да, утырган урынында кулларына башын куйган килеш, йоклап китте.

Моңа кадәр исерек хатыннарны күргәне юк иде Мотгәрәйнең. Алар турында әшәке фикерләр генә ишеткәне бар иде. Менә хәзер аның янында, янәшәсендә исерек хатын сабый бала кебек йоклап утыра. Ләкин гаҗәп: Мотгәрәй аңарда бернинди ямьсезлек күрми. Киресенчә, язмышын аның моңаеп сөйләве, чын күңелдән ачынып елавы Мотгәрәйдә Фәридәгә карата теләктәшлек һәм кызгану гына тудыра иде.

Уятмакчы булып карады Фәридәне Мотгәрәй, тик ул шул кадәр каты йоклап киткән иде — селкенмәде дә.

— Инде ни эшләргә? — дип аптырап, өй эченә күз йөртеп чыкканнан соң, «урынына илтеп яткырырга кирәк» дигән карарга килде Мотгәрәй...

...Иртән алар бер үк вакытта уянып киттеләр. Фәридә башта чаршау артында каты көрсенеп, уфылдап ятты. Торды, Мотгәрәйгә күренергә оялып, чыгарга кыймыйча, озак кына ятагын җыештырып, түшәк-мендәрләрен каккалап йөрде.

Бу вакытта инде Мотгәрәй киенгән, кулына балтасын алып ишек алдына чыгарга җыенган иде.

— Әллә баш авыртамы, Фәридә? — дип, үтә дә якын һәм назлы итеп сорады ул ишек тоткасына тотынгач.

— Уф аллам, ничекләр генә күзеңә күреним, Мотгәрәй! Оятлы булдым бит...

— Ничава, тормыш булгач була инде...

— Тиеш түгел иде дә бит... Кире кайтарып булмый...

Баласын илтергә, эшкә барырга вакыты җиткән, ә Фәридә әле һаман чаршау артыннан чыга алмый.

— И-и, ходаем, нишләгәнмен мин? Син күтәреп салдыңмы мине караватка?

— Күтәрергә бик авыр идең, култыклап кына илттем...

— Бар икән күрәселәрем! Изүемне дә син чиштеңме? — диде, күкрәкләрен каплаштырып.

— Буыла иден ич, чишмәсәм...

Ана уңайсызламас өчен Мотгәрәй чыгып китте, ләкин Фәридәнең күңеле моның белән генә тынычланмады. Берсеннән-берсе ямьсезрәк уйлар килде аның башына. Бик тә начар итте бит аракы эчеп. Нинди генә шайтаннар котыртты икән бу эшкә? Шайтан түгел инде, әнә шул сүз — бораулаучылар тиздән китәчәкләр икән дигән хәбәр. Соңгы көннәрдә генә булса да, Мотгәрәй останы бәхиллетәсе килде Фәридәнең. Аның өчен микән? Ник шунда череп ятмый бурасы, үзе әйбәт кеше Мотгәрәй. Өендә ир-ат булу, аның исен тоеп тору да рәхәт бит. «Ир-атлы йортка җен иләшмәс»,— дип белеп әйткәннәр борынгылар. Ул китеп барса, эч пошудан, ялгызлыктан ни эшләр инде Фәридә?..

Кичә шулай да арттырыбрак җибәрде. Ирсез хатын — йөгәнсез ат шул инде, моңая торгач исерелеп тә киткән. Гомер эченә бер генә мәртәбә анысы да хәрам булмас иде дә, тик менә Мотгәрәйнең.күйләп-яткырып йөрүләре күңелне тырный. Ходаем, карап, капшап бетергәндер инде бөтен җиремне...

Фәридә эшкә әнә шундый чуар, тынгысыз уйлар белән китте.

Кинәт кызы авырып, башына уй-хәсрәт төшмәсә, белмим, Мотгәрәйдән күпмегә кадәр оялып, үзен-үзе битәрләп йөргән булыр иде икән Фәридә. Көннәрдән бер көнне ул баласын каенаналарыннан ут кебек янган хәлдә алып кайтты.

— И балам, бәгърем, күз нурым, ниләр генә булды икән сиңа? — дип, өйгә такмаклап елап керде Фәридә.

— Бар да кеше кулында бала үстерер иде, карамаганнардыр, ялан аяк йөрткәннәрдер, салкын тидергәннәрдер, бәхетле кешенең баласы үз янында тора,— дип, һаман ямьшын каргады, каенанасын, каенатасын тиргәде.

Кечкенә Фатыйманы кулына алып градусник куеп карады Мотгәрәй. Кызның температурасы кырыкка җиткән иде.

— Ни эшләргә соң? Нәрсә эшләп карарга?

Фәридә белән Мотгәрәй икесе берьюлы караватка килеп утырдылар. Уртак хәсрәтне берләштереп, авыру бала икесенең тез өстендә калды.

— Температура төшерә торган берәр даруың бармы? — дип сорады Мотгәрәй шыпырт кына.

— Юк шул. Әллә им-томчы карчыкны чакырыйм микән?

— Булмаганны! Мин тиз генә Рәйсәне алып килим!

Мотгәрәй өстенә плащын элеп чыгып китте.

Октябрь башларында бу якларда таралган грипп эпидемиясе, салкын җилләр, яңгырлар белән бергә, тыныч Язтургайга да килеп җитте. Әүвәле район үзәгенә эш белән барып йөрүчеләр, кунактан, базардан кайткан кешеләр чирләделәр, аннан семьялары, туганнары, тора-бара күршеләре, бергә эшләгән иптәшләре авырый башлады.

Моңарчы күрелмәгән үзенә бер төрле мәкерле грипп иде бу. Кеше бер-ике көн томаулап, кәефсезләнеп йөри дә югары температура белән кинәт түшәккә егыла. Башы әйләнә, тирә-як йота алмаслык булып тамагы шешә, колаклары ишетмәс була. Шулай бер атналар интеккәннең соңында авыру торып йөри башлый, сәламәтләнеп эшкә китә, ә кичкә таба ул аннан үле-мәлле кайтып керә, яңадан урынга ава. Монысында грипп аның йөрәгенә дә бәргән, үпкәсенә дә тигән була. Чит ил туристлары алып килгән бик усал, куркыныч грипп дип яздылар ул хакта.

Рәйсә көндезләрен медпунктка тоташ агылып торган авыруларны кабул итү белән мәшгуль булса, иртә-кичләрен аларның өйләренә барып дәвалап йөрде.

Төн йокысы да аз эләгә башлады. Кайтып ятуы була — ишек шакыйлар. «Духтыр, фәлән кеше бик авыр хәлдә, барып күренә алмассың микән?» «Рәйсә кызым, улыбыз чирли, баш даруыңны гына биреп җибәрә алмассың микән?» Авырулар көтеп, әшсез тилмереп утырган август көннәрен искә төшереп куя иде шунда Рәйсә.

Мона кадәр медикларны «ак сөякләр» дип үртәп йөргән Зөбәеров та, йокысын бүлеп, төннең теләсә кайвакытында ашыгыч ярдәмгә киткән хатынын кызганып кала.

— Синең эш минем буровойдан да көйсезрәк икән.

— Түз инде, Фазыл, түз. Мондый хәлләр еш булып тормас.

— Мин ничек тә түзәрмен, тик чир ияртеп кайта күрмә! Харап итәсең син аннан безне! Мине түгел, буровойны егасың!

— Чыннан да, гриппка каршы укол бирим әле, алайса, сиңа!

Рәйсә, бик мөһим нәрсәне исенә төшергәндәй, ашыгып-ашыгып шприцларны хәзерли башлады.

— Кит, булмаганны! Гомеремдә укол кадатканым юк!

— Калтырама, калтырама! Күтәр әле күлмәгеңне! Мин моны сиңа ирем буларак блат белән генә бирәм!

— Тәнгә энә — ярыйсы блат!

Рәйсә көлә-көлә Фазылның күлмәген күтәрде, тегесе күзләрен чытырдатып йомды.

— Тик син әкренрәк... ипләбрәк...

Дөрестән дә, шушы яшенә җитеп Зөбәеровның авырганы да, укол кадатканы да булмады. Тәненә энә тиюгә үк сискәнеп китте, акырып җибәрде.

— Үтерәсең!

— Эх, син, буровик! Бу уколны авылда күпме кешегә салдым, балалар булып балалар түзде!

— Билләһи, кансыз да халык инде бу медиклар,— дип зарланып ыңгырашты Фазыл.— Кеше тиресен сугымчы урынына туныйлар!..

— Теләсәң нәрсә диген, тик иртәгә үк барлык эшчеләреңне укол алырга медпунктка җибәрәсең.

— Минем батырлар да чирләр дисеңме? Алар андый токымнан түгел...

— Тикшерә ул вирус синең токымыңны! Әгәр бораулаучыларыңны исән-сау саклыйм дисәң — менә шул.

Ишек шакыдылар.

— Башланды! — диде Зөбәеров, көрсенеп.— Па аллам, кайчан бетә инде бу вирусларың?

Авыру урынына өйгә Мотгәрәй килеп кергәч, Зөбәеров аптырап китте.

— Нәрсә бар, Мотгәрәй, әллә буровойда...

— Мин Рәйсә янына,— диде Мотгәрәй, төшенке тавыш белән.— Фәриданең кызы авырый, минем фатир хуҗасының.

— Температурасы бармы?

— Ут кебек яна.

Рәйсә киенә башлады.

— Син ерак торасың бугай?

— Түбән очта, елга буенда.

— Якын тирәдән тапмагансың икән фатирны.

— Шулай туры килде инде...

Фәридәләрдән кайткач, башка вакыттагы кебек, авыруны түгел, ни өчендер Мотгәрәйне уйлады Рәйсә.

— Бигрәк кысан фатирда тора икән, бичара,— диде Зөбәеровка зарланып.— Утырсаң утырыр, ятсаң ятар урыны юк. Тапмадыгызмыни аңа бирәр җүнлерәк урын? Һич кайгыртмыйсың бит кешене, Фазыл.

— Үзе белә торгандыр әле,— Зөбәеров Фәрхетдиннең «Мотгәрәй йортка кергән икән» дигән сүзләрен искә төшереп көлеп алды.

— Ул синнән-миннән сорап тормый...

Хәер, «күңелең киң булса, тар җиргә дә сыясың» дигәннәр бит. Менә Рәйсәләр фатиры иркен дә бит, аның каравы, хуҗаның көннәр буе мыгырданып йөргәнен ишетәсең. Ә Мотгәрәйнең фатир хуҗасы бик ачык, бик мөлаем күренә...

Хатын-кызларда гына була торган яшерен кызыксыну Рәйсәдә тагын шуны да ачты: Мотгәрәй белән Фәридә арасында ниндидер якынлык бар. Бала язмышы өчен борчылуларында да, үзара сөйләшүләрендә дә, хәтта күз карашларында да сизелә ул якынлык.

Йортка килеп кергән ил кизүе Мотгәрәйне дә читләтмәде. Кечкенә кыз терелеп аякка баскан көннәрдә ул төнге вахтадан бик нык өшеп, башы авыртып кайтты да, чәй дә эчмичә, урынына барып ятты. Ярты сәгатьләр тәненә йөгергән калтырауны баса алмыйча интекте. Аннан кинәт кенә җылынып китте, өстен ачып ташлады, торып утырды. Хәзер инде аның сулышларына кадәр кайнар иде.

Мотгәрәйнең борсаланып ятуын Фәридә дә сизде.

— Суык булса, энә, юрганны алып ябын,— диде, йокы аралаш кына. Эштән өшеп кайткан дип уйлый иде ул.

— Кызу... Эссе. Ишекне ачсам, ничек булыр икән?..

Егетнең хәле шәптән түгеллеге карлыккан тавышыннан ук беленеп тора иде. Фәридә торып ут алды, Мотгәрәй янына килеп аның маңгаена сак кына кулын тидерде.

— И-и, канатым, янып чыккансың ич! — Фәридә учы белән изүләрен каплап, кая барып тотынырга белмичә, почмакта уталанып йөрде.— Фатыймадан калган дару бар иде, бирим әле булмаса...

— Кирәкми, үтәр әле.

— Эчәсең, эчәсең! Бу авыру кечкенә кызның бүләге инде... Яныннан да китми йөрдең бит...

Кыстый-кыстый каптыргач, ачы булса да йотты даруны Мотгәрәй.

Фәридә аңа үз караватында урын йомшартты.

— Син монда ятарсың. Юк, юк, киреләнмә дә, тыңламыйм да! Авыру кеше идәндә ауnarга тиеш түгел, карышма дип әйтәм мин сиңа. Кара, нинди тискәре икәнсең!.. Яле, тор!..

Мотгәрәйне кайнар кулыннан тотып караватъ янына илтте. Җайлап кына калын мамык юрган белән өстен ябып яткырды, үзе шунда караватъ читенә утырып, егетнең маңгаена кулын куйды.

Фәридәнең кулын тою Мотгәрәй өчен бернинди сүз белән дә әйтеп бирә алмаслык рәхәт иде.

— Утыр әле бераз, Фәридә, китмә әле...

Баш авыртуы басыла төште, ләкин Фәридәне һич кенә дә яныннан җибәрәсе килмәде Мотгәрәйнең. Фәридә менә шулай йомшак, салкынча кулы белән маңгаен тотып, иркәләп утырса, озаграк чирләргә дә риза булыр иде Мотгәрәй...

Өйгә врач чакырмады Фәридә. «Мин сине үземчә дәвалап карыйм әле»,— дип, чоланнан печән вакытында әзерләп куйган мәтрүшкәсен алып кереп кайнатты, кипкән карлыган һәм кура җиләгеннән чәй ясады. Борыннарны кытыклап өйгә чәчкә исе, үлән исе, болын исе таралды — әйтерсең Фәридә Мотгәрәйгә җәй алып килде.

— Әле дә син бар әле, Фәридә. Юкса, берүзем ни эшләр идем! — дип сөенде егет.

«Иртәгә Ромашкинода яшь нефтьчеләрнең республика слеты була, иртәнге тугыздан да калмыйча буровойдан ике делегат килергә тиеш»,— дип әйтеп җибәрделәр Зөбәеровка конторадан.— «Яшь мастер булырак, берсенә үзең барасың, икенчесен карагыз. Тик комсомол яшеннән чыккан булмасын».

Эш комсомол яшенә генә терәлеп калса икән! Утыз биш тулып узган Кадерматтән һәм утыз яшьлек буйдак Мотгәрәйдән башкалары барысы да эбер-чебер. Менә бүген-иртәгә скважинадан нефть бәреп чыгам дип тора, мондый чакта эшләп утырган буровоеннан кешене алып җибәрү, житмәсә, аның белән бергә үзең китеп бару — бу инде пычаксыз сую белән бер.

Конторада да кыр талашты Зөбәеров. Аңлатырга, төшендерергә тырышып комсомол секретарена да, партоешма секретарена да, директорга да керде, ләкин тегеләрнең туксаннары туксан: «Делегатлар бер синнән генә килми, җибәрәсең булгач җибәрәсең».

Бик тәжел йомышы төшмәсә, бу көннәрдә Зөбәеров үзе дә тегендәмонда китеп йөрми, бөтен вакытын диярлек скважинада уздыра иде. Бораy янадан проектта күрсәтелгән тирәнлеккә житә. Бик сак булырга кирәк хәзер мастерга.

Шушындый чакта Ибраһим-Задәне күргәне бар иде мастерның. Нефть чыгар алдыннан тәүлекләр буе скважинадан кайтмый ятар иде карт мастер. Йокыдан, ашаудан калыр, ябыгыр, йөзен кара сакал басар. «Забойга житү ул — яшь ананың бала көтүе белән бер,— дип сөйләнә иде Ибраһим-Задә.— Куркасың, хәвефләнәсең, шул ук вакытта эчке бер куаныч та була синдә».

Яшь ана кичерешләрен түгел, үз хисләренең дә ни икәнен белмәгән студент-практик өчен әкәмәт кызык тоелган иде Ибраһим-Задәнең бу сүзе. Сорыйсы бар әле Рәйсәдән: Ләләне китергәндә ул нинди хис кичерде икән?

Буровойга килү белән туп-туры Валентин янына атлады Зөбәеров, буровой гөрелтесен басарга тырышып кычкырды:

— Ну, ничек, Тин-Тиныч?

— Әлегә ул-бу күренми.

Валентин тормоз рычагын әкрен генә төшереп, җир астындагы бораyга басым бирә. Соңгы сәгатьтә генә бораy каты доломит катлавын үтеп продуктлы горизонтка — йомшак комташка килеп керде.

Зөбәеров тын гына Валентин янында басып тора да, аның йөзендә үзгәреш күрмәгәч, улак янына китеп, скважина төбеннән су белән юылып чыккан тау токымын иснәп карый. Тирәннән нефть сеңгән комташ килә. Әйе, бүген булмаса иртәгә фонтан атуы бар. Мондый чакта буровойны ташлап китү ярыймы соң?

Зөбәеров, иртәгә булачак слет турында бораулаучыларга бер сүз дә әйтмичә, будкага кереп китте. Янадан ялынып-гозерләп сорады телефоннан: шундый-шундый хәл, нефть исе борынга бәреп тора, мине генә булса да калдырыгыз буровойда, диде. Якын да килми директор: «Син бердәнбер яшь мастер, карап торган алдынгыбыз. Киләсең. Урынына Имаметдиновны калдыр. Үзең белән бик шәп бер егетеңне дә алып киләсең. Сүз бетте».

Бораулаучылар слет турындагы хәбәрне ура кычкырып каршы алдылар:

— Барабыз!

— Китәбез!

— Кайчан?

Зөбәеровның ачуы чыкты:

— Нәрсә бугаз ертасыз! Слет ул сиңа арминкә түгел! Анда баргач тәҗрибә уртаклашырга, трибунага чыгып сөйләргә, бригаданың унай һәм кире якларын күрсәтергә кирәк. Слет ул, турысын гына әйткәндә, нефтьчеләр съезды. Ә съездга теләсә кемне җибәрмиләр!

— Хәтәр икән! — дип куйды Фәрхетдин, өметсезләнеп.

— Мин тагын барыбызны бергә җыеп сыйларга чамалыйлар дип торам. Шулай мин хезмәттә чакта...

— Ташла әле хезмәтенне! — дип бүлдерде аны мастер.— Менә син шуны әйт: бригададан слетка ике кеше китә. Эшли алырбызмы алардан башка?

— И-и, җаным мастер! — диде Фәрхетдин.— Мин хезмәттә чакта бер ефрейтор бар иде. Ничек әле исеме, аты коргыры?.. Шуны демобилизовать итәләр. Кайгыра инде менә!.. Ах та вах килә: китәм бит инде, ди, мин киткәч, ни эшләрсез инде сез, бичаралар, тәртип бетәр инде армиядә, дип елый. «Армия таралмаса ярар инде»,— дип, ул без кайгырган булабыз!..

— Моның белән нәрсә әйтмәкче буласың?

— Билләһи дип әйтәм, шушы верховой бишегеннән бәреп төшерегез мине, аңа карап буровой туктап калмаячак! Алып ыргытыгыз Тин-Тинычны тормоз янынннан — буровой үкереп эшләп торачак! Без булмасак, мастер җаным, икенчеләре табыла аның, бездән дә шәбрәкләре!

— Фу, телең коргыры! — дип, җиргә төкерде Зөбәеров,— эш синдә-миндә түгел, аңлыйсыңмы? Нефть чыгып куйса, ни эшләрбез?

— Чыксын иде әле ул нефть, белер идек ни эшләтергә!

— Алайса, менә шул: берсенә үзем барам. Контрадан шулай куштылар. Урыныма Кадермәт кала. Икенчесенә кемне җибәрәбез?

Сапарбай суыкта күшеккән борынын сөртә-сөртә алга чыкты:

— Фәрхетдиннән дә кулай кеше булмас, юлдашлар. Теле телгә йокмый, сөйләсен бер рәхәтләнеп трибунадан.

— Дөрес! — дип хупладылар бораулаучылар аның тәкъдимен.

— Барсын, ул бөтенебез өчен дә сөйли ала!

Фәрхетдин шундук артка чикте, артистланып ике кулын күкрәгенә куйды, баш иде:

— Ышанычыгыз өчен рәхмәт, дуслар. Әмма ләкин минем тегермәннең шул, җаннашларым, ташы әйләнсә дә, оны чыкмас. Ура урынына каравыл кычкырып куюым бар. Минемчә, бу эшкә Тин-Тинычны җибәрергә кирәк. Ул урысча да белә...

— Әйдә, Тин-Тиныч икән Тин-Тиныч! — дип, Фәрхетдиннең тәкъдименә кушылдылар разведчиклар.— Дөнья күреп кайтсын бер!

Тик Валентин слетка баруга теше-тырнагы белән каршы торды.

— Юк, булмый, җәмәгать! Вахтамны ташлап китәр хәлем юк!

— Синең өчен эшләрбез, курыкма!

— Сөймим мин андый җыелышларны! Аннан, халык алдында гомеремдә чыгыш ясаганым юк!..

Төрле яктан үгетләп, төрткәләп Валентинны күндерделәр.

Зөбәеров белән Валентин килгәндә әле иртә, слет башланырга ерак иде. Шуңа карамастан бораулау конторасының яңа өлгертелгән шактый иркен клубына халык кереп тулган иде.

Тәртип саклар өчен ишек төбенә җиңнәренә кызыл бәйләгән контролерлар куйганнар. Күрәсең, Зөбәеровны таныйлар, язу-фәләнен дә сорап тормыйча, ансат кына үткәреп җибәрделәр. Валентиннан чакыру билеты таләп итә башлаганнар иде, Зөбәеров: «Ул минем егет» диюгә юл бирделәр.

Фойеда регистрация бара. Житез генә өч-дүрт кыз һәркемнең исем-фамилиясен сорап, исемлеккә билге куеп тора. Монда шуны белде

Валентин: республика нефтьчеләреннән тыш слетка чит республикалардан, башка өлкәләрдән дә күп кенә кунаклар чакырылган икән. Алар арасында йөзләре кояшта янган Баку һәм Кавказ нефтьчеләре дә, чуен кебек кара Төркмән кешеләре дә бар иде. Төркем эчендә күршеләребез Башкортстан һәм Куйбышев вәкилләре, Пермь, Сахалин нефтьчеләре дә күп. Фойеда, бер-берсе белән бәхәсләшеп, журналистлар йөри. Валентин өчен элек рәсемнәрдә генә таныш булган язучылар, композиторлар, артистлар гәпләшеп тора. Димәк, хәзер Татарстан нефте бөтен илгә билгеле, аның даны еракларга таралган.

Зөбәеров белән Валентин, слеттагы мондый чуарлыкка күнә алмыйча, балалар кебек бер-беренә ияреп, кешеләрне күзәтеп йөрделәр. Клубка эшләпәле, фуражкалы, түбәтәйле, кубанкалы халык һаман тула торды. Фойе тыгызлана барды.

Бераздан күренеш алмашынды. Фойенең төрле почмакларында үзеннән-үзе кызыклы уеннар, күңел ачулар, җырлар; биюләр оешып китте, Валентин, мастерыннан аерылып, шуларны карый башлады.

Менә, юка гына гәүдәле бер әзербәйҗан егете яшь кенә татар кызын култыклап әйләндерә. Сары чәчле рус кызы, такмак әйтә-әйтә, сызылып киткән кара мыеклы кавказлы белән бии. Ул да булмый, түгәрәк уртасына башкорт нефтьчеләре сикереп чыгалар. Шәп биилар — аяклары җиргә тими.

Чакырсалар, Валентинның да, ялындырып-нитеп тормыйча, «диңгезчеләр чечеткасын» сугып алырга исәбе бар иде дә, ул арада залга чакырып, электр кыңгыравы шалтырый башлады.

Валентин докладны тын калып, үзе моңа кадәр ишетмәгән нәрсәләргә төшенергә тырышып тыңлады. Татарстан нефтенең киләчәге зур, перспективалары бик тә өметле икән. Ул хәзер «кара алтын» чыгару буенча карт Бакуның үкчәсенә басып килә, якын елларда аны куып житеп, узып та китәчәк икән.

Чыгыш ясаучы кунаклар да шул ук сүзне җөплиләр: туганда шактый зәгыйфь булып күренгән Татарстан нефте кыска гына чорда нинди гигант адым ясады дип сокланалар. Нефть чыккан беренче елларны Бакудан, Башкортстаннан, Грозныйдан татар егетләрен өйрәтергә, тәҗрибә бирергә килгән кешеләр әйтә моны. Ул чагында, чыннан да, нефть мәйданнары үзләштерелмәгән, товар парклары корылмаган, җир асты магистральләре сузылмаган иде әле, бердәнбер промысел гына бар иде. Кешеләр асфальт җәймәгән юллардан, төрле җирләрдә казып ташланган канаулардан сикереп йөргәннәрен искә төшереп китәләр. Хәзер инде Ромашкино яклары танымаслык булып үзгәрде, промыселлар гына түгел, шәһәр үсеп чыкты, диләр.

Зөбәеровка сүз бирелде. Ул кыю гына атлап трибунага чыкты, чәчен сыпырып, сөйләп китте.

— Мин үзебезнең нефтьчеләрне тыңлыйм да гаҗәпләнәм: нефть чыгару буенча инде еллык планны үтәдек һәм шуны гади бер күренеш итеп сөйлибез. Һәм ана кул да чапмыйбыз. Девон тирәнлекләренә, ике чакрым җир астына төшү — ул бит әкәмәт дулкынландыргыч вакыйга! Мин Татарстан нефтьчеләренең уңышларына карап хәйран калып утырам һәм бу уңышларның хикмәтен эзләп баш ватам.

Бөтен кеше Зөбәеровка көчле итеп кул чапты.

— Монда, залда, яшь бер бораулаучы утыра,— дип, янадан дәвам итте сүзен. Залдагылар ул әйткән кешене табарга тырышып артларына әйләнеп карый башладылар. Зөбәеров бармагы белән Тин-Тиныч ягына төртте:

— Аның фамилиясе сезгә таныш. Аның кешеләре барыгызга да мәгълүм: Тин-Тинычнныкылар диләр аларны. Алар табигать белән көрәшеп яшиләр, көрәшеп эшлиләр. Алар нинә ел тоташтан каты токымны кимереп баралар. Һәм алар ирешкән уңышларның серенә шунда

гына төшендем: үзләре каты токымнан булганда берпинди каты җир токымнары да каршы тора алмый икән кешеләргә!

Көтелмәгән җылы, матур сүзләрдән кызарып киткән Валентин әйтеп алды:

— Шагыйрь икән бу Зөбәеров, белмәгән идем...

Залда кул чапкан тавышлар тынарга да өлгермәде, трибунага бер кыз чыгып басты. Кем дип, кайдан дип әйтте председательлек итүче, анысын Зөбәеров та, Валентин да ишетә алмый калдылар. Кыз ачык тавыш белән, кыю рәвештә геологлар тормышы, нефть ятмаларын ачуда аларның соңгы уңышлары турында сөйли башлады. Валентин Зөбәеровка, Зөбәеров Валентинга карап алды. Икесенең дә күзләрендә «шул, Валя» дигән очкын кабынган иде.

Шул! Йөзе дә, күзләре дә, иреннәре дә Валяныкы. Нәкъ рәсемдәге Валя. Башында косынкасы, аркасында рюкзагы да кулында кәйләсе юк.

— Шулмы? — дип пышылдады Зөбәеров, егеткә төртеп.

— Шул! — дип кычкырды Валентин үзен-үзе белештермичә. Шундук урыныннан сикереп торды.

Зөбәеров шашкан бу егетне тотып урынына утыртырга дип кулын сузганда, Валентин инде урындыклар арасыннан чыгып, сәхнәгә таба йөгерә иде.

— Тукта, ахмак, кая барасын?

Залдагылар да, президиумдагылар да ни булганын төшенгәнче, егет сәхнә алдына барып җитте. «Валя! Валя!» — дип кычкырып, баскычтан атлап трибунага менде. Кыз ярты сүзендә тукталып калды.

— Суйды бу мине, суйды! — дип, Зөбәеров, оятыннан ни эшләргә дә белмичә, урындыклар арасына башын яшерде.

Залда гөж килделәр. Президиумдагылар аптырау катыш гаҗәпләнү белән бер-берсенә борылып нәрсәдер сораша киттеләр. Слетта председательлек итүче, ашыгып, күзлеген кия-кия, алдындагы чынаяк кадәр җиз кыңгыравына тотынды. Моңа кадәр ишек төбендә бер селкенми басып торган ике милиционер, аралыктан этешә-төртешә, сәхнәгә таба йөгерде.

Бу вакытта Валентин трибунада каушап калган кызны эләктереп алган да:

— Валя, сөеклем, таптым бит мин сине, таптым! — дип ду килә иде.

## 29

Валентин кызны кысып култыклап алган да көзге такыр юлдан җилтерәтә генә.

Халык алдында оятлы булганнан соң клубның арт ишегеннән чыгып качкан Валя әле һаман да зиһенен җыя алмый.

— Тукта әле, Валентин, кая алып барасың мине?

— Киттек, Валя, безгә таба киттек!..

— Кая ул «сезгә таба»?

— Безгә инде, Язтургайга!

— Ерак дисең түгелме соң син аны?

— Телисеңме күтәреп алып барам!

Валяны җирдән очыртып алып, кулына күтәрә егет, зырылдатып әйләндерә башлый.

— Шашма, Валентин! Кара син нинди икән!

— Нинди?

— Пырдымсыз!

Валентинга бу сүз ошап куйды, ул, һич уйлап тормыйча, шигырь сөйли башлады:

Пырдымсызлар яши деньяда,
Пырдымсызга дингез тубыктан...

Валя көмеш чыңнары чыгарып көлә:
— Мин сине бер дә мондый дип күз алдына китерми идем!
— Мин дә сине болай күз алдына китермәгән идем. Беләсеңме, мин сине шушы көнгә кадәр соры күзле дип йөрдем. Валлаһи! Син бит зәп-зәңгәр күзле икән!
— Ә мин сине, карточкаңа карап, тыйнак кына, күп сөйләшми торган, юаш кына бер моряк дип уйладым...
— Сине сагынган чак иде. И елмайтырга тырышты фотограф, и көлдерергә тырышты! Сызгырып та карый, иреннәре белән чөңгереп тә җибәрә — булдыра алмый!
— Мескен кыяфәтле син анда.

Мескен диеп мине уйлама,
Мескен булып җиргә килмәдем.
Кыяфәтем мескен булса да,
Батыр булып тибә йөрәгем!

Валя үчекләп көлде:
— Батыр йөрәкле дип белмәдем, куян йөрәкле дип көлә идем.
— Ә мин сине нәкъ менә шулай төртмә телле кыздыр дип уйлый идем. Чын! Хәтта тавышыңны да ишетә идем! Менә шулай мәктәп кыңгыравы шикелле чың-чың килеп тора иде колагымда.
Валя егетнең чагыштыруларыннан бик риза булып, аның саен чыңлатып көлә.
— Ну, син, Валентин! — ди, куллары белән битен каплап.— Бер дә җитди була белмисең, ахрысы!
— Җитди булу безгә кирәкми...— дип, тагын шигырь сөйли башлый егет.
— Анысы дөрес. Кайчак күңел ачасы да килеп куя. Ә ничек? Кайда? Кем белән? Безнең геологларның да тормышы гел юлда, читтә, кешедә уза бит...
— Ә без бер дә кешедә дип тормыйбыз. О-о, белсәң иде безнең бригадада нинди ансамбль бар! Ишетсәң иде син Саакянның гитарада уйнавын, Кубракның җырын тыңлап торсаң иде! Шаляпинның бер якта торсын! Баянчы кирәк икән баянчы, җырчы кирәк икән җырчы, тел бистәсе дисең икән — анысын да табабыз.
— Барыбер разведчикларга авыр инде, беләбез.
— Нәрсәсе авыр? Дөрес, безнең фатирда тыйнаксыз бозау бар. Якын килдеңме — киемеңне эләктерә дә ала!
Шаян сүз сөйләшеп кайта торгач, биш-алты километр үтелгәне сизелми дә калды. Бер-берсен сынашып, бер-беренә төртмә сүзләр әйтешеп, тагын күпмедер бардылар. Валя аякларына карый башлады.
— Арыдым, Валентин.
— Арыдың? Эх, син, мин геолог дигән буласың, җитмәсә! Беләсеңме, геологлар көненә ничә километр йөрергә тиеш? Йөз километр!
— Шушындый биек үкчәдәнме?
— Биектән горизонт зуррак күренә!
— Без шул горизонтны машиналарда карап барырга яратабыз.
— Нәрсәләр генә эшлисез соң сез?
— Безме? Җир катламының антиклиналь, моноклиналь һәм синклиналь төзелешен тикшерәбез.
— Нәрсә белән ашыйлар соң ул моноклинальләрне?
Егет үтә беркатлылыгы белән Валяга ошаганнан ошый бара. Шуна күрә ул, аксый-аксый булса да, аның белән янәшә, җәяү бара. Менә ул, биек үкчәле туфлиләрен салып, кулына тотты, кеп-кечкенә ап-ак тәпиләре белән көзге каты юлдан бара башлады.

— Әйдә, утырыйк булмаса, машинаны көтик.

Алар юлдан ерак та түгел салам чүмәләсе төбенә барып утырдылар. Көн кояшлы, җилсез, шулай да салкынча икән. Ни әйтсәң дә октябрь урталары, әбиләр чуагы җиткән. Тирә-якта сөрелгән җир өстенә зәгыйфь кенә булып яшел уҗым чыккан, еракта, офыкта, саргайган урман күренә. Моңсу алтын көз.

Валентин үзе янына сыенып утырган кызның җилкәсенә плащын салып каплады да, алда алтынланып күренгән урманга төбәләп экспромт белән шигырь укый башлады. Ул шигырь көз турында һәм көзге урманга карап юлдан килгән кыз турында иде.

— Син, Валентин, нәкъ казакъ җырчысы кебек: далага карасаң, дала турында сөйлисең, тауга карасаң, тау турында!

— Ә мин, беләсеңме, синең турыңда да бик күп шигырь чыгардым.

— Минем турымда? Миңа төбәп?

— Әйе, сине уйлап шигырь язмаган көнем дә булмагандыр.

Валентин чын шагыйрьләрчә башын күккә чөеп, хисләргә бирелеп шигырь укый. Башта бу шигырьгә кимсетебрәк караган кызның торабара уйчанланып, йомшарып китүен һәм әкрен генә үзенә сыена барганын да сизми.

Менә Валя егетнең җилкәсенә башын куйды, куллары белән аның күкрәк турысыннан кочып алды. Аңа болай утыру рәхәт, ул беркайчан да үзенә карата мондый җылы, ягымлы сүзләрне ишеткәне юк иде. Дөрес, аның кулын, йөрәген сорап йөрүче бер егет бар. Геологлар партиясе начальнигы, хуҗа кеше. Ләкин күләгә булып ничә еллар йөрсә дә, ошатмый аны Валя. Элек танышырга йөргән чорларда яхшатланып, шеф иң җиңел эшләргә генә куша иде Валяны, хәзер үч ала: хатын-кыз эшли алмастай иң авыр эшләрне тапшыра һәм: «Булдыксыз, вазифасына салкын карый, тыңламый»,— дип, югарыга рапортлар яза. Гомумән, борчак пешми ике арада. Ярый әле, слетка җибәрде начальник. Югыйсә, Тын океаннан хат язып яткан һәм озак еллар югалып торган бу хыялый егет белән кайчан очраша алыр иде Валя?

Валяның болай бик якын сыенып утыруыннан моңа кадәр бер кызның да кулын тотып карамаган Валентин ояла иде. Аның колаклары тәмам ут кебек кызарып чыкты. Җитмәсә, кыз башын моның җилкәсенә куйган да, кытыкны китереп, кайнар тыны белән муенга өрә.

Егетнең борсаланып куеннан чыгарга азаплануын Валя үзенчә аңлады: «Читтән танышкан мәхәббәт шулай буладыр инде, күрәсең... Моңарда коры шигырь генә...»

Ә Тин-Тиныч болытларга, урманнарга, кырларга карап һаман шигырь укый. Бу вакытта Фәрхетдин булса түзмәс, әйтер иде: «Житәр инде сиңа, Тин-Тиныч, телеңә салынып, куеныңдагы сандугачны очырып җибәрәсең бит инде, имансыз! — дияр иде.— Әйт инде үзенә шунда бер җылы сүз. Күңелендә юк икән, шупы чибәркәйнең кәефе өчен генә булса да тасма телеңне кызганма!» — дияр иде.

Чыннан да, Валентин, шигъри хисләргә бирелеп, үзе дә сизмичә, янындагы кызын — озак еллар хыялына төреп йөргән сөеклесен ычкындырып бара иде...

«Башка бер нәрсә дә беләсе, сорашасы килми микәнни бу егетнең?» — дип, Тин-Тинычның игътибарсызлыгыннан борчыла башлады Валя.

— Нигә мин генә аны тыңлап утырырга тиеш! Ни өчен ул минем уй-хисләрем, карашларым белән кызыксынмый? Әллә мәхәббәт шулай почта аша гына табыла да шуның белән вәссәлам дип уйлыймы? Күрәсең, читтән торып табылган мәхәббәтнең бәясе шуның кадәр генә була торгандыр инде... Юк, егет, әле сиңа чын яратуны аңлау өчен бик күп кирәк...

— Кузгалыйк булмаса,— диде Валя. Кагына-кагына урыныннан торды.
— Әйе шул, сонга калабыз, Валя: кайтасы ерак.
Валяның исәбе егетне мингерәйтерлек бер сүз әйтергә дә китеп барырга иде:
— Әллә син чыннан да мине кайтыр дип уйладыңмы?
— Нигә кайтмаска? Күп булса илле чакрым җир калгандыр!..
— Беләсенме, Валентин,— дип тыныч кына, җитди генә сүз башлап җибәрде кыз.— Мин бит мәхәббәтнең барлыгына гомумән ышанмыйм. Читтән торып гашыйк булганнарын әйтеп тә торасы түгел...
Валентин сәерсенеп кызга карап алды. Юк, ул шаярып сөйләми.
— Син уйлама, Валентин, мин сырлап-сырлап хат яздым да, бу кыз мина муенымнан гашыйк булды дип. Юк, кадерлем. Сине кызганудан, бу бичара матросның авыр хезмәтен аз гына булса да җиңеләйтим, дигән теләктән чыгып кына яздым мин ул хатларны... Син үпкәләмә, Валентин, чын, чын!..
— Димәк, барысы да ялган иде? — дип, куркынып сорады Валентин.
— Сон, уйлап кара: кем инде шулай меңнәрчә чакрымнардан гыйшык тота да ул гыйшыкның тормышка ашарына ышана? Минемчә, бер-беренне якыннан күрмичә, яхшылап белмичә гыйшык тоту — ул җиңел акыллылык, җилбәзәклек!
— Ну, күрештек бит инде!
— Хәзер әйтергә була!
— Әйт алайса, кай җирем ошамады?
Валя, адымнарын әкренәйтеп, читкә карады. Эх, кыз ошатудан гына бәйле булса икән ул мәхәббәт!
— Читтән торып гашыйк булучылар алар, минемчә, якыннан ярата алмыйлар. Алар, хыялланып йөри торгач, күңелләрендә кешене шул кадәр илаһи затка әверелдереп, фәрештәләндереп бетерәләр булса кирәк, очрашкач, бу сыйфатларның берсе дә табылмый — Валяның сизелер-сизелмәс кенә тавышы калтырый башлады — ул әчтән генә елый иде — кавышкач егет алдында матурлыгы белән дә, холкы-фигыле белән дә бөтенләй уйламаган, күз алдына китермәгән гап-гади кыз килеп баса...
Валя кинәт туктады да, читкә карап, егеткә кулын сузды.
— Хуш, Валентин, мин борылыйм инде, сонга калам...
Валентин туктады, гүя баскан җирендә аның аяклары ябышып калды.
— Нишлисең син, Валя?
— Кайтырга кирәк.
— Ничек инде? Миңа бармыйбызмыни?
— Юк инде... Теләсәң хат язарсың. Инде адресны беләсең...
— Хат белән күпме яшәргә була, Валя?
— Алай әйбәтрәк... Хуш...
Валя кинәт кенә борылды да юл буйлап чабып китте...

## 30

Юлда Тин-Тинычны Зөбәеров куып житте.
— Нигә син Валяны үпкәләттең? — Машинасын туктатып, кабинадан чыгу белән аның беренче сүзе шул булды. Кызның ялгызы гына һәм күзе тулы яшь белән Язтургай юлыннан кайтып килүе чыннан да бик гаҗәпләндергән иде Зөбәеровны. Машинасын туктатып: «Тин-Тиныч кая?» — дип сорады ул. Кыз дәшмәде. «Нәрсә булды сезгә?» — дип сорады — кыз дәшмәде. Ахырда: «Әнә, үзеннән сорагыз!» — диде дә үкси-үкси китеп барды.

— Нәрсә булды соң, Тин-Тиныч, әйт, ачуланыштыгызмы?

Валентин үзе дә аптыраган иде, мастерына нәрсә дип аңлатырга да белмәде:

— Мине ошатмагандыр...

— Ошатмагач, нигә елый-елый кайта ул? Ахмак, рәнжеткәнсең син аны! Килешмәгән берәр сүз әйткәнсеңӏ..

— Юк дим бит инде, юк! Алып кайтсаң кайт, кайтмасаң аякларым да яхшы!

Валентин машинаны узып җәяүләп китә башлады.

— Утыр, герой! — аны мастер үзе янына кабинага төртеп кертте.— «Валя, Валя!» — дип, ничә ел хыялланып йөргән булдың — телең генә икән!

Зөбәеров юл буена Тин-Тинычны битәрләп кайтты.

Кайткач бораулаучыларны җыеп слет турында, анда кемнәрнең килүләре турында һәм нәрсәләр булуы турында сөйләргә кирәк иде мастерга, әмма менә бу акмак Тин-Тиныч бөтен планны бозды да куйды. Слет слет булмады Зөбәеровка. Ул үзенең бораулаучысы өчен оялып, тәнәфестән соң залга да кермәде, машинасына утырып кайтты да китте.

— Башсыз икән ул Тин-Тиныч, бернинди этика-эстетика дигән нәрсәләрне белми, шөрепләре ычкынган чын тиле икән! — диде Зөбәеров, буровойга килгәч.

Ул ничек Валентинның слетта Валяны тануын, трибунага йөгереп менүен һәм бөтен халык алдында кызны кочаклап алуын сөйләп китте.

— Җитмәсә, машинаны да көтмичә җәяүләп кызны үзенә алып киткән булган, бераз баргач, аны юлда ташлап калдырган!

— Шулай укмыни!

Зөбәеров ачу белән җиргә төкерде.

— Шуннан соң аның кем икәнен үзегез уйлап карагыз да хөкем йөртегез!

Бәхете икән, Валентин үзе фатирында иде — мондагы тиргәү-каргауларны ишетмәде. Биредә була калса, белмим, чыгырыннан чыгып кызган бораулаучылар арасында әллә ниләр булып бетүе мөмкин иде.

Кайткач Валентин беркая да чыкмады, кешеләр күзенә күренмәде. Абзарда фатир бабайның әллә ничә еллар яткан тирес өемнәрен актарып, бакчага түгү белән мәшгуль булды.

Вахтадан бушагач, Фәрхетдин, Нәҗип белән Сапарбайны ияртеп, Тин-Тиныч янына кайтты. Валя белән нәрсә булганын Тин-Тинычның үз авызыннан ишетәселәре килә иде аларның.

— Вәлетдин Вәлетдинович эштә әле,— дип каршылады аларны фатир бабай.— Кирәкми, ятсын шунда череп ул тиресләр дип тә карадым, тыңламады. Нишлисең, кулы кычытып киткәндер... Бик тә уңган кеше ул, мин әйтәм, сезнең Вәлетдин Вәлетдиновичыгыз...

— Әйе, уңган! — дип кистереп куйды Фәрхетдин.— Бу уңганлыгы өчен аны...

Өчесе дә Валентинны эзләп абзарга кереп киттеләр.

Тин-Тиныч сәнәгенә түмгәк-түмгәк тирес эләктереп, мышный-мышный, аны читән аша бакчага чөеп маташа иде.

— Ник кенә бер тынын чыгарсын бу Тин-Тиныч! — дип, башын селкеп куйды Фәрхетдин. — Ник сөйләмисең, слетта Валяң белән очрашкан икәнсең бит...

Валентин эштән туктамады.

— Очрашса соң?..

— Без дә белик инде: ничегрәк булды һәм кайда ул Валя дигәнең?.. Нигә бездән аны яшерәсең?

— Сезгә нигә кирәк ул?

Егетләр шактый ук каты бәрелделәр:

— Ничек инде? Без синең дусыңмы, дошманыңмы?

Фәрхетдин, шаяртып сөйләмәгәнен белдереп, Валентинның алдына ук килеп басты:

— Алайса, әйт дөресен: үзең кудыңмы син Валяны, әллә үзе ташлап киттеме?

Валентин сәнәгенә сөялеп башын аска иде.

— Да, бар иде Валя...

— Син сөйлә, сөйлә! — дип очына башлады Фәрхетдин.— Кудыңмы, әллә үзе ташлап киттеме?

— Ну үзе инде, үзе! — дип, Валентин сәнәген ыргытты.— Әллә прокурормы сез миннән сорау алырга!

Сапарбай, үз хәлен искә төшереп, Тин-Тинычны чын-чыннан кызганып куйды.

— Ярар, Фәрхетдин, бәйләнмә кешегә. Кызы яратмагандыр гой...

— Ничек инде кыз егетне яратмаска мөмкин?! Юк сүз, пүчтәк! Син аңа, мәхәббәт укыйсы урынга, шигырь укыгансың, шулаймы, Тин-Тиныч? Я, әйт, дөресме? Ул синең лыгырдавыңнан туеп, качып киткән!..

— Бәлки...— дип җилкәләрен җыерды Валентин.

— Тинтәк син, Тин-Тиныч! Кызларны күбрәк кочакларга кирәк аларны, шигырь укырга түгел! Әйдә, киен, алып кайтабыз үзен!

— Кирәкми...

— Ничек, ягъни мәсәлән, кирәкми? Син беләсеңме, егетне кыз ташлап китү ни дигән сүз? Бу, дустым Тин-Тиныч, беләсең килсә, егетләр өстенә кара тап төшерү дигән сүз. Егетләр өстенә генәме? Ир-ат затына, бригада коллективына, алай гына да түгел, СССР илендәге барлык булган разведчикларга хурлык тамгасы салу!

— Син инде бигрәк... Арттырам дигәч тә!

— Арттырыммы? Дөньяда егет намусы бар!

Фәрхетдин фуражкасын бер колагына таба янтайтып куйды да башыннан үткәннәрне сөйли башлады. Әлбәттә, вакыйга, һәрвакыттагыча, «хезмәттә чагында» булган.

— Армиягә яңа килгән чак. Көн-төн «әйт-два» белән куалар, беркая да чыгармыйлар. Ял көннәрне гимнастерка сәдәфләрен чистартып казармада моңаеп утырабыз. Безнең белән карт солдатлар — фронтовиклар да хезмәт итә — демобилизация көтәләр. Аларның эш хутта: күкрәк тулы орден-медаль, старшина кадәр старшинага да «син» дип кенә дәшәләр. Телиләр икән, ятып йоклыйлар, кирәк икән, увольнение алып, шәһәргә чыгып китәләр. Ә кайткач үзләренең кызлар белән ничек гулять иткәннәрен сөйләп бетерә алмыйлар. Кызыгып, көнләшеп ятабыз.

Көннәрдән бер көнне безгә акча бирәләр. Солдатның айлыгы. Күпме диген әле син — бөтен бер кып-кызыл утыз сум! Шатланабыз: төнлә тревогалардан сикереп торулар, түш белән шуулар бөтенләй үк буш түгел икән әле дибез. Инде мин әйтәм, өскә-башка кирәкми, тамак та ач түгел, бу акчаны әни карчыкка салып куандырыйм әле үзен. Шуны гына уйлап кассадан акчаны алуым булды — «шап» арттан җилкәгә кулын салуы булды. Борылып карасам, безнең ротадан бер фронтовик.

— Китер монда акчаны, салага! — ди. Бирдем. Кесәсенә салып куйды да сорый миннән: «Кызлар үпкәнең бармы?» Дәшмим. Шуннан старшина янына җитәкләп алып барды да әйтә: «Старшина, бу салагага увольнение бир, юкса, кызлар үпкәне дә юк икән»,— ди. Билләһи, каян белгәндер, минем ул чагында кызлар убү түгел, кулларын да тоткан юк иде. Увольнение кәгазе яздырып алды да команда бирә: «Шагом марш минем арттан!»

Киттемияреп. Барабыз. Безне патрульләр дә тикшереп тормый. «Минем белән» дип кенә җибәрә теге. Ияреп йөрим. Шәһәр кибетенә кереп вино алды бу минем акчага. Икенче магазинга кереп закуска алды, мөртәт — анысы да минем акчага!

Тагын киттек. «Бу минем газиз башны кая гына илтеп олактырыр икән?» дип уйланып бара торгач, шәһәр читенә үк килеп чыктык. Баракка килеп кердек. Рөхсәтсез-нисез генә тибеп ачты бу ишекне. Кечкенә генә бүлмәдә ике кыз тора.

«Менә, тәти кыз, егет алып килдем сиңа,— ди бу берсенә! — Егете — кровь с молоком!»

Карт солдат өстәлгә кызыл аракы куеп, закускалар чыгарган арада теге кызлар, икесе ике яктан килеп, минем шинельне салдырып та ыргыттылар. Берсе, олырак булса да, төскә-биткә ярыйсы күренә. Икенчесе, яшь булса да, ямьсез — бите сипкел. «Я, ходаем, ниләр генә күрәсем бар икән?» — дип, курка-курка гына өстәл янына утырдым. Теге чуар битлесе дә янга елышты бит, мәлгунь! Мин урындыкны әкрен-әкрен аңардан шудырам, ә ул һаман миңа сырыша. Бер генә дә ошамый бит бу, каһәр, тәкәрлек кукәе! Мин түгел, аңа тигәнәк тә ябышмый инде!

Житмәсә, карт солдат өстәл астыннан йодрык күрсәтә: «Сынатма салага!» — дип, колакка чажгыра. «Яраббым, дим, нинди генә гаепләрем өчен бу солдат миннән үч ала икән, нинди зыяным тиде икән аңа?» — дип карганам эчемнән. Бу җәзаларны биргәнче, лутчы чиратсыз наряд бирдереп казармада көн-төн идән юдырсын иде, я старшинага әйтеп гауптвахтага яптырсын иде, дип тиргим.

Ничек кенә чыгып сызарга дип уйланып, план корып утырганда вино салып бирделәр. Андый зәһәр, ачы нәрсәне авызга да алган юк иде. «Сынатма, салага!» дип бер яктан карт хезмәттәш йодрык күрсәткәч, икенче яктан теге чуар тавык аракыны якага салырга маташа башлагач, бисмилланы укыдым да тондырдым!

Кодрәте юк эчемлекнең дип әйтеп кара инде шуннан соң син: күз алдымда дөньялар яктырып киткәндәй булды, теге чыпчык күкәе ярыйсы гына кыз булып күренә башлады. Билләһи! Бите дә алай ямьсез түгел икән, тавышы да сандугач тавышына әверелгән, буй-сыннары да килешле генә... Биленнән кочаклап та алдым моны...

Исемә килсәм, хезмәттәшем үз кызы белән каядыр чыгып ычкынган, ә мин моның белән боевой устав турында сөйләшеп утырам икән... Сәгатькә күз төшерсәм — кайтырга вакыт. «Тукта әле, эчем авырта башлады» дидем дә, алга-артка карамыйча, тай моның яныннан!

Кайткач сораштыра солдатым: ничек соң, борчак пештеме дә фәлән-төгән. Пеште генә дим инде, сер бирмим!

Молодец, ди бу миңа, егет икәнсең!

Молодец булып бер атна гына йөрдем. Икенче ялда шәһәргә чыгып киткән иде бу солдат. Әй, кайткан лабаса, җикеренепме җикерена бу миңа! Барлык рота алдында кычкыра бит: «Ах, син, салага, ди, ах син, сары томшык, ди, каз тизәге, ди, бөтен пехотаның данын саттың, бөтен солдатның йөзенә кызыллык китердең, бөтен армияне хур иттең, тор, киен хәзер яхшы чакта, бар, үзеңне аклап кайт, ди. Аклап кайтмасаң, солдат исеме дә, егет исеме дә хәрам булсын сиңа!» — дип, увольнительный кәгазь тоттыра. Нишлисең, киенеп яңадан шәһәргә чыгып китәргә туры килде...

Шуннан соңгысын Фәрхетдин сөйләми, егетлек турында үз фәлсәфәсен генә кабатлый:

— Егетлек дигән нәрсә ул, Тин-Тиныч җаным, бер пехотада гына түгел, һәркайда, хәтта буровойда да кирәк!

Зөбәеров хәтта үз-үзенә гаҗәпләнде: бораү продуктлы горизонтка житеп килә, алда дөнья кадәр мәшәкать, ә ул һаман Тин-Тинычны кайгырта. Бер төркем бораулаучылары машинага төялеп, Тин-Тинычның Валясын алырга киткәннәр иде, әле һаман күренмиләр. Ничек икән, алып кайта алдылар микән? Кайткан булсалар, инде шау-гөр килеп, өйдә утыралардыр. Рәйсә каршы алырга тиеш иде аларны, Валяны үз янына чакырырга, кунак итәргә тиеш иде. Нигә буровойга шалтыратмады икән?

— Сез ничек уйлыйсыз, кайтты микән Тин-Тинычның кызы?

— Булмас,— дип, өметсез җавап бирә Кадермәт эш аралаш кына.— Кая инде минем белән Тин-Тинычка кызлар карасын! Ул бит, гомумән, хатын-кыз заты белән сөйләшә белми!

— Әйе шул! Читтән торып хат язышырга гына оста ул!

Скважинага инструмент төшергәндә, Язтургай ягыннан Тин-Тинычлар күренде.

— Егетләр, вахта килә! — дип кычкырды вышка башыннан Миргазиян.

— Тин-Тиныч та киләме?

— Ул да бар.

— Димәк, Валясы кукиш күрсәткән!

«Кызны алып кайта алсаң, бу вахтага килмәссең. Валяң янында булырсың, синең урынга Сергей Саакян эшләр»,— дип әйткән иде Валентинга мастер. Тин-Тиныч вахтага чыга, димәк, кыз белән эш пешмәгән...

Бер минутка эшне туктатып, килүчеләргә карап тордылар.

Егетләрнең йөзе якты күренә. Фәрхетдин Тин-Тиныч янында кулларын бик хәтәр селтәп, нәрсәдер исбат итә. Брезентовкасына башы белән үк кереп чумган Сапарбай, кечкенә гәүдәсе белән аларның бер уңына, бер сулына төшеп, бөтерелеп йөри. Нәҗип исә сүзгә катнашмый, артларыннан салмак кына атлап килә.

Шул хәлдә диярлек буровой күперчегеннән менделәр.

— Я, эшләр ничек? — дип, түземсезләнеп сорады Зөбәеров Фәрхетдиннән. Әйтерсең кызны Валентинга түгел, Фәрхетдингә алырга барганнар.

— Һе, мин дә барыйм, кыз да булмасын! — дип, мактанып тамак кырды Фәрхетдин.— Әллә кайчан сездә, Рәйсә янында, коймак ашап утыра!

— Китсәнә! Чынлап алып кайттыгызмы?

Бу юлы инде барысы да Валентинга карадылар.

Ул күңелсез, ачулы иде, җавап урынына кулын гына селекте.

— Нәрсә, булмадымени?

— Ул тиле бәрән орлыгы ашаган нәрсәгә ияреп барган мин жүләр...

— Ни булды соң?

Валентин иптәшләренә арты белән үк борылды.

Сапарбай белән Нәҗип пырхылдап көлеп җибәрделәр.

— Рәтләп кенә сөйләгез әле, алып кайттыгызмы, юкмы?

Фәрхетдин камбала балыгы кебек шома, майлы бияләйләрен салып ыргытты да фуражкасын колагына таба янтайтып сөйләп китте:

— Билләһи газим, минем бер гаебем дә юк. Бу бит изге ялган! Ну, эш болай булды...

— Сөйләмә, ичмаса, ачу китереп! — дип җикеренде Тин-Тиныч. Фәрхетдин бер читкә тайпылып, сүзен дәвам итте:

Валя үзе Тин-Тинычны авыру дип уйлаган икән, причем монда Фәрхетдин? Мәсьәлә бит болай тора: ялганмы, чынмы, миңа Валяның карашын белергә кирәк иде... Кыз бит, үзегез беләсез, күзенә тузан сипмәсәң кайтмаячак иде... Нинди дә булса план кирәк иде... Ул бит план, стратегия дигән нәрсә һәркайда кирәк, үзегез беләсез... Хезмәттә, армиядә дә ул шулай... Вәт, барганда минем башта гениальный бер план туды. Менә шул план нигезендә Ромашкино больницасы турына житкәч, егетләрне төшердем дә калдырдым. Мин әйтәм, хәзер сез эшкә мишәйт кенә итәсез, Валя янына үзем генә киттем, ә сез мине жылыда, больница коридорында көтеп торыгыз, кыз белән кайтышлый кереп алырмын.

Ромашкинодан шактый ерак булып чыкты авыллары, эзләп таптым йортларын. Ул да, бичара, безнең кебек фатирда, кеше өстендә тора икән. Культурный гына шакып кердем ишекләрен. Бу, мин сиңа әйтим, өстәл янында, башы-аягы белән чумып, китап укып утыра. Кыз ярыйсы гына күренә! Төс-бит дисеңме, түш-аяк дисеңме — барысы да урынында! Тин-Тиныч юкка гына гашыйк булмаган, сайлый белгән, мөртәт! «Здрасте, мин әйтәм, сезме ул, мин әйтәм, Валя?» «Мин»,— ди бу эре генә. Болай үзен горур тота, каһәр! «Әйдәгез, сезне Тин-Тиныч чакыра»,— дип әйткәнгә генә ияреп китәрдәй түгел. Әлеге дә баягы планны, стратегияне эшкә җигәм: «Ах, мин әйтәм, Валя! Нишләттең син безнең егетне? Иң яхшы бораулаучы иде бит ул безнең! — дим.— Үзе шагыйрь, үзе жырчы, үзе биюче. Бөтен разведканың күрке иде бит ул!» — дип җибәрәм. Куркып калды бу: «Ни булган аңа?» — ди. «Ни булганын шайтан үзе белсен,— дим,— түлке бетергәнсез егетне! Аңын югалткан хәлдә юлдан таптым. Әнә хәзер Ромашкино больницасына алып килдем»,— мин әйтәм.— «Неужели?» — дип тагын да хәвефләнеп калды бу. Мин аның саен тегенең күңеленә шөбһә салам: «Валя» дип бер генә сүз әйтә алды, мин әйтәм, бик авыр хәлдә ята»,— дим. «Шулай дип әйттеме? Валя дидеме? — дип калтырый-калтырый, киенә үк башлады кызым. «Кирәкми, борчылып йөрмә, хәбәр итәргә генә килдем»,— дигән булам. Кыз яратамы, юкмы дигән политика бит инде миндә. Ярата икән Тин-Тинычны! «Юк, юк,— ди бу, авыз да ачтырмый, зинһар, алып бар янына, әйдә киттек!» — кенә ди. «Әһә,— мин әйтәм эчтән генә,— сез шул, хатын-кызлар, ир-ат затына бәла килгәндә яхшатлана беләсез.»

Киттек. Кайтып җиттек Ромашкинога. Туктадык больнис янына. Уйлыйм: «Шапырынуын шапырындым да, ну әләгә инде хәзер минем янак төбенә!» Авыру булып кылан, дип, Тин-Тинычны да кисәтеп куймадым!

«Тукта, үзем генә»,— диюемә карамастан, артымнан ук ияреп керде. Керсәм, туганкайларым, куанычымнан нишләгәнемне дә белмим — Тин-Тинычым коридордагы бер буш диванга сузылган да ятып йоклаган! Шундый тәмлекәйләр итеп гырылдый, авызыннан селәгәйләре агып киткән хәтта! Сизеп торам, көтә-көтә арыган инде, бичара. Тин-Тинычны күрүе булды Валяның, кулларын җәеп ташлануы булды моның өстенә! Прости мине, Валентин дорогой,— ди,— милый мой! — ди.— Мин үзем гаепле,— ди!

Разведчиклар буровойны күтәрердәй булып хахылдашалар. Инде Зөбәеровның көлә-көлә күзләреннән чәчрәп яшьләре чыкты, Кадерметнең эче катып бетте. Кайберәүләр тәмам көлә алмас хәлгә җитеп, буровойдагы торбалар өстендә: «Уф, тукта, җитәр, үтерәсең!» — дип, тоташтан үкереп торалар.

Валентин ачуланып кычкыра:

— Нәрсә шул кадәр улыйсыз! Таптыгыз көләр нәрсә!

— Туктагыз әле, җәмәгать, сөйләп бетерсен! — дип тынычландырырга азаплана аларны мастер, тик булдыра алмый.

Сапарбай сүз башламакчы була:
— Калганын, юлдашлар, үзем сөйләем! Бер вакыт Тин-Тиныч торып утырды...
Сапарбайга игътибар итүче булмады.
— Кит әле, белер-белмәс телең белән тыгылма! — дип, Фәрхетдин Сапарбайны этеп җибәрде дә мәзәген дәвам итте:
— Сапарбай бу өлешен күрмәде, читтәрәк калды. Юк, Тин-Тиныч торып утырмады. «Милый, дорогой, прости!» — дип Валясы ташлангач, Тин-Тиныч күзен шар ясап ачып җибәрде дә шул көенчә катты да калды. «Нәрсә булды икән моңа, әллә, чыннан да, авырый микән?» — дип, үзем дә шикләнә калдым. Ә Тин-Тинычыбыз кыз астында. Каушаганмы, гаҗәпләнгәнме — тора алмыйча ята! Шуннан, мин сиңа әйтим, врачлармы, сестралармы үтеп баралар иде, туктадылар бит моның янына. Тин-Тиныч нәрсәдер әйтергә дип авызын гына ачкан иде, гөлт берсе ачы дару моның тамагына!
— И-и, Тин-Тинычның шул чактагы чыраен күрсәң! — дип көлә Нәҗип.— Туксан яшьлек картларныкыннан бер дә ким түгел иде!
— Тфу, чорт, әле булса да әрем тәме авыздан китми! — дип, җиргә төкерде Валентин.
— Җитмәсә, Валясы да бит аның: «Ничево, милый, хорошо!» — дип хуплап тора! «Йот, йот, чирең хәзер үтеп китәчәк!» — ди!
Валентин Фәрхетдинне эттән алып эткә салып тирги:
— Синең аркада әллә нинди хикмәтләргә юлыктым, дуңгыз! Моннан соң синең сүзне тыңласам икән, җеннән туган нәрсә!
— Аның каравы, кызлы булдың! Алып кайтканга рәхмәт юк!..
— Ну, ничек соң, хәйләне сиздеме Валя? — дип кызыксындылар бораулаучылар.
— Әйттек, юри генә кыландык, ул тап-таза, үгез кебек егет, дидек, ышанмый. Әле больниста Тин-Тиныч торырга азаплана башлагач та Валя һаман: «Селкенмә, милый, селкенү сиңа зарарлы!» дип басып ята бирде. Тин-Тинычның холыксызланып: «Китегез, зинһар, янымнан, тотмагыз! — дип тарткалашуына да карамастан, машинага хәтле аны култыклап алып барды, бергә кабинага утырып кайтты.
— Анда да синең сәламәт икәнлегеңә ышанмадымы, Тин-Тиныч?
Валентин көрсенеп алды:
— Кая ышансын инде! Ышану гынамы соң: сөйләшергә дә кушмый, авызны тота, «Вредно», ди! — Аннан кинәт Фәрхетдингә борыла да, җикеренеп кычкырып җибәрә:
— Кешнәп торма әле, ичмаса, сыптырып җибәрермен! Хәзер нәрсә уйлый инде Валя? Билгеле, Валентин чирле, Валентин паралич, бума хастасы! Ягъни мин аңардан авыруымны яшереп йөргән булып чыгам! Таптың шаярыр нәрсә!
Фәрхетдин Тин-Тинычның маҗараларын сөйләп кешеләрнең тәмам хәлләрен алды. Көлгәндә хәзер Нәҗип җилкәләрен калтырата-калтырата тешен генә сызгырта, Сапарбай башын чайкый-чайкый томаулы борының сеңгерә, ә Кадермәт учларын авызына куеп буыла-буыла ютәлли.
— Нигә соң әле син, Тин-Тиныч, Валяңны ташлап эшкә килдең? Мин сиңа ял биргән идем бит,— диде мастер, уенын-чынын бергә кушып.
— Чиратым җиткәнгә килдем.
— Анысын инде артыграк патриотланып киткәнсең. Кунакны калдырып китү ярамас иде...
Кадермәт алга чыгып, Валентинның җилкәсенә кулын салды:
— Бар, кайт, Тин-Тиныч, үзем калырмын...
— Юк, мин эшләргә тиеш! — дип, идарә пультына менеп басты

Валентин.— Нәрсә сез, тагын Валядан көлдерергәме? Мин аңа авыру түгеллегемне исбат итәргә тиеш!

Үтә киреләнеп киткән Валентинны берничек тә туктата алмагач, ахырда Зөбәеров болай диде:

— Ярый калсын. Сменасы беткәч кайтыр... Менә нәрсә, егетләр: Валя хәзер бездә. Тиз генә юынып, өс-башларыгызны алыштырасыз да турыдан-туры Саран Сабирҗаннарга! Камилгә борылды да:— Тфу, чорт, малае монда икән!.. Ярый, Камил үз кеше, гаеп итмәс. Форма: үтүкләнгән яхшы костюм-чалбар, ак күлмәк, галстук һәм эшләпә белән плащтан! Кем дигәндә разведчиклар диярлек булсын. Төшендегезме?

— Төшенүен төшендек тә... Соң бит мин ул галстук дигәнне гомеремдә такканым юк! — дип каршы төште Миргазиян.

— Верховой атала җитмәсә! Акча күп аласың, тап! Күршеңнән булса да сорап тор! Ә син, Камил, кайтышлый ук Сергейга кагыл. Гитарасын алып килсен. Габбаска эндәш, гармунын кыстырсын. Кубракның, Кадермәтләрнең тәрәзәләрен барып чиерт. Шулай-шулай, диген, Тин-Тиныч Валяны алып кайтты, диген, сәгать алтыга, таш яуса да, кичәгә килеп җитегез, диген!

— Аларның төнге вахтага чыгасылары бар бит.

— Өлгерерләр.

Зөбәеров Кадермәткә карап: «Бу картлачка ниндирәк йомыш кушыйм икән?» дигән сыман уйланып торды.

— Мин яшьләр эшенә тагылмам инде, ярар,— диде Кадермәт.

— Килми калу юк! Без сине башкода итеп куябыз!

— Дөрес,— диештеләр бораулаучылар.— Ул җитди кеше, аңа килешә үгет-нәсихәт!

— Ә хәмер ягы ничегрәк? Хәзер кибет тә бикле бит инде...

Мастерның җавабы катгый булды:

— Анысы сезнең эш түгел... Мин сезне чәй белән генә сыйлармын, бәлки...

Зөбәеров кайтканда Рәисә белән Валя көлешә-көлешә күңелле генә чәй эчеп утыралар иде. Фазыл ишек төбендә зур кирза итекләрен салып куйды да килеп Валя белән күреште.

— Менә тагын очраштык.— Күз кырые белән генә өстәлгә карап алды.— Күрәм, бик күңелсез утырасыз...

— Киресенчә, монда Раиса егетләрне сөйләп көлдерә иде әле.

— Сезне көтәбез. Кайда егетләрең? Тин-Тиныч кайда? — дип сорау артыннан сорау тезеп китте Рәисә.

— Тин-Тиныч үз постында,— диде Зөбәеров, рәсми төстә.— Аннары өстен чишенә башлады.

Рәисә дә, Валя да күңелсезләнеп киттеләр.

— Бүгенгә генә, шушы кичкә генә эштән азат итәргә булмадымыни? Эх, мастер! — дип битәрләргә тотынды Рәисә.

— Тин-Тинычны азат итәргә? — Зөбәеров гаҗәпләнгән булды. Валя каршында егетнең дәрәҗәсен күтәрергә маташа иде мастер.— Валентин Валентиновичны азат итү ул, беләсең килсә, буровойны сусыз калдыру белән бер! Менә-менә нефть чыгам дип тора — монда Валентин Валентиновичсыз бер нәрсә дә эшләп булмый!

— Соң бит синең күз өстендәге кашың — Кадермәтең бар түгелме?

— Нәрсә белә ул Кадермәт! — дигән булды Зөбәеров.

«Монысы да, Фәрхетдингә ияреп, ялганларга остарып беткән икән», дип уйлады Рәисә.

— Валентин кайтыр ул,— Фазыл тирә-ягына каранып алды.— Озын сүзнең кыскасы, хәзер егетләр киләчәк, кайда безнең чучка балалары?

Кайдадыр почмакта казынып, Зөбәеров өстәлгә бер-ике шешә шампанский, бер-ике шешә аракы китереп куйды. Рәйсә шул арада ризык әзерләде.

Урамнан ук гитара чиертеп Саакян белән Кубрак килеп керделәр. Зөбәеров аларны ишек төбендә каршы алды да, икесен дә житәкләп, түргә алып килде.

— Таныш булыгыз, Валя, бу егетләр безнең разведка ветераннары. Михаил Кубрак. Украинадан. Җырчы. Арада иң серьезный егетләрнең берсе. Ә монысы Әрмәнстан егете Сергей булыр. Медале бар. Өйләнмәгән.

— Медале булып та өйләнмәгәнме? — дип көлде Валя. Аның кыңгырау кебек тавышы Сергейга ошап куйды.

— Бик өйләнер идем дә, шушындый ачык тавышлы кыз таба алмыйм!

Миргазиян, Габбас, Еланский бергә килделәр. Аларның икесе мастер кушканча галстуктан, эшләпәдән иде. Тик Миргазиян гына үзенә баш киеме таба алмаган, каз оясы кебек зур фуражкасын кигән иде. Зөбәеров аларга да мактау сүзен кызганмады. Булмаган хезмәтләрен дә Валяга бар итеп, эшләмәгәннәрен дә эшләгән итеп, күпертеп күрсәтте. Егетләр үзләре моңардан бик риза калдылар.

Озак та тормый, Кадермәт ишек шакыды.

— Әйдә, әйдә, туган, түрдән уз. Менә таныш: бу безнең еллар буе эзләгән Валябыз булыр...

Кадермәт өстен салып куйгач, өстәл янына килеп Валяга кул бирде:

— Синмени инде ул безнең бригаданың заочный кәләше? — Кызның кулын озак кына селкеп торды да: — Сиңа, Валя, бригада исеменнән каты шелтә! — диде.

— Ни өчен?

— Ни өченме? Беренчедән, Тин-Тиньчтан еллар буе качып йөргәнең өчен, икенчедән, тапкач та китеп барганың өчен.

— Ә килгәнем өчен нәрсә бирәсез?

Валя чыңгырдатып көлде.

— Анысы өчен рәхмәт.

— Минус һәм плюс. Икесен бергә кушсаң, ноль була, димәк. Болай булгач, гаебем юылды!

Хатынша шикелле алъяпкыч ябып, Рәйсәгә табын әзерләшеп йөргән Зөбәеров, кемдер кайтып, Мотгәрәйнең өйдә юклыгын әйткәч, чәнечкесе белән тарелкага кага башлады.

— Җәмәгать, ишеттегезме, Мотгәрәй югалган, ди. Хәерлегә булсын. Үзегез беләсез, бу йортның дип әйтмим, бу бүлмәнең хуҗасы әлегә мин. Шулай булгач, табынга утырышуыгызны һәм мин ни әйтсәм, шуны тыңлавыгызны сорыйм!

Кадермәт кулына рюмкасын алды:

— Нәрсәгә күтәрәбез? Кем хөрмәтенә, нәрсә хакына?

— Барыбыз исеменнән дә Сергей берәр тост әйтсен!

Тост әйтүдә Сергейның һәвәслеген Валядан калганнар беләләр иде инде. Әллә каян гына килешле, матур сүзләрен табып бетерә дә, ничек шуларны тигез итеп, мәгънәле итеп тезеп бирә ала! Тостлары аның бер дә кабатланмас, һәрвакыт яңа, үзенчәлекле булыр, оста язылган шигырь кебек җырланып торыр.

Бу юлы тостында Сергей туган ягындагы Кавказ тауларын, анда шарлап аккан Арарат елгаларын искә төшерде, ул елга өстендә йөзгән ак болытларга менеп китте, якты кояшка, тулган айга үрләде. Инде бу буталды, фикер җебен югалтты, салулап читкә кереп китте дигәндә генә тауларга, таулардан Араратның яшел үзәннәренә төште.

Саакянның күңелгә ятышлы зур тостын һәрвакыт сокланып тыңлыйлар иде. Тик арада Миргазиянның гына түземлеге җитми, ул,

моңаеп, кайчан туктар икән дип, рюмкасына карый, тостның урта бер җирендә бүлдереп:

— Әйдә, шуның өчен! — дип күтәрә башлый иде.

Зөбәеров бүген дә тостны Миргазиянның бүлдерүеннән куркып утырды: «Каһәр малай, кеше алдында да тик тора алмас әле ул»...

Сергей Араратның яшел үзәннәрендә куе булып үсеп утырган виноград куаклыкларын, ул куакларда якут-мәрҗәннәр төсле асылынып торган җимешләрне күрде. Рюмкадагы әнә шул җимешләрдән алынган иң татлы, шифалы шәрабләрне ул Тин-Тинычның һәм Валяның кавышу шатлыгына, аларның дуслык-татулыклары хөрмәтенә күтәрергә тәкъдим итте. Эчмәс җиреңнән эчәрсең!..

— Җырлашып утырыйк әле, дуслар!

Габбас ишек төбендә тартмасы белән куелган гармунын алып килде. Валяга ярарга теләпме, белдеклелеген күрсәтергә тырышыпмы, русның борынгы, озын көен уйнарга керешәте. Аңа табында берничә кеше җыр белән кушылмакчы булып азапланды.

— Сез миңа үз көегезне уйнап күрсәтегез әле, татар көйләрен,— дип үтенде Валя.

— Татарчамы? Була ул!

Татар һәм башкорт көйләрен Габбас җиңел, җиренә җиткереп уйный иде. Хәзер инде аңа кушылучылар да үзләрен иркен тоталар, иркен җырлыйлар. Габбаз тиз генә бер көйдән икенчесенә күчеп, «Китмә, сандугач»ны сузып җибәрде. Барысына да хуш килде бу җыр, чөнки аны бригадада татарлар гына түгел, казакъ баласы Сапарбай да, украинлы Кубрак та, әрмәнле Саакян да беләләр иде.

Китмә, китмә, сандугач!..
Курыкма син кышлардан,
Кал син башка кошлардан,
Саклармын салкын җилдән,
Китмә син туган илдән...

Бу җырны Валяга багышлап, аңа атап җырладылар табындагылар. Кызга карап күз кыса-кыса, баш чайкый-чайкый, дәртләнеп җырладылар. Кыз бу җырда ниндидер яшерен киная барлыгын тоеп, кызарып утырды.

Икенче җыр — «Сарман вальсы» да мәгънәсе белән Валяга төбәлгән кебек иде. Монысында да сүз сөйгән ярны үзенә чакыру турында бара бит. Рәйсә, Валяның колагына иелеп, җырны үзенчә аңлатып, тәрҗемә итеп утырды: «Менә бу якларда Сарман дигән шундый бер матур елга бар, аның шундый ямьле болыннары бар, кыз шул якларга кайтыр идем, каршы алыр иден микән, дип сорый егетеннән»...

Габбас уйнавыннан туктагач, Миша, гитарага кушылып, яраткан «Бандура»сын җырлады. Валя аның соклангыч чиста, матур тембрын мөкиббән китеп тыңлады. «Әйе, талантлы гына егетләр җыелган бу бригадага, сайлап алынган кебек».

«Җырлавын җырлашабыз да, анда буровойда хәлләр ничек икән?» — дип пошынып ут йотып утырды Зөбәеров, кешеләргә сиздерми генә сәгатенә караштырды. Эшнең мондый тыгыз вакытында, нефть катламын ачар алдыннан кунакның килеп чыгуы бик үк куандырмады мастерны. Ләкин сер бирергә ярамый. Бераз гына утырырга кирәк. Аннары иплән, җайлап кына төнге вахта белән буровойга китәргә кирәк булыр... Валя үз кеше, кичерер әле...

Бу турыда Рәйсә белән дә пышылдашып алдылар.

— Зинһар, Тин-Тиныч кайтканны гына көт инде, яхшы түгел,— дип ялынды Рәйсә.

Рәйсә тарафыннан ашык-пошык оештырылган бу кичәдә егетләр әле тагын бик озак күңел ачтылар: җырладылар, биеделәр, төрле шаян

сүзләр сөйләделәр. Валя ипле-тәртипле генә булып, елмаеп-көлеп кенә торды, геологларга хас күзәтүчәнлеге белән карап, сынап утырды: егетләр ачыклар, әйбәтләр, татулар, гадиләр. Тирәләреннән чыгарга житешеп кунакка ярарга, аның күңелен табарга тырышалар үзләре, бии белмәгәне дә биегән була, тавышы югы да ялындырмыйча җырларга чыга.

Мастер Зөбәеровның да катылыгы сизелеп китте: эшчеләре алдында тәртипне шул кадәр куйган, бер күз сирпүе белән үк бораулаучылар аның нәрсә әйтәсен аңлап алалар, булган-булмаган һөнәрләрен карусыз-нисез күрсәтергә тотыналар. Төнге сәгать уникедә вахтага китәргә тиешләре аның рөхсәтеннән башка рюмкага да кагылмады. «Буровойда да шулай бер-берсен аңлашып, ярашып эшлисәләр, эшләре әйбәттер»,— дип уйлады Валя һәм шунда кинәт күңеленең Валентинга битараф булмавын аңлады.

Бераз хәмер белән кызып киткәч, тагын да ачыла төште егетләр. Барысы да беравыздан Валяның монда калуын үтенергә тотындылар. Буровойны мактадылар, авылны мактадылар, Тин-Тинычны мактадылар. Тин-Тиныч алтын булды, дөнья бәясе кеше булды, бораулауда зур осталарның берсе булды. Тин-Тинычның хыялында бары сез генә, ул сезне ничә еллар тилмереп эзләде. Сездән башка тора алмый, ышанмасагыз, әнә, безнең хөрмәтле Рәйсәдән, олы кешебез Кадермәттән, башлыгыбыз иптәш Зөбәеровтан сорагыз. Сез дигәндә Тин-Тиныч утка керергә, суга төшәргә, күкләргә ияргә риза...

Миргазиян хәтта исереп китеп: «Мин барыгыздан да бөек кеше, мин верховой! — дип кычкырды.— Верховой белән Верховный бер сүз. Шулай булгач, миңа югарыдан күренәрәк төшә: безнең Тин-Тиныч ул разведка тарихында сирәк очрый торган экземплярларның берсе!» — дип күкрәк какты.

Ләкин ни генә дисәләр дә, хәйлә белән, очраклы рәвештә генә монда китерелгән кыз кала алмый иде. Аңа иртәгә эшкә чыгарга, бүген таң белән кайтып китәргә кирәк иде.

Төнге сәгать унберләр тирәсендә бораулаучыларның бер төркеме кузгалышып вахтага китәргә җыена башлады. Буровойга барганчы фатирларына кайтып, өс-башларын алыштырасылары бар иде аларның, тик берсенең дә гаять кыска тоелган бу мәҗлесне ташлап китәсе килми иде. Хушлашуы ярыйсы гына озакка сузылды.

— Син, Валя, бөтенләй кала торгансыңдыр бит инде?

— Иртәгә күрешәбез ич?

— Туйны кайчан ясыйбыз соң?

Валя һәрберсенә кулын бирә-бирә чыңгырдатып көлә.

— Уйлармын әле, иртә җитсен! Тәртибегезгә карармын! Тин-Тиныч нәрсә дияр бит?

Зөбәеров Валя кырыена күчеп утырды да, нәрсә турындадыр уйланып киткән кызны сискәндереп, сорау бирде:

— Безнең мәҗлес ошамады булса кирәк?

— Ошады! Бик тә ошады! Бар якка да булдыралар икән егетләрең!

— Димәк, бездән китмисез инде?

— Китәм, Зөбәеров дустым. Рәхмәт, миңе анда эш көтә.

— Ә Валентин?

— Без элеккечә хат алышып торырбыз. Кунакка йөрешербез.

— Романтика!

Киенеп-ясанып Валентин белән Фәрхетдиннен, Сапарбай белән Нәҗип килеп керүе табынны җанландырып җибәрер төсле иде, ләкин алай булмады.

Моңа Зөбәеров үзе сәбәпче иде. Чишенергә, табынга утырырга да өлгермәгән егетләрдән буровой турында, скважинаның хәле-холкы турында сораша башлады.

— Авыш скважина түгел, кыек, кәкре-бөкре, тагын әллә нинди скважиналар салсаң да, нефть чыгасы юк ул Баланлы төбәктән! — дип җавап бирделәр аңа. Моннан соң инде штрафка бирелгән аракы да, Фәрхетдиннең мәзәкләре дә, Тин-Тиничның яңа шигырьләре дә, Сапарбайның биергә теләп азапланулары да өйдәгеләрнең кәефенә тәэсир итә алмады. Ярты төн күптән узган, күңел ачып утырырга соң һәм кешеләр дә шактый ялыккан иде.

Валентин белән кунак кызын бераз гына булса да бергә калдыру нияте белән Рәйсә егетләргә тәкъдим ясады:

— Төн дә матур, әйдәгез, һава сулап керәбез!

Тиз генә киенеп, бар да өерелеп урамга чыктылар.

«Сез монда гына утырыгыз»,— дию.ләренә карамастан, төркемгә Валя белән Валентин да иярде.

Төн, чыннан да, матур иде. Күктә, башын пычак белән кисеп алган ак көмәч төсле, бер кыры китек ай балкый. Аның нурлары ап-ак булып йортларның салам түбәләренә төшкән, урам буендагы талларга, киртә-рәшәткәләргә кунган. Урамда култыклашып алган Валя белән Валентинның да, алар артыннан ун-унбиш адым калып барган хуҗалар белән егетләрнең дә киемнәрен сыек бәс сарган төсле.

Авыл йоклаган. Аның тынлыгын сирәк-мирәк өреп куйган эт тавышлары кисеп ала да, анда-санда кычкырган әтәчләр генә бүлеп куя. Шушы тынлыкны сакларга тырышкандай, бар да сүзсез калып, салмак кына атлыйлар.

Бераздан Валентин:

— Шулай да безнең Язтургай матур бит! — диде.

— Бик тә матур! — дип җавап бирде кызы.

Рәйсә дә, Зөбәеров та, «эшләр рәтләнә» дигәнне аңлатып, култыклашкан җиреннән терсәкләрен кысып куйдылар.

Тин-Тиныч тагын эшне бозды, һич кирәкмәгәнгә Валяга шигырь укырга тотынды.

Бер нәрсәгә алыштырмам сине,
Сагындыкны, Балан төбәген;
Анда салган буровойда минем
Нефть арттыруда теләгем!

Фәрхетдин арттан йодрык янап, усал итеп пышылдады:

— Җимерәсең бит эшне, ахмак! — Аннары Тин-Тинычка төрттереп шигырь укыган булып китте:

Бер нәрсәгә алыштырмам сине,
Палаткам бит минем мировой;
Менә тиздән нефть арттырам дип,
Яшәү көче бирә буровой!

— Аларның әле мәхәббәте өлгермәгән,— диде Рәйсә әкрен генә.

— Икесенең дә бик зур сынау үтәселәре бар шул.

Соңгы өйләрне дә калдырып басу капкасына җиттеләр. Ерак та түгел, кырда, ялгыз йортларны хәтерләтеп, салам эскертләре күтәрелеп тора, ә алардан ары, офыкта диярлек, буровой утлары җемелди. Дикъкатьләбрәк тыңласаң, дизельләрнең гөрләвен дә, торбаларның чыңлап китүләрен дә ишетергә була. Димәк, егетләр эшли...

— Менә, ниһаять, Валентинга яшәү көче биргән буровойны да күрдек! — диде Валя, кайтырга кирәк икәнлеккә ишарә ясап.

Зөбәеровның күңеле һава сулап йөрүдә дә, кыз белән егетнең мөнәсәбәтләрендә дә түгел, әнә анда, өч-дүрт кенә чакрым ераклыкта, утлары ялтырап күренгән шаулы буровойда иде. Юк, ул хәзер бер генә минут та болар янында кала алмый...

Зөбәеров егет белән кызның иңбашларына кулын куйды:

— Гафу итегез, мин буровойга киттем... Дөнья хәлен белеп булмый...

Бераз баргач туктады да:

— Башкасын иртән сөйләшербез,— диде. Караңгыга кереп югалды.

Калганнары кайту ягына борылдылар. Сөйләшеп бара торгач, урам чатыннан каршыга ук килеп чыккан ир белән хатынга чак бәрелмичә туктап калдылар. Бала күтәргән ир кеше кинәт кырыйга тайпылды.

— Мотгәрәй түгелме соң бу? — дип кычкырып җибәрде Миргазиян, аны зур кабак башыннан танып.— Син ни эшләп йөрисең, Мотгәрәй?

Таң алдыннан урамда Рәйсәне һәм нефтьче иптәшләрен күреп, Мотгәрәй аптырап калды, ни әйтергә белмичә, кулында йоклаган баланы селки башлады, аннан аны янында сыенып торган хатынга сузды. Шуннан соң гына тел керде Мотгәрәйгә:

— Бабайлардан кайтып килеш,— диде ул, утә каушап.— Хәер-фатиха алып...— Янындагы хатынны күрсәтте: — Бу минем хатын була инде... Фәридә исемле...

— Һы!..

— Ничек була инде бу, ягъни...

Ни дияргә дә аптырады егетләр. Мотгәрәй өйләнгән... Башлы-күзле булган... Димәк, теге вакытта «Мотгәрәй йортка кергән икән» дигән сүз дөрес булып чыкты?.. Ә бу кечкенә бала кай арада соң әле? Әһә, бирнәсе белән алган бу хатынны...

Уңайсыз тынлыктан Рәйсә коткарды:

— Котларга кирәк ләбаса, егетләр, нәрсә карап каттыгыз? — Шунда ук Фәридәгә, Мотгәрәйгә кул бирде.— Яхшы булган, бик яхшы... Менә, үрнәк алырга кирәк, егетләр!

Бораулаучылар да ниндидер аңлаешсыз сүзләр мыгырдап яңа өйләнешкәннәрнең һәр икесенә дә кул суздылар.

Фәрхетдин анда да телсез калмады:

— Никах укыттыгызмы соң? Теге ничек әле... «Өммәтинә өммәти... көндез тимә, төнлә ти-и-и...»

Көлешеп таралыштылар.

Мотгәрәй белән Фәридә түбән очка, үзләренә таба китте, егетләр үз фатирларына юл тоттылар. Валентин белән Валя Рәйсәгә ияреләр.

— Кешеләр бер дә озын-озак уйлап тормыйлар, әнә,— дип, үзалдына сөйләнгәндәй сөйләп китте Рәйсә.— Һәм дөрес тә эшлиләр. Киләчәк тормышны кайгырта башласаң булмый ул. Бергә торыйм дисәң, Мотгәрәй кебек кыю, тәвәккәл булырга кирәк.

Ләкин Рәйсә көткән тәвәккәллек һәр икесе тарафыннан да булмады. Валентин: кал, мин сине яратам, җибәрмим,— дип өзеп кенә әйтә алмады, кызы горурланып баш бирмәде, менә эш кетә дә фәлән-төгән, дигән булды. Килешә алмадылар. Юк шул, мәхәббәт дигән нәрсә дә җимеш кебек икән, вакыты җитмичә пешми дә, өзелеп тә төшми икән.

Таң ату белән Валентин Зөбәеровның шоферын уятып, машина алып кайтты. Ул Валяны ерак Ташлыяр мәйданына кадәр озата барачак иде.

Валя белән кабинага кереп утыргач һәм кузгалабыз дип кенә торганда, өнenә-тынына капланып, буровойдан Габбас чабып кайтты. Ул мазутка баткан, танымаслык булып каралган иде.

— Тин-Тиныч, нефть чыкты бит, нефть! — дип шашынып акыра иде ул.

Тимер көпчәкле тарантасында, «һай, һай!» дип атын куа-куа, Баланлы ягына таба Галләм узып китте.
Ат өстендә, каты юртып, кайдандыр югары очтан авыл башлыгы Хафизов килеп чыкты.
— Әй, кешеләр, ишетәсезме, нефть! Нефть! — дип кычкыра иде ул бар көченә.
Бер генә минутка капка төбендә туктап, машина янында аты белән таптанып торды.
— Җен икәнсез! Молодцы! Булдырдыгыз! — һәм сөрән салып буровойга таба чапты:
— Кешеләр! Ишетәсезме, нефть! Бәйрәм бүген! Не-фет! Барыгыз да ми-ти-нгка!..
Шушы төндә генә тормышка хәер-фатиха алып, шушы төндә генә жылы куеныннан ирен — Мотгәрәйне буровойга озатып җибәргән Фәридә дә ишетте бу тавышны. Иртән суга барган җирендә — кое янында көянтә-чиләкләрен ташлап, үкси-үкси өенә кайтып китте...
Сабирҗаннарның ишегеН киң ачып өйдән Рәйсә атылып чыкты.
Спецовка җиңен кия-кия, баскычтан Камил сикерде:
— Дөресме, Габбас абый?
— Нефть дисеңме? Чыкты дисеңме? — Тин-Тиныч кабинаны ачып җиргә сикерде.
— Чыкты инде, чыкты! Мастер анда яхшы киемнәре белән муеннан нефтькә чумып йөри! Әй, күрсәң иде ничек кыланганын нефтьнең! Өскә атылмакчы торбадан! Без аны балчык белән бастырмакчы — ә ул һаман бәрә! Без аны барит белән бастырмакчы — ә ул һаман атылмакчы!
— Атылмакчы дисеңме? Бәрә дисеңме? Менә бит ул ничек, Валя!

> Бәрә нефть девон куеныннан,
> Ургымакчы булып һавага!
> Атылмакчы булып болытларга
> Шашып-шашып өскә яварга!..

— Тукта әле, Тин-Тиныч, шигырь соңыннан! Сиңа мастер хәзер үк бөтен бораулаучыларны җыеп буровойга килергә кушты.
Йортларда ишекләр ачылды, капкалар шыгырдады, урамнарга, тыкрыкларга кешеләр тулды.
Язтургайның яңа таңы уянды.
Һәркайда иртәнге тынлыкны җимереп «нефть», «җир мае», «кара алтын» дигән сүзләр ишетелә, разведчиклар исеменә мактау сүзләре яңгырый...
Башта берәм-сәрәм, аннан икәүләп, өчәүләп, тора-бара төркем-төркеме белән Баланлы төбәккә карап юл тота башлады халык, әйтерсең ирләре, хатыннары, бала-чагалары белән авыл Баланлыга күченә. Барысы да буровойга, әнә шул урман буендагы серле, хикмәтле булып җәй буе, көз буе утырган вышкага таба бара. Кешеләр Баланлы төбәктә чыккан могҗизалы җир маен үз күзләре белән күрү өчен ашыгалар. Баланлы юлы атлар чабышын, машиналар ярышын, кешеләр узышын хәтерләтә.
Ә телләрдә: нефть, нефть, нефть!
Инде бу бәйрәмне, бу тантананы ташлап Валя да китә алмый. Әнә күзләрен тутырып сорау, ялвару белән аңа Валентин текәлгән. Ул да хәзер эшен ташлап озатырга бара алмаячак...
Калмый булдыра алмый хәзер Валя... Егетләрнең шатлыкларын уртаклашырга кирәк...
Һәм Валя, сихерләнгән шикелле, Тин-Тиныч белән кабинада утырып Баланлыга бара...

Инде барысы да эшләнде кебек. Буровой җиһазлары озатылды, машинага кирәк-яраклар төялде, кайсы кая таралып беткән кешеләр дә җыелды — кузгалырга вакыт.

Зөбәеров, буровой күперчегеннән тирә-ягына каранып, тагын берничә минут басып торды. Кырларны, аланлыкны, урман өсләрен тутырып Баланлы төбәктә ишеп-ишеп кар ява. Беренче кар. Аның йомшак мамыгы төркем-төркем булып автобус янына җыелган разведчикларның киемнәренә, аларны озата килгән Язтургай кешеләренең җилкәләренә, бүрекләренә, шәлләренә катлам булып утырырга өлгергән.

Бирегә авылның әллә тагын ярты халкы килгән. Бораулаучыларның фатир хуҗалары, механизаторлар, мәктәп балалары, тагын Зөбәеров өчен таныш булмаган апалар, абыйлар, әбиләр, бабайлар... Алар арасында укытучылары белән мәктәп директоры Дәминов басып тора, зур гәүдәсе белән кешеләрне ерып, авыл Советы председателе Хафизов йөри. Ул кайсына кулы белән кагылып үтә, нәрсәдер әйтеп, кайсының җилкәсеннән кага. Кешеләр көлешәләр, тавышланалар, төртептөртеп Зөбәеров ягына — буровойга таба күрсәтәләр. «Әнә шул үзе инде буровойның башлыгы, шул Зөбәеров дигән мастер инде Баланлы төбәктән нефть табучы», диләр бугай. Халык бит ул кызык: зур бер коллективның эшен дә аерым бер кешенеке итеп күрсәтергә өйрәнгән. Сәгать төзәтү мастерлары яки итек тегү осталары белән тиңлиләр, күрәсең.

Кызлар тирәсендә аеруча җанлылык. Халатларын да салмыйча, ашыгып, сыер савучылар килгән, безнең егетләр күбрәк шулар янында чуала. Алар арасында киемнәре, йөреш-торышлары белән өч кыз аерылып тора — болары үз кешеләр, буровойга кочегар булып эшләү өчен Ык буеннан әле кичә генә килеп төшкән Гөлниса, Кәримә, Разия...

Безнең егетләр эше — яшерен хатлар, танышулар нәтиҗәсе. Кызлар икенче сезонны да разведчиклар белән үткәрәчәкләр. Әйдә, барсыннар. Шәп кызлар, уңган кызлар. Тиздән машина аларны бораулаучылар белән Язтургайдан унбиш километр ары Баллы авылы кырына алып китәчәк. Яңа нефть чыганагы эзләп килгән разведчиклар быел кышын Баллыда төпләнәчәкләр.

Зөбәеров сәгатенә карап алды. Китәргә вакыт, кызы Ләйлә белән Рәйсә әле һаман Язтургайдан килеп җитмиләр. Озатырга дип әзерләнеп йөргәндә генә иртүк Сабирҗаннарга алып кереп киттеләр. Картның хәле начарлана башлаган. Фатир хуҗасы гына түгел бит әле ул Сабирҗан, бораулаучы Камилнең этисе дә. Һәрвакыт шулай җайсыз туры килә инде Фазыл белән Рәйсәгә — киткәндә рәтләп хушлаша да алмыйлар.

Борчылып, Зөбәеров халык җыелып торган урынга килде.

Сорау артыннан сорау яудыра кешеләр:

— Карагыз әле, иптәш мастер, электр мәсьәләсе ничек, сез киткәч сүнәчәкме ул, яначакмы?

— Киресенчә, без киткәч, бөтен авыл гөлт итәчәк! Бүген-иртәгә безнең урынга нефть чыгаручылар килә. Алар инде күченеп йөрүне яратмыйлар...

— Рәйсә апа бездә каламы, әллә үзең белән алып китәсеңме?

— Сезгә яңа Рәйсә бирерләр...

— Бу нефть дигәннәре озакка барыр микән?

— Кайгырмагыз, сезнең гомергә җитәрлек.

— Безнең Язтургайда нефть Ромашкинодагыдан да күбрәк диләр, дөресме?

Зөбәеровка лектор ролен дә үтәргә туры килә. Ул Язтургайда шушы скважина белән яңа чыганак ачылу турында, аның Ромашкино чыганагыннан аерым булуын, ләкин әле нефть запасының билгеле түгеллеген, разведчикларның бурычы шуны ачыклау икәнлеген сөйләп китә.

Сораулар кубәйгәннән-кубәя барып, аңа җавап биреп бетерергә мөмкинлек калмагач, Зөбәеров үзен кысып алган халык арасыннан чыгып тайды. Хафизовны эзләп тапты ул.

— Озаклады бит синең фельдшерың,— диде, сәгатенә карап.— Сабирҗан бабай ныклап чирләп китте микәнни соң?

— Аның чире безгә мәгълүм инде, бер бүген генә түгел. Рәйсә урынында булсам, төкерер идем мин аның капризларына!

— Нигә алай дисең, иптәш Хафизов? Чир сорап килми бит ул...

— Именно ул чирне үзе теләп алды! Сугышка бармас өчен. Әнә, кордашы Галләмнән сора аның кем икәнен...

Ә кешеләр бер хәбәрсез көлешәләр, шаулашалар, нефтьчеләр белән әңгәмә алып баралар. Яшьләр бер тирәдәрәк. Авыл кызлары бораулаучы егетләр янында чыр-чу килеп, Фәрхетдинне ирештерәләр:

— Кызганыч, атказанган артистыбыз да китә.

— Аннан башка кем чыгар инде хәзер ялан аяк сәхнәгә?

— Монысы әле аның ничего! — ди Фәрхетдин.— Менә кыш көне кардан йөреп карагыз әле ялан аяк!

— Карда да йөргәнең бармы?

— Егет чакта кеше башына ниләр генә төшми! Шулай бер вакыт, юк, монысы хезмәттә түгел, буровойда эшләгән чакта, вахтадан соң киттем кыз янына. Шундый назлы нәрсә — капка төпләрендә көттерергә ярата иде. Ягъни мәсәлән, минем чыдамлыкны сыный бу. Ә кышкы суыкларда, үзегез беләсез, ай-һай, авыр көтеп торулар! Бер минуты бер ел! Моңа кадәр дә салкыннар үзәкка үткәч, әчтән яхшы гына төренеп, аякка олтанлы итекне киеп алдым. Юк, мин әйтәм, сандугачкаем, Фәрхетдин дә юкәдән ясалмаган, мондый калын табанлы пима белән хәзер суык түгел, бронебойный снаряд та ала алмас! Уем шул: биш сәгать көтсәм дә киту юк капка төбеннән!

Часовой урынына басып күпмедер торгач, ниһаять, чыкты бит минем асыл кошым. Йөгереп барып биленнән кочарга дип омтылып карыйм — кузгала гына алмыйм бит урынымнан! Итекнең төбе бозга каткан! Кызым килеп култыклап алды, клубка кинога сөйри башлады, ә мин казып утырткан мыни, баскан урынымда каткан да калган! Шулай да кызга сиздермәдем, аякны кубарып алдым. Итек олтаны бозга ябышып калды, без клубка киттек. Кар өстеннән ялан аяк атлыйм.

— Өшисеңме әллә? — ди кызым.— Юк, мин әйтәм, киресенчә, мин тирлим! Ә суыгы! Табаннардан чымырдап кереп, йөрәккә кадәр менә! Киносы ничек булгандыр — хәтерләмим. Тик шунысы истә: кешеләр йоклап утыра, ә мин бии-бии кул чабам. «Неужели шул кадәр интересно?» — дип гаҗәпләнә кызым.— Мин бер дә кызыгын тапмыйм»,— ди. Ну, мин әйтәм, надан да инде син! Бу бит сәяси картина! Моны аңлау өчен гыйлем кирәк!

— Ул кадәр үк ялан аяк булмагандыр инде,— дип көлешәләр кызлар.

— И уйлап та чыгара соң әкиятне!

— Әкиятме? Ышанмасагыз үзеннән сорагыз.

— Кемнең?

— Кызның!

— Каян табыйк ди без синең әллә кайдагы кызларыңны!

— Табабыз аны!

Фәрхетдин Гөлнисага таба борылды.

— Әйт, Гөлниса, дөрес бит кинода йоклап утыруың?

— Әгәр шунда, Фәрхетдинкәем, ялан аяк утырганыңны белсәм, тәпиеңне учымда гына тоткан булыр идем!..

Шып булдылар Язтургай кызлары. Бораулаучы егетләр тамак кырып алды. Барысы да аңлашылды. Моңа кадәр Фәрхетдин бер вакытта да анекдотның иясен, фактларны күрсәтеп сөйләми иде. Бигрәк тә кызлар алдында. Бу инде Фәрхетдиннең башка кызлар белән араны өзүе, янында үзенең «сандугачы», «асыл кошы» бар икәнен ачыктан-ачык белдерүе иде. Күптәнге дуслар Гөлниса белән Фәрхетдиннең кавышуы шушы икән. Менә ни өчен хат язган икән егет Ык буйларына, менә ни өчен килгән икән Гөлниса бу якларга...

Шушы минутта гомер шаян Фәрхетдин бөтен кызлар, егетләр алдында беренче мәртәбә олыгая башлаган җитди кеше булып килеп басты. Әйе, Фәрхетдиннең дә гамьсез яшьлеге узып бара...

Кемдер:

— Рәйсә килә! — дип кычкырды. Халык арасында:

«Духтыр килә! Мастерның җәмәгате килә» — дигән сүзләр йөгерде.

— Рәйсә духтырны да алып китә булыр инде ул...

— Духтырсыз ни эшләрбез инде хәзер?

— Урынына яңа кеше килә диләр ич...

— Бигрәк тә уңган, бигрәк тә булган хатын иде...

Зөбәеровның машинага утырырга команда бирүе булды, халык тагын гөжли башлады. Хушлашулар, кул бирешүләр, арка кагышулар, кочаклашулар китте. Һәр бораулаучы үзенең фатир хуҗасын тапкан, янына кызларны, егетләрне җыеп алган. «Гаеп итмәгез»ләр, гафу үтенүләр, «тагын килегез»ләр, кунакка чакырулар... Язтургай кызлары янында инде бары тик Сергей, Габбас, Нәҗипкенә калган... Кем белсен, бәлки, Язтургай чибәрләренә алар салып киткән очкын киләчәккә зур мәхәббәт уты булып та кабынып китәр...

Тин-Тинычны озатырга Ташлыяр мәйданыннан Валя килгән. Иртәдән бирле ике гашыйк бер-беренә сыенып, култыклашып, читтә басып торалар. Валя Тин-Тинычка үзенең монда ничек килүе турында сөйли. Сөйләгәндә тавышы бик әкрен булса да, көлгәндә һаваны ярып, чыңгырап тора:

— Көнләшсәң көнләш, дустым Тин-Тиныч, синең хакка тәки үбәргә туры килде бит начальникны! — ди ул. — Тфу, иреннәрендәге тозлы балык тәме әле дә булса авызымнан китми!

— Син кара аны! — дип бармак яный Тин-Тиныч.

— Гариза тотып, бер генә көнгә җибәрүен үтенеп, өч тапкыр кердем шеф янына. Сөенде бу үзенә ялынычым төшкәнгә, куанды, кинәнде, бичара! «Әйт, кемең янына барасың анда Язтургайга?» — дип теңкәгә тия. Ахырда әйттем: «Сөйгән егетем янына», дидем. Агарынып, күгәренеп китте. «Сөйгәннәреңне белмим дә, күрмим дә, никах язуыңны китер, җибәрәм»,— ди. Кирәк булса бер түгел, бишне алып кайтам, мин әйтәм. Уйлап кара, нинди түбәнчелеккә төштем: зинһар, җибәр инде, җаным, дип үбеп алдым үзен. Тфу, әле дә булса тоз тәме авызымнан китми!

— Елан инде ул хатын-кыз!

— Бер үбү — каян килеп кая китмәгән иде дә... Тынычлык бирмәс инде ул хәзер миңа... Үзенә карамаган өчен төрле сәбәпләр табып, шелтә артыннан шелтәне тондырып кына торыр...

— Безнең янга күч, Валя! Ишетәсеңме, хәзер Язтургай мәйданы телгә менде! Сенсация! Үзебез дә белмичә яңа нефть ятмасы ачканбыз бит! Кил, эш монда барыбызга да җитәрлек. Бәлки, бу ятма Ромашкино ише генә дә түгелдер!..

— Тәртибеңә карармын! — дип тагын чыңгырдатып көлә Валя. Һәм эченнән генә уйлый: «Эшләп булмас ул начальник белән... Валентин янына күчәргә туры килер...»

Кызы-Лэлэсен күтэреп алган Зөбэеров бораулаучыларны автобуска куа.

— Утырышыйк, җәмәгать, соңга калабыз. Сергей, ишетәсеңме, кузгалабыз! Син кая киттең әле, Нәҗип, Габбас, җитте мәхәббәт сату! Җибәрегез аны, кызлар, тотмагыз! Ах, авыр да соң аерылышулар!..

Шул арада Зөбэеров бер генә минутка Рәйсәсе янына туктый.

— Исәп-хисапларың белән соңлама инде, Рәйсә... Шуны бел, сине яңа урында да көтәләр...

— Сабирҗанның хәле начар... ычкыныр, ахры... Бүген булмаса иртәгә...

— Димәк, Камил бүген килә алмаячак?

— Әйе, бу араларда аңа әтисе янында булырга кирәк...

Зөбэеров кызының суыктан кызарып чыккан бит алмасын үбеп алды да әнисенә бирде.

— Яхшы гына тор, кызым, авырма, елама...

Автобустан ишелеп егетләрнең төшә башлаганын күргәч, Зөбэеров кычкырып машина янына ташланды.

— Тагын нигә кузгалдыгыз әле!? Нигә коеласыз?

— Мотгәрәй юк бит, мастер!

— Тагын югалдымыни? Ну, бу Мотгәрәйне!

— Килмәс инде ул, мастер,— диде Кадермәт, уфтанып.

— Уе аның буровойда түгел...

— Әлбәттә, килми! — диештеләр бораулаучылар.— Яшь хатынын ташлап нигә безнең белән китсен ул! Бигрәк тә сөйгән комбайнын!

Зөбэеров бер мәлгә уйланып калды.

— Әйе, хәзер инде Мотгәрәй безнең өчен киселгән икмәк...

Шулай ук хушлашырга да килмәс микәнни?

— Минем, мачтыр, шундый тәкъдим бар,— фуражкасын кырын салып, арага Фәрхетдин керде.— Кешене разведкага алганда моннан соң тикшереп алырга кирәк. Сынау кебекме шунда бер нәрсә үткәреп. Пашпортын карарга: ялгыз булуы — беренче шарт. Әгәр инде буйдак икән, ант бирсен: бер вакытта да кызларга карамаска! Өйләнмәскә, йорт-җир кормаска, бала-чагалы булмаска! Разведчик барысыннан да ваз кичәргә тиеш!

Ләкин Зөбэеровның хәле шаярып-көлеп торудан узган иде.

— Барып килергә кирәк фатирына.

— Өенә диген, нинди фатир булсын!!

Машинаны Язтургайга борырга дип кенә торганда арадан берәү кычкырды:

— Мотгәрәй килә! Әкәмәт!

Яхшы күк айгыр җигелгән председатель чанасында Фәридә белән янәшә утырып килүче кеше, чыннан да, Мотгәрәй иде. Атны колхоз председателе Галләм куа.

— Килештерә белә бу Мотгәрәй! — диештеләр разведчиклар.

Атлы чана, халык төркемен урталай ярып, автобус янына килеп туктады. Чана тәртәләре хәтта машинаның артына төртелделәр.

Чанадан берьюлы диярлек өч кеше сикереп төште.

Чак кызмача Галләм Зөбэеров янына килде:

— Син аны кичер инде, мастер. Соңладык... Мин гаепле... Ни әйтсәң дә безнең авыл кияве бит Мотгәрәй... Кызганыч, калдырып булмады үзен... Белмим, нефтьтә ничектер, әмма комбайнда үтергән дә куйган! Кирәк иде мондый кешеләр безгә... Нишлисең!..

Бу вакытта Мотгәрәй, беркемгә игътибар итмәстән, Фәридә белән хушлаша иде. Ул Фәридәсенең бармакларын учларына йомарлап тоткан, күкрәгенә китереп кыскан, гүя хатынына үзенең йөрәк тибешен тыңлата иде.

— Борчылма, Фәридә, жае чыгу белән мин сине килеп алырмын... Бергә яшәрбез, кайгырма,— дип юата иде.

— Кара, Мотгәрәй дә ярата белә икән! — дип гажәпләнделәр бораулаучылар.

Ә Фәридә, күз яшьләренә тыгылып, өмет белән Мотгәрәйгә карап тора, сизелер-сизелмәс иреннәрен кыймылдата:

— Синсез ничек яшәрбез инде... Озаклама... Онытма безне...

Әле утырышкач, машина кабынгач та, разведчиклар кызыксынып автобус тәрәзәсеннән бичара парлыларның аерылу минутларын карап тордылар. Кызык, һәркем үзенчә хушлаша икән. Тин-Тиныч Валя каршына басып кулларын селти-селти нидер исбат итә дә, Валяны үбеп, автобуска йөгерә һәм тагын килеп кулларын болгый башлый. Аерылышу турында шигырь сөйли бугай...

Мотгәрәй дә автобуска ашыга, ләкин муеныннан һаман Фәридәнең кулларын ычкындыра алмый.

Зөбәеров белән Рәйсә, кечкенә Ләләне туп урынына кулдан-кулга йөртеп, бер-берсенә әйтәсе сүзләрен, хисләрен бала аша белдерәләр:

— Хуш инде, әти, диген, кызым. Авырма-чирләмә, яхшы гына эшлә, диген...

— Язтургайда озак юанмыйк инде, әни, диген, кызым. Безне анда әти сагынып көтә, диген...

Зөбәеров, кискен борылып, автобуска менеп утырды да шоферга кузгалырга кушты.

Киттеләр. Тагын билгесез якларга, яңа урынга, яңа мәйданга, таныш булмаган кешеләр яши торган җирләргә, авыр эш көткән Баллы кырларына киттеләр. Артта разведчикларга хәерле юл теләп, дистәләгән кеше кул изәп калды.

Хушыгыз, дуслар! Тау итәгендә баскыч-баскыч булып утырган тәбәнәк өйләрең, тар урамнарың, кысан тыкрыкларың белән, Баланлы төбәгендәге шаулы иманнәрең, Сагындык буйларың, чокыр-чакырлы басу-кырларың белән хуш, Язтургай!

Авыл тормышы өчен янып-көеп, һәрнәрсәгә куанып, китапча сүзләр кушып, газета информацияләре кертеп сөйли торган киң күңелле Хафизовларың, үз колхозыннан башканы белергә дә, ишетергә дә теләми торган дуамал Галләмнәрең, төртмә телле, оялчан карашлы кызларың һәм, ниһаять, әрлән кебек үз оясын гына кайгыртучы калтыравык Сабирҗаннарың белән бәхил бул, Язтургай!

Монда кыр бүлешеп, өй бүлешеп, кысылып яшәгән чаклар, «булыр микән, юк микән» дип борчылып-хәвефләнеп эшләгән вакытлар, зур мәшәкать һәм газаплар белән тиреннән нефть аттырган көннәр күңелдән китмәс инде... Бер вакытта да китмәс...

Мотгәрәй (аерылышу тәэсиреннән айный алмыйча, алдында һаман Фәридәне күреп, аның тавышын ишетеп, аның белән күңеленнән сөйләшеп бара). Ничек синсез яшәрбез инде, дисең. Үзең үйлап кара, Фәридә, китми булмый бит... Синең янда калсам, буровойда бергә эшләгән иптәшләрем ни уйлар? Юк, мин, Мотгәрәй йортка керде, дип әйтүләреннән курыкмыйм. Төкерәм мин ул сүзләргә. Мин сине яраттым. Тик кешеләр нефть кадәр нефть чыгарганда синең ишек алдында бикләнеп кала алмыйм... Вөҗданым кушмый... Ләкин син борчылма, Фәридә, жае чыгу белән мин сине килеп алырмын...

Тин-Тиныч (баш чайкап, үз-үзенә гажәпләнеп бара). Син тагын кая киттең соң әле Валентин Валентинович? Синең Язтургайдан да ары китмәскә дип биргән антларың кайда? Нәрсә өчен дип килгән идең бу якларга, Валяны эзләү өчен түгелме? Я, таптың, максатыңа ирештең, шулай булгач, нигә дип монда утырып барасың? Нигә китмәдең Валяңа яреп? (Көрсенеп ала.) Тормыш син уйлаганча ансат кына түгел икән шул, Тин-Тиныч! Син көткәнчә җиңел генә үзенә чакыра

торганнардан да, няреп китүчеләрдән дә булып чыкмады Валяң. Әле һаман «тәртибеңә карый». Әле һаман булса сыный. Әйдә, сына, кыландыр, җаным, түзәрмен! Менеке генә бул!

Сапарбай (кызып-кызып янында утырган Кәримә белән сөйләшеп бара). Син мине һаман шул «калым» белән үртисең, Кәримә. Мин гаепләме монда? Йола, гадәт шундый булгач, җыйган идем инде... Рәйхана үзе дә бик чибәр кыз иде... Юк, сез, нугайлар, бернәрсә дә аңламыйсыз!.. Чын, син көлмә, Кәримә. Хәзер мин үзем дә төшендем... (Кинәт.) Телисеңме, бөтен акчаны сиңа бирәм! Юк, калым итеп түгел, болай гына! Кая куйыйм мин эшләгән акчаларны хәзер? Көлмә, Кәримә, көлмә...

Фәрхетдин (иң арттагы утыргычта Гөлнисаны кысып алган). Ни эшләттең син мине, Гөлниса, нинди ырымнар белән сихерләдең?! Ык буеннан киткәндә әллә сөйдергеч бөти тагып җибәрдеңме? Мин бит мона кадәр кызларны санга сукмый идем.

Кадермәт (тәрәзәгә борылып, кешеләргә күрсәтми генә хат укый). «Иптәш Имаметдинов! Берләшмәнең кадрлар бүлеге Сезгә кабат мөрәҗәгать итә: Сез махсус белем алган кеше, тау техникы, бораулау белгече. Шулай булгач, кадрлар бүлеге Сезне яңадан үз эшегезгә кайтырга, яңа төзелгән бригадада мастерлык вазифасын үз кулыгызга алырга чакыра.

Кадрлар бүлеге начальнигы: Куприянов.

P. S. Кадермәт, бала булма, үткәннәрне онып! Гаеп атта да, тәртәдә дә булды. Шушы арада берләшмәгә килеп чыгуыңны көтәм».

Һаман онытмыйлар үзләре. Кеше җитми, күрәсең... Юк шул инде, иптәш Куприянов, миңа монда да начар түгел. Рәхмәт, какшаган нервларымны ныгытырга дип җибәрдегез. Хәзер, аллага шөкер, савыгып киләм...

Саакян (тәрәзәгә карап күңелсезләнеп бара). Кайтып булмады, ахры, инде туган якларга... (Үз-үзенә гаҗәпләнеп). Кара син, бер-ике генә буровойда эшләргә дип килгән кеше кая китеп бара? Ошады сиңа Татарстан! Мастер Зөбәеров Ибраһим-Зададән ким булып чыкмады. Бригада кешеләре дә менә дигән...

Миргазиян (янәшәсендә утырган Саакянга). Нәрсә, Сергей брат, уйга чумдың? Әллә Арарат буйлары искә төштеме?

Саакян (Миргазиянга төрттереп). Менә, уйлап барам әле: бу крестьян балаларыннан «рабочий класс» чыгар микән, дим.

Зөбәеров (аларның әңгәмәсен елмаеп тыңлап барганнан соң, түземичә, артына борылып). Кызык бәндә син, Миргазиян туган! Инде Мотгәрәй булып Мотгәрәй дә бездән калмагач, крестьяннан эшче чыкты дигән сүз инде.

Миргазиян (ык-мык итеп торгач). Алай дип үк әйтеп бетермә, мастер... Рабочий класс — зур ул! Әкәмәт тә зур...

Зөбәеров (тун төймәләрен ычкындырып). Уф, исән-сау китәсе көннәр дә бар икән. (Моңсуланып.) Утсыз-сусыз җиргә киләсең, җиде кат җирне тишәсең-тишәсең дә китеп барасың. Син киткәч, монда алма тәгәрәтерлек юллар сузылыр, чөлтәр баганалар килеп утырыр, утлар балкыр. Якты, зур урамлы, ташпулатлы шәһәр салыныр. Шуларның барысын нәкъ менә син, җир мае эзләүче тынгысыз кеше китергәнне кешеләр, матур калаларда яшәүче бәхетле кешеләр, башларына да китермәсләр. Син — разведчик. Синең исемең әнә шул яңа калаларда, яңа юлларда, яңа утларда...

Алда сине тагын яңа борчу, яңа мәшәкатьләр көтә.

*Лениногорск.*
*1968—1972*

## Әхсән Баянов

### Челтәрләргә карап

Дөнья киң.
Шуңадыр аны
Кискәләгән челтәрләр:
Милләтләр,
Илләр,
Сыйныфлар,
Меридианнар,
Бүтәннәр...

Күп анда ялган сызыклар,
Бөек,
Изге чикләр бар.
Кай адәмнәр
Изгесен дә
Җимереп,
Таптап үтәләр.

Үтәләр дә,
Күкрәк кагып,
Безгә бармак төртәләр.
Аларны хыянәтче дип,
Я... герой дип йөртәләр...

Күк үкерә өлап,
Шуларны
Күккә чөеп йөртүдән.
Үлгән геройлар
Кабердә
Борылып ята йөзтүбән.

Нәфрәтләрен тешкә кысып,
Яши бирә терелләр.
Алар,
Вакыты җиткәнче,
Әле герой түгелләр.

Мин дә дәшмим.
Тик сүз бирәм:
— Тиргәсәң дә, сойсәң дә,

Булган даннарың яңгыратып
Шатлансаң да,
Көйсәң дә —
Мин булырмын синең белән,
Әй, күпне күргән халкым! —

Бу инде
Гомердә минем
Беренче,
Соңгы антым.

●

Көлке түгел, әби чәч буятса,
Иннек сөртсә, кершән ягынса.
Ул елларның булыр үз шөгыле,
Ачыл бүген! Бөтен барыңча
Ярат мине!

Син яшьлекнең фани байлыкларын
Инде кемгә саклый, җыясың?
Килер буын табар башкаларын,
Ә боларын кая куярсың?
Ярат мине!

Күкрәгеңдә — сөю, пар тәлгәше
Йөзем төсле изге җимешнең.
Киләчәкнең булыр үз бәхете,
Ә болары — минем өлешем,
Ярат мине!

●

Сөям диеп үзең әйтмәсәң дә,
Мин барыбер аны ишеттем.
Кичектең, дип, синең сүзне килеп
Әйтә алмас инде һичберкем.

Ялгышуың кабат аңлап, дустым,
Шул кадәр дә дөрес иткәнсең.
Мәхәббәттә соңга калу юк дип,
Сандугачка сөйләп киткәнсең.

Шул кадәр дә моңлы синең хисләр —
Йокыларны бүлә таңнарда.
Серләреңне сөйли сандугачлар,
Сөюебез илгә тарала.

●

— Без аерылдык, инде сөймимен.—
Дусларыма шулай сөйлимен.
Кабатлыймын кичен-көндезен:
— Сөймимен.

Шулай уза көннәр-иртәләр,
Ямансулап кичләр җитәләр.
Тәрәзәңне күзләп йөримен:
— Сөймимен.

Тәрәзәңдә утлар янсалар,
Җанга, никтер, рәхәт чәнчәләр.
Ә караңгы булса, билге, дим:
— Сөймимен.

Ул бит инде күптән чит, димен.
Эзләреңне ләкин эзлимен.
Нигә шулай эзлим, белмимен.
— Сөймимен,
Сөймимен,
Сөймимен!

## Картаелды

Беренче кат күргәч кырда,
тракторга:
«Күк арбасы төшкән!» диеп,
бала-чага
Иярә йөрдек чаба-чаба.—
Булды дәвер...
Айга менгән арба сәер
түгел хәзер.

Урамнан уза калтырап
атлы арба.
Артыннан этләр һау-һаулап
өрә бара.
Еллар түгел, чорлар кичтек...
Ярый әле,
Ярый әле, кызлар әз-мәз
карый әле...
Һай, гомерләр!

●

Хыянәтче төсле минем күзләр,
Серләремне саклый белмиләр.
Сөюемне, рәнҗү, шикләремне
Сөйләп йөри, чәчеп йөриләр.

Кемгә булса ачулансам, күреп
Кайтара ул моны йөзләтә.
Кемне булса мавыгып күбрәк сөйсәм,
Ул масаеп мине йөдәтә.

Үпкәләсәм, йомшаклыгым сизеп,
Кабат үртәп, кабат яралый.
Кемне булса мин артыграк сөйсәм,
Кемгәдер бу тагын ярамый...

Хисләремне яшерә белсәм, нинди
Тыныч яшәр идем мин, җүләр!
Күзләрем тик — хыянәтче төсле,
Серләремне чәчеп йөриләр.

## Кечке диалог

— Әйт әле, ник мине яратасың,
Яратырлык миндә нәрсә бар?
— Чибәр булган өчен...
— Алай дими бер дә башкалар,
Мин матур тик сиңа гына. Уйлап кара.
— Ә Зөһрә соң ник Таһирны сөйгән?
Джульетта ник Ромео өчен үлгән?
Галиябану диеп Хәлил җанын биргән,
Ник соң?
— Мин бит сорыйм синнән!
— Бөек Гейне гади кибетче кыз өчен
Шашып йөргән... Ник соң?
Ник кояшсыз яши алмый үлән?
Мин дә белмим, нигә яратамдыр,
Әйтсә моны безгә
Афродита гына әйталыр.

●

Тәмәкедән калган төпчек итеп
Таптап уздым синең карашны.
Нишлим инде, үзең шундый түбән
Караш белән карап баргач соң.

Йөрәгеңдә рәтле ният булса,
Калмас идең күзгә карамый.
Авыр йөкләр шулай аска тарта,
Ә яхшылык җирдә аунамый.

Оялулар, тыйнак уйлар түгел,
Чыраеңда көйри үч синең.
Ә мин карыйм шул йөзгә дә туры,
Сизәм, синнән байтак көчлемен.

Мин кичердем барлык яманлыгың,
Таптап уздым күңелең карасын.
Һәм уйларым йөри синнән өстә,
Аларны син таптый алмассың.

●

Горурлыгым, ирлегемне онытып,
Әй, үкседем әрнеп мин бүген.
Газапларым синең хыянәттән
Түгел ләкин,
Түгел,
Юк,
Түгел!

Малай чакта үлгән аксак этем
Искә төшеп кисте бәгырьне.
Шул көннәрдән бүгенгәчә булган
Югалтулар яшькә әверелде.

Кичә кемдер каты дәшкән иде,
Еладым бүген шуңар үпкәләп.
Хәтерләдем күпне... Кирәк булса,
Табылачак тагын мең сәбәп.

Горурлыгым, ирлегемне онытып,
Өзгәләндем шуңа мин бүген.
Тик уйлама, кичә син ясаган
Җәрәхәттән түгел,
Түгел,
Юк,
Түгел!

●

Ярый әле, тәмуг дигәннәрен
Чынлап яратмаган Табигать.
Гүр җәзасы бары кызык әкият,
Безгә шулай әйбәт бу бигрәк.

Син китергән сагыш, әрнешләрдән
Каргышларым төшеп, я раббым,
Ул дөньяда син кичерер идең
Монда мин кичергән газапны.

Янар идең... Юк, ялгышам ләкин,
Күрмәс идең син ут диңгезен.
Синең өчен төшеп, анда тагын
Кисәү булыр идем мин үзем.

1971

## Фәния Чанышева

### Гомер мизгелләре

Уналты яшь — умырзая
Язның якты иртәсендә,
Унҗидедә идеалларың
Җидегән йолдыз тирәсендә.

Егермедә бу гомерең
Пешеп җиткән анар кебек,
Утызларда — күкрәгеңдә
Дәртләр мәңге янар кебек.

Кырыкларда кырынрак
Минутларның артыр чагы,
Көч-гайрәтнең ут-суларны
Кичеп чыга алыр чагы.

Кырыкмаса кырык төрле
Хыялларың — кырык биштә.
Яшьлегеңнән аерылырга
Ниятең юк әле һич тә.

Илледә дә илле эшең
Сине көтеп ятар сыман,
Бу дөньяга мәхәббәтең
Илле тапкыр артыр сыман.

### Хәсән Туфанга

Материя мин, җаным, бары аның
Уйлый, җырлый, сагына торганы...

*Х. Туфан.*

Булды артка чигеп дереслеге,
Иңнәреңне басты ялганы.
Әрнүләрнең бардыр күңелеңдә
Мәңгелеккә торып калганы.

Булды,
Карлы-бозлы яңгырларның
Сиңа гына атап яуганы,
Сагышларның сары койганнары,
Кайгыларның йөрәк ярганы.

Булды,
Тын кичләрдә ерак офыкларга
Карап күзләреңнең талганы,
Туган якка аккан болытларны,
Кыр казларын озатып калганың.

Бирешмәде ләкин шигъриятең,
Имин калды намус, вөҗданың,
Кайтарасы иде елларыңның
Дусларыңнан читтә узганын.

## Тыңлагыз, Казан сөйли...

Җилләр инде яфракларның
Соңгыларын җиргә сибә;
Кар аралаш яңгыр ява,
Бик ямансу әллә нигә...

Шул сагышлы көзге көнне
Таныш тавыш котлый безне,
Ул хәерле иртә тели:
— Тыңлагыз, Казан сөйли!

Килеп керде дусларымны
Иң сагынган чакта гына,
Алып китте Казанына,
Чаллы, Кама якларына...

Иркәләде колагымны
Әткәм-әнкәм сүзе белән,
Салих Сәйдәшев моңнарын
Алып килде үзе белән.

Шушы моңнар озатып бара
Елларымның агышында,
Алар җылы агым булып
Кергән минем язмышыма.

Бүген дә боек күңелемне
Ул туган моңнарга күмде,
Ак бәхетләр тели-тели:
— Тыңлагыз, Казан сөйли!

# Без һаман бергә икән...

*Сибгат Хәкимгә*

Алтмыш ел — алтын гомерең
Син сарыф кыл да икән,
Уйланма да, моңланма да
Чын шагыйрь бул да икән.

Дусларым якында гына,
Бергә дип йөр дә икән.
Агыйдел, Дим тугайларын
Бер барып күрмә икән.

Йөз яшьтә дә әйтсәк иде:
Юлыгыз үргә икән.
Урыныгыз түрдә икән,
Без һаман бергә икән!
Бергә икән!

**Нэзир Сэфэрев**

# КАРГЫШЛЫ ҺӘМ ӨМЕТЛЕ КӨН

РОМАН

* * *



Хужа газен бакчасы тирәли туфрак дивар өелгән. Бакча эчендәге озын тирәкләрнең башлары күккә тиярлек. Алардан җиргә сыргалар коела. Уртада киң хавыз. Аның як-ягындагы карагачлар күләгәсенә сәкеләр тезелгән. Аларга келәм, палас, көрпәләр җәелгән. Бүген бакча эче тулы хатын-кыз. Анда ир-атка керергә ярамый. Шуңа күрә барысының да йөзләре ачык: пәрәнҗә, чачваннары юк. Ярәшелгән кызлар гына битләрен яртылаш яулык белән каплаганнар. Бакчага хатын-кыз һаман агыла да агыла. Соңлап килүчеләр үзләренә урын эзли. Таныш-белешләре аларны:

— Әйдәгез, түргә узыгыз, күңелең киң булса, урын табылыр,— дип, үз янына чакыралар. Шулай итеп, аш-су, табак-савыт уртага куела.

Кыз-кыркыннар табыннан табынга күчеп, яңа төшкән киленнәрне карыйлар. Яшь киленнәр исә ире ягыннан булган кызларны аягүрә каршы алалар. Каенаналары кунак кызларын түргә чакыралар. Кызлар утырышкач, яшь киленнәр аларга, кулларын күкрәкләренә куеп, гәүдәләрен бөгә-бөгә, кат-кат сәлам бирәләр. Бөгелгән саен түшендәге көмеш тәңкәләре чыңлап куя. Аннары килгән кызларны сый-хөрмәт итү башлана.

Койма артында да халык мәш килә. Аерата зур капка төбендә яшь-җилкенчәкләр утка җыелган күбәләкләр кебек тулганалар. Күбесе ярәшелгән кызларын күрү өмете белән йөри. Ул заманда өйләнәсе егет белән ярәшелгән кыз бер-берсен күреп белмиләр иде. Шуңа күрә дә кызлар башы — палакма[1] ташы, дип әйткәннәр. Бу әлек-әлектән килгән гореф-гадәткә яшьләр буйсынырга мәҗбүр. Эчке якта кызлар,

---

Ахыры. Башы 6 санда.

[1] Борынгы замандагы таш ату коралы.

тышта егетләр бер-берсен күрергә зар-интизар. Ә язмыш аларның хистойгылары белән исәпләшми...

Хуҗа газен бакчасы янындагы зур мәйданда базар кайный. Анда ни генә сатмыйлар: кызыл мал, савыт-саба, көзге дисеңме, конфетпрәннек, хәлвә, нишәллә дисеңме. Дивар буена тезелгән чәчтараш[1], чәйханәче, пешекче — һәркайсы үз малын мактап кычкыра:

— Килегез, алыгыз! Теләсәгез, татып карагыз!.. Тәмле чәкчәк!.. Баллы чәкчәк!.. Бер таңкәгә арзан чәкчәк!

— Лүле кәбаб! Авыз итегез!.. Лүле кәбаб! Ашасагыз, үкенечкә калмассыз!... Акчасы барга — кәбаб, акчасы юкның эше харап!..

— Бәррә равәч![2] Кемгә кирәк бәррә равәч!..

— Кайнар мәнте!.. Кайнар мәнте!.. Ашаган кеше телен йотар!..

Гыйшык утында янучы егетләргә ашау кайгысымыни?! Алар бакча тирәсендә кызлар күзли. Берсе яңгыравыклы тавыш белән җырлап җибәрде:

> Өй түбәсенә кына чәчсәм, үсәм, ди.
> Сөйгәнем янына барсам, китәм, ди.
> Китмә, җаным, гөл-чәчәкләр өзәрмен!
> Синсез, бәгърем, белмим ничек түзәрмен?..

Билгеле, җыр бакчадагы кызларның йөрәген кытыкламый калмый. Егетләрнең кыюлары булган кебек, кызларның да чәчрәп торганнары бар. Шундыйларның берсе бакча эченнән:

— Әй, кайсыгыз анда шул кадәр өзгәләнә? — дип кычкырды.— Алай бик ярата белгәч, нурлы йөзен дә күрсәтсен иде! Әллә кызлар ялынганны көтәме?

Һай, әгәр шулай җиңел генә кызлар ягына кереп, сөйләшергә мөмкин булса иде! Егетләр бу кадәр янып йөрмәс иде. Ә хәзер дуамал гына кызлар алдына басып, кемнең көлкегә каласы килсен? Аз гына ялгыш атласаң да, сөйгәнеңә бик начар булып бетүе бар.

Ул заманда яратышып кавышу бәхете бик сирәкләргә насыйп була иде. Шуңа күрә дә гашыйкларга хат йөртү безнеңише малай-шалайларга зур гөнаһ саналмый иде. Аеруча мәхәббәт утында янучы берәр егет синнән ялынып-ялвара башласа, ничек инде аның хатын апаңа илтмисең ди?..

— Зинһар өчен дип әйтәм, кайнеш. Сүземне яхшылап тыңла. Апаңнан башка берәү дә белмәсен. Комрыйга әйт. Кызлар белән килен-киртә карарга киткән булып, әнә теге йорт янына барсын. Мин шунда көтеп торырмын. Яме?

— Ярый.

— Менә бу кечтеки генә күчтәнәчне башкаларга сиздермичә апаңа бир,— дип, җырчы егет миңа төенчек сузды.— Мин дивардан күтәрелеп караганда, Комрый, башындагы яулыгын күтәреп, миңа йөзен ачсын.

— Шәехләр[3] күрсә, башыгызга бәла булмагае?

— Борчылма, энекәш. Шәехләрнең дә тамагы тишек була икән. Мин аларны майладым инде. Күрсәләр дә күрмәмешкә салышырлар...

— Ярый алайса.

— Апаңа әйт, куркып-нитеп тормасын. Бу серне өчебездән башка беркем дә белми, диген. Киләсе чәршәмбедә Котырбулакта буласы бәйрәмгә чыксын. Анда мондагы кебек биек дивар юк. Тау кочагы киң...

Мин шыпырт кына бакчага кердем. Теге абый бүләгән апама бирергә уңайлы минут көтеп торганда, минем яннан бер малай йөгереп узды да сәке янына барып кызларның берсенә төенчек сузды:

---

[1] Парикмахер.
[2] Дару үләне.
[3] Дин башлыклары.

— Менә сезгә бүләк, абый җибәрде,— диде.
Кызның йөзенә мәк чәчәге кебек кызыллык йөгерсә дә, бүләкне кире кайтармады.
— И ахирәт, егетең бүләге котлы булсын! — диде кызларның берсе.
— Безне инде аның белән сабый чакта ук ата-аналарыбыз колагыбызны тешләтеп, ярәштергән булганнар,— дип аңлатты бүләкне алган кыз.
— Егетеңне күргәнең бармы соң? Ахирәтебезгә пар булырдаймы?
— Узган бәйрәмдә ерактан гына күргәнием...
— Абиджан, абыеңның билбау яулыгын мә, үзең белән алып кит.
Төенчек чишелеп, яулык бушатылды. Дәстәрхан өстенә чикләвек, мәез, кәләвә, чуклы конфетлар чәчелде.
Сәкедә утыручы кызларның берсе Абиджанга:
— Абыеңа барыбыздан да рәхмәт әйт! Нәүрүз бәйрәме котлы булсын! — дип кычкырып калды.
Бу ничек була инде? Абыйсы җибәргән бәйрәм бүләген сөйгән кызына Абиджан ачыктан-ачык китереп бирде. Ә мин шундый ук бүләкне яшертен юллар белән тапшырырга тиеш булам? Уйлап карасам, Абиджан китергән бүләк ярәшелгән кызга икән. Ә мин исә чын мәхәббәт белән янучы, ләкин ата-анасы тарафыннан хәл ителмәгән егет бүләген илтәм икән. Болай булгач, ата-ана ихтыяры чын мәхәббәт тойгысыннан өстен булып чыга түгелме? Шуның өчен бичара җырчы егет сөйгәне йөрәгенә астыртын юллар белән барырга мәҗбүр икән...
Бакчада уен-көлке башланды. Бер төркем кыз, зур мәйданга җыелып, түгәрәк ясадылар. Аларның һәркайсысы уртага чыгып, үз сәләтен күрсәтте: берсе газәл[1] сөйләде, икенчесе саз уйнады. Аннары берничә кыз алга чыгып кубыз чиертә башлады. Аларның нечкә бармаклары гаҗәеп матур аһәң чыгарды. Кызлар шуңа үз тавышларын да өстәп җибәргәч, кубызлар телгә килгәндәй булды:

Кияү-кияү, кемгә кияү, кияү-кияү, кемгә кияү...
Кияү-кияү, мина кияү, кияү-кияү, миңа кияү...
Синә кияү, сиңа кияү... бие-бие, бие-бие, бие-бие...

Кубыз туктауга, бер төркем кыз биергә кереште. Түгәрәк читендә басып торучылар аларга такмак әйтеп, кул чабып торалар.
Сәкедә утырган хатыннар да төрле шаян сүзләр сөйләп күңел ачтылар. Аннары бер яшь ана, кулына дүтәр алып, «Танавар» көен уйнады. Икенче бер хатын моңлы итеп җырлап җибәрде:

Кара чәчкәйләрем кашыма төште...
Дөнья кайгылары башыма төште...

Олы гына яшьтәге бер хатын шуңа тәэсирләнеп:
— Җитәр, кызым. Бу җырың бигрәк авыр икән,— диде, яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп алды.— Бирегә без сыкранырга түгел, күңел ачарга дип килдек. Берәр шатлыклырак көй җырласагызчы...
Бакчаның икенче башында кыз-кыркыннар шау-гөр килеп таган атыналар. Ун-унике метр биеклектәге агач ботакларына бәйләнгән баулар-га тотынып атыныр өчен дә зур осталык кирәк. Кайберсе һавага күтәрелә башлаганда ук арканнарга уралып көлкегә кала. Ә инде аның серен төшенгәннәргә нинди рәхәт! Өскә күтәрелгән саен күтәреләсе килә. Сиңа канат чыккан шикелле. Йөрәгең дөп-дөп итеп тибә башлый. Дөнья киңәеп киткәндәй була.
Минә шуның ише уен-көлке белән көннең беренче яртысы уза. Казаннарда аш-су пешә. Хатыннар арасында сый-хөрмәт күрсәтү башлана...

[1] Гарәп поэзиясендә шигырьнең бер төре.

на. Дәстәрхан өстенә зур табаклар белән буланып торган пылау китерелә. Саф һавада бу ризыклар тагын да тәмлерәк булып тоела. Хатын-кыз, бер-берсен кыстый-кыстый, төрле мәзәк хәлләрне искә алып, көлешә-көлешә ашарга тотына.

Аштан соң да бәйрәм дәвам итә. Котырбулак тирәсендә ат чабыштыру, көрәш башлана. Хуҗа газен бакчасындагы хатын-кызлар бу уеннарны бер читтән күзәтеп торалар. Кайвакыт берәрсенең әйткән шаян сүзенә шаркылдап көлеп җибәрәләр.

Аннары кызлар якты тормышка, мәхәббәт, турылык, тиңлеккә багышлап җыр җырлыйлар. Тиң булмаган никахлардан, яшь кызларга өйләнгән картлардан көлеп такмак әйтәләр.

Бер җырны икенчесе алыштыра. Хатын-кыз мөмкин кадәр күбрәк күңел ачып калырга тырыша. Нәүрүз узгач, кайчан тагын шулай бергә җыелырлар?

— Тагын җырлачы! — дип үтенә хатыннарның берсе.

— Газәл җырын башкарчы, Мәйсәрә! — ди икенчесе.

— Тагын берне, тагын берне,— дип үтенәләр шатлыкка сусаган хатын-кызлар. Ләкин ел буена җыелган юшкыннарны, кайгы-хәсрәт кичергән күңелләрне бер көн белән генә юатып буламы соң!.. Мәйле, бер генә көнлек булса да, берничә сәгатькә сузылса да, бәйрәм шатлыгы колач җәйсен! Яз бәйрәме нәүрүз яшәсен! Кайсы буын кешеләре уйлап чыгаргандыр бу бәйрәмне? Яз башында, табигать каты йокыдан уянганда, игенче чәчүгә чыгар алдыннан болай бәйрәм итүне кайсы изгесе гадәт итте икән? Аны бөек халкыбыз уйлап чыгарган! Шуңа күрә дә мәңге үлмәс халкыбызга дан!

## САБЫР КӘСАСЕ ТУЛГАНДА

Уразаның үзәкләргә үткән чагы иде. Икендедә[1] итеңне ас, ахшам житкәч авызыңны ач, дигәндәй, кешеләр, ураза тотканга, бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр авызларына су да капмыйча ач йөриләр. Чәйханәләр бикле, ашханәләр буш. Ач халыкка ачу иткәндәй, нәкъ шул көннәрдә Дөятартар буасы да китте. Ир-атның күбесе шунда юнәлгәнгә, мәхәлләдә адәм рәтле кеше дә калмады.

Дөятартарга барырга дигәндә, балаларның түгел, олыларның да коты алына. Су һәр җирдә дә газиз булып, җир ананың изге каны саналса, жиззахлылар өчен ул икеләтә газиз. Дөятартар каналыннан су килмәсә, Җиззахта үсемлек үсми. Шулай да канал суының дуамаллыгы халыкның теңкәсенә тигән. Дөятартарга ел саен бихисап көч салына. Каналның ач авызы дөнья байлыкларын йота бара. Яз килеп, Зәрәфшаннан зарыгып су көткәндә, берәр җирдән афәт чыга да халыкның бөтен өметен җилгә очыра. Дөятартарга көне белән кешеләр җибәрергә туры килә. Мәхәлләдә бөтен халык аякка баса. Кешеләр арбаларына бүрәнә, такта, сипая[2], китмән, кирәк төяп, җыйнаулашып шәһәрдән йөзәр чакрым ераклыктагы буаны буарга өмәгә китә.

Каналның тирәнлеге урыны-урыны белән ун-унбиш метрга җитә. Аның төбеннән бер китмән балчык чыгарыр өчен унбишәр китмәнче тезелеп басарга тиеш була. Һәркайсысы үзенә аяк басарлык урын ясый да, аннары түптәге балчыкны берсе берсенә бирә башлыйлар. Шулай итеп, бер китмән балчык ун-унбиш кешенең кулыннан узып, ниһаять, яр өстенә чыгарыла. Сулы җирләрдә диһканнар, билдән балчык ерып, канал чистарталар. Яр читенә сипая куеп, аны чыбык-чабыклар белән

[1] Кояш баер алды.
[2] Су буар өчен ясалган өчаяк.

кыгыталар. Канал буылып беткәч, аңа Зәрәфшан елгасыннан су җибәрәләр. Ул яр буендагы балчыкны ашый-ашый, болганчыкланып Җиззахка таба  ага башлый. Тик шул чакны гына диһканнарның арыган йөзендә елмаю пәйда була. Ләкин бу шатлык озакка бармый. Аны яңадан хәсрәт сөреме басып китә: кайдадыр яңа афәт чыга. Җиззахлылар тагын айлар буена сусыз калалар. Игеннәр саргая. Диһканнар зарыгып көткән уңыш юкка чыга. Өстәвенә, исән-сау киткәннәрнең күбесе чирләп, имгәнеп кайта, медицина ярдәме булмаганга, кайберсе вакытсыз дөнья куя һәм ничәмә-ничә гаилә ятим кала.

Безнең Уратүбә мәхәлләсендә яшәүчеләрнең Дөятартар каналына салган көче шактый гына иде. Кирәк икән, алар, актык әйберен сатып булса да, тиешле акчасын түлиләр. Шулай да Карабай мираб[1] бар кешегә тигез карамый. Уратүбәгә канал суы гадәттә Бигарык аша килә. Анда су күренү белән, барысы да аякка баса. Эшләрен ташлыйлар. Кешеләр иген басуларын, бакчаларын сугару белән мәш килә. Су башында тынычлык бетә. Анда Карабай Әминнең генә үз туксаны туксан. Су бүлү аның кулында. Шуңа күрә барысы да аны майларга тырыша. Менә шунда хәллеләрнең сүзе уң, ярлыларның сүзе туң була да инде. Карабай атаң бер дә югалып калмый. Коры кашык авыз ерта дигәндәй, аның нәфсен буш сүз белән генә туйдыра алмыйсың. Җитмәсә тагын, ул үзен ярлылар яклы итеп күрсәтергә ярата. Әйтерсең лә су җитмәгәнгә ярлының түгел, аның бәгыре яна...

Иллебашының агачлы-күләгәле хавыз буе Карабай Әминнең идарә урынына әйләнә. Киң сәке өстенә келәм белән юрган җәелә. Мираб, йомшак мендәргә кырын төшеп кенә, кешеләргә әмер биреп ята. Алдындагы дәстәрханда нинди генә ризык юк! Тапканы гөлчәчәк, тапмаганы бер бәйләм суган дигәндәй, берәвесе пешереп пылау китерсә, икенчесе ботка китерә. Берсе кайнар сумса белән сыйласа, икенчесе майлы мәнте куя. Карабай Әмин боларны үзе генә ашап бетерә алмый, билгеле. Ул:

— Каяле, агай-энеләр, дәстәрханга якынрак килегез,— дип, нәүбәт суы көтүче диһканнарны ашка чакырган була.— Ярлының бер туйганы— ярты байга торганы, диләр. Тамагыгыз туйгач, канал буена барып, суны сагаларсыз. Юкса, арыкта нишләптер су кимеде.

— Рәхмәт, мираб. Карыныбыз болай да тук. Борчылмыйча гына ашый бирегез. Касыйм әкәдән соң нәүбәт минеке бугай? — дип сорады Ташмәт.

— Нәүбәтең житкәч, үзем әйтермен. Ә син хәзергә су башына бар. Алла боерса, берегезне дә сусыз калдырмам,— диде Карабай Әмин гамьсез генә.— Әй, Ишмәтҗан!

— Ләббәй!

— Сиңа нәүбәт җитте. Суны үз басуыңа таба борып җибәр,— дип, мираб кояш сәгатенә күз ташлады.

— Рәхмәт. Җаным-тәнем белән! — ди-ди, Ишмәт китмәнен алып үз җиренә таба йөгерде.

Ләкин су нәүбәте Касыйм белән күрше Ташмәтнеке иде. Касыйм да үз җиренә суны тиешенчә җибәреп бетермәгән иде әле. Билгеле, ул тавыш куптарды. Ишмәт суны үз җиренә җибәрмәкче, ә Касыйм моңа риза түгел. Алар үзара бугазга бугаз килделәр. Ярлыга ерма-сукма, киемен ерт дигәндәй, ике ярлы-ябагай, бер-берсенең якасына ябышып, күлмәкләрен ертып бетерделәр.

Мирабка шул гына кирәк иде. Аларның талашуыннан файдаланып, Карабай Әмин суны бөтенләй кире яктагы ишан хәзрәт җиренә борып җибәрде. Шулай итеп, үз нәүбәтен көтеп утырган диһканнар сусыз калды. Мираб җирбитләнеп: «Ишмәтнең нәүбәте узды!» дип әйтә куй-

[1] Су бүлүче.

ды. Ә Ишмәт, Касыйм белән тартышып, суны үз арыгына юньләп ачып та өлгермәгән иде. Бай байга багар, суы сайга агар дигәннәре дөрес булып чыкты. Карабайның янчыгына акчаны кем күбрәк төртсә, су да шуңа күбрәк акты. Байларның һәр җирдә дә сүзе үтеп, кулы уйнаганга, су башлыгы аларга хәрәмлек эшли алмый иде. Эшләп кенә карасын! Шунда ук көне бетеп, ризыгы өзеләчәк. Моны мираб үзе дә яхшы белә. Дөрес, ул ярлыларга да кайвакыт якты чырай күрсәткәли. Барысына да түгел, билгеле, теле үткәннәргә генә. Суны биргәндә дә игеннәрне коендырырлык итеп түгел, җан бирүче кешенең авызына тамызган тамчы кебек кенә җибәрә иде.

Ул заманда диһканнар су өчен вакыт хисабыннан салым түлиләр иде. Шуңардан чыгып, Карабай Әмин берсенең арыгына суны ярты сәгатькә генә җибәрсә, икенче берәүгә сәгатьләр буе агыза иде. Шунысы кызык, вакыт белән эш иткән мирабның чын сәгате юк иде. Дөресен әйткәндә, Уратүбә мәхәлләсендә ике генә кешенең сәгате бар: берсе вагончы Абдулла Мәгъсумда булса, икенчесе Азизханнарда иде.

Аның каравы, Карабай Әминнең вакытны чамалый торган үз «сәгате» бар. Берсе аяз көнне булса, икенчесе болытлы көнне яки төнлә куллана. Кояш сәгате шуннан гыйбарәт: җиргә зур түгәрәк сызылып, уртасына таяк кагылган була. Мираб, түгәрәк читенә вак-вак бүлекләр сызып, вакыт узганын күләгәнең йөрүенә карап белә. Шуңа карап, суны берәүләр җиренә ярты сәгать, башкаларныкына кимрәк яки артыграк агыза иде. Диһканнарга исә мирабтан миһербан көтүдән башка берни калмый иде.

Карабай Әминнең чүлмәк «сәгате» тагын да кызыклырак. Бер чиләк су сыешлы чүлмәкнең муеныннан төбенә хәтле энә күзе кадәр генә тишекләр тишелгән. Вакытны белер өчен чүлмәккә су салына. Суның әнә шул тишекләрдән агуына карап, нәүбәт бер кешедән икенчесенә күчә. Кешеләр бу «сәгать»ләргә күнеккән булсалар да, мирабның хәрәмлегенә түзә алмыйлар. Гауга куптарырга сәбәп чыгып кына тора:

— Нишләп ярты сәгать узсын, ди? Гаделлек кирәк, Карабай әкә! Су агымы капкабыз төбеннән әле генә үтте. Ә сез аны инде туктатмакчы буласыз.

— Капкаңнан узганмы, узмаганмы, анда минем эшем юк. Арыгың рәтләп казылмагандыр. Су үргә таба акмый икән, моңа үзең гаепле! — диде мираб, күзен дә йоммады.

— Арыгым тирән. Ышанмасагыз, барып карагыз!

— Караганнан ни файда. Хәзер мин аны җәбраил фәрештә өстенә языйммы?! Барыбер вакытың узды. Мин сәгатькә карап эш итәм,— дип, Карабай чүлмәгенә күрсәтте.

— Сез кем? Күз буучымы әллә? Сихерне дә бит җаена китереп ясыйлар.

— Теленә салынма, башыңа житмәгәе!

— Гаделлек өчен башым китсен. Алай бик каныксагыз, мәгез алыгыз! — дип, диһкан үз башын мирабка таба сузды.

— Бар, бар! Кибәк башың үзеңә булсын. Нигә болай тамак ертасың? Берәү дә кеше хакына керми. Сине дә кеше якларга куймаганнар!

— Мин үз хакымны сорыйм. Дөятартарга канал казырга беренче булып без барабыз. Ай буена билдән су кичеп, арык төбеннән балчыкны без чыгарабыз! — дип, диһкан да ярсый төште.— Ә килгән судан байлар файдалана. Шул да гаделлек булдымы? Теләсәгез нишләгез, бу суны мин үз арыгыма җибәрәм,— диде дә, иллебашы җиренә аккан суны үзенә бормакчы булды.

Ләкин иллебашының ялчылары аңа каршы төштеләр. Шулай сүз арты сүз чыгып, ике арада талаш-тартыш башланды. Күкерт кебек кабынып китеп, бер-берсенең якасына ябыштылар. Ялчылар, диһканны җиргә егып, типкәләргә тотындылар. Су нәүбәтен көтеп, кара көеп

утыручы диһканнар ялчыларга ташландылар. Талаш зурга китте. Кемдер Карабай Әминнең «сәгатен» күтәреп жиргә бәрде. Чүлмәк челпәрәмә килде. Мираб качып котылды. Ләкин җәнҗал моның белән генә бетмәде. Түрәләр бу талашның төп сәбәпчесе булган Карабай Әминне яклап калдылар. Гаепле кеше акланып, гаепсезләр жавапка тартылды. Җәнҗалга катышкан өч-дүрт диһканны төрмәгә яптылар.

Дөнья сугышы башлануга ике ел булды. Ярлы халыкның тормышы авырайганнан-авырая барды. Бәхетсезлеккә каршы дигәндәй, шул көннәрне мәрдекарьлеккә[1] кешеләр җибәрү турында патша указы чыкты. Халыкка ул аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. «Ак патша мөселманнарны солдатка ала. Ир-ат, хатынын, бала-чагаларын калдырып, сугышка китә икән», дигән шомлы хәбәр илгә бик тиз таралды. Ураза алдыннан, 1916 нчы елның 6 нчы июнендә, патша указы рәсми рәвештә игълан ителде. Указда: «19 яшьтән алып 43 яшькә кадәр булган ирләр һәм егетләр окоп казу, корылма төзү эшенә сугыш беткәнче мәрдекарьлеккә озатыла», диелгән иде. Әйтерсең лә илдә кояш сүнеп, күк йөзен кара болыт каплап алды! Кешеләрнең йөзен кайгы-хәсрәт сөреме басты. Урамда дүрт-биш кеше очрашса, сүзләре сугыш та мәрдекарьлек турында иде.

Йөргән таш шомара дигәндәй, безнең эткәй гомере буена дөнья гизеп шомарып беткән кеше иде. Ул кышлактан-кышлакка йөргәндә, төрле кешеләр очрата, төрле сүзләр ишетә һәм һәр кайтканында бер кочак яңалык алып кайта иде. Соңгы сәфәреннән ул бөтенләй күңелсез кыяфәт белән кайтып керде. Сукса тимер өзәрдәй Насыйр белән Касыйм абыйларның китмәгәндә бер-бер артлы үлеп китүләре аны аяктан ега язды. Бертуктаусыз йөрәге сызланып, юк кына нәрсәгә дә кызып китүчән булып калды. Шуңа карамастан, уразасын бозмады. Касыйм абыйның кырыгын уздырырга йөри башлады. Әни каршы килсә дә, җомга намазына баргач, мәчеттә мәхәллә картлары белән киңәшергә булды.

— Дөнья хәлләре гел үзгәреп тора. Иртәгә нәрсә буласын бүген әйтеп булмый. Никулай патшаның солдатка алу турындагы указы барысының да рухын төшерде. Бер-бер хәл булмагае дип куркам, анасы,— диде.

— Алла ярдәм итсә, берни дә булмас әле,— дип, этине тынычландырырга теләгән анам үзе дә көрсенеп куйды.

— Саңзар, Яңакурган, Ямь кышлакларындагы чуалышлар бездә дә булмагае, алла сакласын,— диде эткәй.— Бу Мирзаһашимны әүлия диярсең. Гәҗитенә карап фал ачамыни? Аның сөйләгәннәре барысы да дөрескә чыга.

— Фал ачу төрлечә була бит. Кайберәүләр кәсадәге суга, кайберсе көзгегә карап сөйли. Мирзаһашим, күрәсең, әнә шул син әйткән... һы, аты корысын, ничек диләр әле...

— Гәҗитме?

— Әйе, әнә шуңа карап фал ача торгандыр.

— Юкны сөйлисең, карчык,— дип каш җыерды атам.

Эткәйнең сөйләвенә караганда, кышлакларда шактый хәлләр булып алган. Җиззах хакиме ак патшаның мәрдекарьлеккә алу турындагы указын халыкка аңлатырга дип Саңзарга барган икән. Дустбәк меңбашы мәхәллә кешеләрен мәйданга җыйган. Анда хәтта, имчәк балаларын күтәреп, яшь киленчәкләргә кадәр килгән. Хаким халыкка карап нотык сөйләгән. Аның сүзләрен тылмач бәйнә-бәйнә тәрҗемә итеп торган. Хаким: «Саңзар халкы бөек падишаһ указын җиренә җиткереп үтәр дип ышанам!» дип сүзен бетергән. Аңа җавап итеп, Дустбәк меңбашы: «Минем халкым — патша хәзрәтләренә бирелгән халык. Урусия дошманнарын җинәр өчен, файдалары кайда күбрәк тисә шунда, зур тырыш-

[1] Кара эшче, көнлекләп эшләүче.

лык белән хезмәт итәрләр. Саңзарлыларның вәгъдәсе дә, антлары да менә шул, хаким җәнаблары», дигән.

Меңбашы сүзен бетерергә дә өлгермәгән, халык арасыннан берсе: «Мелла Дустбәк, саңзарлылар исеменнән хаким түрәгә сүз бирдегез. Әмма бу турыда халыкның үзеннән, күнел өчен булса да, бер авыз сүз сорамадыгыз!» дип кычкырган. Меңбашы моңа каушап калмаган: «Җәмәгать, хаким түрә әле генә сезгә карап: соравыгыз яки берәр үтенечегез бармы, сөйләгез, диде. Шуңа берегез дә җавап кайтармадыгыз. Ә дәшмәү бездә ризалык билгесенә йөри. Мин монда гореф-гадәтебезгә ярамаслык бер ни дә эшләмәдем» дип, оста гына котылмакчы булган. Ләкин теге кеше моңа канәгать булмыйча: «Җәмәгать, ник дәшмисез? Телегезне йоттыгызмы әллә? Безгә хәзер ятып калганчы, атып калырга кирәк. Күңелегездә булганын барысын да сөйләгез. Патшага мәрдекарь бирергә, аталарыгызны, улларыгызны кара эшкә җибәрергә ризамысыз?» — дип сораган.

Шул мәлне халык арасыннан: «Мәрдекарьлеккә кеше бирмибез! Кара эшкә бармыйбыз!» дип кычкырган тавышлар ишетелгән. Халык диңгез кебек шаулый башлаган. Балчыктан очкын чыкмый дип уйлаган хаким түрә белән меңбашы, бу көтмәгән хәлгә аптырый төшеп, тизрәк шылу ягын караганнар.

Атам моны Янакурган базарыннан Усматлы дигән бер танышыннан ишетеп кайткан. Өстәвенә, кайтышлый Кырыклы дигән кышлакка туктагач, яшьләрнең: «Әгәр дә берәрсе мәрдекарьлеккә җибәрелүчеләрнең исемлеген төзесә, ул кешене юк итәргә!» дип сүз куешканнарын үз колагы белән тыңлап торган.

— Юлбарыс — эзеннән, ир-егет сүзеннән кайтмас, диләр. Алла сакласын, бу көннәрдә берәр хәл булмагае,— дип борчылды атам.— Берсенең дә исән килеш үлемгә барасы килми. Урусиягә китү — Дөятартарда арык казып кайту түгел. Аның авырлыгы ярлы-ябагайга төшәчәк. Байлар алар бер әмәлен табарлар. Мин мәчеткә барып кайтам: анда да сүз булмый калмас әле.

Атам, тәһарәт яңартып, урамга чыгарга торганда, ишек алдына Җурабай тагам [1] килеп керде. Ул, Ашурмәт әмәкедән тимерчелек һөнәренә өйрәнгәч, үзенә аерым алачык салып, көн-төн шунда эшли иде. Җура тагам егерме бишләр тирәсендә булып, гәүдәгә таза иде. Сакалмыегы төртеп чыкканга, йөзе тагын да карала төшкән. Башында зәңгәр сәллә [2], өстендә ак җилән, аягында кәвеш. Өс-башына пөхтә киенгәнгә, кешеләр аны ыспай Җурабай дип тә йөртәләр иде. Ул атам белән исәнләште дә:

— Җизни, сезне каләндәрханәдә мәхәллә егетләре көтә,— диде.

— Аларның миндә ни йомышлары бар икән?

— Күрәсең, мәрдекарьгә китү турында сорашмакчы булалардыр.

— Анысын иллебашы белән меңбашыннан сорасыннар иде.

— Белмим шул. Саңзар халкы мәрдекарьгә бармыйбыз дип меңбашына каршы килгәннәр. Сезне шул вакыйгадан хәбәрдар, диләр. Шул турыда төрле сүз йөри.

— Нинди сүзләр?

— Башта ак патшаның указы барысына да бер — баеннан да, ярлыдан да мәрдекарь алына дигәннәр иде. Ә хәзер байлар, акчага кеше яллап, үзләре котылып калмакчы икән. Шул да гаделлек булдымы? — дип, Җурабай тагам ярсып китте.

Атам да, башына сәлләсен урап, өстенә җиләнен киде. Аннары әнигә борылып:

---

[1] Әнисе ягыннан булган абзый.
[2] Чалма кебегрәк баш киеме.

— Мин озакламый кайтырмын,— диде.

— Хәерлегә булсын бу йөрүләрең. Мәчеткә баргач, Сандзар хәлләрен күп сөйләмә. Кул йөгерегe — ашка, тел йөгерегe — башка, диләр. Мәхәллә егетләре кемнән үч алырга белми йөри. Алар да, Сандзардагы кебек, иллебашы, меңбашына кул күтәрсәләр, алла сакласын, кем коткы салды, фәлән дип, үзеңне җавапка тарттырмасыннар тагын. Сиңа бу көннәрдә кеше күзенә күренмәү хәерлерәк булыр иде. Җомга намазына бер тапкыр бармаганнан дөньяң кырылмас әле.

— Әй син, анасы, көтүдән алда тузан туздырма. Мин анда кешеләргә коткы салыр өчен бармыйм,— диде әткәй, аннары Җурабай тагама борылып:— Я, мәчеткә син дә барасыңмы? — дип сорады.

Зурларга ияреп, мин дә урамга чыктым. Кешеләр төркем-төркем булып мәчеткә агыла иде. Бездән бераз алда Урынбай ата белән улы Корбанбай сумсачы бара. Мин аларда еш булам. Урынбай атаның гаиләсен безнең мәхәлләдә белмәгән кеше юк. Алар бик ярлы торса да, тырыш кешеләр. Ишек аллары өч-дүрт чыпта җәярлек кенә, йортлары да тавык кетәгe кебек кенә. Стеналары тандер төтененә ысланып беткән. Менә шул бер бүлмәле өтек кенә өйдә ике улы, ике кызы белән — барысы алты җан яшиләр. Ишек төпләрендә җир тандер тора, шуның бер ягына киң такта кейләнгән. Менә шунда Урынбай атаның хатыны камыр җәя, кызлары суган турый, уллары ит тураклый. Аннары берсе камыр кисә, икенчесе сумса ясый. Урынбай ата учакка ут ягып, тандерне кыздыра. Ут яктысында аның сакал-мыегы көя төшкән сарык йоны кебек күренә. Эш белән мәш килгән сумсачы карт безне дә онытмый:

— Борчылмагыз, балакайлар. Күз ачып йомганчы сумса әзер булыр. Бераз сабыр итсәгез, морадыгызга җитәрсез. Алма да бит вакыты җиткәч кенә тәмләнә. Урынбай атагызның сумсалары тандергә төшүе булыр — кызарып пешүе булыр,— дип күңелебезне таба. Аннары кулына калын бияләй кия дә, аңа икешәр сумса салып, «бисмилла» дип, аларны тандер эченә чәпи бара. Күп тә үтми, йөзләгән сумса кызу тандер йөзенә ябыштырылган була. Урынбай ата, кулъяулыгы белән маңгай тирен сөрткәч, тандернең капкачын ябып, өстенә мамыктан сырылган киндер тышлы юрган каплап куя.

Анам, туйга-нигә барасы булса, кулыма көмеш тәңкә тоттырып, Урынбай аталарга йөгертә иде. Ләкин син килгәндә генә сумсалары әзер булып тормый. Ишек алларында, синнән башка да, сумса пешкәнен көтеп утыручы малайлар шактый... Ниһаять, сумса өлгерә. Ләкин алар барыбызга да җитми. Урынбай ата, сумсаны чираты җиткәннәргә биреп, калганнарыннан гафу үтенә:

— Борчылмагыз, күгәрченнәрем. Сез кара күзләрдән башка да сумса көтеп утыручы кешеләрем бар. Бикмәт аксакал чәйханәсендә үзегез дә күргәнсездер. Вакытында илтмәсәң, өемә кереп, мине тереләй ашардай булалар. Әгәр мине тере көемә ашауларын теләсәгез, мәйле, сумсаны башта сезгә бирәм,— дип, үл безгә күз кыса.

— Ю-ук! Теләмибез! — дип җавап бирәбез.

— Сезне тереләй ашасалар, малайларга кем тәмле сумса пешерер? — дип, елмая-елмая Корбанбай әкә җиз табага сумсаларын тезә башлый. Аннары ул безне изелгән сумсалар белән сыйлый. Моңа малайларның авызы колакларына җитә яза. Майланган авызларны сөртә-сөртә:

— Без котәрбез! Бу сумсаларны чәйханәгә илтегез! — дибез.

Корбанбай, пешкән сумсаларны зур табакка тезеп бетергәч, кызарган йөзләренә май сөртә, тоз белән борыч сибә. Аннары шулар өстенә яңаларын тезә. Табак тәмам тулгач, аны дәстәрханга урап, баш түбәсенә куя да чәйханәгә йөгерә. Күп тә үтми, бушаган табагын күтәреп, кайтып та керә.

— Ничек соң? Чәйханәдә сумса көтүчеләр күпме? — дип сорый Урынбай ата улыннан.

— Җитәрлек. Мин бу табакны Бикмәк аксакал чәйханәсендә үк бушаттым. Гүзәрдәгеләргә [1] хәзер алып чыгам дип котылдым.

— Алайса эшне кызулата төшик! — ди Урынбай ата, яңадан кызган тандер эченә су сибә.

Безнең мәхәллә гүзәрендә кеше бер кайчан да өзелми. Андагы чәйханәләрдә халык гөж килә. Гүзәрдә бер-берсе белән янәшә дүрт чәйханә, ашханә, кибетләр тезелеп киткән. Үткән-сүткәннең кайсысын гына алма, берәр сәбәп табып, гүзәргә сугыла. Ерак юлдан килүче мөсафирлар чәйханәләрдә куна, кайберләре челем яки әфьюн тартып кәефләнә иде.

Гүзәр кибетләрендә ниләр генә булмый: халыкка иң кирәкле тоз, сабын, керосиннан алып, бизгәк даруына кадәр була иде. Кибеткә дип килгән кешеләр Урынбай атаның сумсасын авыз итми калмый. Чәйханәдәгеләрне әйткән дә юк — алар сумсачы картның даими клиентлары санала. Урынбай гаиләсе көн саен өчәр тапкыр сумса пешереп, гүзәргә чыгарып торса да, халыкка сумса җитми. Шунысы кызык, Урынбай ата китергән табагын юл буендагы сәкегә куя да үзе савыт-саба төзәтүче Мирбакы останың алачыгына барып утыра. Картның һәрвакыт үз янында йөртә торган китек борынлы чәйнеге һәм кызыл чәчкә төшерелгән кәсәсе бар. Кәсәсендәге янчыктан бер кайчан да күк чәй өзелми. Урынбай ата, шул чәйнеген күтәреп, чәйханәдәге зур самовар янына бара. Башта кайнар су агызып, чәйнеген чайкый. Аннары берничә чеметем күк чәй салып, самовардан су агыза да яңадан Мирбакы янына барып утыра. Ул арада аның сумсасы янына кешеләр җыелган була. Урынбай ата аларга борылып та карамый.

— Җәмәгать, шикәр аз чагында гына тәмле. Кайнар сумсаны безгә дә калдырыгыз! — диләр артта торучылар.

Урынбай ата ашыкмыйча гына кәсәсенә чәй ясый. Чәе ныгытып пешсен өчен, кәсәдәгесен яңадан чәйнеккә сала. Өч-дүрт тапкыр шулай иткәч, билендәге яулыгын чишеп, чәйнекнең өстен сөртә. Чәйгә тәмам тәм чыгып, гәрәбә төсенә кергәч кенә кәсәсенә ясап чәй эчә башлый.

— Каяле, дусларым, калган сумсаны алып бетерегез. Бу дөньяның мәшәкате бер дә бетәр төсле түгел. Урынбай атагыз, тынгылык белмичә, теге дөньяга китәргә тора. Исән чакта сумсаларымны ашап калыгыз. Берәр искә алып сөйләрсез. Ягез, я, сумса суынганчы алып калыгыз! — ди Урынбай ата. Аннары Мирбакыга борылып: — Кәсәгезнең бөтене бармы, оста? Сезгә дә чәй ясыйм әле,— ди.

Мирбакы аңа кәсә суза. Урынбай ата аның берничә җиреннән чатнаган кәсәсен кабат-кабат әйләндереп карагач, башын чайкый:

— Сезгә хәйран калам, Мирбакы. Тугыз җирдән чатнаган кәсәнең гомерен озайткансыз. Бу кәсәнең ишәгеннән тышавы кыйбатрак төшмәдеме икән? Һай, кеше гомерен дә шулай озайтып булса иде!

— Ялганган кәсәдән чәй эчү зур савап, диләр.

— Савабы булмаса, мин дә менә бу китек борынлы кытай чәйнегеннән чәй эчәр идемме? — дип, сумсачы карт та көлемсерәп куя.

— Дөрес эшлисез. Адәм баласы бу дөньядан, саваптан башка, бер нәрсә дә алып китә алмый...

— Хак сүз әйттегез. Савап ясыйм дип, кешеләр хавыз казыта, күпер төзәтә, мәчет салдыра. Менә бу сумсалар да, алланың рәхмәте белән пешеп, безнең алга ризык булып төште. Шуңа күрә дә мин бер дә сатулашып тормыйм. Кеше теләгән кадәр ашап, акчасын үзе түләр. Әйдә, оста, сумсадан авыз итегез. Моның миңа да савабы булыр,— ди Урынбай ата.

[1] Мәхәлләдә берничә чәйханә һәм кибетләр урнашкан җир.

— Әлбәттә,— дип, Мирбакы оста «алланың рәхмәте белән» пешкән майлы сумсаны авызына каба.— Саваплы эшнең бүләге ахирәттә булыр, ходай насыйп итсә...

— Иншалла, шулай булсын,— дип чәй ясый карт сумсачы.

Шул мәлне сумса ашаучыларның берсе:

— Урынбай ата, табагыгыз бушады! — дип кычкыра. Икенчесе дә яулыгы белән авыз тирәсен сөртә-сөртә:

— Базары килгәндә, тагын бер табак чыгарсагыз шәп булыр иде! — ди.

— Сабыр итегез, сабыр. Тандер кызсын. Икенчесе дә булыр. Сумса пешү белән, Корбанбайның аягы җиргә тимәс,— ди карт сумсачы.

— Әттәгенәй, авыз тәме килгәндә генә сумса бетте. Тагын бераз булса, йөземгә дә керешер идек,— ди өченчесе. Аннары, салмак кына атлап, Урынбай ата янына килә дә, колагына нәрсәдер пышылдый. Сумсачы карт, чебен куган кебек, кулын изи:

— Кирәкмәс. Акча санау гадәте юк миндә. Булганына шөкер,— дип әңгәмәнең серен ача.

— Сез борынгы кеше. Барысын да үзегез кебек күрмәгез. Акча санаганны ярата.

— Гомерем буена санамадым. Аллаһы тәгалә моннан ары да кешеләргә инсаф бирсен.

— Әнә бармакларыгыз да тигез түгел. Шуның кебек, кешеләр арасында да төрлесе бар.

— Булса булыр. Мин исәп-хисап йөртергә күнекмәгән. Ходайга шөкерләр булсын, кырык ел сумса пешерәм, шулай да ач-ялангач булмадым. Туклыктан да корсак ярылмады. Янчык актарып кына баеп булмас инде...

— Алайса, аллаһы тагәлә янчыгыгыздан бәрәкәтен өзмәсен!

— Амин, шулай булсын! — дип, барысы да бит сыпыралар.

Урынбай атаның көннәре менә шулай уза. Халык уразага кергәч кенә бераз үзгәрә төшә. Чөнки кешеләр көндез чәйханәгә чыкмый. Шулай да бу җомгада чәйханәләр нишләптер эшли иде. Мәхәллә кешеләре, төркем-төркем булып, мәчеткә агылды. Күбесенең йөзе борчулы. Җайнак абзый да бар. Мин аның элек мәчеткә йөргәнен хәтерләмим. Ул бүген мәхәллә картларына патша указы турында сөйли. Аның сүз эзләп күршегә кермәүче кеше икәнен беренче күрүдә үк сизгән идем.

Көн бөркү булуга карамастан, намазга баручыларның очы-кырые күренми. Мәчет янындагы тут агачы төбендә пәрәнҗә ябынган берничә хатын-кыз басып тора. Мин, зур капкадан керергә җөрьәт итмичә, хөҗрә артындагы дивар аша кереп, карагач янына барып чүгәләдем. Арык буенда сабакташларым Ирмәт, Сәет, Миркәрим һәм тагын берничә малай утыра иде. Без, дамелладан шүрләп, мәчет алдындагы зур мәйданга барырга кыймадык. Анда болай да кеше шыгрым тулган иде. Җомга намазына халык атна саен җыелса да, бу кадәр күп булмый торган иде. Өстәвенә, бүген башка мәхәлләләрдән дә кешеләр килгән. Күбесе безгә таныш булмаган ят кешеләр. Мәхәллә малайлары бу хәлне һәркайсысы үзенчә гөман итте.

— Мирзаяр меңбашын төшерәләр, имеш. Күрәсең, аның урынына башка кешене сайлый торганнардыр...

— Әйе, иллебашын да байларга сатылган дип сөйләгәннәр иде.

— Ата-агаларыбызны мәрдекарьлеккә озатсалар, нишләрбез?

— Берни дә эшли алмыйсың. Барысының да атасы Абдулаһатнеке кебек акчалы түгел. Бай балаларына рәхәт ул! Кайгы-хәсрәтнең нәрсә икәнен дә белмиләр...

Шул мәлне мәйдандагы халык җанлана төште. Капка ягыннан: «Киләләр, киләләр!» дигән тавыш ишетелде. Без, урыныбыздан торып, шул якка карадык. Башта иллебашы белән полицейский күренде. Алар артыннан Мирзаяр меңбашы белән Гарифҗан аксакал килеп керде. Гадәттә, халык меңбашын түгел, иллебашын да урыныннан торып каршы ала иде. Ә бүген нигәдер алай итмәделәр. Могътәбәр түрәләрне күрүгә, халык арасыннан берничә кеше урыннарыннан кузгалса да, күпчелек утырган җирендә калды. Меңбашына ияреп Абделкасыйм иллебашы, Гарифҗан аксакал һәм Садыйк миршаб таш баскычтан террасага мендeләр. Анда утыручы ишан хәзрәт, мелла Хафизбай, тагын кемнәрдер урыннарыннан торды. Алар, башларын ия-ия, һәркайсысы аерым күрешеп, хәл-әхвәл сораштылар. Аннары Абделкасыйм иллебашы мөнбәргә менде. Ул базык буйлы, төлкенеке сыман озын йөзле, кәҗә сакаллы кеше иде. Батып торган очлы күзләре мәетнеке кебек нурсыз. Урамда күрсәк, без аңа очрамаска тырышабыз. Ә инде көтмәгәндә каршыга килеп чыкса, сәламебезне алмыйча узып китә торган иде. Абделкасыйм иллебашы мәйданга вәкарь белән күз йөртеп чыккач:

— Җәмагать, җомга намазына күп калмады. Арык буендагылар якынрак килсен! Мәрдекарьлеккә җибәрү турында Мирзаяр галиҗәнаб сезгә сүз сөйләячәк. Тыңлагыз! — диде.

Мирзаяр меңбашы да сүзен кыска тотты:

— Мөэмин-мөселманнар, сүз боткасы — ишәккә азык, диләр. Мәрдекарьлек йортыбызга төшкән зур туй булды. Солдатка җибәреләсе кешеләрнең исемлеге бездә әзер. Аны хәзер Мирза писер укып чыгачак. Исеме әйтелгәннәргә киләсе җомгада нәкъ менә шушы урында акча белән кием өләшенәчәк. Урусия һавасы салкын була. Ак патша хәзрәтләре мәрдекарьлеккә баручыларны аталарча кайгыртып, җылы киемнәр тектергән. Каяле, тәкъсир, мәрдекарьлеккә китүчеләр хакына дога кылыйк! — диде.

Ишан хәзрәт, нәкъ шуны көткәндәй, бөтен мәйданга ишетелерлек итеп: «Амин!» диде. Аннары кулларын җәеп, бер кычкырып, бер авыз эченнән пышылдап, корьән аятьләрен укырга керешә. Дистәләгән әүлияләрнең исемен тезеп китте: «Пәйгамбәребез Мөхәммәт мостафа, галәйһиссәлам әйкадер лямязал, дошманнарны тар-мар ит, ак патша хәзрәтләре галиҗәнабләренә һәр җирдә юлдаш бул. Мәрдекарьлеккә баручы мөэмин-мөселман бәндәләренә изге хәзрәти Гали батырлыгы багышла!..»

— Амин! — дип кабатладылар мәйдандагы кешеләр.

— Лафәтә иллә Гали, лосәйфә илла зөлфикарь. Мөселман бәндәләренне бәла-казадан сакла, аяд даф кунад пәрвәрдигар! Без җибәргән мәрдекарьләр исән барып, аман кайтсыннар! Аллаһы тәгаләнең җирдәге күләгәсе булган ак падишаһ галиҗәнабләре үз балаларына янә дә баш булсын! Якын көндә, яхшы сәгатьтә, яңадан күрешергә насыйп кылсын. Амин, рәббилгаләмин! — дип ишан хәзрәт бит сыпырды.

Ләкин мәйдандагы халык элекке кебек бердәм тавыш белән дога кылмады. Күбесе хәтта кымшанмады да. Йөзләрендә ризасызлык иде.

Мирза писер мәрдекарьгә җибәрелүче кешеләрнең исемнәрен укыды. Халык шылт та итмичә тыңлап торды. Ара-тирә кайберсенең офтанып, ахылдап куюы ишетелсә дә, беркем сүз катмады. Аның каравы, исемлек укылып бетү белән, мәйданда кинәттән шау-шу купты. Кемнең нәрсә дигәнен аңлау кыен иде. Иллебашы белән полицейский күпме кычкырмасын, халыкны бер ничек тә тыя алмадылар.

Шул мәлне Җайнак абзый утырган җиреннән торды да, кешеләрне ерып үтеп, айван баскычына барып басты. Ул халыкка борылып кул күтәрде:

— Җәмагать! Тынычланыгыз. Күңелебездәгесен хәзер әйтмәсәк, кайчан әйтербез! — диде.

Кешеләр: «Утырыгыз әле! Тыңларга ирек бирегез!» ди-ди, бер-берсенең чабуыннан тартып, халыкны тынычландырырга кереште.

Әле генә диңгез кебек шаулаган халык бердәм тынып калды. Җайнак абзый башындагы сәлләсен салып, салмак кына сүз башлады:

— Агач башындагы сыерчыклар кебек, барыбыз да берьюлы сайраганнан беркинди мәгънә чыкмас. Билгеле, һәркемнең сөйләргә хакы бар. Шулаймы, тәкъсир? — дип, ул ишан хәзрәткә карады.

Ишан хәзрәт моңа нәрсә дип җавап бирергә дә белмәде. Меңбашы ишарә иткәч кенә телгә килде:

— Әлбәттә, әлбәттә. Ак патша әмере безнең барыбыз өчен дә изге, һәм ул, һичшиксез, үтәлергә тиеш. Аллаһы тәгалә үзе дә: «Бәндәләремнең бөек бурычы җирдәге күләгәм патша хәзрәтләренең кушканын җиренә җиткереп үтәү», дигән, иллә мәгәр...— дип тезеп китте.

— Анысы безгә аңлашыла, тәкъсир,— дип, ишанны сүзеннән бүлде Җайнак абзый.— Андый вәгазьләрне беренче тапкыр ишетмибез. Менә сез патшаның әмере бар кешегә дә изге, дидегез.

Меңбашы тынып калган халыкка усал күзләрен йөртеп чыккач, Җайнак абзыйга борылды:

— Я, шуннан? Тик сүзеңне кыскарак тот! Әнә, җомга намазын укыр вакыт җитте. Шулаймы, тәкъсир?

Хәзрәт, шуннан файдаланып, әңгәмәне өзәр өчен: «Дәрвакыйгъ, я бисмилла» дип, урыныннан торган иде, халык янә шаулый башлады.

— Патшаның әмере бар кешегә дә изге булгач, ни өчен Мирза укыган кәгазьдә сезнең исемнәр чыкмады? — диде Җайнак абзый.— Кая байларныкы, кая муллаларныкы? Менә шул сорауга ачык итеп җавап бирегез! Шулаймы, җәмәгать?

Мәйдандагы кешеләр төрле яктан: «Шулай, шулай! Бик дөрес әйттең. Җавап бирсеннәр!» дип кычкырдылар.

Мирзаяр меңбашы яшь этәч кебек кызарып-бүртенеп урыныннан торды. Ул патша хезмәтендәге иллебашы, казый, полицейский, муллаларның Төркстан губернаторы әмере белән мәрдекарьлек хезмәтеннән азат ителүләре турында әйтте.

— Ә инде исемлектә бай һәм бай малайларының булмавына килсәк,— дип дәвам итте меңбашы,— анысы барыбызга да мәгълүм. Мәрдекарьлеккә һәр дүрт гаиләдән бер кеше җибәрелә. Димәк, дүрт гаилә берләшеп бер мәрдекарь яллый. Әгәренки акчалы кешеләр үзе урынына башка берәүне яллый икән, моның ни гаебе бар?.. Аларның бу эше патша әмеренә һич каршы килми. Сезгә моның нәрсәсе аңлашылмый?

— Әгәр бу хәл бер минем башыма гына төшсә, ачу да килмәс иде. Ул мәрдекарьлек дигәнең ярлы халыкның башына бәла икән. Байтүрәләр бу юлы да патша хөкүмәтенең иркәтайлары булып, мәрдекарьлекнең бөтен авырлыгы ярлы-ябагайга әләгә икән. Чәнчелеп китсен бу ярлылык! Моннан ары да шулай булса, илгә чыгып, хәер сорашасы гына кала!..

— Туктал, бозык баш! Сүз күбеге монда пычагыма да кирәкми! Кешеләрнең зиһенен чуалтып, юлдан яздырмакчы буласыңмы, бәдбәхет! — дип кычкырды меңбашы.

Ишан хәзрәт тә тәсбихен болгап:

— Ул динсезне күптән акылга утыртырга вакыт! — дип җикерде.

Меңбашы күзләреннән утлар чәчеп: «Кулга алыгыз үзен!» дигәндәй, Садыйк миршабка[1] ишарә ясады. Полицейский, мыек очларын бөтереп алгач, кылыч сабын тотып, баскычка таба атлады. Ләкин халыкның ярсуыннан куркып булса кирәк, террасадан төшәргә кыймады. Җайнак абзыйга: «Чык әле монда!» дип боерды.

[1] Полицейский.

Кешеләр: «Җайнак әкә, акылың булса анда чыга күрмә!» — дип кычкырдылар. Айван баскычы янында басып торган Корбанбай пәһлеван исә Җайнак абзыйны кулыннан тотып аска тартып төшерде. Ә Садыйк миршаб мәйданга төшеп, аны халык арасыннан аерып алырга батырчылык итмәде. Ә бит Садыйкны, үтә кыю булганга, Җиззахлылар «дуамал Садыйк» дип йөртәләр иде... Бурсыкка охшаган таза гәүдәле, очлы күзле, озын мыеклы, көрәк сакаллы полицейский чынлап та теләсә кемнең котын алырлык иде. Дуамал Садыйкның болай икеләнүенә ачуы килгән Мирзаяр меңбашы: «Нигә сузасың?» дигәндәй аяк типте. Полицейский нәрсә дип җавап бирергә белмичә иңбашын җыерды. Ул арада мәйданнан:

— Мәрдекарьгә байгуралар үзләре барсын!.. Ярлылар, мәрдекарьлеккә ялланудан баш тартыгыз! Әгәр берәрегез акчага сатылса, андый сатлык җанны акылга утыртырга кирәк!.. — дигән тавышлар ишетелде.

Бу шау-шуга карамастан, мәзин азан әйтә башлады. Ләкин мәйдандагы халык аңа игътибар итмәде. Гадәттә кешеләр, азан тавышын ишетү белән, сөйләшүдән шып туктап, җиргә чүгәлиләр иде. Бу юлы алай булмады. Халык төркем-төркем булып, бәхәсләшә-бәхәсләшә, мәчет капкасыннан чыга башлады

* * *

Дәрес бетеп, дамелла тәнәфес игълан итте. Балалар шау-гөр килеп ишек алдына сибелде. Җәйнең нәкъ уртасы иде. Ураза ае. Рәхимсез рәвештә кояш кыздыра. Минем ише тугыз-ун яшьлек балалар да ураза тота. Дөресрәге, тотарга мәҗбүр итәләр. Җиде-сигезләрдәге малайлар гына уразадан азат. Әнә алар таштай каткан нанпарын суда җебетеп керт-керт кимерәләр. Ә ураза тотучылар, көндезге кызуда үзләрен кая куярга белмичә, хавыз буендагы карагач төбендә утыралар. Күбесенең авыз әче кибеп, иреннәре ярылган. Кайберсе ара-тирә каядыр китеп, югалып тора...

Беркөнне мин шулай тәнәфес вакытында хавыз буенда ял итеп утыра идем. Ми кайнарлык кызу. Сусынны ничек басарга белмим. Һай, әгәр хавыз буена ятып, туйганчы су эчә алсам иде!.. Юк, ярамый: зур гөнаһ санала. Шулай да, бик интеккән чакта, авыз чайкарга ярый, диләр! Ләкин авыз чайкап кына сусау басылырмы соң? Хәер, басылмаса да, бераз җиңелрәк булыр. Нигә болай үземне газаплыйм соң әле, дигән уй күңелне кытыклый башлады бит, әй. Шул гөнаһ шомлыгыннан ничек котылырга дип торганда, хавыз буена төшеп, суга үрелгәнемне үзем дә сизми калдым. Аннары берәрсе күрми микән дип як-ягыма карандым. Күреп мулла абзыйга җиткерсәләр, нишләрсең?

Чымырдап торган су өстенә күзем төшү белән чирканып куйдым. Өере-өере белән йөзүче кызыл башлы кортлар кояш яктысында аермачык булып күренә иде. Суга кулымны тыгып болгатуга, балык кебек качып та беттеләр. Ләкин, кулымны алу белән, яңадан чыгып җемелди башладылар. Күпме тырышсам да, бушка булды. Гадәттә хавыз суын өйдә марля аша сөзәләр. Бер чиләк судан кайвакыт бер кәсә корт чыга. Теләсәм-теләмәсәм дә, мин куш учлап су кабып авызымны чайкый башладым. Күккә карап, аны бугаз төбенә төшергән саен, кортлы су голт-голт итеп тамагымнан үтә. Боламык ялап тамак туймаган кебек, авыз чайкаганда эчкә киткән су белән дә сусауны басып булмый икән. Алдыңда су торып та, туйганчы эчә алмагач, бигрәк үкенечле була икән. Минем бүтән түзәрлек хәлем калмады: авыз чайкаган булып, суның яртысын йота бардым.

Мәктәптә Нәүраз атлы эләкче бер малай бар иде. Шул минем авыз чайкавымны күреп, дамеллага җиткергән. Мулла абзыйның боерыгы белән, шундук яныма берничә малай килеп, кул-аягымнан өстери баш-

ладылар. Мин ай-вайлап караган идем, кая ул! Җилтерәтеп бүлмәгә алып керделәр. Түр башындагы мендәргә кырын яткан дамелла миңа усал күзләрен кадады. Ләкин сорау алырга өлгермәде, бүлмәгә атылып суфый килеп керде дә сулышы кысылып:

— Тәкъсир, һәлакәт! Меңбашын үтерганнәр! — диде.

— Алла сакласын, кемнәр үтергән? — дип, мулла абзый сикереп торды.

— Халык, тәкъсир, халык! Мәрдекарьлеккә барудан баш тартучылар. Мин шунда киттем! — дип, суфый, килеп кергәндәге кебек, шундук юкка да чыкты.

Бу көтелмәгән хәбәр дамеллага аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Миңа:

— Югал моннан, каһәр төшкән нәмәрсә! — дип кычкырды да киерелеп торып зур учы белән чалтыратып салып та җибәрде. Күземнән очкыннар чәчрәде. Мин шунда артыма авып, һуштан язганмын. Аңыма килә алмыйча бик озак ятканмын. Бер мизгелдән күземне ачсам, бүлмәдә беркем юк. Сул яңагымның авыртуына түзәрлек түгел. Кулым белән күземне угалап, ишек алдына карадым. Анда малайлар сафка тезелгән. Дәрес бетәр алдыннан без көн дә шулай сафка басабыз. Дамелла ишарә итүгә: «Әссәламәгаләйкем!» дип саубуллашабыз. Иллеалтмыш баланың бердән кычкыруы бөтен мәхәлләгә ишетелә диярлек. Дамелланың рәсми төскә керткән бу кагыйдәсендә тәгаен мәгънә бар: «Ата-аналар, ишетегез. Балаларыгыз дәрестән кайта. Урамда тулганып йөрмәсеннәр, каршы алыгыз!» дигән мәгънә иде бу. Шуңа күрә балачага да тизрәк өйгә кайтырга тырыша. Әгәр берәрсе, урамда тырай тибеп, соңга калса һәм моны ата-анасы дамеллага ишеттерсә, ул бала, һичшиксез, җәзага тартыла иде. Аны дәрестән соң саф алдына бастыралар. Өстәвенә, башкалар өйләренә кайтып киткәндә, суфый карамагына калдыралар. Ә суфый аңардан мәктәп һәм мәчет бүлмәләрен себертә. Шунысы гаҗәп, еллар буена үтәлеп килгән бу кагыйдә нишләптер бүген үтәлмәде — айван янындагы балалар «Әссәламәгаләйкем!» дип тә кычкырмадылар. Дамелла: «Барыгыз, өегезгә кайтыгыз! Шауламыйча гына таралыгыз!» диюгә, барысы да капкага йөгерде. Мин, мулла абзыйның күзенә күренүдән куркып, сиздермичә генә ишек алдына чыктым. Айвандагы букчамны да алмыйча, туп-туры урамга сыздым. Анда шәкертләрдән башка берәү дә күренми. Алар да артык шауламыйча өйләренә ашыга иде.

Әнкәй, мине көтеп, капка төбендә басып тора икән: «И балакаем, бу яңагыңа ни булды?» дип, мине кочаклап алды. Аннары, кулыннан төшермичә, бакчага алып керде. «Әни, җаным, тизрәк су бир! Эчәкбавырым яна. Уразасы чәнчелеп китсен!» — дидем.

Әнкәй хәлемне аңлады булса кирәк. Мине тиз генә җиргә төшерде дә: «Бу кыямәттә сиңа ураза тотмасаң да була!» дип, бер касә салкын су бирде. Аннары күлмәк итәге белән битемә җилпеде. Миңа ничектер рәхәт булып китте.

Шул мәлне капкадан әти кайтып керде. Әнкәй базардагы хәлне сорашмакчы иде дә атамның алҗыган йөзен күреп тынып калды. Әткәй җиләнен салып чөйгә элде. Башындагы сәлләсен әнкәйгә сузганда: «Уф, арыдым, су бармы?» — диде. Әни: «Бәй, уразаң нишли?» дигәндәй карап алгач, тәкчәдәге касәгә үрелде. Салкын чәй ясап, атама бирде. Әткәй: «Ходай берьюлыга кичерер әле» дип, касәдәге чәйне голт-голт эчеп, авыз кырыйларын сөртте. Аның маңгаена бөрчек-бөрчек тир чыкты. Анам камыш җилпәзәсе белән җилләндергәндә:

— Меңбашын үтерганнәр, диләр. Шул расмы? — дип сорады.

— Мирзаярга күптәннән шул кирәк иде. Үле гәүдәсе әле дә идарә янында ята, — диде атам күңелсез генә. — Халык нәфрәте меңбашын үтерү белән генә тынса ярар иде дә бит. Кызганычка каршы, күбесе

кулларына корал алып, Бишкуырга киттеләр. Алла сакласын, әгәр пеләш хакимгә дә кул күтәрсәләр, илдә зур афәт булачак...

— Атыңны кайда калдырдың соң? — дип сорады әнкәй.

— Аңа үлек юучының улы Урдүшмәт атланды. «Куй, балам, атыма кагыласы булма», дигән идем дә, колагына да элмәде. «Әгәр меңбашы белән пеләш хаким ягында булсагыз, мәйле, атыгызны бирмәгез!» — ди. Карасам, күзләрен кан баскан, зурдан кубарга тора. Аттан төшеп, йөгәнне кулына тоттырдым. Хәер, буласы эш булган. Исән булсак, ат табылыр. Миңа хәзер кибеткә чыгып керергә кирәк.

— Шундый хәвефле чактамы?

— Андагы маллар бер ходай карамагында калды. Берәрсе талап чыкканчы, өйгә алып кайту хәерлерәк булыр. Анда Мансур, Җурабай, Мираземнәрнең дә алачыклары ачык калган. Үзләре каядыр китеп югалган. Иртәгә ни буласын берәү дә белми. Пеләш хакимне тиле дип уйлама. Кулына корал күтәргән халыкны якты чырай белән каршы алмас. Меңбашын үтергәндә, ил хакиме кул кушырып утырыр дисеңме? Үгезнең мөгезенә суксаң, тоягы авырта, диләр. Бу гауганың ахыры хәерлегә булмас. Бар, анасы, хурҗунны чыгар. Бер-ике капчык та бир. Нәзиркол, синә да минем белән барырга туры килер.

Без капкадан чыкканда, әнием арттан: «Зинһар, сак булыгыз. Малмөлкәт бер кая да качмас. Кибетне басып кергән булсалар, янына бара күрмәгез. Баш исән булса, мал табылыр»,— дип борчылып калды.

Урамда халык умарта корты кебек гөж килә. Кулларында сәнәк тә балта. Үзләре шау-гөр килеп сөйләшәләр. Базар аша узганда, таш юл буенда күземә ниндидер кара нәрсә чалынды. Идарә ишек төбендә ертык-портык кәгазьләр, дәфтәрләр чәчелгән. Арык буенда юргандыр, ястыктыр кебек төрле өй җиһазлары аунап ята. Бездән алда баручы ике диһкан кара түшкәгә таш атты, аннары берсе: «Синең дә эт кебек дөмегер көнең килер икән, залим!» дип, аягы белән типте. Карасам, еракта түшкә булып күренгән нәрсә меңбашының канга батып кара көйгән гәүдәсе икән. Әгәр аягы-кулы булмаса, аны саман тутырылган капчык диярга була иде. Башы урталай ярылып, каны җиргә аккан...

Миңа чирканыч булып китте. Тиз-тиз атлап, әткәйне куып җиттем. Ул каршыга килүче кешеләрдән: «Анда ни бар? Нәрсә булды?» дип сораштырса да, берәү дә җавап кайтармый иде. Без Җурабай тагамның алачыгын узганда, Бишкуыр ягыннан чабып килүче берничә атлы күренде. Алар безнең яннан тузан болыты күтәреп узып та киттеләр.

— Болар хаким түрә солдатларыннан качып бармый микән? — дип борчылды әткәй.— Ай-һай, берәр хәл булмагае!..

Озак та үтмәде, яна шәһәр юлыннан бихисап кеше күренде. Әйтерсең лә артларыннан яу киләмени! Барысының да күзе тонган, сулышлары капкан, җәйге эсседә шыбыр тиргә батканнар иде. Ул арада халык агымы, язгы ташкын кебек урамга тулып, безнең яннан уза башлады. Кинәт мин шулар арасында Мансур абыйны күреп: «Әти, әнә әкәм килә!» — дип кычкырдым. Атам аны күрүгә: «Мансур! Монда кил!» — дип кул изәде.

Абый, төркемнән аерылып, безгә таба борылды. Кулына паяльник тоткан. Иөгерә торгач, хәлдән тайган булса кирәк. Алачык алдындагы сәкегә дөп итеп барып утырды. Әткәй сораганнарга да рәтләп җавап кайтармады. Ә халык һаман агыла да агыла — очы-кырые юк иде. Мин бизгәк тоткандагы кебек дерелдим:

— Әти, әйдә тизрәк кайтыйк. Әнә, барысы да кача бит!

— Ә кибеттәге малны кемгә калдырабыз? Бераз сабыр ит, улым.

Без өчәүләшеп хурҗун-капчыкларга кибеттәге малларны тутырдык. Бер капчыкка шикәр-чәй кебек ашамлык әйберләре, икенчесенә сабын, шырпы, җепләр сыеп бетте. Аннары, кибетне бикләп, өйгә кайтып киттек.

* * *

Кояш баеп, кичке эңгер төште. Гадәттә, бу вакытта беренче булып Аширмәт суфыйның сузып-сузып азан әйткәне ишетелә иде. Чөнки якын-тирәдә сәгатьле кеше булмаганга, азан безнең мәхәлләдәге Абдулла Мәгъсүмнең сәгатенә карап әйтелә башлый. Аширмәт суфыйның «аллаһе әкбәр»е ишетелгәнгә кадәр, башка мәчетләрдән тавыш-тын чыкмый.

Кузгалыш башланган көнне, төн кара пәрдәсен япкач та, мәчеттә азан әйтелмәде. Авыз ачу да такы-токы гына булды. Кичә генә әле без бу вакытта, дастәрхан тирәсенә тезелешеп, азан әйтелгәнен көткән идек. Ураза ахшамында табында нәрсәләр генә булмый: майлы пәтер нан[1], мәкле ак көлчә дисеңме, кыздырылган ит, мәнте, чәчвәрә яки мәшхүрдә[2] дисеңме, нишәллә, мәрәббә, хөрмә, шафталы, кавын-карбыз дисеңме — барысы да бар. Көн буена ач йөргәнгә, бу ризыклар тагын да тәмлерәк булып тоела. Кыскасы, бары барынча, югы хәленчә дигәндәй, өйдә булган ризыкларның барысы да дәстәрханга куела. Ә бүген, кузгалыш аркасында, күңелле авыз ачу да, намаз-гыйбадәт тә, мул табын да юкка чыгып, кешеләрнең йөзен борчу сөреме басты. Зурлар, бала-чага буласын көтеп, мал-туарларны эчкәрәк кертеп яптылар. Атам хурҗундагы товарларын сандыкка салып, капкачын кадаклап ук куйды. Уртанчы абыем, кое төбенә агач ботаклары ташлап, сандык белән әнкәйнең тегү машинасын төшерде. Ишек алдында барысы да мәш килә, кулга нәрсә эләксә, шуны яшерергә тырыша. Кемнендер киңәше белән юрган-ястыкларны, киез-keләмнәрне дә өй түбәсенә җәйделәр. Без, бала-чага, ахшамга кадәр үк инде шунда менеп кунаклаган идек. Эшләрен бетергәч, олылар да түбәгә менде. Алар һаман да шул кузгалыш турында сөйләшәләр иде.

Күршедәге Җәләл останың хатыны безнең ишек алдына ай-вайлап килеп кергәндә, шактый соң иде инде. Әткәй: «Нәрсә булды Җәмиләхан? Әллә берәр хәл бармы?» — дип сорады. Җәмилә тутәйнең сөйләвенә караганда, Бишкуыр юлында солдатлар белән сугышып яралананнар арасында Җәләл останы да күргәннәр. Ул тере икән әле. Рәват мәхәлләсеннән килгән кеше: «Ирегез Ташлакта арык буенда ыңгырашып ята», дигән. Бу хәбәр барыбызны да борчуга салды. Мансур белән Җурабай тагам шунда ук аска төштеләр. Кулларына носилка алып, Җәмиләттәй белән Ташлакка киттеләр. Без бик озак тынычлана алмадык. Мин абыйларга дәрестән соң урамда Җәләл останы күрүем турында сөйләдем. Атам: «Җитәр, шауламагыз, сезгә йокларга вакыт!» дип кисәткәч тә әле, бик озак йоклый алмый яттык. Күз алдыннан бер-бер артлы Мирзаяр меңбашының кара гәүдәсе, Мансур белән Җурабай тагам сөйләгән коточкыч күренешләр узды.

Башта Мирзаяр меңбашы белән хаким түрәне үтерү уе берәүнең дә башына килмәгән булган. Дөрес, төнлә мәхәллә яшьләре каләндәрханәгә җыелганнар. Анда Рәват, Аккурган, Уратүбә, Савынгәр мәхәлләләренең дә гәп-гәштәк егетләре катышкан. Үзара бик озак киңәшкәч: «Үлсәк үләрбез, әммә мәрдекарьлеккә бармыйбыз! Әгәр мәхәллә егетләренең берәрсе акчага сатылып, мәрдекарьлеккә ялланса, андый хаинне юк итәргә. Моны үтәмәгән егеткә ана сөте харам булсын!» дип сүз куешканнар.

Иртәгесен Җурабай тагам алачыгына чыга. Учакка күмер салып, ут кабыза. Аннары, урак чүкеп маташканда, кавын базарына таба йөгерүче кешеләрне күрә. Нәрсә булды икән? дип урамга чыкса, анда барысы да идарәгә таба йөгерә икән. Шул мәлне кулына паяльник тоткан Мансур да килеп җиткән. Алар, эш киемнәрен дә салмыйча, кавын

[1] Көлчәнең бер төре.
[2] Үзбәк ашлары.

базарына таба китәләр. Барсалар, идарә алдында Мирзаяр меңбашы белән чүлмәкче Дәмин бугазга-бугаз килеп кычкырышалар икән. Чүлмәкченең өс-башы пычрак, ыштан балаклары тезенә кадәр сызганылган, ди. Күрәсең, ул бирегә эшханәсеннән үк килгән булгандыр. Меңбашы ярсып:

— Мәрдекарьлеккә башканың улы бармаса да, син имансызның улын җибәрәчәкмен! — дип җикергән.

Дәмин оста да сүз эзләп күршегә керә торган түгел.

— Син үзең имансыз! Ярлы-ябагайны таларга гына торасың! — дигән.

— Югал моннан, хатының талак!

— Хатының талак син ул, бәдбәхет! — дип, кул йомарлап кычкырган чүлмәкче.

— Син юньсезне нишләтергә инде?

— Бер нәрсә дә эшләтмә. Мәрдекарьлеккә баручыларның исемлеген бир! — дип, Дәмин оста меңбашының дәфтәренә ябышкан. Ике арада талашу-тартышу башланган. Корбанбай да ярдәмгә килеп, дәфтәр Дәминнең кулына күчкән. Чүлмәкче аны кисәк-кисәкләргә ерткалап җиргә атып бәргән. Меңбашы камчысы белән аның башына суккан. Икенче тапкыр кизәнгәндә, Урдушмәт аның кулыннан камчыны тартып алган. Чүлмәкче Дәмин Мирзаярның якасыннан тотып таш юлга өстерәгән:

— Алай бик батыр булсаң, әйдә, мәйданга чык! — дип, бугазыннан алган.

Урамдагы халык төрле яктан:

— Каны чыкмаслык төшенә сук, кызы талакның,— дип кычкыра икән.

— Ныграк бу, ныграк!

— Бөеренә тип!

Дәмин оста, җирдән таш алып, тегенең башына кундырган. Меңбашы һуштан язып җиргә егылган. Нәкъ шуны гына көткәндәй, ярсыган халык, Мирзаярга ташланып, ничек әлекте шулай типкәләргә тотынганнар. Меңбашы бөтенләй тынып калган. Кешеләр моның белән генә чикләнмичә, идарә әйберләрен чыгарып тондырганнар, эш кәгазьләрен ут төртеп яндырганнар.

Баш күтәрүчеләр арасыннан берсе:

— Җәмәгать! Буласы эш булды! Инде моны азагына кадәр җиткерергә кирәк. Әйдәгез, хәзер Хедер меңбашын да дөмектерәбез! — дип кычкырган.

Атлылар атка атланып, калганнары җәяү Ямь кышлагына киткәннәр. Бу хәлне алдан сизгән Хедер меңбашы өеннән чыгып сызган. Баш күтәрүчеләр, идарәне күпме актарсалар да, меңбашын таба алмаганнар. Шул ачудан халык өй җиһазларын чыгарып яндырган.

— Мөселманнар! Меңбашы үтерелеп, пеләш хаким исән калса, безгә барыбер көн булмаячак! Әйдәгез, Бишкуырга! — дип өндәгән әлеге кеше.

Җайдаклар ат башын яңа шәһәргә таба боралар. Алар артыннан әшыга-кабалана: «Әйдәгез, тизрәк кыймылдагыз!» дип, җәяүлеләр кузгала. Халык агымының башы Җиззахның зур урамына җиткәндә, Ташлак юлыннан каршыга килүче хаким түрәнең фаэтоны белән берничә атлы полицейский күренә.

Баш күтәрүчеләр аларның юлын бүләләр. Өяз хакиме ярдәмчесе белән фаэтоннан төшә. Башындагы фуражкасын салып, ярсыган халыкка мөрәҗәгать итә. Мирзаһәмдәм тылмач аның сүзләрен тәрҗемә итеп тора: «Җәмәгать, тынычланыгыз! Хаким җәнаблары, минем поданныйларым ни өчен болай тәртип бозып йөри? Аларга нәрсә кирәк? Әйтсеннәр», ди.

Халык кинәт тынып калган. Мирзаһәмдәм: «Нигә дәшмисез? Берәрегез, уртага чыгып, халыкның теләген әйтсен», дигән.

Баш күтәрүчеләрнең барысы да берьюлы сөйли башлаганнар:

— Мәрдекарьлеккә кеше җибәрмибез!

— Сүзебезне тыңлаучы кеше юк!

— Мирзаярның башына җиттек. Хәзер кяфер хакимнең дә әҗәле безнең кулда!..

Өяз түрәләренә бу көтелмәгән яңалык була. Алар, Җиззах байлары һәм аксакаллары белән мәрдекарьлеккә кеше җибәрү турында сөйләшергә дип, мәдрәсәгә баралар икән. Хаким түрә, ярсыган халык чолганышында калганын күреп, хәйләгә күчкән:

— Яхшы, подданныйлар белән хөкүмәт башындагылар арасында андый гына аңлашылмаулар булып тора. Әгәр меңбашы халыкка тел тапмаган икән, Мирзаяр кебек үз башына гына житәчәк. Халык кулыннан дүрт-биш кеше үтерелгән икән, ул безнең өчен зур югалту түгел!— дигән.

— Ул хәтле булмады әле,— дип кычкырган берсе халык арасыннан.— Мирзаярга сезне дә куш итсәк, ул чакта, чынлап та, дүрт-биш була!..

Халык тагын шаулый башлаган. Берсе: «Җәмәгать, тынычланыгыз! Башта хакимнең сүзен тыңлыйк!» дип әйтүгә, Мөхәммәди дигән кеше: «Бай-түрәләрне тыңлап, без күп алдандык, артык түзәр хәлебез калмады. Һай, мөселманнар, байлар безгә бер вакытта да кардәш булмаячак!» дип, атын камчылап, өяз хакименең өстенә ташланган. Камил миршаб аңа мылтыктан аткан. Пулясы Мөхәммәдигә тимичә, башка бер кешене егып салган.

Нәкъ шул мәлне яңа шәһәрдә баш күтәргәннәр дә килеп җитеп, гауга зурга киткән. Хаким түрә хәйлә белән эш барып чыкмасын күргәч, полицейскийларына ишарә иткән дә, тегеләр шатыр-шотыр ата да башлаганнар. Мылтык-наган тавышлары баш күтәрүчеләрнең ярсуын көчәйткән генә. Алар шунда ук өяз хакиме полковник Рукинны, пристав штабс-капитаны Золотоглазовны, тылмач Мирзаһәмдәмне, Камил миршабны үтереп тә ташлаганнар. Сабир миршаб исә, аты белән халык төркемен аралап-ерып, качып котылган.

Шунда кола атка атланган бер кеше уртага чыгып: «Берадәрләр!»[1] дип кул күтәргән. Ярсыган халык бераз тынычлангач:

— Берадәрләр! Залимнәрдән үч алып бик дөрес эшләдек! Әнә, алар үз каннарына баттылар. Явыз түрәләрне юк итүче ил батырларына дан! Ләкин, дуслар, бу эшне без ярты юлда гына калдырырга тиеш түгел. Дошманның черки кадәр генә булса да, игътибарсыз калдырырга ярамый, диләр. Әйдәгез, яңа шәһәргә. Анда да кайбер эшләрне бетерәсебез бар! Йа амин, аллаһе әкбәр! — дип, ялангач кылычын баш өстендә уйнатып, Бишкуырга таба чабып киткән.

Көрәк, китмән, сәнәк, балта белән коралланган халык Җиззах базарыннан алып Ташлакка кадәр сузылган юлдан язгы ташкын кебек шаулап яңа шәһәргә таба агылган. Ләкин юлда аларга каршы коралды солдатлар очраган. Алар подполковник Афанасьев боерыгы белән, өяз хакимен хәвеф-хәтәрдән сакларга дип, иске шәһәргә баралар икән. Баш күтәрүчеләрне күрү белән, атарга әзерләнеп, җиргә ятканнар. Солдатларга беренче булып Гаеб дигән егет ташланган. Ләкин кара туры атына пуля тиеп, ат өстеннән мәтәлеп төшкән. Болытларга сикерердәй чаптар ат, тыпырчынып, шундук җан биргән. Шул арада ике як йөзгә-йөз килеп сугыша башлаган. Баш күтәрүчеләр, мылтык-пулемет утыннан кырылып, җиргә егыла барганнар. Халыкның дошманга каршы то-

---

[1] Туганнар.

рырлык бүтән әмәле калмаган. Алар артларына борылып кача башлаганнар...

Кузгалышка үзе катнашкан Мансур абыем белән Журабай тагам сөйләгәннәр һәм колагыма кургашын кебек сеңеп калган бу вакыйга ул елны Жиззахта булган коточкыч хәлләрнең бер өлеше генә иде.

* * *

Еракта таң йолдызы җемелди. Ә мин һаман да әле йоклый алмыйм. Атам белән анам да йокламыйлар, күрәсең:

— Болар нишләп кайтмый инде? — диде әни, авыр сулап.

— Таң атарга вакыт бар әле, исән булсалар, әйләнеп кайтырлар. Ташлак юлы якын ара түгел. Бакча, диварлар аша кеше гәүдәсен күтәреп кайту җиңел дип беләсеңме? Бу әле баласы гына... Таң аткач, ниләр буласын бер алла гына белә,— диде әткәй.

— Булмаган нәрсәләрне уйлап баш ватма. Тәкъдиргә нәрсә язылса, шуны күрербез,— дип көрсенде анам.

— Алай димә, карчык. Туфрак кургандагы (жиззахлылар яңа шәһәрдәге казарманы шулай дип атыйлар иде) офицерлар, мылтык атып, халыкны тарату белән генә тынычланмаслар. Алар бу кузгалыш турында губернаторга, хәтта патшаның үзенә дә җиткерерләр. Билгеле, Мирзаяр белән Мирзаһәмдәм кебек өч-дүрт сартның [1] үлүенә ак патшаның исе китмәс. Ләкин Жиззахтагы хәлнең башка шәһәрләргә дә күчүе бар бит. Якташларың баш күтәреп патшалыкның бер түгел, ике нигезен какшаттылар, анасы. Моның өчен Никулай патша рәхмәт әйтмәс, алла сакласын...

Урамда Мансур абыйның тавышы ишетелгәндә, еракта таң сызыла башлаган иде инде. Ул, кайтып керү белән, Ташлактагы хәлләрне сөйләде. Дошман пулясы Жәлал остаңың үт капчыгына тигән икән. Алар эзләп тапканда, оста бөтенләй аңсыз булып, «су-су», дип ыңгырашып яткан. Якын тирәдә су булмаганга, абыйлар аны носилкага салып юлга чыкканнар. Жиззахка җиткәч, зират аша каләндәрханәгә керергә булганнар. Зиратта Жәлал оста җан биргән. Хуҗамазарга Ташлак бәрелешендә корбан булган тагын берничә кешене китергәннәр. Шундагы мулла: «Газаватта [2] һәлак булганнар шәһид [3] санала. Аларның мәете гадәттә юылмый, кәфенгә дә төрелми. Сугыш кырында нинди хәлəттә җан бирсә, шул көенә җиргә күмү саваплы», дигән. Дамелланың киңәше белән, Жәмилә түтәй дә килешкәч, мәетне өйгә алып кайтмыйча, шунда гына җирләргә булганнар. Мансур абый шул турыда Жәлал остаңың туган-кардәшләренә, мәхәллә кешеләренә әйтергә дип кайткан икән.

Атам белән жизни, тагын берничә ир-ат зиратка юнәлделәр. Мансур абыем остаңың үлүе турында әйтергә күршеләргә кереп китте.

## АНА ЙӨРӘГЕ

Жәза бирү отряды озак көттермәде. Ил өстенә кара болыт булып ябырылып килеп тә җитте. Әйтерсең лә коры урманга ут төрттеләр дә, агач ботаклары шатыр-шотыр килеп яна башлады. Барлык бәхетсезлек бай-түрәләрдән чыга, пеләш хакимне, меңбашларны үтерсәк, гаделсезлек бетәр дип уйлаган халык илгә бу кадәр кайгы-хәсрәт килә-

---

[1] Үзбәк.
[2] Дин юлындагы изге сугышта.
[3] Дин юлында яки кеше кулыннан вафат булучы.

сен күтмәгән иде. Золым-җәбер үзәкләренә үтеп, сабыр тартмасы тулганга, Җиззах халкы баш күтәрде. Политикасы талауга, колонизациягә корылган рус патшалыгы халыкның энә кадәр «гаебенә» дөя кадәр җәза белән җавап кайтарды.

Җиззахлыларның кузгалышы берничә түрәне үтерүдән артыкка бармады. Баштанаяк коралланган җәза бирү отрядының һөҗүменә коралсыз халык каршы тора алмады, билгеле. Солдатлар, котырган эт кебек ырылдап, йорттан йортка йөреп, халыкның мал-мөлкәтен таладылар. Өй җиһазларын арбаларга төяп, мал-туарларын куып чыгарып, йортларына ут төрттеләр. Җае туры килгәндә, хатын-кызларны көчләп, ир-атларны атып үтерделәр. Патша җәлладлары үз вәхшилекләрен: «Хөкүмәткә каршы баш күтәрүчеләргә менә шулай җәза бирелә», дип акладылар. Хәер, Николай патша никадәр шәфкатьсез булмасын, җәза бирү отряды никадәр рәхимсез кыланмасын, халыкның рухын бөтенләйгә төшерә алмадылар. Җиззахлылар күңелендә һаман да әле үч алу теләге сүнмәгән иде. Ак патшага каршы коры таяк белән күтәрелгән кешеләр үз ялгышының нихәтле авыр булганын аңласалар да, нәфрәт тойгысы аларга тынгылык бирмәде. Залимнәргә баш иеп, кайгыхәсрәттә яшәгәнче, зур көрәшкә, халык азатлыгы өчен үләргә риза булган арыслан йөрәкле батырлар илдә аз түгел иде.

Җәйге чиллә вакыты. Кояш җир йөзенә нурын түгел, ялкынын чәчә. Көн бөркү. Чикерткәләр, кереп качарга тишек таба алмагандай, бертуктаусыз череллиләр. Баш күтәрүчеләрнең берсе дә өйдә калмаган. Кая туры килде шунда качканнар. Хатын-кызлар биек дивар артындагы куе куаклыкка посканнар. Безнең әниләр дә шунда.

Җәйге көн озын була икән. Хәвеф-хәтәрдән сакланыр өчен ышыграк җирләргә кереп качкан бичара аналарның хәле тагы да авыр. Яшүсмерләр, имчәк балалары читлектәге кошчык кебек талпыналар. Иң хәвефле вакытта да тыела алмыйча чәрелдәп елап җибәрәләр.

Яшь кенә бер ана бертуктаусыз елаган имчәк баласына:

— Туктыйсыңмы, юкмы, каһәр суккыры? Болай да сәгатебез санаулы калды. Бәхетсез бала булмасаң, шундый мәхшәр көндә дөньяга килер идеңме? — дип ачуланды.

— Куй, алай димә, кызым. Сабыйның ни гаебе бар?! Үзе теләп дөньяга тумаган лабаса. Ирең белән бергә тапкансыз,— диде бер карчык.

Шул мәлне бер-бер артлы атылган мылтык тавышы карчыкның сүзен бүлде. Баш өстеннән чыжылдап пулялар очып китте. Кемдер куаклык арасыннан:

— Үләсегез килмәсә, качыгыз!..— дип кычкырды. Ләкин кая качарга? Алда биек дивар, артта куе куаклык. Шулай да хатын-кыз, чыр-чу килеп, төрле якка сибелде. Аналарның ай-вае, балаларның үкереп елавы барысы бергә буталды. Әнкәй һәмрә апаны диварга менәргә ашыктырды:

— Син өскә мен, ә мин астан балаларны бирә торырмын,— дип, үзе стена төбенә чүгәләде. Апам, аның җилкәсенә басып, өскә менмәкче булды. Мин дивар башына менеп атланган идем инде. Апама булышырга дип кул сузганда, тагын шарт-шорт ата башладылар. Карасам, диварның теге ягыннан зур гәүдәле бер солдат килә, күзләре тонган: мылтыгын кешеләргә түгел, күккә гөбәп ата иде. Әллә дивардан сикереп качыйммы икән дип тә уйлап алдым. Ләкин коймa төбендәге анамны, тырыша-тырмаша өскә менәргә азапланган апамны, аның итәгенә ябышып елаучы балаларны күреп, ул уемнан кире кайттым.

— Нәзиркол! Кулыңны бирче! — диде апам, диварга тотынган килеш.

Мин, ярышта бәрән белән тартышкан көрәшче сыман, диварның бер

ягына авышып, Һәмрәның кулыннан тарттым. Ниһаять, ул да койма өстенә атланды. Анам аңа берәм-берәм сабыйларны бирде.

— Нәзиркол, син хәзер җиргә төшеп, балаларга булыш,— диде апам. Мин шулай эшләдем. Апам сабыйларны бер-бер артлы миңа бирә барды. Куркудан котлары алынган балаларны иплəп кенә җиргә төшердем. Иң азактан дивар өстендә әнкәй күренде. Алар апам белән аска сикергәндә икесе дә җиргә егылды. Әнкәй энекәшне, апам ике кызын житәкләп, ышыграк җиргә яшеренделәр. Шул чакны койма артында ай-вайлаган хатын-кыз тавышы ишетелде. Әни нишләргә дә белмичә:

— Бичара Мөһри солдат кулына эләкте,— дип аһылдап куйды.

Мөһри безнең күрше хатын иде. Хәер, анам бу минутта нәрсә генә эшли алыр иде икән?!

Мин печәнлек буйлап качып барганда, тигәнәкле җиргә туры килеп, табан астыма бихисап чәнечке кадалды. Нindидер каты нәрсәгә бәрелеп, бармагымны канаттым. Дивар артында янә берничә тапкыр мылтык аттылар. Табаным авыртуын искә дә алган юк. Ул минутта минем өчен тән кайгысы түгел, җан кайгысы иде. Шулай аксый-чатанлый бакчадагы мәйданчыкка барып чыктым. Сулышым кысылып, йөрәгем дөп-дөп тибә. Авызым кибеп, иреннәрем ярылган. Табан астым үтереп авырта, бармагымның канавы һаман да туктамый.

Кинәт мәйданчыкта бер кеше пәйда булды. Ул як-ягына каранды да миннән якында гына тирән чокырга сикерде. Ә мин яткан җир — ачык мәйдан. Әллә миңа да шунда төшәргәме дип уйлап алдым. Түшем белән шуышып чокыр янына килдем. Теге кеше мине күрү белән: «Монда төшмә! Кит моннан, юньсез, кит!» — дип пышылдады.

Мин, аңа игътибар итмичә, артым белән шуып чокырга төштем. Ул мәхәллә картларының берсе — Ширназар суфый булып чыкты. Шатлыгымнан чак кына кычкырып җибәрмәдем: «Әмәкеҗан, атамны табарга булышыгыз әле»,— дип, тегенә чат ябыштым. Суфыйның күзләре дүрт булды. Ул, миннән ничек котылырга белмичә, җилән чабуларын тарта, ә мин җибәрмим.

Берни дә чыкмагач, ул миңа ялына башлады: «Ата-бабаңа рәхмәтләр төшкере. Нәзирҗан улым, син мине җибәрә күр инде. Солдатлар күрсә, икебезне дә атып үтерерләр!» — ди. Ә мин һаман: «Әткәйне тап!» — дим.

— Тавышыңны чыгарма, юньсез!.. Кайсы гүрдән ябышты әле бу бәласе! — дип, суфый күкрәгемә төртте. Ә үзенең көче юк диярлек. Тире белән сөяк кенә. Муены ташбаканыкы сыман кат-кат булып җыерчыкланган. Чигәсендәге зәңгәр кан тамырлары дерт-дерт тибә. Ак сакалын тигәнәк сырып алган. Нурсыз күзләре эчкә батып кергән.

— Җибәр!.. Җибәр дим, каһәр төшкере! — дип, ул яңадан җилән чабуын тартты. Ә мин аңа тигәнәк кебек ябыштым да каттым. Суфый көчкә үрмәләп чокырдан чыкты. Ә мин чабуына ябышкан килеш аста торам. Бер мәлне күтәрелеп карасам, суфыйның җиләне миндә, ә үзеннән җилләр искән. Әмәлен табып, мин дә тиз генә чокырдан чыккан идем, ни күрим! Суфый, биленә кадәр шәрә килеш, җил-җил атлап, качып бара. Тиздән ул да койма артына кереп, күздән югалды.

Мине һаман чәнечкеләр газаплый. Кымшанган саен аягым энә кадалгандай итә. Шунда күңелем тулды. «Әни!» — дип кычкырасым килде. Алар кайда яшеренде икән? Солдатлар кулына эләгеп, ул-бу булмады микән? Берәрсенә пуля тимәде микән? Бичара Мөһри түтәй нишләде икән? Һай, бу аналар! Артларыннан яу килсә дә, мылтык атсалар да, сабыйларын ташламаслар! Үз баласы өчен ана йөрәгениләр генә кичерми? Шул кадәр авырлык, шул кадәр кайгы-хәсрәтне кичерергә алар каян көч табалар? Иң дәһшәтле минутларда да, баласы аягына тышау булып уралганда да, ана сабыйларыннан ваз кичми. Кыр кәҗәсе кебек,

ерткычка җим булганда да, алар үзләрен түгел, балаларын кайгырталар...

Ниһаять, кояш баеп, җир өстенә караңгы төште. Күз бәйләнү белән, аналар, балаларын ияртеп, берәм-берәм өйләренә кайттылар. Тирә-як кинәт тынып калды. Солдатлар да юкка чыкты. Күрәсең, яңа шәһәрдәге казармаларына кайтып киттеләр. Төн караңгысында баш күтәрүчеләр арасында калудан курыктылар бугай.

Мин арык буена утырып, табаныма кадалган чәнечкеләрне тырнагым белән берәм-берәм тартып чыгардым. Аннары иплэп кенә аягыма басып карадым. Ләкин файдасызга булды. Бик тирән кергән чәнечкеләр, әнә кадалгандай авырттырып, атларга ирек бирми. Ә караңгы һаман төшә генә бара. Нәрсә эшләргә? Аяксызлар тез башлары белән атлап йөриләр бит, дигән уй башыма килде. Мин дә шулай, мүкәйләп дигәндәй, кузгалып киттем. Чокыр-чакырлы җирдәге тигәнәкләргә тез башларым, битләремне сыдырып бетердем. Тирә-юньгә дәһшәтле тынлык урнашкан. Этләр дә өрми, ичмасам. Ара-тирә яңа шәһәр ягыннан атылган мылтык тавышлары гына ишетелгәли. Төн карасында пулялар кызыл сызык сызып кинәт юк булалар. Тез белән ерак барып булмый икән. Шулай да азаплана торгач, Лотфулла бабайларның бакчасына килеп җиткәнмен. Ике битем, терсәкләрем, тез башларым канап, чи иткә әйләнде. Түзәр хәлем калмыйча, карагач төбенә утырып, елап җибәрдем. Бәхетемә, агачлар арасыннан ай калыкты. Күңелем шуңа бераз тынычлангандай булды. Кинәт дивар чатыннан миңа таба килүче бер кара шәүлә күренде. Йөрәгем жу итеп китте. Ләкин «Кем анда?» дип сорарга җөрьәт итмәдем.

— Нәзир!.. Нәзиркол улым!.. Син кайда?

Бу әнкәй тавышы иде. Мин:

— Әни! — дип кычкыруымны сизми дә калдым.

— Анасы! Улың табылды. Бирегә кил,— дип, шунда әти дә койма яныннан кычкырды. Ай яктысында атам белән анамның шәүләсе күренде.

— Син кайда, балакаем, күз нурым?

— Монда, әнкәй, монда!

Мин аларга каршы җирдән шуышып бара идем, әнинең коты алынды.

— Курыкма, әнкәй. Миңа берни дә булмады. Табан астыма чәнечкеләр генә кадалды,— дип, аны тынычландырырга ашыктым.

Әти мине шунда ук күтәреп алды.

## СӨРЕЛҮ

Өйдәгеләр бүген аеруча борчулы. Барысы да тиздән мәхәлләнең тупка тотылуын көтә. Шуннан ничек котылырга белмиләр. Атам сусыз хавыз төбенә төшәргә киңәш бирде. Хатыннар, балаларын алып, берәм-берәм шунда төште. Ирләр дивар артындагы чокырга яшеренде. Алар, ара-тирә ишек алдына кереп, хатын-кызларның хәлен белешеп торалар иде. Без, алда буласы мәхшәрне көтеп, хавыз төбендә ятабыз. Тирә-як кабердәй тын. Кояш бакча артыннан күтәрелеп килә.

Кинәт урам ягыннан Таҗи диванаын тупас тавышы ишетелде:

— Әй! Алланың кашка тәкәләре! Кайда яшерендегез? Тавыш бирегез!

— Без монда, хавыз төбендә,— дип эндәште әнкәй.

Таҗихан хавыз буена килеп басты.

— Әҗәлегез житте! Җаны барлар качып котылыгыз! Мәхәлләгә ябырылып яу килә. Солдатлар кешегә карчыга кебек ташланалар. Ха-

лыкны көтүе-көтүе белән каядыр куып баралар,— дип, шом салды да үзе шундук юкка чыкты.

Хавыз төбендәгеләр берни аңламый калды. Кайберләре борчылып урыннарыннан торды. Чыннан да, ерактан дәһшәтле шау-шу ишетелде. Мин, хавыздан чыгып, урам ягына карадым. Анда урам тулы халык ашыга-кабалана безгә таба килә иде. Алдан һәм як-яктан кораллы солдатлар урап алганнар.

— Но, но! Пошел! — дип, мал куган кебек, мәхәллә халкын каядыр ашыктыралар.

Безнекеләр хавыз чокырыннан чыгарга да өлгермәде, каяндыр ике солдат килеп, безгә мылтык төбәде. Бала-чага үкереп елый башлады.

Солдатлар:

— Монда чыгыгыз! Әйдә, тизрәк булыгыз! — дип җикеренделәр.

Хатыннар, балаларын кайсы күтәреп, кайсы җитәкләп, ава-түнә хавыздан чыктылар. Солдатлар безне этә-төртә халык төркеменә илтеп кушты. Без нәрсә булганын, кая баруыбызны белмибез. Артта калучы карт-корыларны мылтык түтәсе белән төрткәлиләр. Без, шулай бара торгач, базар урамына җиттек. Андагы халыкның күплегенә исең китәр! Юл өстен тузан каплап алган. Соры болыт эченнән кешеләр көчкә күренә. Атлы казаклар кылыч уйнатып әрле-бирле чабып тора. Инешләр кушылып дәрья хасил иткән кебек, мәхәлләләрдән җыелган кешеләр дә дулкынлана-дулкынлана каядыр агыла. Мин дә шул ташкында йомычка кисәге кебек аңсыз рәвештә агып барам. Шулай атлый торгач, халык каядыр килеп туктады. Кайсы җир икәнен башта абаламыйча тордым. Карасам, зур мәйданга чыкканбыз. Тирә-юньдәге йортлар янып, кайнар көл өеме генә торып калган. Кешеләрнең коты алынган. Өс-башларына тузан кунган. Утлы күмер шикелле җемелдәгән елтыр күзләре белән ак тешләре генә күренә иде.

Күзләрем таш колонкаларга төште. Аннары Нуретдин хаҗиның мәдрәсәсен күрдем. Аның уң як манарасы исән калып, сул яктагысы җимерелгән. Күптән түгел генә әле без, Акылбәк белән шунда менеп, шәһәрне караган идек. Манара башыннан шәһәр манзарасы гаҗәеп матур булып күренгән иде. Бишкуыр белән иске шәһәр арасындагы таш юлда фаэтоннар, арбалар, кыр казлары кебек, бер-бер артлы үтеп кенә тора иде.

Ә хәзер базар тирәсендәге йөзләгән йорт, кибет, чәйханәләр янып кара күмергә әйләнгән. Бары тик мәдрәсә белән ак йорт [1] кына исән калган. Без тукталган җир кәппан [2] базарының уртасы булып чыкты. Бу мәйдан елның дүрт фасылында да кешеләр белән тулы булып, анда беркайчан да сәүдә өзелми иде. Моннан бер атна гына элек биредә капчык-капчык бодай, арпа, дөге, маш [3], киндер, борчак, кукуруз дисенме, төрле сорт он, кузы, мәез, өрек, алма, шафталы дисеңме — барысы да тау-тау өелеп ята иде. Ә хәзер мәйданда кешедән башка берни дә юк. Янгын исе, борынны ярып, сулышны кысып, күңелне чиркандыра.

Биш гектардан артык мәйданга карты-яше тыгызлап тутырылгандай тулган. Аларны төрле яктан кораллы солдатлар урап алган. Уртадагы калку җирдә алтын погонлы офицерлар басып тора. Алар бер кайгысыз гәпләшәләр... Кара тиргә баткан җиззахлылар үз язмышларының нәрсә белән бетәсен белмиләр. Ара-тирә, эсседән һушын җуеп, авып китүчеләр дә күренгәли. Берәүгә дә утырган җиреннән торырга ярамый. Әгәр берәрсә кузгала башласа, солдатлар шундук мылтык түтәсе белән кизәнә башлыйлар.

---

[1] Җиззахлылар өчен ачылган рус мәктәбе.
[2] Бакалея кибетләре урнашкан җир.
[3] Кузаклы үсемлекләрнең бер төре.

Төш вакыты якынлашып килә. Баш өстенә күтәрелгән кояш мәйданга аяусыз ялкынын сибә. Халык сусаудан нишләргә белми. Вакыт узган саен кешеләрнең — бигрәк тә карт-корыларның — кысталуы табигый хәл. Кайберләре солдатларга ялына башлады.

— Йомышлары булганнар утырган җирләрендә бетерсен? — дип кычкырды сары чәчле офицер. Менә халыкның ачуы ашып ташыды. Кешеләрнең күзләрендә нәфрәт очкыннары чагылды. Төрле яктан атыюлы белән сүгенү ишетелде.

— Кабахәтләр!

— Мона кадәр кеше идек, бу инсафсызлар кулында хайванга әйләндек!

— Ялынмагыз шул этләргә!

— Патшалары белән бергә дөмеккерләре!

Солдатлар, көтүгә ташланган ач бүре кебек, бертуктаусыз халыкка ырылдыйлар. Ул арада аналар кочагындагы сабыйларны тартып алып, кычкырта-акырта бәдрәф янына җыярга керештеләр. Аналар ай-вайлап балалары артыннан йөгерә, хәрбиләр юлларын бүлеп, аларны нәниләре янына җибәрмиләр. Бичара сабыйлар буыла-буыла елыйлар.

Мәйданда йөкле хатыннар да күренгәли иде. Кайберсен тулгак тота башлады. Шуның газабыннан җирдә аунаучы хатыннарга ярдәмгә ашыккан карчыкларның да солдатлар юлын бүлде.

— Түрәҗан! Зинһар, җибәр. Бәбинең кендеге киселмәсә, ана да, бала да харап булачак! — дип ялварды яулыгы иңсәсенә төшкән чал чәчле карчык.

Бу коточкыч хәлгә теләсә кемнең йөрәге эрергә тиеш иде. Һәм шулай булды да. Бер солдат кара канга баткан ана янына барырга ашыгучы карчыкка рөхсәт бирде, шуның аркасында үзе дә бәлагә тарыды. Әтәч кикригедәй кызыл йөзле, коңгырт мыеклы бер офицерга рус солдатының үзбәк хатынына иткән шәфкате ошамады. Әлеге солдатны баш күтәргән сартлар алдында коралсызландырып, мәйданнан кудылар. Кәппандагы халык моны үзенчә гөман кылды.

— Солдатларның да рәхимлеләре булыр икән.

— Алар да бит патша колы! Юкса...

— Үз башы бәлагә каласын белсә дә, түзмәде, бичара...

— Ул да бит — ана баласы...

— Кайсы милләт кешесе булмасын, бае байга карый, ярлысы ярлыны таный...

— Сартларга шәфкать иткәне өчен ул бичаракайны атмасалар ярар иде...

Бу хәл рус солдаты белән офицерлар арасында ниндидер аңлаешсыз каршылык барлыгын күрсәтте. Җәзага тартылган солдатка карата кызгану тойгысы уянды. Кайберләре алтын погонлы офицерларны каргап алды.

Мәхәллә урамнарыннан кәппанга таба агылучы кешеләрнең азагы һаман да күренми иде әле. Тора-бара халык мәйданга сыймый башлады. Кешеләр тагы да бер-берсенә елыша төште. Алда нәрсә буласын берәү дә белми. Һәркем үзенчә фикер итә. Берсе: «Безне монда җыеп Себергә озаталар икән» дисә, икенчесе: «Бәйдәге эт ауга яраксыз, диләр. Шул кадәр кешене, үз башына бәла итеп, патша Себергә җибәрәме соң? Шушында гына кырып бетерәчәкләр» дип, халыкның котын ала. Хатын-кыз кыямәт җиткәндәгедәй еларга керешге; ирләр, аллаһе тәгаләдән залимнәргә мәрхәмәт бирүен сорап, авыз эченнән дога кылып алдылар. Безнең гаилә калкурак җирдә утыра иде. Каршыда гына янган өйнең көл-күмере пыскып ята, аннан әчкелтем көек исе килә.

Шул мәлне солдатлар хәрәкәткә килеп, икегә бүленделәр. Аннары мәйданның көнчыгыш һәм көнбатыш тарафына узып, уракта́й түгәрәк

рәвешендә бастылар. Көньякта бер солдат та калмагач, халыкның шомлануы көчәя төште.

— Әйткәнем килдеме? — диде баягы кеше.— Әнә, тупларны монда таба боралар. Хәзер шулардан безгә атачаклар. Соңгы догагызны укыгыз, мөселманнар! Лә иләһе иллалаһе мөхәммәде рәсүлулла! — дип амин тотты.

Мин тупларны карарга дип аягүрә бастым. Чыннан да, әлеге абзый юкны сөйләми икән: солдатлар атка җигелгән тупларын рәткә тезеп, көбәкләрен безгә таба каратып куйганнар иде. Мин исем китеп нәрсәдер әйтмәкче идем, анам итәгемнән тартып җиргә утыртты.

— Анда карама! Күзеңне йом! Тизрәк доганы укы! — дип, әнем белән икебезне күкрәгенә кысты. Тыным кысылып, буыла башлагач кына, башымны бер читкә бордым. Ә энем, эссегә чыдый алмыйча, мәет кебек салынып төшкән иде.

Җәза бирү отряды ниндидер акылга сыймастай явызлык эшләргә җыена бугай. Аларның сафы тагын да тыгызлана төште. Сакчысыз калган курган ягын искә алмаганда, кәппан тирәсен өч яктан да рәт-рәт солдатлар урап алган иде. Мәйдандагы кешеләр, якты дөньядан өметләрен өзеп, бер-берсе белән бәхилләшергә керештеләр. Аналар, балаларын кочаклап, үкерә-үкерә елый башладылар. Мәйданда күз яше белән аһ ору, җан өшеткеч тавышлар көчәйгәннән-көчәя барды. Солдатлар, мылтыкларын халыкка төбәп, команда көттеләр. Кешеләр: «Әҗәлебезнең килүе шушыдыр инде», дип башларын аска иде.

Шул чакны котырынган мәхшәрдә кинәт ерактан автомобиль гөрелтесе ишетелде. Бу миңа таныш тавыш иде. Яз башында мин ул машинаны күргән идем инде. Ул җомга көнне иде. Без бер төркем малай куй базары янында чүрәкәй уйный идек. Шул вакыт Ташкент юлыннан, тузан туздырып, машина узып китте. Без уеннарыбызны ташлап, артыннан йөгердек. Ләкин куып җитә алмадык. Соңыннан абыйның сөйләвенә караганда, ул Төркстан генерал-губернаторының автомобиле булып чыкты. Мин гөрелте ишетелгән якка таба сузылып карадым. Әйе, без күргән машинаның нәкъ үзе иде. Автомобиль өстенә бер кеше баскан. Кулында зур пакет. Ул аны болгый-болгый нәрсәдер әйтмәкче була. Машина курган янына килеп туктау белән, аны бер көтү офицер урап алды. Өстендәге кара җиләненең чабулары җиргә тия язган, озын чәчле, коңгырт сакаллы бер кеше (поп булса кирәк) алга чыгып конвертны алды. Офицерлар аны урап алып бик озак сөйләштеләр. Халыкның игътибары шуларда булды. Мин шул якка карап, күргәннәремне бәйнә-бәйнә анама сөйләп тордым. Ә ул башын аска иеп: «Ул якка карама, улым! Залимнәрнең йөзе корысын! Доганы укы!» дип, кулымнан тартты. Ә мин һаман үзсүзләнеп офицерлардан күземне алмадым.

Тиздән офицерлар таралышты. Халыкка мылтык төбәгән солдатлар, тагын да бүленешеп, биш-ун адым алга килделәр. Берничә офицер, әҗәл көтеп утырган халыкны ера-ера, мәйдан уртасына узды. Шул тирәдәге кешеләрне этә-төртә артка чигендерделәр. Алтын погонлы офицер, халыкка тәкәббер генә күз ташлагач: «Тынычланыгыз!» дигәндәй кул изәде. Аннары янында басып торган табак битле, почык борынлы кешегә бер кәгазь сузды. Тегесе, алу белән, кәгазьне бер-ике тапкыр үпкәч, кулын чигәсенә куеп, итекләрен шык итеп бәреп честь бирде. Кәгазьгә күз йөртеп чыкты да түрәсенә карап баш какты. Мәйдан су сипкән кебек тынып калды. Барысы да табак битленең авызына текәлделәр.

— Мөселманнар! — диде ул, камчысын уйнатып алды.— Нанхур күзгаланчылар! [1] Колак салыгыз! Соңыннан ишетмәдек диярлек булмасын.

[1] Үз икмәгенә төкерүче фетнәчеләр.

Даны вә шөһрәте дөньяга таралган бөек император хәзрәтләренә каршы баш күтәреп, сез бик зур гөнаһлы булдыгыз. Ак патша хәзрәтләре барыгызны да атып үтерү урынына, сезгә зур шәфкать күрсәтеп, үлем җәзасын сөргенгә җибәрү белән алыштырган. Менә шул турыда мөбәрәк имзасын куеп, гали мөһерен баскан бөек Указы килде. Указ нигезендә, бүгеннән алып, Ташкент дәһәсенә[1] караган яше-карты Кәле чүленә, Уратүбә дәһәсендәгеләр Өчтүбә чүленә сөреләчәк...

Кешеләрнең сулышы бугазына тыгылгандай булды. Мәйданда шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Шулай бераз тынып торгач, капыл гына барысы берьюлы сөйләнә-сөйләнә урыннарыннан куптылар. Солдатлар аларны берничек тә утырта алмагач, күккә төбәп шарт-шорт мылтык атып алдылар. Шуннан соң гына, утырмаганнарын утырырга өндәп, карышканнарның иңбашларына сугып, «утыр!» ди-ди, җиргә чүгәләттеләр.

Патша указы белән таныштыручы табак битле кеше баш күтәрүчеләр үтергән Мирзаһәмдәм тылмачның улы Әнвәрбәк булып чыкты. Мәйдан янә тынып калды.

— Тыңлагыз! — дип дәвам итте Әнвәрбәк.— Әйткән сүзләремне колагыгызга киртеп куегыз. Ташкент дәһәсенә караган халык, гаилә башлары хатын-кызларын алып, мәдрәсә артындагы намаз мәйданына узсын. Уратүбә дәһәсендәгеләр утырган җирләрендә кала. Аңлашыламы?

Төрле яктан сораулар яуды. Ләкин мәйданда шау-шу кузгалганга, аларны тыңлаучы да юк иде. Кешеләр урыннарыннан торып, кая барырга белмичә буталып беттеләр. Бала-чага тагын еларга керешге. Олылар гаилә кешеләрен чакырып, бер-берсен эзләделәр. Гадәттә, бер ил икенче илгә кыз бирә. Ташкент дәһәсеннән Уратүбәгә яки, киресенчә, Уратүбәдән Ташкент дәһәсенә озатылган яшь киленнәр, ярәшелгән кызлар мәйданда шактый иде. Хәзер, халык икегә бүленергә булгач, аналары кызларын үзләре белән алып китмәкче. Каенаналары исә киленнәрен үзләре ягына тарта башлады. Бичара кызлар белән яшь киленчәкләр кая барырга белмичә аптырап калдылар. Ике уртада талаш-тартыш китте. Ә патша указы кичектерүсез үтәлергә тиеш. Халыкны берничек тә икегә аера алмагач, кылычлар кыныдан чыгарылып, сөңге һәм камчылар эшкә җигелде. Атлы казаклар кешеләр өстенә ташланды. Җиззах халкын, мал куган кебек этә-төртә, Кәлә һәм Өчтүбә чүлләренә таба алып киттеләр.

## СӨРГЕНДӘ

Без киң юл буйлап барабыз. Кояш кайнар нурларын аяусыз сибә. Кызган туфрак табан асларын куырып ала. Атлаган саен тузан балтырга кадәр күтәрелә. Солдатларның йөзе ачулы. Алар бертуктаусыз: «Атла, тизрәк бул!» дип җикеренәләр. Атлы казаклар, баш өстендә кылычларын уйнатып, әрле-бирле чабалар.

Бу тәмуг кызуында бигрәк тә карт-коры белән бала-чаганың хәле мөшкел. Мин, әнкәйнең итәгеннән тотып, аксый-аксый атлыйм. Әнем бертуктаусыз: «Су-су!» дип ыңгыраша, тавышы бөтенләй карлыккан. Кешеләр су урынына тузан йоталар. Карт-корылар бер-берсенә булыша-булыша көчкә атлыйлар. Кайберләре бу газапка түзә алмый аяктан егыла.

Шулай бара торгач, Хаҗи газен бакчасына килеп җиттек. Күптән түгел генә әле монда бизәнгән-ясанган хатын-кызлар, «Яр-яр»ны җырлап, нәүрүз бәйрәменә килгән иде. Егетләр һәм кызлар, такмаклар әйтеп, уен-көлке ясап, күңел ачканнар иде. Шуларны уйлап мин артта калганмын. Кинәт баш өстендә казак камчысы сызгырып, иңсәмне ян-

[1] Районына.

лырып алды. Башым әйләнеп җиргә егылдым. Арттан килүчеләр минем өстән атлап үтте. Кайберсе абайламыйча сөртенеп тә егылды. Мин күпме тырышсам да, тиз генә аягыма баса алмадым. Солдатлар камчылый-камчылый ашыктырганга, кешеләр дә мина булышырга өлгерә алмадылар. Ничек итеп җирдән торганымны белмим. Торгач та, елый-елый, әнкәйне эзләп алга йөгердем. Юлда минем кебек ата-анасыннан аерылган балалар күп иде. Бу ыгы-зыгыда өлкәннәр дә акылларын җуя язган. Минем бүтән йөгерерлек хәлем калмады. Ярый әле, кешеләр кызу барудан баш тарттылар. Атлы казаклар, баш өстендә камчы уйнатып, солдатлар мылтык түтәләре белән кизәнеп тә берни чыкмагач, халык агымы кинәт туктап калды. Кешеләр җиргә чүкте. Солдатлар да юл читенә чыгып, тәмәке кабыздылар, кайберсе флягасыннан су эчеп алды. Иңсәсенә алтын погон таккан атлы казак халыкка нәрсәдер сөйли. Ләкин кешеләр берни аңламый. Аннары тагын бер атлысы килеп, үзбәкчә кычкырды:

— Ходаның каһәре төшкере аңгыра бәрәннәр! Полковник әфәнде барыгызга да йөзтүбән ятарга куша! Хәзер үк җиргә карап ятыгыз!

Кешеләр, монын сәбәбен ни дип юрарга белмичә, тагын шаулый башлыйлар.

— Күп сөйләшмәгез!.. Җиргә ятыгыз! Юк, алай түгел, йөзтүбән ятыгыз! Тизрәк булыгыз, имансызлар!

— Бу кем булыр, тавышы кабердән чыккыры? — дип сорады минем янда ятучы бер хатын.

— Әнвәрбәк түгелме соң?

— Шул! Каһәр төшкере, Мирзаһәмдәм малае.

Әнвәрбәк атын камчылап, әле бер якка, әле икенче якка чабып, кешеләрне җиргә яткырып йөрде. Ләкин аның әйткәннәре балаларның үкереп елаган тавышына күмелде.

Халык арасыннан кемдер:

— Әнвәрбәк, син дә мөселман баласы бит. Үз динендәгеләргә бераз шәфкатьлерәк булыр идең,— диде.

Мирзаһәмдәм малае бу сүзләрне колагына да элмәде:

— Мөселманлыгыгыз белән чәнчелеп китегез! — дип, камчы сабын итек кунычына сукты.

— Алайса, үз динеңнән ваз кичкәнсең икән! Ярый, шулай да булсын, ди. Ләкин син дә биг газиз ана баласы. Үз балаларың да бардыр әле. Картларны булмаса, менә бу сабыйларны кызганыр идең!..

Әнвәрбәк җавап кайтармады. Ул, атының тезгенен тартып, икенче якка борылды да янында торган офицерга нәрсәдер сөйләп алды.

Ә халык һаман шаулады:

— Кешеләрнең әчәселәре килә! Нигә аларны болай газаплыйсыз? Чыкмаган җаннары гына калды бит.

— Ак патшаның рәхимсезлеге аркасында, күрмәгән золым-җәберләрне күрдек!

— Күп сөйләшмәгез! Сүзегез барыбер үтмәячәк! Күрәселәрегез алда әле! Сыйның зурысы чүлдә булыр! — дип куркытты Әнвәрбәк.

Ул, халыкка ачу итеп, аларны юри үртәргә, яраларына тоз салырга тырыша иде. Тәкате калмаган кешеләр түзмәделәр, аты-юлы белән сүгенә башладылар.

— Мәлгунь! Ләгънәт төшкере!

— Залим!

Халыкның нәфрәте көчәя барды. Солдатлар, сүз белән тынычландыра алмагач, мылтык чакмаларын чакылдаттылар. Баш өстеннән пулялар сызгырып үтте.

Әнвәрбәк һаман халыкка җикеренде:

— Кем дә кем җирдән башын күтәрә, шунда ук атып үтереләчәк. Офицер җәнабләренең боерыгы шундый.

— Алай бик теләсәгез, атыгыз! Ат!
— Мондый хурлыкны күргәнче, үлгәнем мең шөкер!
Соңгы чиккә җиткән кешеләрне хәзер үлем дә куркытмый башлады. Мин, күземне йомган килеш, йөзтүбән ята бирдем. Туфрак утлы көл кебек кызу. Кояш һаман да әле баш өстендә тора. Мин җирнең кызу сулышына тирләп-пешеп чыктым. Иреннәрем кибеп, телем аңкавыма ябышты. Өстемдә бер кат күлмәк-ыштан булганга, күкрәк тирәләре, тез башлары кызарып чыкты. Маңгаемнан туктаусыз тир ага.
Җирдә ятучы ир-атларның берсе:
— Мөселманнар! — дип кычкырды.— Әҗәлебез җитеп, соңгы көнебез килде. Ак патша безгә кургашын кызганды. Безне ачлыктан, сусызлыктан, тәнебезне кояшка яндырып үтермәкче була. Дога кылыгыз, мөэмин-мөселманнар! Лә иләһе илаллаһе мөхәммәде рәсүлулла, ашһәде әннә иләһе...— дип, пәйгамбәрләрнең исемнәрен телгә алганда, кешеләр дә гөрләшеп «Лә иләһә илаллаһу»ны кабатладылар. Меңләгән кешенең бердән әйтелгән тавышлары далада дәһшәтле яңгырады.
Шунда ук берничә җирдән мылтык атылды. Кешеләрнең шау-шуы басыла төште. Бала-чаганың черелдәп елавы гына дәвам итте. Әнвәрбәк халыкка торырга рөхсәт бирде. Йөзтүбән яткан кешеләр баштанаяк тузанга манчылган иде. Урыннарыннан торганда: «Аллага шөкер!» дигәләшеп өс-башларын кактылар.
Кеше кешене танымас хәлгә килгән иде. Өс-башлары гына түгел, сакал-мыеклары да пычрак чәпәгәндәй булган. Әнвәрбәк барысына да баягы тәртип белән тезелергә боерды. Кешеләр, тузан туздырып, урыннарына бастылар. Әнвәрбәк карлыккан тавыш белән:
— Юлда берәрегез читкә чыгасы яки артка каласы булмагыз! Шунда ук атып үтерәчәкләр. Өчтүбә чүленә күп калмады. Тизрәк кыймылдасагыз, кичкә кадәр барып та җитәрбез. Әйдәгез, кузгалыгыз! — дип, атын камчылады.
Солдатлар тагын эт кебек ырылдарга керештеләр: «Әйдә! Пошел!» дип, халыкны мал кебек кудылар. Шулай мең төрле газап белән атлый торгач, кичке эңгердә Өчтүбә чүленә барып җиттек. Атлы казаклар, әрле-бирле чабып, кешеләргә утырырга боердылар. Көчкә басып торган адәмнәр бердәй җиргә аудылар.
Тагын Әнвәрбәкнең ямьсез тавышы ишетелде:
— Болай котыгыз алынмаса да була иде. Ак патша хәзрәтләре сезне атып үтерү турындагы указын үзгәртеп, көтмәгәндә зур рәхимлек күрсәтте. Миңа хәзер сез Кәле белән Өчтүбә чүлендә үз көнегезне күрерсез. Моннан бер-ике чакрым җирдә Такырсай инеше бар. Шунда камышлык булыр. Әнә шул камыштан үзегезгә алачык салырсыз. Сезнең иншә имансызларга моннан да зур мәрхәмәтнең булуы мөмкин түгел! Шуңа күрә аллага шөкер диегез, ходайның җирдәге күләгәсе ак патша хәзрәтләренә, аның мөхтәрәменә, угыл-кызларына дога кылыгыз. Сез мөселманнар өчен бу — һәм фарыз һәм карыз [1]. Әйдәгез әле, барыбыз да бердәй булып, дога кылыйк! — дип, Әнвәрбәк кулларын җәйде.
Шул мәлне халык арасыннан кемнеңдер калын тавышы ишетелде:
— Мөселманнар!.. Бу кара язмышны бергә уртаклашучы җан дусларым! Борынгы бабаларыбыз, сусыз җиргә йорт корма, утсыз [2] җиргә ил корма, дигәннәр. Догаи хәер бар, догаи бәд [3] бар. Каяле, амин тотыйк, мөселманнар!
— А-амин!..
Халыкның нәфрәт тулы тавышы еракка яңгырап, киң чүлдән кайтаваз булып ишетелде. Әлеге адәм сүзен дәвам иттерде:

---

[1] Бурыч.
[2] Үлән.
[3] Бәддога.

— Амин диегез, мөселманнар! Ак патша хәзрәтләренең безгә күрсәткән «мәрхәмәте» ун тапкыр булып ходайдан үзенә кайтсын!
— Иләһи амин!..
— Амин диегез, мөселманнар! Ходай ходавәндә, ак патша хәзрәтләре пәйтәхетеннән төшсен — тормасын!
— Иләһи амин! — дип кабатладылар башкалар. Чүлдән кире кайтып «...төшсен-тормасын...» дигән тавыш яңгырады.
— Ак патша язмышы мондагы түрәләр башына да килсен!
— Иа рабби, шулай булсын!...
Эшнең кая таба барганын сизгән Әнвәрбәк, шартлардай булып:
— Туктагыз, бәдбәхетләр! — дип кычкырды.— Тукталыгыз!
Ләкин аның тавышы халыкның нәфрәтле каргышына күмелде.
— Никулай аркасында күргәннәребез үзенә меңе белән әйләнеп кайтсын. Аның дәверендә тагын да зуррак кузгалышлар булсын.
— Амин, шулай булсын!..
Ир-атларның шаулавы, солдатларның кычкыруы, балаларның елавы, хатыннарның каргавы барысы бергә буталды...
Шул мәлне мин кинәт анамның дәшкән тавышын ишеттем.
— И, балакаем, синме бу? Аллага шөкер, табылдың! — дип, әни мине кочаклап алды.
Йорт-җирләрдән аерылып, әллә нинди сахра кочагында түшәк-ястыксыз, бер йотым суга интегеп уздырылган бу төн минем күңелдә мәңге саклана.
Мин, бик озак йоклый алмыйча, күк йөзенә карап яттым. Анда йолдызлар җемелди. Алар безне кызгана, кайгыбызны уртаклашырга тели кебек. Далада кешеләр гырылдавы, ара-тирә кайберсенең ютәлләп куюы, чикерткәләрнең чырелдәве ишетелә. Мин атам белән абыем турында борчылам. Алар хәзер кайда икән? Бу ыгы-зыгы вакытында берәр хәл булмадымы икән? Шул турыда әни белән сөйләшмәкче булам. Ләкин ул да хәзер йокыга киткән бугай.
Кинәт чүлдәге кешеләр хәрәкәткә килеп алды. Кайберләре сикереп урыннарыннан торды. Шул тавышка анам да уянды. Кайсыдыр ялгыш энекәшнең аягына баскан. Энем акырып елап җибәрде: әнкәй аны кочагына алып юатырга тотынды. Уянган кешеләр: «Ни бар? Нәрсә булды?» дип, бер-берсеннән сораштырып та карады. Ләкин сәбәбен белүче булмады. Тора-бара Җиззах юлы ягыннан бер ир-атның тавышы ишетелде:
— Җәмәгать, тынычланыгыз! Шәһәрдә качып калган кешеләрнең берничәсе безне эзләп килгән.
— Кемнәр икән?
— Берсе Шакирҗан бугай.
— Кайсы Шакирҗан?
— Ялама Шакирлар гаиләсеннән булганнар бирегә килсен!
Бер баштан хатын-кыз тавышы ишетелде. Икенче берсе шул тарафтан: «Шакирҗан әкә, монда килегез. Гаиләгез биредә!» дип чакырды.
— Җәмәгать, шауламагыз әле! Әтәч Сәлименең малае Акылбәк белән Дусмәт улы Сәет тә биредә. Ата-анасы булса, монда килсен! — дип дәште баягы тавыш. Акылбәк белән Сәет минем дусларым лабаса! Мин шулар янына йөгерергә дип торганда, анам итәгемнән тартты: «Беркая бармыйсың! Юкса, тагын югалырсың».
Мин бик озак Җиззах юлына карап тордым. Чү, ниндидер кара нокта күренә түгелме соң? Әйе-әйе. Вакыт узган саен, нокта зурая бара. Ниһаять, ул өчкә бүленде. Икесе җәяүле кеше, берсе ат шәүләсе булып чыкты. Алар бездән берничә адым җирдә туктадылар. Атның ун ягындагысы Мансур абыйга охшаган. Йөрәгем кинәт жу итте: «Мансур әкә!» дип кычкыруымны үзем дә сизми калдым. Абый шунда ук без-

нең янга атылды. Атам да тиз-тиз атлап безнең янга килде. Ул барыбызны да берәм-берәм кочаклап: «Бәгырькәйләрем, исәннәрмесез!» ди, ә күзләрендә яшь.

Безне шундук туган-тумачалар, таныш-белешләр сырып алды. Алар шәһәрдәге хәлләрне сораштылар.

Чүлдәге халыкның күпчелеге таң атканчы йокламады диярлек. Атамның сөйләвенә караганда, шәһәрдә бөтенләй кеше калмаган булса кирәк. Тоткарланганы да ашарына алып, тизрәк чүлгә китү ягын карый икән. Әткәй белән абый да буш кул гына килмәгәннәр. Атка йөкләп ярты капчык бодай, өч юрган, комган, казан, җиз чүлмәк белән май, бер чиләк йөзем алып килгәннәр. Әнкәй, юрганның берсен җиргә җәеп, энекәшне йокларга салды.

Безнең янга җыелган кешеләр этигә сораулар яудырдылар:

— Сәфәр әкә, юлда солдатлар очрамадымы?

Атам, бер түгел, дүрт солдатны очратуларын сөйләде.

— Сезгә бәйләнмәделәрме?

— Үзебезне тентегәч, юрган-ястыкларны актарып карадылар. Аннары, Мансурның иңсәсеннән кагып, «баранчук, баранчук» дип, бер әйбергә дә тимичә җибәрделәр.

— Безгә дә, өйгә кайтып, гаиләгә азык-төлек алып килү турында рөхсәт сорарга кирәк булыр.

— Әйе, ятып калганчы, атып калырга кирәк,— диде атам.— Сөйләшер өчен, арабыздан бер вәкил җибәрик.

Әле таң атмаса да, кешеләр берәм-берәм йокыларыннан уянып тора башладылар. Хәер, такыр җирдә, ач карынга, балаларның «әни, су» дип ыңгырашкан чагында, нинди йокы булсын ди ул? Шул мәлне кечкенә бер калкулык өстеннән мәзиннең сузып-сузып: «Аллаһу әкбәр, аллаһу әкбәр!» дип азан әйткәне ишетелде. Кешеләр сөйләшүдән туктадылар. Аягүрә торучылар җиргә чүгәләде, җирдә утыручылар кулларын җәеп дога кылырга әзерләнделәр. Ниһаять, мәзин: «Лә иләһе иллалла!» дип азанын бетерде. Өлкәннәр битләрен сыпырып, картлар утырган җирләреннән торып, иртәнге намазга барырга әзерләнделәр. Кемдер: «Җәмәгать, чүлдә су булмагач, тәһарәтне ничек яңартабыз?» дип сорады. Икенчесе аңа: «Пәйгамбәребез су юкта, «таяммим җаиз», дигән, ягъни су булмаганда тәһарәтне ком белән яңартыгыз, дип аңлатты. Ирләр, җиңнәрен сызганып, учлары белән җиргә суга-суга, ком белән кулларын, беләкләрен, битләрен, колак артларын «юдылар». Аннары барысы да, иртәнге намазны укырга дип, мәзин тавышы ишетелгән калкулыкка таба киттеләр.

Анам яктыру белән куырмач[1] кыздырырмын дигән иде. Әткәй намазга китәр алдыннан: «Бодайны саклабрак тотыгыз. Намаздан соң халык киңәшергә уйлый. Ничек яшәү турында фикер алышу булачак. Шуңа карап эш йөртербез», дигән иде. Без энем белән, куырмыч кыздыр дип күпме көйсезләнсәк тә, анам әткәйнең киңәшеннән чыкмады. Минем карыным ачып, күземә ак-кара күренмәс булды. Нәфесемне тыя алмыйча, тагын шул йөземле чиләккә кул суздым.

— Бер үзең генә ашама, улым. Әнә иптәшләреңә дә авыз иттер,— дип, әнкәй безнең белән янәшәдә утыручы хатынның балаларына ымлады. Алар чынлап та: «Әни, ашыйсыбыз килә!» дип, аналарын интектереп бетергәннәр иде. Әнкәй, яулыгына берничә тәлгәш йөзем салып, теге хатынга сузды: «Мәгез, Сафияхан, балаларыгызга бирегез», диде. Сафияхан, әнигә рәхмәт әйтеп, йөзем тәлгәшен өч кызына, бер улына бүлеп бирде. Балалары, чыр-чу килеп, йөземгә ташланды. Күрше хатын әнигә кайгысын уртаклашты: «Урман тавыгы кебек юаш иремне кузгалышка җитәкчелек иткән дип гаепләп, төрмәгә яптылар. Шуңа бер дә

[1] Казанда кыздырылган бодай.

күңелем тыныч түгел. Атып үтермәгәйләрә дип куркам!» дип, яшьләрен сөртте. Кылый күзле малае — Хәкимҗан атлы икән, мин аның белән бик тиз дуслашып киттем. Йөземемнең яртысын аңа бирдем.

Йөзем белән генә тамак туймый, билгеле. Без энем белән: «Әни, куырмач кыздыр! Куырмач!» дип, әнкәйнең теңкәсенә тиеп беттек. Ә ул: «Борынгылар кырга бодай чәчтем, уңышы булгач, тандергә нан ябармын» дигәч тә түзгәннәр әле. Ә сез атагызның әйләнеп кайтканын да көтәргә теләмисез!» — дип ачуланды.

Минем башка: «Әгәр бодайны куырмыйча гына ашасаң, нәрсә була икән?» дигән бер уй килде. Бу уемны абый да хуплады. Әнкәй күрмәгәндә, капчык өстендәге юрганны күтәреп, астына постым. Капчык авызы ныгытып бәйләнгән. Күпме тырышсам да, чишә алмадым. Аннары капчыкның ертык җирен эзләп карадым. Юк, бер генә тишеге дә күренми. Һай, әгәр кулымда пычак булсамы, түбәтәемне тутырганчы бодай агызып алыр идем!

— Балалар, озакламый атагыз кайтыр. Куырмач кыздырырга утын кирәк булыр. Әллә даладан коры-сары җыеп кайтасызмы? — диде анам.

— Нинди коры-сары?

— Тигәнәлектә гадәттә ак курай [1] үсә торган иде.

Ул арада мин дә, юрган астыннан чыгып, абый янына килеп бастым. Без далага утын җыярга киттек. Анам безнең арттан:

— Хәкимҗанны да үзегез белән алып барагыз! — дип кычкырды.

Без утын эзләп шактый ерак киттек. Кояш күтәрелү белән көн җылына төште. Аяк астыннан ара-тирә тургайлар пырылдап очып китә. Без тигәнәклеккә килеп җитеп, ак курай йолкырга керештек. Аның тамыры тирәндә икән. Хәкимҗан аны тамыры белән чыгара алмыйча бик озак маташты. Аяк-кулына кадалып бетте. Мин аңа: «Син бутән азапланма. Без йолкып бирә торырбыз, син бер җиргә җыя торырсың», дидем.

Бер мәлне күтәрелеп карасам, бездән ярты чакрымдагы басуда кешеләр иелә-иелә нәрсәдер җыялар иде. Өчебез дә, ак курай эзләп, шунда таба киттек. Ләкин бу тирәдәге тигәнәкләр үтә чәнечкеле булып чыкты. Аның каравы, ак курай да сирәгәя барды. Мин:

— Әллә кире кайтабызмы? — дигән идем, абый өнәмәде:

— Тегеләр янына барыйк әле. Тикмәгә генә җиргә ябышып ятмыйлардыр,— дип, адымын кызулата төште.

Без Хәкимҗан белән арткарак калып, сөйләшеп бардык. Аның атасы мәхәлләбездә мәшһүр карый [2] икән. Уразада мәчеттә корьән чыкканда барысын да таң калдырган. Яңгыравык тавышы белән корьән сүзләрен көйгә салып укый икән. Хәкимҗан күп кенә сүрәләрне атасыннан отып алган. Мин дә берничә аятьне яттан белә идем. Без бер-беребезгә аятьләр укырга керештек. Хәкимҗан остарак булып чыкты. Мин сүрәләрнең мәгънәсен сорадым. Дустым: «Аның мәгънәсен ходайдан башка беркем дә белми», диде. Аннары Хәкимҗан атасының яңа мәктәп ачарга йөргәнен, шул мәктәптә укыган балаларның бер-ике елда ук укый-язарга өйрәнәчәкләре турында сөйләде.

Абый, басуга җиткәч, безгә кул изәде:

— Нәзиркол, тизрәк булыгыз. Биредә хәзинә бар,— дип кычкырды. Без якынрак килгәч: — Менә күрегез, бирәм дигән колына чыгарып салыр юлына, диләр. Башак, бодай башагы! — дип кулындагы кечкенә көлтәне күрсәтте.

Бармак арасына шырпы кадалып, мин җиргә утырдым. Карасам, алдымда берничә башак ята!

---

[1] Саксаулның бер төре.
[2] Корьән укучы.

— Абый, мин дә башак таптым! — дип шатланып кычкырдым.

— Монда башак барыбызга да житәрлек,— диде абый.

Мин учым белән башак уып, өреп кибәген аердым да шатыр-шотыр чәйни башладым. Камыр исе авыз суларын китерде. Мин, бу эшнен тәменә кереп, жирдәге башакларны ашыга-ашыга жыярга керештем.

— Хәкимжан, ак кураенны калдырып тор! Монда кил. Син башакның нәрсә икәнен беләсенме? Без ашый торган ипине шунардан пешерәләр бит инде. Капсаң, валлаһи, телеңне йотарсың! — дип, жыйган башакларымны түбәтәемә сала бардым. Ул-бу дигәнче түбәтәем тулды. Абый да итәге тулы башаклар жыеп безнең янга килде. Ул тиз генә күлмәгемне салдырды да, жиңнәре белән якасын бәйләп, капчык ясады. Жыйган башакларыбызны шуңа бушата башладык. Озак та үтмәде, «капчыгыбыз» тулды да.

Бездән алдарак килгән кешеләр, кайсысы яулыгына, кайсысы итәгенә башак тутырып, кире кайтып киттеләр. Озакламый без дә кайтыр юлга чыктык. Абый башак тулы күлмәкне, Хәкимжан белән мин ак курайны күтәрдек.

Безне әткәй караңгы чырай белән каршы алды:

— Кая китеп югалдыгыз болай? «Балана эш боер, үзен артыннан йөгер», дигәннәре шулдыр инде!

— Талкан ашагач, баланы суга йөгерткәндәй булды бу, атасы,— диде әнкәй да шелтә белән. Ләкин аларның ачуы озакка бармады. Анам «капчык»тагы башакларны күрүгә үк:

— Шөкерана диген, атасы. Балаларын ашарга икмәк алып кайткан лабаса. Авыр көненнең берсе узганга да рәхмәт диярсең. Каяле, балакайлар, түбәтәегезне тотыгыз,— дип, әни барыбызга да берәр уч кайнар куырмач салды.— Алдан ук әйтеп куям, барысын да берьюлы ашамагыз. Данәсе-данәсе белән кабып, авызда җебеткәч, чәйнәп йотсагыз, палвәйтәр[1] ашаган кебек булырсыз,— диде. Аннары һәркайсыбызга берәр йотым кайнар су бирде. «Чәе» тәмсез иде. Шулай да, һай, әгәр шуны берәр кәса эчсән иде!..

Без басудан әйләнеп кайтканда, Өчтүбәдәге кешеләрнең күбесе яңа урынга күченеп киткән, ә калганнары юлга чыгарга жыенып тора иде. Атам, коега барып, чиләк белән комганга су тутырып кайткан икән. Әйберләрне атка төяп, без дә халык күченгән якка таба кузгалдык. Юл өстендә кешеләр кырмыска кебек мыж килә. Тиздән без дә кое янына барып җиттек. Монда да тигез дала. Күптән түгел биредә бишалты ыруг казакълар торган икән. Жиззах кузгалышы тар-мар ителеп, җәза бирү отрядының халыкка ябырылуын ишеткәч, каядыр күчеп киткәннәр. Китәр алдыннан тизәк өеме эченә казан белән агач чиләк яшереп киткәннәр. Жиззахлылар чиләген коедан су алырга, казанын куырмач кыздырырга җайлаштырдылар.

Кое янына халык жыелган. Үгезне мөгезеннән тотып жиргә егарлык таза егетләр, коены урап алып, кешеләрне якын да жибәрмиләр. Чал чәчле бер кеше:

— Мөселманнар, сабыр итегез! — диде.— Әгәр барыбыз да берьюлы ябырылсак, суы житми калачак. Шуна күрә минә мондый тәкъдим бар. Хәзер барыгыз да тукталган жирегезгә кайтасыз. Монда гаилә башлары гына калып, чиратка бассыннар. Тегермән нәүбәт белән дигәндәй, әгәр һәрбер ата кеше үз чираты белән кое янына килсә, җан башына берәр кәса исәбеннән су алыр. Каяле, җәмәгать, шулай итик әле!

Ир-атлар бер-берсен этә-төртә чиратка бастылар. Кое янындагы шау-шу чүлгә таралды. Берничә егет коедан су чыгара тора, нәүбәте житкәне чиләк, чүлмәк, комганнарына су тутырып: «Бәрәкалла! Тормышыгыз шушы судай мул булсын!» дип, кое яныннан китә тора.

---

[1] Шикәр белән камырдан пешерелгән ашамлык.

Чүлдәге гаиләнең кайсын гына алма, барысы да ашарына әзерләү белән мәшгуль. Араларында атна буена икмәк йөзен күрмәүче, кайнар аш ашамаучылар да бар иде. Сөргендәгеләрнең бердәнбер азыгы куырмач булды. Хатыннар далада бер түгел, берничә казанда куырмач кыздырдылар.

Атам учакка утын хәзерләде. Без басудан алып кайткан башакны күмәкләшеп сугарга керештек. Бу эштә диһкан малае Акылбәкнең киңәше ярап куйды. Ул сугылган башакны түбәтәенә салып, җилгәреп торды. Әзер бодайны әнигә бирдек. Анам ике апам белән казанда куырмач кыздырып, барыбызга да бер тигез өләшеп чыкты. Бер мәезне кырык кеше бүлеп ашаган, диләр. Шуның кебек, без дә куырмач ярмасын берәм-берәм чәйнәп, тамак ялгадык.

Күрше хатыннар да килеп, учак янында чиратлашып куырмач кыздырдылар.

Шулай көн мәшәкатьләре белән төш вакыты җитте. Кояш бүген дә кайнар нурлары белән аяусыз кыздыра. Сусызлыктан кешеләр генә түгел, бөтен җан иясе: «Су, су!» — дип ыңгыраша кебек иде. Халык күләгәле урын эзләде. Ләкин далада аны каян табасың? Хәер, торабара моның да бер җае табылды. Ак курай чыбыкларыннан куыш ясап, эченә сабыйларны, карт-корыларны, авыруларны яткырдылар. Ләкин «ходай» моны да артык күрде, ахры. Бәхетсезгә гел вакытсыз, дигәндәй, көтмәгәндә каяндыр көчле җил кубып, куышларыбызны ватып-җимереп китте. Мондый давылны беренче тапкыр күрүем иде. Аның көчле өермәсе, бөтерелә-бөтерелә, гаять зур баганадай күккә сузылды. Җир өстендәге комны, чүп-чарны себереп, һавага күтәрде дә, зур болыт ясап, кабат кешеләр өстенә яудырды. Яулык, түбәтәйләрен йолкып алып очырды, учактагы күмерләрне далага таратып, юрган-ястыкларга, кием-салымнарга ут төртте. Кыскасы, күз ачып йомган арада давыл дөньяның астын-өскә китерде.

Халык бу гарасатны куар өчен бертуктаусыз дога укып: «Я аш, пычак, каләмфер! Я аш, пычак, каләмфер!» [1] дип кычкыра. Мин, нәрсә булганын аңлый алмыйча, җиргә йөзтүбән ятам. Давыл күпкә бармады, басылды. Кешеләр, өс-башларын кагып, урыннарыннан тордылар. Хатын-кызлар яулыклары белән йөзләрен каплап: «Йа аллавандә, бәла-казадан сакла!» ди-ди, давыл очырган әйберләрен җыярга керештеләр. Алар: «Бу гадәти җил түгел, җен-пәриләр өермәсе, «каләмфер»не кабатламасаң, кешене аяктан егып, авыз-борынын кыйшайта, аяк-кулларын гарип итә» дип сөйләнгәннәр иде. Шуңа күрә мин давылдан исән калганыма гаҗәпләндем: «Әни, мин ул «каләмфер»не әйтмәдем бит. Миңа нишләп җен-пәриләр кагылмады икән»? дип сораган идем, анам: «Җен-пәриләр каләмфердән куркучан була. Шул кадәр кеше «аш, пычак»ны әйткәч, алар безгә якын килергә җөрьәт итмәделәр. Өстебездән сикереп узганга, диюләрнең җиле генә котырды», дип аңлатты.

Беренче көннәрне ач дала кочагында сусыз, икмәксез, өйсез булганга, сөргендәгеләр бөтенләй өметсез калган иде. Тора-бара төрлечә әмәлен табып, яшәү өчен көрәшә башладылар. Ирләр Өчтүбәдән бишалты чакрым җирдәге Такырсайдан кочак-кочак камыш ташыдылар. Безнең әти дә, абый белән җизниләрне ияртеп, камышка китте. Без берничә малай башак җыярга басуга юнәлдек. Ләкин бу юлы инде башак күп түгел иде. Ач халыкка күпмегә җитсен. Кырдан без арыпталып кайттык. Кичке эңгердә, атларына камыш төяп, әтиләр дә кайтты. Камышны чабарга берниндә кораллары булмаганга, йолкыййолкый бик интегеп беткәннәр. Кул-аякларын сыдыртып, йөз-битләрен канатканнар.

---

[1] Кызыл борыч.

Ул төнне чүлдәге кешеләр күз йоммады диярлек. Бертуктаусыз камыш ташып, үзләренә алачык салдылар. Чүлгә килгәч, өч көн дә узмады, һәр гаиләнең үз куышы булды. Хәтта ялгыз карт-коры, тол хатыннарга да өмә ясап, аерым куыш салып бирделәр.

Баш исән булса, түбәтәй табылыр, дигәндәй, кешеләрнең хәзер кечкенә генә булса да үз куышы булды. Чүл буйлап камыш алачыклар төзелгәч, яңа сүзләр дә чыкты: «Ул фәләннең кәпәсе[1]... Ул төгән кәпә белән күрше» дип сөйләшә башладылар. Ләкин куыш корып кына чүлдә көн күреп булмый икән. Казакъларның дүрт-биш тирмәсен тәэмин иткән коеның суы икенче көнне үк бетте. Халыкка тагын су кайгысы төште. Җир-суларыннан аерылган җиззахлыларны гел шулай бәла-каза берсе артыннан икенчесе куа килде. Башкасын әйткән дә юк, сусыз, тозсыз, бер сынык икмәксез зар-интизар булып яшәү — бәхетсезлек түгелмени?..

Мәхәллә картлары, ир-атлар жыелып, киңәш тоттылар. Алар беренче нәүбәттә кое казуны хәл иттеләр. Типсә тимер өзәрдәй таза егетләр бил буып эшкә керештеләр. Төн буена нәүбәтләшеп кое казыдылар. Иртәгесен чүлдә бер түгел, өч кое әзер иде инде. Шуларның икесе уңышлы чыгып, ил суга туйды, мохтаҗлыкның иң зурысы бетерелде. Ләкин аның белән генә тамак туймый, кешенең ашарына да кирәк бит. Инде хәзер ачлыктан котылу юлын табу кирәк иде.

Мәхәллә картлары тагын киңәшкә утырды.

— Җәмәгать, дүрт ягыбыздан да кораллы гаскәр уратып алган. Өчтүбәдән чыгып, Җиззахка яки Ташкент ягына китәргә берсенең дә хакы юк: юлыбызга киртә салганнар. Бу нинди каһәрләнгән көнгә калдык?! Иелгән башны кылыч кисмәс, диләр, әллә арабыздан илче сайлап, солдатлар янына җибәрәбезме? Илчегә үлем юк. Аңа тимәсләр әле. Вәкилебез, таяк башына ак чүпрәк тагып, сакчылар янына барсын. Котылгысыз хәлебезне сөйләсен. Икмәксез, сусыз, йорт-җирсез, ач дала кочагында каңгырып калдык, дисен. Халыкка тиз вакыт эчендә икмәк китертү яки тир-каныбыз тамган Җиззахыбызга кире кайтару мәсьәләсен кузгатырга кирәк,— дигәннәр.

Менә шул турыда әткәй безгә сөйләгәндә, күршедәге кәпәләрдән кешеләр чыгып, тау ягына текәлделәр. Малайлар өерә шунда таба йөгерде. Мин дә аларга иярдем. Еракта кечкенә тау сыртыннан Өчтүбәгә таба килүче бер атлы кеше белән дөя җитәкләгән ике казакъ күренде. Безгә әкияттәге кебек тоелган бу кечкенә кәрван акрын гына атлый торгач, иске кое янына килеп туктады. Җайдак атыннан төште. Дөяләр, артларына чүгеп, җиргә утырдылар. Мин коеның әлекке хуҗалары кайткан дип торам. Юк, алай түгел икән. Юлчылар сөргендәгеләр белән кочаклаша-кочаклаша: «Чырагым, бәгырем» дип күрештеләр. Хәл-әхвәл сораштылар. Безнең аяныч хәлебезне күреп, аһ ордылар. Чал чәчлесе:

— Без Басымбәк ыруыннан булабыз,— дип, үз янындагы ике егеткә ымлады. Өчтүбәгә сөрелүегез турында кичә генә ишеттек. Күп булмаса да, бодай белән елкы китердек. Яман көннең берсенә ярап куяр дидек...

Бу сөйкемле казакъ картының сөйләгәндә күзләренә яшь килде. Ул бер уңайдан ак патша белән урындагы түрәләргә ләгънәт укыды. Сөргендәгеләргә ярдәм кулы сузган казакъ туганнарны безнекеләр кая утыртырга белмәделәр. Тизлек белән кәпәләрнең берсен бушатып, кунакларны шунда чакырдылар. Булмаган ризыкларын чыгарып, аларны сый-хөрмәт иттеләр. Кунаклар сорау артыннан сорау яудырдылар. Җиз-

---

[1] Куышы.

захлылар үз башларына төшкән кайгы-хәсрәтне бәйнә-бәйнә сөйләделәр. Казакъ карты китергән елкыны суярга фатыйхасын бирде. Адымжан атлы үзбәк кәссабы[1] аны шундук рәхәтләнеп суеп та ташлады. Ит белән сигез капчык бодайны шунда ук бүлеп, халыкка тараттылар.

Көннәр шулай бер-бер артлы уза торды. Өчтүбәдә берничә хатын бала тапты, берничә кеше гүргә керде. Тормыш үзенекен итте. Күргәннең көне кадерле дигәндәй, кәпәдән кәпәгә кызлар озатылды. Бер кәса су биреп никах укылып, кыз белән егет кавыштырылды. Зур апамның кызы Нәрәкбүвене дә шулай кияүгә бирдек.

Бер көнне аксакаллар җибәргән илчеләр дә Өчтүбәгә кире әйләнеп кайттылар. Безнекеләр белән офицерлар арасында бер татар солдаты тылмачлык кылган. Командир илчеләрнең моң-зарын тыңлагач, бу турыда өяз хакименә җиткерергә вәгъдә биргән.

Менә шул көннән башлап, барыбызның да күзебез юлда булды. Бер вакыт кырда башак җыеп йөргәндә, Җиззах юлыннан атны юртып безгә таба килүче бер җайдакны күрдек. Мин, маңгаема кулым куеп, бик озак карап тордым. Ләкин аның хәрбиме, бүтәнме икәнен аера алмадык. Без, җыйган башакларны капчыкка салып, кәпәләргә кайта идек. Өчтүбәгә бер ярты чакрым калганда, җайдак безне куып җитте. Айгыры кара тиргә баткан, пошкыра-пошкыра, борыннарын җыерып, еш-еш тын ала иде.

Без юлчыга сәлам бирдек. Ул баш кагып:

— Капчыгыгызда нәрсә бар? — дип сорады.

— Башак,— дидек.

— Аны сез нишләтәсез?

— Куырмач кыздырып ашыйбыз.

— Ашарыгызга бүтән ризык юкмыни?

— Юк шул...

— Сез кем балалары буласыз?

— Мин Сәфәр чәйфруш[2] малае.

— Ә минем әти Әтәч Сәлим атлы.

— Ягез, малайлар, сөенчегә нәрсә бирәсез?

— Нинди сөенче?

— Сөрген тәмам! Җиззахлыларга иминлек килде. Хәзер барыгыз да өегезгә кайта аласыз! — диде дә, атын камчылап, безнең алдан узып китте.

— Ур-ра! Сөрген тәмам! Яшәсен азатлык! — дип кычкыра-кычкыра, без куышларга таба йөгердек.

Без Өчтүбәгә кайтып кергәндә, атчабарны халык сырып алган иде инде. Бу шатлыкка кешеләр ни эшләргә белми. Берсе өстендәге чапанын салып юлчының өстенә ташлый, икенчеләре башындагы түбәтәй-яулыкларын һавага чөя. Җайдак шул сөенчеләргә күмелә язган. Адәмнәр бер-берсен кочаклый, кулларын җәеп, кыйшык-мыйшык атлап биегән була, җылый, куана...

— Илгә иминлек килде. Иминлек мөбарәк булсын!

— Яшәсен азатлык!

— Өчтүбә чүлен бүтән җилкә чокырына гына күрергә язсын!

Әйтерсең лә Өчтүбәдән ташкын кузгалды. Бала-чагаларын житәкләгән аналар, аркаларына сабыйларын кочтырган аталар, кулларына юрган-ястык, чиләк, казан күтәргән хатын-кызлар — барысы да Җиззахка таба агылды.

---

[1] Мал суючы.
[2] Чәй сатучы.

Сөргеннән кайткач та халыкка тынгылык булмады. Дөнья сугышының кызган чагы иде. Ак патшаның Җиззах баш күтәрүчеләренә күрсәткән «шәфкате» төбендә чынлап та бер сер булган икән. Күп тә үтмәде, мәрдекарьлеккә җибәрү турындагы патша указы яңадан кайтты. Дәһәләргә яңа меңбашлары, мәхәлләләргә иллебашлары куелды. Мәрдекарьлеккә китәсе ирләр взвод-роталарга бүленеп, аларга унбашы, йөзбашы, меңбашлары билгеләнде. Шул унай белән булган мәхәллә мәҗлесендә тискәре сүз сөйләгәннәре өчен Корбанбай белән Урдүшмәтне кул-аякларына богаулар салып, зинданга озаттылар. Башка мәхәлләләрдә дә шундый ук хәлләр булып алды. Дөрес, бу юлы мәхәллә урамнарында кораллы полиция белән хәрби патрульләр әрле-бирле йөреп тордылар. Авызы пешкән — өреп эчкән дигәндәй, июнь кузгалышының авырлыгын күргән җиззахлылар сабырның соңгы чигенә житсәләр дә, бу юлы саграк булдылар. Нәфрәтләрен ихтыярсыздан эчләренә йотып, тешләрен кысып булса да түзделәр.

Шулай итеп, мәрдекарьлеккә барудан баш тартырга бүтән бернинди әмәл калмады. Ил азаматлары үз язмышына тыштан буйсынсалар да, уңайлы вакыт килер дә, безгә дә бер бәхет йолдызы елмаер әле дип өмет иттеләр. Ул көннәрдә каләндәрханә бакчасы тулы кеше иде. Алар илдәге хәлләр, мәрдекарьлеккә китү, тормышның авырая баруы турында сөйләштеләр. Бер вакытта да уеннан туймаган без малайлар да шул тирәдә бөтерелдек. Шунысы гаҗәп, соңгы вакытта ярлы-ябагайларның балалары байбәтчәләрдән читләшә башлады. Тамагы болай да икмәккә туймаган малайлар аталары сугышка китсә тормышлары тагын да авыраячагын беләләр иде. Шуңа күрә без дә, өеребез белән, каләндәрханә бакчасында колагыбызны сакка куеп, андагы сүзләрне берәмберәм чүлдерә идек.

Көннәрнең берсендә бакчада атка атланган Иргәш унбашы пәйда булды. Гадәттә, унбашы ат өстендә күренмәгәндә, халыкның игътибары аңа юнәлгән була. Чөнки ул яңа хәбәр китерә. Бүгенге шомлы көндә аннан яхшы хәбәр көтеп булмый, билгеле. Шуңа күрә, ул күренү белән, каләндәрханәдәге кешеләр сагая төште.

Иргәш унбашы иярдә коеп куйган кебек нык утырган. Чандыр булса да, буй-сыны үзенә килешеп тора. Җәенке битле, көрәк сакаллы, ачык йөзле, киң күңелле, бер сөйләп, ун көлә торган кеше иде. Юлда очраганда, өлкәнеме-кечесеме, барысына да «балаҗаннарым» дип дәшә. Кешеләр дә, ул күренүгә: «Әнә, Балаҗан әкә килә», диләр. Безнең ише малайлар аны очратканда: «Әссәламәгаләйкем, Балаҗан әкә» дисәк: «Вәгаләйкүм әссәлам, балакайлар» дип, амин тотып, көлемсерәп узып китә торган иде.

Унбашы бүген, башына хаҗи түбәтәе киеп, зәңгәр сәлләсен ураган. Иненда ямаулы йон чикмән, аягында иске кәвеш. Аты да хуҗасы кебек: кыска аяклы, йонлач, кыска муенлы, бакча капкасыннан юргалап килеп керү белән, аякларын күтәреп, артына чигенде дә шып туктады. Бакчадагылар баш кагып, сәлам биргәч, Иргәш унбашы камчы сабын чигәсенә терәп, әле бер, әле икенче якка борыла-борыла, мәзин азан әйткәндәге кебек сузынкы тавыш белән бәет әйтергә кереште:

Әүвәл сәлам халкыма!
Баһадирлар хакына
Колак салып тыңлагыз,
Аңламыйча калмагыз,—

дигәч, ул тавышын тагын да көчәйтә төште:

Он ялаган ончылар!
Кан ялаган итчеләр!
Балтачы һәм чәчтараш,
Кузгалышка булды баш.
Җир хуҗасы дичканым,
Агызучы тир-канын,
Атбагар һәм куйбагар!
Илгә бирделәр җанын.
Ир, башына көн туса,
Итеге белән су кичәр;
Ат, башына көн туса,
Авызлыгы белән су эчәр,
Ишетмәгән бар микән
Җиззахлылар каһәрен,
Бай-морзалар алдылар
Үз өлешен — әҗерен.
Мирзаярлар, Рукиннар
Берсе исән калмады.
Нәфрәтләнгән ач халык
Артыгына бармады.
Хаким түрәне кем атты?
Шуны белеп торыгыз,
Мөхәммәдидер аты.
Йосыфҗандыр канаты.
Язмышында бар икән,
Батырга яр — дар икән.
Муенына бау салгач,
Кайсыгыз елар икән?
Елар Һәмрә атасы,
Җәләлетдин агасы,
Мөхәррәмә хатыны —
Күз нурының карасы.
Елар кызы Рахәтәй:
«Нишләдең син, дип әткәй?»
Нәрсә диярсез, дуслар,
Мөхәммәдине асканда?
Соңгы сүз әйтер өчен,
Каршыгызга басканда:
«Еламагыз, дусларым!
Елама, улым Йосыфҗан!
Елап кайгы басылмас,
Күк капусы ачылмас
Үсеп бөркет булыгыз!
Көрәш юлына басыгыз,
Безне аскан залимнәрне
Үз дарына асыгыз!
Зиннәт атлы анасы,
Дарда торса баласы,
Ана күңеле ничек түзәр,
Әрнер йөрәк ярасы.
Калмас аның тәкате,
Килеп житәр сәгате.
Үкси-үкси елар ул.
Чәч толымы тузар шул.
— Әнкәй җаным, өзгәләнмә,
Еламасын бәбкәем!
Еламагыз, яшьтәшләрем!
Мөхәррәмә гөлкәем!
Мөхәммәди бичара,
Дар астында әвәрә.
Куропаткин урдага
Кордырткан ди биек дар,
Булса билбау биләндә,
Мөхәммәдигә бул яр!
Бүген көн уртасында
Мөхәммәдине асалар.
Утырганнар торсыннар,
Торганнар йөгерсеннәр.
Мәйдан ягына барсыннар.
Батыр үлемен күрсеннәр! Һа-әй!..

Бу коточкыч хәбәр авыздан-авызга, колактан-колакка күчеп яшен тизлеге белән шәһәргә таралды. Олысы-кечесе, ире-хатыны бер-берсен өндәп: «Әйдәгез, ил батырын соңгы юлга озатабыз. Үләр алдыннан ул бичара: «Мине юксынучылар бар икән. Азатлык өчен үләнемне халкым белә икән», дип үзенә юаныч тапсын» ди-ди, кешеләр барлык мәхәллә, кышлаклардан урда ягына таба агылдылар.

Мәйданның зурлыгы сиксән гектар чамасы. Урда кузгалышка кадәр шәһәребезнең иң матур урыны иде. Җәза бирү отряды андагы кибетләргә, торак йортларга ут төртеп яндыргач, хәзер ул каберстанга охшап калган. Урда уртасындагы калкулыкта Куропаткинның коточкыч дар агачы тора. «Дар» дигәндә, мин бөтенләй икенче нәрсәне күз алдына китерә идем. Ул Ташпулат җәлладның дарына бер дә охшамаган. Калкулыкка озын бүрәнә утыртылган. Бүрәнә башына, карачкы кулы сыман, аркылыга агач кадакланган. Шунарга элмәкле бау эленгән.

Урда мәйданы халык белән шыгрым тулы. Калкулык өстендәге полицейскийлар мәйдандагыларга ара-тирә усал гына карап куялар.

Сентябрь башы. Көн җиләс. Күк йөзендә ярты-йорты болытлар күренә. Үзенә табыш барлыгын тойган кебек, һавада козгыннар оча. Мәйдандагы кешеләр кинәттән: «Киләләр, киләләр!» дип, утын базарына таба борылдылар.

Бер төркем атлы казак, кылычларын иңбашына салган килеш, өсте келәм белән ябылган арбаны урап алып, мәйданга таба киләләр. Полицейскийлар, утлы күмергә баскан мәче сымак, арлы-бирле йөгерешәләр: «Һай, мөселманнар! Юл бирегез! Урыныгыздан кузгалмагыз! Урда өстендә пулемет тора. Ходай ул көнне күрсәтмәсен, күз ачып йомган арада барыгызны да кырып салыр!» дип куркыталар.

Шул чак көтелмәгән бер хәл булып алды. Полицейскийларның шаушу килүенә карамастан, өстенә ертык камзул кигән, ялан баш, ялан аяклы бер малай халык арасыннан атылып чыкты да: «Дәдә! Дәдәҗан!»[1] дип арбага таба йөгерде. Садыйк мирбашмы, әллә Талипмы, хәзер хәтерләмим, аты-юлы белән сүгенеп ат башын малайга таба борды:

— Һай бала, яшьләй үләсең киләме әллә?! Кит юлдан! — дип, камчысы белән тегенең аркасына сыдырды. Малай, җан-фәрманга кычкырып, халык арасына кереп югалды.

Ул минем яңа дустым Хәкимҗан иде. Бездән берничә адым җирдә, иңбашын тоткан килеш, ул һаман үкси-үкси елый, күзләреннән мөлдерәп яшь ага. Мин аның янына барып юата башладым. Дустымның атасын төрмәгә утыртканнарын белә идем. Абдулла улы Зыякарый да, Мөхәммәди кебек, патшага каршы баш күтәргәне өчен, Төркстан махсус вакытлы дала хәрби суды тарафыннан 1916 елның 19 нчы августында, егерме өч кеше белән беррәттән, җавапка тартылган иде.

Атлы казаклар, тирә-якка дәһшәт чәчеп, зур тәгәрмәчле, өсте ябык кукан арбасын урап алган килеш, атларын куа-куа, халык алдыннан узып киттеләр. Мәйдандагы халыкның олысы-кечесе тораташ булып катып калды.

Арба, калку урынны урап, өскә менде. Кешеләр барысы да күзләрен шунда текәделәр. Урда өстендә авыр тынлык урнашты. Кукан арбасын әкрен генә дар астына китерделәр. Аның эчендә бер Мөхәммәди генәме, әллә башкалар да бармы? Патшага каршы баш күтәрде дип гаепләнеп кулга алынган Корбанбай Урынбаев, Урдушмәт Атабаев кебек унлаган ил батырларының үлем җәзасына хөкем ителгәнен жиззахлылар белә иде инде. Шуңа күрә мәйданга һәркайсысының хатыны, бала-чагасы, ата-аналары, туган-тумачалары килеп, хәзер коточкыч авыр минутлар

[1] Әти, әти җаным.

кичерәләр иде. Асылынырга тиешле кешенең арбадан төшерелүен зур кайгы белән көттеләр.

Арба, арт ягы белән куелганга, халыкка тискәре булды. Кешеләр, күпме үрелмәсен, алгы якта нәрсә булганын күрә алмадылар. Ике солдат, авыр носилкага күгәреп, алты полицейский уртасыннан мәйданчыкка күтәрелгәндә, кешеләр аһылдап куйды.

— Носилка өстендә ак нәрсә күренде!..

— Бичара Мөхәммәдинең гәүдәседер...

— Ул яраланды микәнни?

— Юктыр, Өчтүбәгә хатынын эзләп килгәндә, исән-сау иде әле. Аны Мәхмүт Лачын саткан, диләр.

Носилканы дар астына куйдылар. Солдатлар, ак бәзгә уралган кешене күтәреп алып, озын аяклы урындыкка утырттылар.

— Ул кем икән? Мөхәммәдиме?

Шул мәлне кычкырып елаган хатын-кыз тавышы ишетелде. Полицейскийлар аны тиз туктаттылар. Калкулыкта басып торучы офицерлар арасыннан икесе, алга чыгып, халыкка мөрәҗәгать итте. Аларның берсе Әнвәрбәк иде.

— Җиззахлылар, тыңлагыз! — диде ул кул күтәреп. Кешеләр һәйкәл кебек катып калды. Күзлекле офицер, кулындагы кәгазьгә карап, рус телендә хөкем карарын укыды. Халыкка аның «Мөхәммәди Һамраев» дигәне генә аңлашылды. Әнвәрбәк хөкем карарын үзбәкчәгә тәрҗемә итте. Тылмач башлаган сүзен әйтеп тә бетермәде, халык арасыннан җан әрнеткеч тавыш ишетелде:

— Вай, балакаем! Син үлгәнче анаң үлсә ни булган, җан балам!..

Ләкин ана тавышы озакка бармады. Ташка бәрелеп ватылган кирәч кебек кинәт тынды. Бичара Зиннәт карчыкның йөрәге бу кайгыны күтәрә алмады. Егылган җиреннән бүтән кузгалмады. Улы Мөхәммәдинең үлемен күргәнче, үзе гүргә керүне артык тапты, күрәсең.

Анасының тавышын ишетүгә, кәфендәге кеше кинәт терелгәндәй сискәнеп куйды. Солдатлар аның кулларын кысып тоттылар. Ул ыңгыраша-ыңгыраша тыпырчынырга кереште. Мәйдандагы халык шаулый башлады:

— Каһәр төшкере җан кыючылар! Асарга булгач, ник асмыйсыз? Ни өчен болай озак җәфалыйсыз? — дип кычкырдылар.

Әнвәрбәк мәйданга борылып:

— Хәзер, хәзер, мөселманнар, тынычланыгыз! Мөхәммәдигә соңгы теләген әйтер өчен сүз бирелә, тыңлагыз! — диде.

Күзлекле офицер ишарәләү белән, солдатларның берсе кәфеннең өс ягындагы төенен чиште. Мөхәммәдинең башы күренде. Күзе кара яулык белән бәйләнгән. Авызына тыгылган ниндидер бөкене алып ташладылар. Әнвәрбәк аска карап:

— Мөхәммәди, соңгы теләгең булса әйт! — диде.

Кәфендәге кеше бер мизгел дәшми торды, аннары карлыккан тавыш белән:

— Минем өч теләгем бар,— диде.

Тавышы чыкмасын өчен, авызын томалаганга, тыны кысылып, карлыккан булса кирәк. Авыр тынлыктан соң ул тагын телгә килде:

— Беренче теләгем — күземне, кул-аягымны чишсеннәр иде. Иреклә көенә җан бирәсем килә.

Әнвәрбәк аның сүзләрен рус теленә тәрҗемә итте. Күзлекле офицер нәрсәдер әйтте.

— Күзеңне ачу турындагы теләгең кабул ителә. Әмма аяк-кулың чишелми,— диде Әнвәрбәк.

Бер солдат, Мөхәммәдинең күзенә бәйләнгән яулыкны чишеп, урындык артына куйды.

Мөхәммәди, башын күтәреп, халыкка, күк йөзенә, тирә-юненә карады. Мәйданда шылт иткән тавыш та ишетелмәде.

— Дусларым, ага-энеләрем! Аллага шөкер, күзләрем сезне күрде. Болай булгач, үкенечем калмады. Асылынырга хөкем ителгәннәр бер мин генә түгел. Без күбәүләр... Күп уйландым... Хәер, без юкка үлмибез!.. Мине бер генә нәрсә борчый: Йосыфҗан улым белән Рахәтәй кызым яшьләй ятим калалар. Хатыным йөкле. Тиздән бәбиләргә тиеш. Бәгырькәем, әгәр ир бала тапсаң, исемен Урын пәһлеван дип, кыз тапсаң, Урынай куй! Әнкәй җаным! Син юкка үзеңә үлем теләдең. Ул бездән беркая да качмас. Оныкларыңны тәрбияләп үстерәсең бар әле. Миңа насыйп булмаган гомерне сез күрегез... Инде соңгы теләгем шул: — дип Мөхәммәди тавышын күтәрә төште.— Ләгънәт төшкере залим Никулай патшаның үзенә дә үлем килсен! Бәхил булыгыз!.. Бәхил булыгыз, дуслар!

Барабанчылар кинәт дангыр-доңгыр барабаннарны кагарга керештеләр. Мөхәммәдинең тавышы бөтән ишетелмәде. Кешеләр тагын шаулый башлады. Хатыннар, бала-чага үкереп еларга тотынды.

Шул мәлне Мөхәммәдинең муенына бау салынды. Элмәк өскә тартылды. Кәфендәге гәүдә, һавада чайкалып ике-өч тапкыр тыпырчынгач, аягын җыерды да кинәт язып җибәрде.

Шулай итеп, милли азатлык хәрәкәтенең каһарманнарыннан берсе Мөхәммәди Озын колак Һәмрә улы белән аның анасы алтмыш яшьтәге Зиннәт карчык бер көнне урда мәйданында җан бирделәр. Улы Куропаткинның дары астында, әнкәсе туган туфрак өстендә үлде.

## ТАҢ АЛДЫННАН

Баш күтәрүчеләрнең утыздан артыгы Җиззах белән Сәмәрканд төрмәләрендә асып үтерелде, берничәсе Себергә озатылды. Кузгалыш рәхимсез рәвештә бастырылгач, мәрдекарьлеккә җибәрү эшен дә тизләттеләр.

Бүгенге кебек хәтеремдә, көз көне иде. Мәрдекарьлеккә китүчеләр мәхәлләсе-мәхәлләсе белән җыелдылар. Ирен өсләренә бала йоны тибеп кенә чыккан яшьләр белән беррәттән сакал-мыегына чал кергән ир-атлар да бар иде. Мәрдекарьләрнең барысын да мунчага алып барып юындырдылар, чәчләрен, сакал-мыекларын кырдылар. Кием-салым өләштеләр. Кырык алтынчы үлчәм киюче табәнәк буйлыларга илле ике, илле бишле кием туры килеп, озын буйлы таза егетләргә, киресенчә, кечкенә үлчәмле чалбар яки ботинка эләккән. Берсе сумак[1] кебек сузылып, нечкәреп калса, икенчесе капчык кидергән карачкы сыман иде. Ыштан урынына чалбар, чапан урынына лыпырдап торган мамык камзул-бушлат, читек-кавеш урынына солдат ботинкасы, түбәтәй урынына колаклы бүрекләр кигәч, кеше ничектер сәер булып кала икән. Хәтта хатыннары белән балалары да үз аталарын көчкә таныдылар.

Мәрдекарьләрне, дүртәрләп сафка тезеп, станциягә алып киттеләр. Алар артыннан озата баручы аналар, киленнәр, апа-сеңелләр, бала-чагалар иярде. Унбашы, йөзбашы, меңбашы һәм бихисап полицейскийлар мәрдекарьләр тирәсендә корт кебек мыжласалар да, арттан килүчеләрне берничек тә куып җибәрә алмадылар. Урамнарга, июль кузгалышындагы кебек, халык тулды.

Мәшһүр халык җырчысы Мәхмүтҗан алга басып «Сау булыгыз, анаҗаннар»[2] дигән яңа җырын җырлады. Моңа тәэсирләнмәгән кеше калмады:

---

[1] Бишектәге бәбиләр астын чылатмасын өчен куела торган озын торба.
[2] Әнкәй җаным.

— Балам китә дип еглама,
Йөрәк бәгырен даглама[1].
Сау булыгыз, анажаннар!..
Сау булыгыз, жанажаннар!..[2]
— Без калырбыз ертып яка[3],
Сез китәрсез ерак якка.
Сау йөрегез, жанажаннар!.:
— Сау калыгыз, жанажаннар!..

Шулай кайгы-хәсрәт кичереп баручы мәрдекарьләр Җиззах вокзалына килеп життеләр. Офицерлар һәм полицейскийлар аларга туганнары белән саубуллашырга да ирек бирмәделәр. Килеп туктау белән кызыл вагончарга кертеп, ишекләрен яптылар. Халык арасында ризасызлык башланды. Кайсы елый, кайсы сүгенә. Ул арада паровоз кычкыртты. Ул, аждаһа кебек пышылдый-пышылдый, кузгала башлады. Вагоннар бер-берсенә так-ток бәрелеп урыннарыннан кузгалдылар. Хатын-кыз, бала-чага, елый-елый, эшелон артыннан йөгерде. Ләкин ике ара ераклашканнан-еракләшә барды... Ниһаять, поезд борылышка житеп күздән югалды. Озатучылар, хәлдән таеп, кире кайттылар. Янып күмергә әйләнгән жимерек йортлар, аерылышу кайгысы, тапталган намус, хурлык, хокуксызлык, ачлык — барысы бергә өстәлеп, җиззахлыларның кара язмышына әйләнде. Мәрдекарьгә киткәннәрнең хәле тагын да авыррак иде. Көньяк кояшы жылысында үсеп буйга житкән егетләргә төньяк салкынында хезмәт итү, билгеле, жинел булмаган. «Үзбәк, таҗик, казакъ, кыргыз мәрдекарьләре тайгада урман кискәндә боз булып ката торган идек. Салкында кул-аякларын өшетеп, гариләнеп калучылар да шактый булды...» — дип сөйләгән иде шунда булган бер туганым.

Урта Азиядән барган мәрдекарьләр фронтта окоп казыган, заводларда чуен койган,, тимер юлларында шпаллар алыштырган, шахталарга төшеп, ташкүмер чыгарганнар. Туган-үскән якларыннан еракта ярым ач, ярым ялангач көенә гомер кичергәннәр. Бу авырлыклардан тәкате калмаган мәрдекарьләр золым-җәберләүләргә каршы теләсә нинди көрәшкә әзер булган.

Көннәрдән бер көнне, яз башында: «Урыс мастеровойлары Никулайны тәхетеннән төшереп, кулга алганнар», дигән сүз таралды. Җиззахлыларның шатлыгы эченә сыймады. Урамдагы кешеләр бер-берсен кочаклап тәбрикләделәр. Атамның йөзе кояш кебек яктырган иде: «Анасы, хәтерлисеңме? Ак патшаны бер мөселманнар гына җиңә алмас, җинсә урыслар үзләре җинәр, дигән идем. Күңелгә килгән алдыңа килми каламы соң? Без хаким түрәне ничек кыйнап үтергән булсак, урыслар да шулай ак патшаны, тәхетеннән бәреп төшереп, аламан[4] кылганнар, азаматлар», дип сөйләде. Анамның шуңа жавап итеп: «Мөселманнарны бик үк хурлама. Җиззахлылар, хаким түрәне үтереп, урысларга юл күрсәтмәсә, алар үз патшасын үтерүне кайдан белерләр иде», дип мактанганы әле дә хәтеремдә.

Тагын шунысы да истә калган: нәкъ шул көнне Җиззах кузгалышында гаепләнеп кулга алынган Урдушмәт белән Корбанбай әкәләр төрмәдән чыгарылды. Алар, мәхәллә чәйханәсендә чәйләп утырганда, кулларындагы яра эзләрен күрсәтеп: «Болар богаудан калган тамгалар. Рәхмәт төшкере урыслар, үз патшаларын кулга алып, залим хөкүмәтне кумасалар, Мөхәммәдиләр артыннан безне дә бүген булмаса иртәгә дарга асмакчылар иде», дигәнен яхшы хәтерлим.

Шул мәлне берсе, белдеклеләнеп:

---

[1] Өзгәләмә.
[2] Жаныйлар.
[3] Кайгырып (үзбәк халык әйтеме).
[4] Урам суды.

— Никулай урынына Керенский дигәннәре патша булган. Ул үзе Төркстаннан, имеш. Кешеләрнең сөйләвенә караганда, яңа патша Ташкенттан мәрдекарь булып киткән икән,— диде.

Шуңа берсе:

— Алай ук булмаса да, мәрдекарьлеккә меңбашы булып баруы бик ихтимал,— диде.

— Хәер, кем генә булмасын, дәүләт хәзер аның кулында. Төркстанлыларга рәхиме килеп, мәрдекарьләрне кайтарып җибәрүе дә бик ихтимал,— диде өченчесе.

Февраль революциясеннән соң барысының да күзе мәрдекарьләр киткән юлда булды. Ләкин алар тиз генә әйләнеп кайтмадылар. Берничә айдан берәмләп, биш-унлап кына күренгәләделәр. Әҗәле житеп, Россиянең карурманнарында үлгән хәбәре алган гаиләләрдә кайгылы аза[1] уздырдылар.

Мөлкәллек иленнән мәрдекарьгә барган Урдуш ата Мукимов болай дип сөйләде:

— Мең тугыз йөз уналтынчы елның сентябрь ае иде. Көнен тәгаен хәтерләмим. Җиззахның иске шәһәреннән безне, вокзалга чыгарып, мал төягән кебек, кызыл вагоннарга кертеп яптылар. Йөзбашыбыз Җура миршаб, меңбашыбыз мулла Исхак Хәлмөхәммәтовлар безне Ташкентка алып бардылар. Анда эшелонга мәрдекарьләр төялгән тагын берничә вагонны тагып, казакъ сахралары аша, Сызрань дигән шәһәргә китерделәр. Шул турыда мәрдекарьләр җыр да чыгарганнар иде.

— Нинди җыр? — дип сорадым.

Урдуш ата, бераз уйлана торгач, җырлап ук күрсәтте:

Анда бардык, монда киллек,
Сызрань дигән калага.
Һай, дусларым, кемнәр түзәр
Анда күргән бәлагә?
Шулпа дип гел су бирделәр,
Авызга да капмадык.
Кара наны ачы булгач,
Бүтән эмәл тапмадык.
Яртыбыз тоз казырга китте,
Яртыбыз зур шахтага,
Яртыбыз фронтка китте,
Калганыбыз мәхшәргә...

Урдуш ата мыегы астыннан гына көлеп куйды:

— Хәтердә калганы менә шул, мелла Нәзиркол. Фронттан кайткач, Җиззах станциясендә шушы җырны җырлаганга илле ел булгандыр инде?

— Бераз артыграк та әле,— дидем.

— Анда булган хәлләрне үзегез дә беләсездер?

— Житәрлек түгел. Башыгыздан кичергәннәрне сөйләгез әле.

— Солдатта да һөнәре булганнар отты,— дип дәвам итте Урдуш ата.— Мәрдекарьләрне, кәсебенә карап, эшкә бүлделәр. Берсе тимерчелектә, икенчесе төзү эшенә дигәндәй... Мөлкәллек иленнән баручыларның күбесе дийһкан булганга, без кара эштән башкасына ярамадык. Безгә Назәрмәт дигән кешене йөзбашы итеп билгеләделәр. Ул рус телен сукалый, бераз язу-сызуны да белештерә икән. Эш белгәнче тел бел, дигәннәр түгелме? Кайбер җирдә аңысы да артык түгел икән, мелла Нәзиркол. Озын сүзнең кыскасы, Назәрмәт безгә баш булып, тимер юлларын төзәтеп, йортлар ремонтлап йөрдек. Торагыбыз яккач җылынса да, ашатуларының бер дә рәте-чираты булмады. Барып төшкәннән бирле ачлы-туклы гомер кичердек. Көзен-кышын мең җәфа белән

[1] Үлгән кешене искә алып елау йоласы.

уздырып, язга чыктык. Ул якларда җәен бездә үскән җимешләр өлгермичә икән. Бигрәк шуңа кыйналдык. Буш капчыкны җиргә утыртып булмый, диләр. Авызыбызны ачсак, тамагыбыз күренә торган булды. Качып китик дисәк, әмәлебез юк. Эшкә чыкмасаң, ачтан үләрсең. Ул көннәрне бүтән күрергә язмасын. Туган-үскән якларыбызга кайтып үлсәк, үкенечкә калмас идек, дип сөйләнде кайберәүләре. Шул шомлы көннәрдә арабызда бер яңа кеше пәйда булды. Милләте татар булса кирәк. «Иптәш, иптәш» дип сөйләшә. Телен дә аңлыйбыз. Кайбер көннәрне шул иптәш бер-ике сәгатькә югалып тора да каяндыр бәрәңге табып кайта. Аны утлы көлгә тәгәрәтеп пешергәч, өстенә тоз сибеп ярабыз гына. Биргән — ходайга яраган дигәндәй, барыбыз да шул кешене ошаттык. Ул нәрсә дисә, шуны эшли торган булдык. Элегрәк ачлыкка интеккәч, бер-икесе эшкә чыкмаса, карцерга утыртып, кәбестә шулпасыннан да мәхрүм итәләр иде. Татар иптәш: «Алай ярамый!.. Берегезне наказать итсәләр, барыгыз да эшкә чыкмагыз. Иттифак кирәк! Бер кешене кулга алырга була, ә барыгызны да утыртсалар, эшләрен кем эшләр?» дип кинәш бирде. Кыскасы, без барыбыз да аның авызына карап калдык. «Карныбыз ач! Эшкә ярамас булдык! Ашыгызның итемәе юк! Сасыган балык шулпасын бүтән ашамыйбыз, икмәк паегын арттырыгыз!» дип даулаша башладык.

Бер көнне татар иптәш, култык астына кыстырып, ике метрлы кызыл ситсы алып килде:

— Иртәгә сәгать икедә паровозлар берьюлы кычкырта башларлар. Шунда барыгыз да эшегезне ташлап, урамга чыгыгыз. Менә бу ситсыдан байрак ясап, вокзал янындагы мәйданга барыгыз,— диде. Байракны мин тотып бара торган булдым. Аңа рус хәрефләре белән нәрсәләр язылган иде. Без сорашкач, курыкмагыз, рус мастеровойлары да нәкъ шундый байрак белән чыгачак. Барысына бер үк сүзләр язылган: «Бетсен сугыш! Бетсен самодержавие!» диелгән,— ди.

Безнең белән бергә ун-унбиш рус эшчесе дә барырга булды. Йөрәккә ут кабынды. Җаныбызны ниндидер шатлыклы тойгы биләп алды. Иртәгесен таң ату белән барыбыз да эшкә чыктык. Төш вакытында безгә рус иптәшләр кушылды. Төгәл сәгать икедә берничә җирдән берьюлы паровоз кычкырта башлады. Бу тавышка күк белән җир дә тетрәр иде. Барыбыз да көрәкләрне атып бәрдек. Урыс эшчеләре белән сафка бастык. Алар алдан атлады. Карасак, урам тулы халык. Андагы байракларның исәп-хисабына чыгарлык түгел. Урамнар лалә болыны кебек кып-кызыл. Рус эшчеләре җыр җырлап, таш урамнардан гөрс-гөрс атлап баралар. Безне кыюрак булырга өндиләр. Атлы полицейскийлар күренгәч тә, эшчеләр югалып калмады. Таш ыргытып, ничек туры килсә шулай каршы килеп, тегеләрне куып җибәрделәр бит, әй. Шунда рус эшчеләренең батырлыгына хәйран калган идек. Байраклар күз явын алырлык. Шул кадәр әләмне каян таптылар икән дип исем китте. Сызраньда ярты ел торып, мондый зур демонстрацияне беренче күрүебез иде. Шуннан соң ул бик еш була башлады.

Бер көнне иртә белән эшкә чыксак, рус эшчеләре тагын эш ташлаган. Сорасак, Никулай патша тәхетеннән төшерелгән, диләр... Йа алла, шундый көнне дә күрәсебез бар микәнни? Явыз патшаның да көннәре санаулы була икән ләбаса! — дип шатлыгыбыздан нишләргә белмибез. Рус эшчеләре безне кочаклап үбәләр: «Поздравляем, теперь домой пойдешь», диләр. Без исә: «Авызыгызга бал да май, товарищ!» дип аларны котлыйбыз.

Шуннан соң кулларыбыз эшкә ятмыйча, уй-хыялларыбыз да өйгә кайту гына булды. Татар иптәш: «Сабыр итегез! Сез өлкән кешеләр бит», ди. Ә безнең сабыр тартмасы күптән тулган. Алтын-көмеш чыккан җирдән туган-үскән ил якын, диләр бит. Һәй, әгәр канатларыбыз булып, Җиззахыбызга очып кына кайта алсак иде! Ата-анабызны, туганнары-

бызны сагынып, үксез бала кебек, балавыз сыккан көннәребез дә булгалады, мелла Нәзиркол,— дип көрсенеп куйды Урдуш ата.— Урдада асылган Мөхәммәди дә бит җан бирер алдыннан: «Никулай патшага үлем телим!» — дигән иде. Кызганычка каршы, аның кебек бик күп ил батырларына бу көнне күрергә язмаган икән... Һәрбер эшнең үз вакыты, үз сәгате була икән шул,— дип, Урдуш ата беркавым уйланып торды.— Мелла Нәзиркол. әңгәмәбез Сызраньдагы хәлләр турында иде түгелме, Җиззах монда ничек килеп керде соң әле? — дип елмаеп алды.

Мин, Урдуш атаның сөйләгәннәрен игътибар белән тыңлап, күңел дәфтәренә яза бардым.

— Аз булса да хезмәт хакы ала идек. Бер заман айлык бирү көне житмәсә дә, торагыбызга кассир килмәсенме: «Акчагызны кесәгезгә салыгыз да Төркстаныгызга кайтыгыз!» — димәсенме бу! Без шунда ук станциягә чыктык, кызыл вагоннарга утырдык. Вагоныбыз нииндидер эшелонга тагылды. Безгә бер рус егете юлдаш булды. Татар иптәш саубуллашканда: «Андагы туган-кардәшләрегезгә бездән сәлам әйтегез! Минә бу Алексей иптәш сезне Җиззахка кадәр озата барачак», диде. Без аны Алексей әкә дип йөрттек. Кайтышлый нииндидер бер станциядә эшелоныбыз өч көн туктап торды. Поезддагы халыкның яртысы диярлек төркстанлылар икән. Бик күп таныш-белешләрне очраттык. Үлгәннәрне искә алдык. Үзбәк, таҗик, төркмән, казакъ, кыргыз мәрдекарьләре арасында имгәнеп-җәрәхәтләнгәне, йөзендә нуры калмаган чирлеләре дә шактый иде. Эшелонның болай озак торуы безне борчый башлады. Без тагын гауга күтәрдек. Алексей әкә: «Җәнҗал кирәкми. Юл буш түгел. Чираты житкәч, безне дә жибәрерләр», дип тынычландырды. Чынлап та, иртәгесен паровозыбыз озын гудок бирде. Ниһаять, без кузгалып киттек. Казакъ чүленең очы-кырые булмас төсле. Яз ае булуга карамастан, ком сахрасы тап-такыр, үлән-чирәме дә рәтләп күренми. Сабыры житмәгәннәр ташбака кебек өстерәлгән паровозның тетмәсен тетә, казакъ чүлен узсак, теге ягын җәяү дә кайтып житәр идек, диләр.

Шулай итеп, мең җәфа белән булса да, ниһаять, Җиззахыбызга кайтып төштек бит, әй!.. Май ае иде. Язгы йомшак җил битләрне сөеп иркәли... Сулган кырга су сипкәндәй, безгә дә җан керде. Шул көнне Җиззах станциясендә булган тантананы сөйләп бетергесез! Ул кәрнайсорнайлар, ул дөтәр тавышлары дисеңме! Мәрдекарьләрне ата-аналары, туган-тумачалары сырып алып, барыбыз да иске шәһәргә юл тоттык. Урамнан барганда дөнья шаулатып җыр җырладык:

Әссәламмөгаләйкем,
Шагланамсың, иллебашы?
Мәрдекарьне мин бирәм диг,
Кул куйдыгыз, иллебашы.
Кызыл кәгазь пул[1] бирдегез,
Кызы талак, иллебашы.
Пулны алып, безне сатты,
Хатыны талак, иллебашы.
Такта күпер беттеме,
Никулай патша киттеме?
Җиззаһ шәһәрен вәйран[2] кылып,
Үз башына життеме!..

— Бу җырның үзенә күрә бер мәгънәсе бар,— диде колхоз төзелешенең ветераны, карт коммунист Урдуш ата.— Мәрдекарьләр кендек каны тамган туган якларына кайтып кергәндә, царизмнан, Николайдан һәм аның урындагы түрәләреннән көлеп җырлаган йөрәк тавышы иде бу...

[1] Акча.
[2] Җимереп-ватып.

Җиззахка мәрдекарьләр кайткач, ташландык курага хуҗасы кайткан кебек, урамнарга ямь керде. Кешеләрнең йөзләре яктырды. Бакчалар ап-ак чәчәкләргә күмелде. Тут җимеше өлгерде. Кыш буена ачлы-туклы торган Җиззах халкына ул да ярап торды. Мин, елдагыча, иртәдән алып кичкә кадәр агач башыннан төшмичә, бәләкәй чиләгем белән өйгә тут ташыдым.

Бер көнне шәһәрдә Россиядән кайткан мәрдекарьләр Хафиз байның бакчасына җыела икән дигән сүз таралды. Без Акылбәк дустым белән шунда барырга булдык.

Әле күптән түгел генә безне Хафизбайның бакчасына полицейскийлар якын да җибәрмиләр иде. Ә бүген аның капкасы бар кешегә дә ачык. Җәннәт почмагы дип телгә кергән иң ямьле урынына шәһәрнең хезмәт халкы җыелган. Күбесенең өстендә ертык чапан, аякларында ямаулы читек яки солдат ботинкасы. Мәрдекарьлектән яңарак кайтканнарның өстендә сырма, билендә брезент билбау, башларында бүрек яки түбәтәй иде.

Халык арасыннан озын буйлы бер кеше айванга менде. Бүгенгедәй хәтеремдә, ул кара кашлы, озын мыеклы, ак чырайлы кеше өстенә гимнастерка, аягына хром итек кигән иде. Халыкка күз йөртеп чыккач, ягымлы тавыш белән:

— Мөселман агайнеләр, кадерле уртаклар»[1] — дип сүз башлады. Бакча эче кинәттән тынып калды.— Бүген бирегә ни өчен җыелуыбызны үзегез дә белә торгансыздыр. Без залимнәргә каршы баш күтәрдек. Меңбашы, хаким-түрә, миршабларны юк иткәч, золым-җәберлекләр бетәр дип уйладык. Ләкин без ялгышканбыз икән, иптәшләр. Чөнки Мирзаяр, Рукин кебек меңләгән түрәләрнең башында Николай патша торганын оныткандыз. Җиззах кузгалышын аяусыз бастырган кораллы гаскәр барлыгын истән чыгарганбыз. Халык нәфрәте никадәр көчле булмасын, көрәк-сәнәк белән генә берни дә кырып булмый. Ахырын үзегез беләсез. Бостан[2] кебек калабыз көл түбәгә әйләнде. Арыкларыбызда су бетте. Бакчаларыбыз корыды. Халкыбыз бер сынык икмәккә зар-интизар булды. Ачлык көннән-көн бугазыбыздан буа бара! Уртаклар, бер Төркстанда гына түгел, бөтен Урусиядә эшче-диһканнар ак патшадан, бай-морзалардан газап чиктеләр. Романовлар золымлыгына каршы көрәштә газиз башларын төрмәләрдә череткән урыс революционерлары илдә шактый. Мин шул турыда газеталардан укып торам. Анда язылганнардан шундый нәтиҗә ясарга була: без, җиззахлылар, үзебездәге золым-җәберлекләргә каршы баш күтәреп, царизмны бетерү өчен көрәшүче урыс иптәшләребезгә зур булышлык иткәнбез икән. Менә хәзер урыс эшчеләре патшаны бәреп төшереп, безнең өчен үч алдылар. Шуңа күрә, әйдәгез, уртаклар, урыс эшче-диһканнарын тәбрик итик! Яшәсен февраль инкыйлабы каһарманнары! Яшәсен урыс эшчеләре! Яшәсен эшче диһканнардан чыккан инкыйлаби солдатлар!

Бакчадагы халык ораторның сүзләренә кушылып:

— Яшәсен хөррият! Яшәсен азатлык! — дип кычкырдылар.

Бу тавышка бай бакчасындагы йортлар да тетрәгәндәй булды. Якын-тирәдәге ишек алларыннан кешеләр чыгып, як-якка карандылар. Агач ботакларына кунаклаган малайлар сызгырды.

— Уртаклар, инкыйлаб корбансыз булмый,— дип дәвам итте теге кеше.— Ул корбаннар урынына без бүгенге көндә нәрсә күрәбез? Нәрсәгә ия булдык?

---

[1] Иптәшләр.
[2] Гөл бакчасы.

— Көл түбәгә! Хәрабәләргә!

— Ачлыкка!

— Хәзер безгә әнә шул ачлыктан котылу юлларын эзләргә кирәк. Патшаны төшерү белән генә эш бетмәде әле! Җиззахлылар мәрдекарьлеккә куылган көтү булып китсәләр дә, аннан күзләре ачылып кайтты. Алар ил азатлыгы өчен ничек көрәшергә кирәклеген белеп кайттылар. Менә безнең арабызда урыс эшчеләренең вәкиле, Сызрань шәһәреннән килгән Алексей әкә утыра.

Кешеләр үрелә-сузыла, кайберләре хәтта урыннарыннан торып, терраса янындагы рус кешесенә карадылар.

— Дөресен әйткәндә, бүгенге җыелыш Алексей әкәнең тәкъдиме белән уздырыла,— дип дәвам итте оратор.— Белмәгәннәр белсен, танымаганнар танысын. Алексей әкәне монда Сызраньдагы тимер юл эшчеләре җибәргән. Безнең мәрдекарьләр анда газап чиккәндә, урыс эшчеләре аларга аталарча ярдәм иткән. Алексей әкә Җиззахка килгәч, берничә көн буена мондагы хәлләр, халыкның авыр тормышы белән танышты. Хәзер без сүзне аның үзенә бирәбез.

Бакчадагы халык эшчеләр вәкилен алкышлап каршы алды. Шул мәлне өстенә гади генә киенгән рус кешесе, урыныннан торып, айванга таба атлады. Ул ялан баш, озын йөзле, зәңгәр күзле, сирәк сары чәчле кырыклар тирәсендәге ир-ат иде. Төскә ябык булса да, инбашлары киң, өстендә коңгырт күлмәк, кара чалбар, аягында күн итек.

Эшчеләр вәкиле, башта халыкка таба баш иеп, сәлам бирде. Аннары рус телендә нәрсәдер сөйли башлады. Яхшы әле, җыелышны ачкан кеше аның сүзләрен бәйнә-бәйнә тәрҗемә итеп торды. Карап торуга юаш кына күренгән Алексей әкәнең сүзгә шул кадәр оста булуына халык хәйран калды. Кыска гына вакыт эчендә ул халыкны үзенә җәлеп итте. Тыңлап торучыларның йөрәгенә керә белде. Патша хөкүмәтенең, бай-морзаларның илгә никадәр золымлык эшләгәнен сөйләде. Николайны Россия халыкларының җәллады, юксыллар дөньясының явыз дошманы дип атады. Нигезенә кадәр черегән патша строена каршы баш күтәреп, зур батырлык эшләгәнсез, дип, Җиззахларны мактап алды.

— Россия пролетариаты, крестьяннар белән бергә, Николай патшаны тәхетеннән төшерде. Аның реакцион хөкүмәте юкка чыгарылды. Ләкин бу әле үз максатыбызга ирештек дигән сүз түгел. Илдә һаман да сугыш дәвам итә! Вакытлы хөкүмәт халыкның моң-зарына колак салмый. Ул буржуазия интересыннан чыгып эш йөртә. Халыкка сугыш кирәкми! Без чын хөррият таләп итәбез. Завод-фабрикалар эшчеләр кулына, җир-сулар крестьяннарга күчәргә тиеш! Безгә хезмәтчел халыклар арасындагы дошманлыкны бетерә торган гадел хөкүмәт кирәк. Эшче-крестьяннарның юлбашчысы иптәш Ленин безне азатлык өчен яңа көрәшкә өнди!

Җиззахлы иптәшләр! Хәлегезнең авыр булуын күреп торам. Менә бер елдан артык арыкларыгыздан су акмый, басуларыгызда иген үсми. Бу хәлгә бүтән түзәргә ярамый. Рукин урынына билгеләнгән яңа хаким бу көннәрдә нәрсә белән мәшгуль, дисез? Яңадан восстание күтәрелмәсен дип, җәза отряды төзеп ята. Юк, без ул атлы казаклардан курку чорын узган инде. Мин, иптәшләремнең киңәше белән, бирегә килдем. Дөресен әйтәм, Җиззахка килгәнем өчен үкенмим. Өч көн буена мондагы хәлләр белән таныштым. Җиззах халкы чынлап та ач-ялангач калган! Ашарыгызга икмәк, эчәрегезгә су калмаган. Вакытлы хөкүмәтнең урындагы вәкилләре халык хәлен кайгыртмыйлар. Аларны бай-морзаларның иминлеге күбрәк борчый.

Бакчадагы халык Алексей әкәнең ялкынлы сүзләренә иярер:

— Балаларыбыз ач-ялангач утыра, товарищ! — диделәр.

— Бер уч ярмага мохтаҗ булдык!

— Чәчик дисәк, орлыгыбыз юк! Җир сөрергә атыбыз юк!

— Йортларыбыз утта янды. Хуҗалыгыбыз туздЫ! Син яхшы урыс күренәсең. Ерак җирдән хәлебезне белешергә дип килгәнсең. Күңелебездәгесен сөйләдең, рәхмәт яугыры! Дөресен әйткәндә, урыслар белән безнең арада бернинди дошманлык юк! Никулай патша барлык милләтләрнең дә явыз дошманы иде. Мирзаяр белән Рукиннарны юк итүебезне мәгъкуль таптың. Үткән эшкә салават, диләр. Хәзер, моннан ары безгә нәрсә эшләргә соң? Әйдәгез, шул турыда киңәшик!

— Күреп торасың, Алексей әкә! Халыкның бернинди әмәле калмады. Дөятартар каналының буасы китте. Сәнзардан килгән нәүбәт суы да акса — ага, акмаса — юк! Сусыз диһканның эше бармый. Халыкның тормышы суга бәйле. Су булмаса, безнең илдә берни үсми. Элек Җиззахта мелла Хакбирде дигән мираб бар иде. Аның әмере белән арыкларга су җибәрелә иде. Шул кешене казаклар атып үтергәннән бирле, нәүбәт суын бүлү эше буталды. Дөрес, җиззахлылар аннан су гына түгел, зәһәр дә эчә торганнар иде. Алексей әкә, син дөнья күргән кешегә охшыйсың. Зинһар, безне яңа хаким алдына алып бар. Пычакның очлы башы сөякләргә үтте. Без соңгы чиккә җиттек. Кулыңнан килгән кадәр безгә ярдәм ит! — диделәр.

Шуннан соң мәрдекарьләр сафка тезелеп, кулларына кызыл байрак күтәреп, Алексей әкәне алга бастырып, Җиззах хакименең идарәсенә барганнар. Халыкка икмәк, диһканнарга орлык бирүне, арыкларга су җибәрүне таләп иткәннәр. Аларга яңа шәһәрдә яшәүче рус мастеровойлары да кушылган.

Яңа хаким халыкның моң-зарын тыңлагач:

— Дөятартар каналын тиз арада буып булмас. Сәнзар суын Җиззахка җибәртербез. Моны тизлек белән эшләтер өчен, сезгә ун-унбиш солдат бирәм. Сәнзар суы Җиззахка килгәнне сагалар өчен, үз арагыздан кешеләр билгеләгез, дигән. Шулай да яңа хаким ач халыкка икмәк, диһканнарга орлык вәгъдә итмәгән.

Шул көннән соң арыкларга тулып су килде. Ләкин Сәнзар суы гына халыкка иң кирәкле булган икмәк белән орлыкны алыштыра алмады.

Ачлык халыкның бугазыннан рәхимсез рәвештә буа барды.

Үзбәкчәдән Я. ШӘМСЕТДИНОВ
тәрҗемәсе.

## Рәшит Гәрәй

# ТУГАН—ҮСКӘН ҖИРЛӘРЕМ

## Җыр өйрәткән авылым аркылы

Тиргәүчеләр, әйдә, тирги бирсен,
Күнеккәнбез инде аңа без.
Җырларымда, имеш, һич күренми
Үзем генә салган яңа эз.

Яңадырмы, юкмы... Тәүге эзем
Авыл буйларында салынган.
Илләр гизсәм гизим, язмышым тик
Аермасын туган ягымнан.

Гомерем таңы кырлар өстендәге
Язгы кояш булып балкыды.
Туган җирне, илне сөюем уза
Җыр өйрәткән авылым аркылы.

## Уҗымнарым

Уҗымнарым, күпме җырласам да,
Сезнең хакта җырлап туймамын.
Язлар җиткән саен сезнең белән
Бергә шыта минем уйларым.

Уҗымнарым, кайчак бергә-бергә,
Ә кайчакта аерым яшәлгән.
Язларында кайтсам кырларыма,
Яшь уҗымнар кебек яшәрәм.

Уҗымнарым, бергә булсак та без,
Кирәк чакта аерым булсак та,—
Сулышыбыз бер үк туфракта ич,
Язмышыбыз бер үк туфракта.

## Тургайларны сайратырлык

Яңгыр коя... Инде купме гомер
Зарыгып көткән идек бит аны?!
Кинәт яуган яңгыр бирер микән
Җиремә кирәк булган шифаны?

Мин, инәлеп шушы сорау белән,
Болытларга теким күземне.
Болытларга кумелеп, һәр тарафта
Тургайларым сайрый түгелме?

Эсселәргә күзен йомган гөлләр
Тургай тавышын ишетеп уяныр.
Тургайларны сайратырлык булгач,
Ник шифасыз булсын бу яңгыр!

## Тугайларда атлар йөри

Тугайларда, әнә, атлар йөри,
Кешнәмичә генә чемченеп.
Әйтерсең лә алар уйланалар
Тай чакларын искә төшереп.

Заманында күпме авыр йөкне
Сөйрәгәннәр икән ул атлар!
Искә төшә алар көче белән
Башкарылган чәчү-ураклар.

Читтән генә карап узмыйк әле
Юл буенда йөргән атларга.
Аларга да җылы сүз кирәктер,
Кирәк булган кебек картларга.

## Тормыш

Тормыш акмый һаман тигез генә,
Я, кем шуны уйлап карамас:
Шатлык кына түгел, бу тормышта
Кайгысы да килә аралаш.

Күпне күргән кеше күңелендә
Мәңге-мәңге көләч яз түгел.
Яу кырында якыннары калган
Елаучылар җирдә аз түгел.

Мин үзем дә көләч кайбер көнне,
Иң бәхетле кеше шикелле.
Кайбер көнем шундый моңсу була,—
Тол хатыннар төше шикелле.

## Серемне яшереп тирәнгә

Бәбкәләр үстергән йортларда
Өмәләр гөрләде быел да.
Өр-яңа сүрүле түшәкләр
Өлгерер күпләрнең туена.

Казларның йомшак, ак мамыгын
Парлылар тутыра мендәргә...
Агылды уйларым ерактан
Яшьлегем елмайган көннәргә.

Серемне яшереп тирәнгә,
Ялгызым яндым мин эчтән бер.
«Пар канат булыгыз, оланнар...» —
Шул сүзләр ник искә төшкәндер.

## Сөюем белән бергә

Ышыкланыр өчен давылларда
Каеннарга кирәк иманнәр.
Ир егеткә янып сөйгәненең
Мәхәббәте — терәк, дигәннәр.

Сине уйлап йөргән көннәремдә
Җиңел эшлим һәрбер эшемне.
Кыен чакта мин соң үзем синең
Таянычың булыр кешеме?

Гомер юлын бергә кичкән чакта
Әрнемәсме синең йөрәгең?
Мин бит сиңа сөюем белән бергә
Җил-давыллар алып киләмен.

## Сагышланма, акыллым

Зәңгәр күлдән күтәрелә аккошлар,
Юл тотарлар, белмим, кайсы якларга.
Сагыш били, моңнар били күңелне
Пар аккошлар очып узган чакларда.

Ямансулап кала күлдә камышлар
Сердәшләрен озатканда еракка.
Таныш түгел димә сагыш-моңнары
Туган җирдән читтә йөргән ир-атка.

Зәңгәр күлдән күтәрелә аккошлар,
Күзәтәмсең син аларны, акыллым.
Тик син алай сагышланма... Яныңа
Шул аккошлар белән бергә кайтырмын.

## Флера Гыйззәтуллина

### Ничек онытыйм?

Үгет бирү ансат кешеләргә:
«Онытып тор, диләр, тынычлан!..»
Тау-тау булып минем төшкә керә
Кешеләргә булган бурычлар.

Төшкә керә күрше Сәлихәттәй,
Икмәк бүлеп алты кисәккә,
Иң зурысын сайлап миңа бирә,—
Ул кисәкләр бар да исәптә...

...Сәлихәттәйләрме? —
Алар сөргән
Туган кырым буразналарын,
Истә, истә баштан кичкәннәрем,
Күз йомып та күрәм мин барын:

Күрәм авылымның аръякларын,
Югары очын,
әле бу очын...
Миңа колач ачкан бу очларга,
Юк, бетәсе түгел бурычым.

Юк, юк, ничек онытыйм очтан-очка
Тоташ килгән шушы тормышны?
Тынгы белмәс моңлы күкрәгемдә
Җир сулышы, илем сулышы.

●

Коя гына яңгыр,
коя гына...
Үтмәс өчен килгән болытмы?
Яңгырларда киттем,
күз ачкысыз
Бураннарга килеп юлыктым.

Көртләр ярам,
ташкыннарны кичәм,
Карлар белән сулар бутала.
Тукта, яңгыр, тукта!
Тукта, буран!
Мөмкин түгел миңа туктарга!

## Унҗиде яшь сиңа

Унҗиде яшь сиңа —
Аңларлык, белерлек,
Билкәең бөгелә тал кебек.
Мин синең күзләрең аркылы
бу көнгә
Багландым унҗиде ел элек.

Унҗиде яшь сиңа!
Бу тормыш каршында
Һәр көнне өр-яңа юл башы.
Мин тыныч бүгенгә,
Унҗиде елдан да,
«Ялгыштык!» — диярлек булмасын!

Гел сине җитәкләп
Киләчәк бәхеткә,—
Уздырдым унҗиде елымны.
Билкәең тал кебек,—
Чыктың син биләүдән,
Иректә сайла үз юлыңны.

## Шахтер атлар

Ил өстендә канлы сугыш бара,
Ир-егетләр яуда егылып кала.
Җиде катлы кара җир астында,
Биниһая караңгыга карап,
Вагон тартып шахтер атлар бара.

Атларны соң кемнәр куа әйдәп?
Алларына печән кемнәр сала?
Иңрәеп, ир-ат эшләр эшне
Үз иңенә салды бит кыз бала...

Кизәнә дә,
сыптыра да идем,
Булды атым, вагоннарым белән
Ауган,
тәгәрәгән чакларым да.

...Кул кисәге кадәр кара икмәк!..
Күзгә карап мөлдериләр атлар,
Үзем капсам — калмый атларыма.

Мин ишеткән идем, кешеләр дип,
Баштанаяк корымнарга батып,
Җитмеш гасыр катламнарын ачып,
Кристаллардай саф бәхетләр таба...

Эзләдем ил өчен бәхет мин дә,
Йөзләремә кунды күмер оны.
Кулларымда — күмер дымы булды,
Җир өстендә канлы сугыш бара!!!

Кулларымда кирәк,
авыр кәйлә,
Кул кисәге кадәр кара икмәк!..
Җанга куәт биреп шул икмәкнең
Исе аңкый бөтен шахтабызда.
Юк, мин андый тәмне, ул хуш исне
Татымаган, иснәмәгән идем
Җир өстендә, кояш яктысында.

Мин ишеттем тагын кешеләрдән:
«Икмәк кадерен белсәң — җирең таныр,
Ил кадерен белсәң — илең таныр!..»
Ил язмышы — газиз җир язмышы! —
Йөкләр авыр, үтәр юллар авыр,
Ат җаннары сабыр, ай-һай, сабыр!

Мин дә сабыр идем,
сабыр иттем:
Йөзләремә кунган күмер оны,
Кулларымда кара күмер дымы,
Икмәк төреп йөрткән ипле киндер...
Малкаемның күзе мөлдер-мөлдер...

◇◇◇◇◇◇◇◇◇

**Ариф Сәфәрев**

# ДЗЕРЖИНСКИЙ ОРДЕРЫ

ХИКӘЯ

*Язучы Ариф Сәфәревкә 60 яшь тулды.*

*Ул рус телендә чыккан дистәләгән китап авторы. А. Сәфәрев озак еллар «Крестьянская правда», «Ленинградская правда» газеталарында эшли. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән башлап Ленинград оборонасында катнаша, фронт газетасында редактор була. Сугыштагы батырлыклары һәм хезмәте өчен хөкүмәтебез аны Кызыл Йолдыз ордены, ике тапкыр Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкли. Язучының бөтен гомере диярлек Ленинград белән бәйле, шуңа күрә әсәрләренең күбесе Ленин шәһәренә, аның кешеләренә багышланган.*

*Ариф ага Сәфәревне зур юбилее белән котлыйбыз, аңа сәламәтлек һәм иҗат уңышлары телибез.*

*Укучыларыбызга язучының чекистлар турында язган яңа китабыннан бер хикәя тәкъдим итәбез.*

Атналар буе туктаусыз яуган көзге яңгырлар бетеп, ниһаять, декабрь салкыннары килде. Киң Нева елгасында да боз катты, бөтен җирне кар көртләре каплап китте. Петроградның болай да авыр тормышына тагын суык килеп өстәлде.

Феликс Эдмундовичның да эш кабинеты салкын. Биек, якты тәрәзәләрдән тыштагы карлы агачлар күренеп тора, әнә Александр бакчасының бозланып каткан рәшәткәсе буенда флоттагыча кыска тун һәм бескозырка кигән сакчы йөренә, Гороховый урамыннан чаналар шыгырдап узганы ишетелә, болар барысы бизәкле түшәменнән зур люстра асылынып торган иркен кабинет эчен тагы да салкынрак, тагы да шыксызрак итә кебек.

Дзержинский шинельдән утыра, мех бүреген маңгаена басып кигән. Бармаклар салкында сыкрап-сыкрап туңа, язып булмый. «Триумф» дигән керосин миче дә (Феликс Эдмундович өчен дип, аны интендантлардан табып алганнар иде) аякларны җылытудан бигрәк, корым гына пыскытып утыра. Мичнең ялкынын әз генә калдырып, филтәсен кыса төшәргә туры килде.

Феликс Эдмундович коллегия членнарына әйткәнчә, Гадәттән тыш комиссиянең яңа оешкан чагындагы беренче көннәре мәшәкатьле оештыру эшләре белән узды диярлек. Асылда, комитетның бинасыннан башка берни дә юк иде әле. Бирегә, Смольныйдан алган язуларын тотып, көн саен яңа хезмәткәрләр килеп тора. Аларның һәркайсы белән Дзержинский үзе сөйләшергә тырыша, тик ул югында гына андый әңгәмәләрне, комиссия председателенә охшарга тырышып, Ксенофонтов яисә Петерс уздыра иде.

Эшкә яңа килүчеләрдән, бигрәк тә подполье елларында да, давыллы Октябрь көннәрендә дә үзенә очрамаган кешеләрдән Дзержинский:

— Париж Коммунасының ни сәбәптән һәлак булганлыгын онытмагансыздыр? — дип сорый һәм, әлеге кешенең җавап биргәнен дә көтмәстән, ышандыргыч итеп әйтеп бирә: — Контрреволюция куркынычын коммунарлар бик соң аңлыйлар. Әгәр без, алар хатасын кабатласак, ахмак кешеләр булырбыз...— ди.

Гороховый урамы ягындагы авыр имән ишеккә фанер тактага язылган игълан кадаклап куелган. Феликс Эдмундович чатлы-чотлы хәрефләр белән: «Контрреволюциягә һәм саботажга каршы көрәш буенча Халык Комиссарлары Советы янындагы Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссиясе. Килүчеләр сәгать 12 дән 5 кә кадәр кабул ителә»,— дип, игъланны үзе язды.

Ул, соңгы җөмләгә бик зур мәгънә биргән кебек, калын итеп игъланның астына сызды, цифрларын еракта ук күренерлек эре итеп куйды.

Ләкин бу игълан ишектә нибары бер генә көн торды. Икенче төнне, җайлы вакытын туры китереп, кемнәрдер аны кара буяу белән буяп киткәннәр иде.

Комендант бу күңелсез хәлне Дзержинскийга килеп әйтте. Сакчы учак янына җылынырга киткән булган, ялгыш иткән, теге-бу дип сөйләнде, үзен ачулануларын, тиргәп ташлауларын көтте. Гаҗәпкә каршы, комиссия председателе аңа бөтенләй ачуланмады, киресенчә, сөенде шикелле әле.

— Я, нәрсә диярсез моңа, Яков Христофорович? — диде Дзержинский, Петерска таба җәһәт кенә борылып.— Тәэсиренә каршы бик тиз җавап бирделәр бит, ә? Юк, төнлә дегет белән эш итеп йөрүчеләр җүләр түгел алар! Гадәттән тыш комиссиянең нинди көче булачагын бик яхшы аңлыйлар, хәзер үк шуннан куркып торалар. Әлегә безнең атаклы криминалистларыбыз юк, әлбәттә; аның каравы, хезмәт иясе безне яклый. Монысы инде алар өчен бетү дигән сүз, алар аны бик яхшы сизәләр... Ә сез кичә ничек дежур иттегез?

— Әйбәт. Кичке сәгать тугызынчыда кешеләрне кабул итеп бетердем.

— Килүчеләр күп булдымы?

— Уникеләп кеше. Журналдан карап тикшерергә була.

— Ярый, эшне башлаганда начар түгел бу. Тик килүче кешеләр күбрәк булырга тиеш. Югыйсә, без банкротка чыгарбыз...

Дзержинскийның кушуы буенча Петроградтагы барлык газета редакцияләренә Гадәттән тыш комиссиянең адресын һәм кабул итү сәгатьләрен әйтеп кәгазь җибәрделәр. «Биржа хәбәрләре», кадетларның «Рече» һәм башка буржуаз газеталар бу игъланны басмадылар, анлык урын тапмадылар, күрәсең; ә «ЦИК хәбәрләре» бу игъланны беренче биткә бастырып чыгарган иде.

Феликс Эдмундович, беренче чиратта, кешеләрнең Гадәттән тыш комиссиягә үзләре теләп ярдәм итәчәкләренә исәп тотып ялгышмады. Көн саен Гороховый урамына килә торган сигналлар шактый җитди, алар буенча ашыгыч чаралар күрергә кирәк иде.

Комитетка килүчеләр бигрәк тә спекулянт һәм алып-сатарларның оятсыз махинацияләре, Петроград учреждениеләрендә саботаж оештыручылар, урамда кеше үтерү һәм кеше талауларның ешаеп китүе турында нәфрәтләнеп сөйлиләр иде.

Луга өязеннән Гороховыйга берьюлы ике кеше килде: берсе — волость Советы председателе — өстенә озын итәкле кавалерия шинеле кигән тәбәнәк буйлы, оялчан гына бер фронтовик; икенчесе — агач аяклы, гөлдерәп торган калын тавышлы бер инвалид. Кабул итү бүлмәсенә кергәч, сүзне нидән башларга белмичә, байтак вакыт бер-берсенә карашып тордылар, аннары алар ягындагы бер алпавыт утарында Петроградтан качкан Керенскийның яшеренеп ятуын сөйләп бирделәр. Алар үзләре аны күрмәгәннәр, ләкин халык арасында шул хакта сүз йөри икән. Имеш, ул көне буе бикләнеп утыра, иннидер атчабарлар килгәнен көтә, ди, тик төннәрен крестьян киеме киеп кенә чыгып йөри, болай танырлык та түгел, ди.

Дзержинский иртәдән бирле шөгыльләнгән икенче бер җәнҗаллы эш тә хезмәт ияләренең сигналы буенча билгеле булды. Комитетка бер төркем тимер юлчылар килмәгән булса, хәлләрнең ничек булып бетәсен әйтүе кыен булыр иде. Хәрби кирәк-яраклар төягән «Кызыл Хач» эшелоны көньякка, генерал Каледин һәм аның иярченнәренә китеп барган булыр иде.

Әмма бармаклар һаман туңа, кул күшеккән, язу язып булмый — Феликс Эдмундович сулышы белән бармакларын җылытырга тырыша. «Известия» өчен язып торган бу мәкалә «Соңгы тапкыр кисәтү» дип аталачак. Чыннан да, элементар әдәп кагыйдәләрен дә оныткан ул әфәнделәрнең кыланышларына түзеп тору җитте инде. Совет властеның да сабырлыгының чиге барлыгын, үзләренең мәкерле эшләре фаш ителгәнлеген белеп торсыннар.

«Союздаш дәүләтләрнең кайбер офицерлары, хәрби миссия һәм илчелек әгъзалары бик актив рәвештә Россиянең эчке эшләренә тыкшыналар; әлбәттә, алар халык өчен түгел, бәлки революциягә каршы булган империалистик калединчы кадет көчләрен яклап эш итәләр. Без бу әфәнделәрне бер генә тапкыр кисәтмәдек инде. Соңгы тапкыр кисәтергә вакыт җитте, күрәсең»,— дип, Дзержинский мәкаләне тизрәк бетерергә тырышып, ашыга-ашыга язды.

Бу эшне тикшерү озакка бармады. Тимер юлчыларның шиге дөрес икәнлеге расланды.

Революцион Петроградның үзендә көпә-көндез, бөтен кеше күз алдында, контрреволюционер Каледин өчен эшелонга автомобильләр төягәннәр. Заговорчылар, Кызыл Хач дигән зур исем артына яшеренеп, берниндн тартынусыз эш иткәннәр.

Тикшерү нәтиҗәсендә заговорның җеп очы Фурштад урамындагы Америка илчелегенә барып тоташканлыгы да билгеле булды. Эшелонны озату эше белән Америка илчесе Давид Р. Фрэнсис әфәнде, узган җәйдә, большевикларны кырыгыз, иң элек Ленинны юк итегез, дип Керенскийны котырткан шул Давид Р. Фрэнсис үзе шөгыльләнгән икән.

Американың «Кызыл Хач» эшелонына җитәкчелек итүче Андрей Колпашников дигән бер рус полковнигын кулга алырга туры килде. Башта ул гаепсез-гөнаһсыз бер кеше булып кыланды: мин Кызыл Хачтагы Америка миссиясендә хезмәт итәм, миңа эшелонны Яссы шәһәренә озатып куярга куштылар, шуңа күрә ашыгыч рәвештә җибәрергә тырышам, калган эшләргә берниндн катнашым юк, дип сөйләнде. Сүзенең дөреслеген раслау өчен Колпашников Америка илчесенең имзасы куелган документ та чыгарып күрсәтте. Анда: «Бу документны караган һәркемнән полковник Колпашниковка якты йөз белән булышлык күрсәтүен үтенәм», дигән сүзләр язылган иде.

— Минем белүемчә, Яссы шәһәре Румыниядә шикелле? — дип сорады следователь.

— Дөрес. Румыниядә. Безнең эшелон нәкъ шунда барырга тиеш. Дөресен әйткәндә, мин үземне ни өчен кулга алуларын бөтенләй аңламыйм... Минемчә, Кызыл Хачның кешелекле максатлары...

— Аз гына сабыр итегез, хәзер аңларсыз,— диде следователь тыныч кына.— Шулай итеп, сез Яссы шәһәренә, ягъни Румыния җиренә китәргә тиешбез дисез инде? Алайса, сезнең башлыгыгыз Андерсон әфәнденең боерыгын ничек аңларга соң?

— Нинди боерык? — диде калтыранган тавыш белән Колпашников, үзенең тотылганлыгын сизеп.

— Сезнең исемгә телеграф белән җибәрелгән боерык, полковник әфәнде,— диде следователь, авыз кырые белән генә көлеп һәм күзлеген киеп Андерсон телеграммасын укып күрсәтте: — «Беренче поезд белән җибәрү өчен, җыелган һәм җыелмаган автомобильләрнең барысын да алу чарасын күрегез. Аларны Ростовка чаклы үзегез озатырга тырышыгыз...»

Тикшерү эше шуның белән бетте диярлек. Колпашников Яссы шәһәренең эз яздыру өчен генә уйлап чыгарылганлыгын, ә аңа «талбот» һәм «форд» маркалы җитмеш автомобильне һәм американнарның башка техник җиһазларын Дондагы фетнә башлыгы генерал Калединга илтеп тапшырырга кушылганын икърар итәргә мәҗбүр булды.

— Полковник Андерсоннан башка сезгә тагын кемнәр боерык бирде?

— Мин аларның исемен әйтүне кирәк тапмас идем...

— Ихтыярыгыз, Колпашников әфәнде,— диде следователь.— Гадәттән тыш комиссиягә ул кешеләрнең исемнәре билгеле. Без аларны үзебез генә белеп калмабыз, бөтен дөньяга фаш итәргә тырышырбыз...

Феликс Эдмундович иртәдән бирле язып утырган мәкаләсендә әнә шул максатны: дипломат паспорты белән йөрүче интриганнарның һәркайсын исеме белән атап әйтү, аларны хурлык баганасына терәүне күздә тота иде. Яшь Совет республикасы заговор корырга яратучыларның һәрбер мәкерле эшен күздән ычкындырмавын алар белеп торсыннар.

«Хәзер ул серле поезд беркая да китмәячәк. Совет власте аны Петроградта тотып калды. Америка (һәм башка ил) империалистларының калединчылар белән бергәләп корган заговорлары фаш ителде»,— дип язды Дзержинский мәкаләнең ахырында.

Аның эше бетүен көткән кебек, шул минутта ук кабинетка секретарь Иван Ильич Ильин килеп керде.

— Телефонда Наркомпрод урынбасары. Бүген өченче тапкыр шалтырата инде,— диде ул.

Дзержинский өстәл артыннан кузгалып, беркадәр читтәрәк торган телефон өстәле янына килде. Ни турында сөйләшәселәре аңа алдан ук билгеле иде инде, чиновникларның үчлек белән оештырган саботажларыннан Наркомпрод кына түгел, башка комиссариатлар да зыян күрәләр иде.

Саботаж Совет властена каршы көрәшү коралына әверелде.

Чиновниклар эшкә килеп үз өстәлләре артына утыралар да көне буе юри берни эшләмиләр: безнең кебек тәҗрибәле белгечләрдән башка комиссар әфәнделәр ни эш кыра алырлар икән?! — дип, эчләреннән сөенеп утыралар. Тагы да гадирәк икенче бер ысул да бар: эшкә бөтенләй килмичә, эшләрен һәм хәтта сейф ачкычларын тапшырудан баш тартып, өйләрендә генә яталар.

Ноябрь урталарында банк хезмәткәрләренең бик яхшылап хәзерләнгән забастовкасы башланды. Банк һәм саклык кассаларының ишекләренә стачка комитетының усал сүзләр язган плакатларын элделәр, ә чиновниклар иртәдән алып кичкә кадәр, митинглар җыеп, Смольный билгеләгән комиссарлар исеменә үткен-үткен сүзләр әйтеп тел-теш тидерергә маташтылар: дәүләт белән пешекче балалары идарә итәчәк диделәр, янәсе; менә хәзер идарә итегез инде, без сезгә булышмаячакбыз, имеш...

Ул чакта Феликс Эдмундовичка, Ленин кушуы буенча, банк хезмәткәрләре саботажы белән шөгыльләнергә туры килде. Хәрби-революцион комитет тарафыннан җибәрелгән ревизорлар бик кызыклы хәлләрне ачтылар. Стачка комитеты составына төрле-төрле халык — меньшевиклардан алып элекке патша министрларына чаклы кергән икән. «Саботаж фонды» өчен кирәкле акчаны гадел юл белән тапмаганлыклары да мәгълүм булды.

Стачка комитеты члены, меньшевикларның күренекле бер эшлеклесе Харитонов белән Дзержинский арасында кызыклы гына сөйләшү булды:

— Без сезне хәрби-революцион трибунал хөкеменә тартырга тиеш булабыз. Әгәр бу җинаятьчел саботаж тукталмаса, сезне хәзер үк хөкем итәчәкбез...— диде аңа Дзержинский.

Харитонов, әлбәттә, шундук ярсып китте. Чал кәҗә сакалын селкә-селкә, законсыз рәвештә властьны үз кулларына алган большевикларның башбаштаклыгы, гражданнарның забастовка ясарга хокуклары барлыгы турында, Смольный ул изге хокукны тупас көч белән бастырырга тели, фәлән-төгән дип чәчрәп сөйләргә кереште. Мин патша төрмәсендә дә бик күп утырдым, трибуналдан курыкмыйм, үземнең политик карашларым өчен яңадан газап күрергә әзермен, бу хакта курыкмыйча, туп-туры әйтәм...— дип сөйли бирде.

— Туктагыз әле, туктагыз, Александр Александрович! — дип, Дзержинский аны ялкынлы сүзеннән бүлдерде.— Сез, хөрмәтле әфәндем, нәрсәдер бутыйсыз. Бирегә политик карашларның ни катнашы бар? Без сезне караклык өчен гаепләп хөкемгә тартырга уйлыйбыз...

Харитоновның озынча йөзе тагы да озыная төште.

— Әйе, әйе, бер дә гаҗәпләнмәгез... Без сезне бөтен халык алдында халык байлыгын урлаган өчен хөкем итәчәкбез. Патша сановниклары белән уртак тел тапкан бөтен стачка комитетыгызны хөкемгә тартачакбыз. Нинди гөнаһларыгыз барлыгын тәгаен белергә телисезме?

Дзержинский өстәле өстендә акт кәгазе ята. Ул актта дәүләттән кайчан күпме акча урланганлыгы аерым-аерым күрсәтеп санап чыгылган иде. Стачка комитеты дүрт йөз унбиш мең сум акчаны ялган документлар ярдәмендә коммерческий банк активыннан алган, йөз егерме мең сумны саклык кассалары идарәсеннән урлаганнар, чит ил валюталары — доллар, фунт-стерлинг, франклар белән байтак акча алганнар. Рус-Азия банкы кладовойларындагы капчык-капчык вак акчаларны алудан да тартынмаганнар.

— Башка чара булмаганлыктан эшләнде ул,— диде Харитонов уңайсызланып.— Демократияне яклау максаты белән тартып алдык...

— Кемнән тартып алдыгыз? Халыктан, хезмәт ияләреннәнме? Әйтегез әле, кем файдасына? Ни өчен алай чиновник әфәнделәр дәүләт исәбенә саботаж ясап йөрергә тиешләр? Бөтен уңайлы шартларны тудырып, жалованиесенә кадәр алып...

Наркомпродтагы саботаж да бик хәтәр иде. Менә бишенче атна инде чиновниклар эшкә килмиләр. Өйләренә курьер җибәргәч, ишек-

ләрен ачмыйлар, үз күз алдында мыскыл итәләр, гомумән, бөтенесенә дә үзләре хуҗа кебек, теләсә ни кыланалар. Эш хәтта шуңа барып җитте: алардан сейф ачкычларын алып булмый, ә сейфларда тимер юл белән икмәк ташу схемасы, статистик мәгълүматлар һәм башка документлар саклана. Комиссариат ансыз — ике кулсыз...

Наркомпрод урынбасары, дулкынлана-дулкынлана, телефон трубкасына:

— Гадәттән тыш комиссиягә зур хокуклар бирелгән, иптәш Дзержинский,— дип кычкырып сөйли башлады.— Сездән бик каты репрессив чаралар күрүегезне сорыйбыз. Сез хәлне беләсез, Петроградны азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе бик кыен хәлдә, шуның өстенә, әлеге бу үчлекле адәмнәр...

— Нинди чаралар күрергә кирәк дип саныйсыз соң?

— Иң актив саботажчыларны кулга алып, революцион законның бөтен катылыгы белән хөкем итәргә кирәк...

— Актив саботажчылар күпме алар сездә?

Наркомпрод урынбасары комиссариатта төзелгән исемлек буенча актив саботажчыларны атап әйтә башлады. Барлык бүлек һәм бүлекчә башлыклары саботажны оештыручылар булып чыкты. Боларга тагын тугыз кешедән торган стачка комитеты идарәсе дә өстәлә иде.

— Димәк, сез үзегезнең утыз чиновнигыгызны кулга алдырырга телисез? — диде Дзержинский, ачуы килеп.— Гадәттән тыш комиссиянең хокукларын һәм бурычларын сез гаҗәп сәер аңлыйсыз! Без кешеләрне, патша охранкасы шикелле, тикшерми-нитми кулга алырга тиеш булабызмыни?!

— Дошман кешеләр бит алар, иптәш Дзержинский! Үзләре интеллигент кешеләр, үзләре бернинди закон белән исәпләшмиләр, базар хатыннары шикелле кыланалар!

— Кулга алып булмый! — диде Феликс Эдмундович өзеп.— Икенчерәк төрле эшләп карыйк. Аларның комитетта башлап йөрүчеләре кем?

Наркомпрод урынбасары белән телефоннан сөйләшү Иван Ильич Ильин өчен гадәттә булмый торган үзенә бер төрлерәк йомыш белән тәмамланды. Феликс Эдмундович, үз янына секретарьны да чакырып тормыйча, алдан ук ордер хәзерләп куйды.

Гадәттән тыш комиссиянең әле махсус эшләнгән ордер бланклары юк, типографиядә бастырып алырга өлгермәгәннәр иде. Үзләренең түгәрәк печатьлары да юк, аның урынына Смольныйдан вакытлыча Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты печатен алып торганнар иде.

Дзержинский чиста ак кәгазьнең дүрттән бер кисәген ертып алды да ихтыярсыздан уйлана калды. Киләчәктә революция тарихын язучылар, шушы кәгазь кисәгенә язылачак документ кулларына килеп кергәч, бик гаҗәпләнерләр әле. Аптырарлар, моның хикмәтенә төшенергә тырышырлар, ахырда күбесе аңларлар. Кайчагында кечкенә генә бер билгедән чыгып та хәлне тулаем күз алдына китереп була бит.

Хәер, Дзержинскийның вакыты бик тыгыз иде, ул сәгать унбергә Смольныйга барырга тиеш, тизрәк ашыгырга кирәк иде.

«Контрреволюциягә һәм саботажга каршы көрәшү буенча Халык Комиссарлары Советы янындагы Бөтенроссия Гадәттән тыш комиссиясе. Ив. Ильич Ильинга шундый эш тапшырыла...» — дип ашыга-ашыга язды Дзержинский.

Ордерга кул куеп, печать басканнан соң, Феликс Эдмундович Ильинны чакырды.

Озак аңлатып торасы булмады. Биш минуттан соң инде Ильин, Гадәттән тыш комиссия председателе тапшырган эшне үтәү өчен, подъезд янында дежурда торган «мерседес-бенц» машинасына чыгып утырды.

Шофер Гороховый урамыннан уңга борылып, Нева проспектына чыкты, аннары, вокзал мәйданына җитәрәк, тагын уңга борылды да Стремянный урамы чатында машинаны әкрен генә китереп туктатты.

Күптән түгел генә әле статский советник һәм министрлыкта канцелярия идарәчесе булган, хәзер исә Наркомпродның фураж бүлекчәсендә мөдир хезмәтендә эшләгән Николай Николаевич Вяткинның бу хакта бернинди хәбәре юк иде.

Ул Дзержинский язып биргән ордерны да, аларның икенче каттагы квартирына күн куртка, күн фуражка кигән, биленә киң каеш буган кырыс кыяфәтле бер ир һәм, аның артыннан, әлеге ирнең бил каешына таккан агач саплы маузерга шикләнеп карый-карый, дворник Кузьма менеп килгәнен дә белми иде.

Николай Николаевичларның квартиры Дзержинский кабинеты шикелле салкын түгел,— җылы, рәхәт. Йокы бүлмәсендә, тәрәзәләрне калын пәрдәләр белән каплап, караватта хуҗаның чибәр генә хатыны баш өянәге белән авырып ята. Асраулары Ксюша, карават янында идәнгә тезләнеп, хуҗа хатынның маңгаена салкын суга чылаткан сөлге яба. Балалар бүлмәсеннән, тавышлану катгый тыелган булса да, ниндидер күңелле шаулашу ишетелә. Николай Николаевич үзе исә бер ялгызы кабинетында иртән килгән хатны укып утыра иде.

Хат Мәскәүдән килде. Дөресрәге, ул хат түгел,— Мәскәүдә азыктөлек хезмәткәрләренең съезды булды, Николай Николаевич, кызганычка каршы, ул съездга катнаша алмады,— хат белән җибәрелгән әйбер әнә шул съездның машинкада басылган резолюциясе иде.

Мәскәүлеләр съезды Наркомпрод хезмәткәрләренең саботажын бик яклаган. Большевиклар съезд делегатларын үз йогынтыларына буйсындыра алмаганнар, күрәсең. Резолюция бернинди килешүгә юл куймый торган усал сүзләр белән язылган иде.

Забастовка башланган чакта ук Николай Николаевичны бертавыштан стачка комитетының председателе итеп сайладылар. Хәзер ул Мәскәү съезды резолюциясен укып, җыелышта барлык хезмәткәрләрне шушы зур документ белән әйбәтләп таныштырырга кирәклеге турында уйланып утыра иде.

Алгы бүлмәдә каты итеп чылтыраган кыңгырау тавышы Николай Николаевичның уйларын бүлдерде. Танышларыннан берәү дә болай каты чылтыратмый иде шикелле. Тагын эш урыныннан курьер җибәргәннәрдер. Бу комиссар әфәнделәр әле һаман да нәрсәгәдер өмет итәләр, стачка комитетының нияте бик җитди икәнлегенә һаман да ышанмыйлар.

— Ксюша, чыгып әйтегез әле: өйдә берсе дә юк. Урамда йөрергә чыгып киттеләр, кайчан кайтасылары билгесез, дип әйтегез,— диде Николай Николаевич, йокы бүлмәсенең ишеген ачып.

— Борчып йөрмәсеннәр, дип әйтегез! — диде хуҗаның хатыны, ачуы килеп.— Ишекне ача күрмә. Ходаем, кайчан котылырбыз бу тамашалардан!

Асрау кыз тышкы ишек төбенә барып, тиз генә әйләнеп тә килде. Аның куркуы тавышына ук чыккан, ә алгы бүлмәдә һаман кыңгырау чылтырый иде.

— Курьер түгел ул... Берсүзсез ачарга кушалар, яннарында дворник Кузьма да бар...

Николай Николаевич алгы бүлмәгә чыгып җитмәс борын ук моның Наркомпрод курьеры түгеллеген сизенде. Ишекнең чылбырын ычкындырмыйча, аз гына ачты.

— Ни кирәк сезгә?

Комиссар курткасы кигән кеше усал тавыш белән:

— Хәзер үк ачыгыз! — диде дә кесәсеннән ниндидер кәгазь кисәге чыгарды.— Мена иптәш Дзержинский ордеры. Контрреволюциягә каршы көрәшү буенча Гадәттән тыш комиссиядән килдем мин...

Калган хәлләр төштә күргән кебек кенә булды.

Дөресен әйткәндә, Николай Николаевич ордерны рәтләп укый да алмады. Дзержинскийның имзасын, түгәрәк казна печатен һәм үзенең исем-фамилиясе белән адресын күрде дә өнсез калды. Мондый башбаштаклыкка каршы үзенең чарасыз бер кеше булуы турында сөйләнә башлады. Аның бу халәте гадәттәге тотышына бер дә охшамаган иде, ничектер бик килешсез чыкты.

— Гражданин Вяткин, җыеныгыз! — дип боерды күн курткалы кеше.— Көтеп торырга вакытыбыз юк! Сезнең мыгырдаганны да ишетергә теләмибез!

И алла, бу хәтле дә тиз үзгәрсә үзгәрә икән дөнья! Әле генә кешенең тыныч, рәхәт йорты, көйле тормышы бар иде, болар барысы кинәт юкка чыкты, адәм аңламаслык бер хәлгә әйләнде. Хатыны, башы авыртуын шундук онытып, алгы бүлмәгә йөгереп чыкты, ахвах итә, чәт-чәт килеп тузгына башлады. Әниләреннән күреп балалар да шыңшый, асрау кыз шашкан кебек әрле-бирле йөгереп йөри, барысы ах-вах итә, ыгы-зыгы килә, ә Николай Николаевичка кайбер әйберләрен җыеп бирергә, беркадәр азык та алырга кирәк, чөнки төрмәгә аны кунак итәргә чакырмыйлар иде.

— Тукта, зинһар. Җыенырга дигәннәрен ишеттең бит...— диде Николай Николаевич хатынына.

Күн тужуркалы кеше нәрсәдер әйтмәкче иде дә әйтми калды. Эчкә кермичә, дворник Кузьма белән алгы бүлмәдә тегеләрнең елаша-елаша Николай Николаевичны юлга әзерләүләрен көтеп торды. Аның йөзе таш кебек салкын, кырыс иде.

Баскычтан төшеп, урамга чыккач, Николай Николаевич өйләре катында зур кара автомобиль күрде. Машина янына кешеләр җыелган иде.

Николай Николаевич, үзен зур батырлык эшләгәндәй хис итеп, машина янына җыелучы кешеләр ишетсен дип:

— Менә рус демократиясе нинди хәлгә төште! — диде.

Кешеләр тып-тын гына читкә тайпылыштылар. Күн тужуркалы кеше дә берни әйтмичә, ишекне ачып, Николай Николаевичны машинага кертте, һәм кара «мерседес-бенц» әкрен генә кузгалып китте.

Юл әллә ни ерак булмады. Машина, Николай Николаевич уйлаганча, Литейный күперенә таба да, «Кресты»га да китмәде, ә туптуры Нева проспекты буйлап җилдерде. Әһә, Николай Николаевичны башта Гороховый урамына комитетка допроска алып баралар икән, аннары төрмәгә җибәрерләр. Ләкин Фонтанканы узганнан соң машина кинәт сулга борылды да Наркомпрод урнашкан Аничков сарае янына килеп туктады.

— Хәзер эшләрегезне тапшырасыз,— диде күн курткалы кеше кырыс бер төс белән. Бераз сүзсез торгач: — Минем алда тапшырасыз...— дип өстәде.

Комиссариатта эш-тормыш дәвам итә иде. Дөрес, забастовкадан баш тартып, эшкә чыгучылар бик аз иде, стачка комитеты аларны

штрейкбрехерлар дип атады. Әнә шундый кешеләрнең берсенә — актив коммунистка — Николай Николаевич үзенең эшләрен тапшыра башлады. Бу эш сәгать ярымга сузылды. Күн тужуркалы кеше берничә тапкыр аларның икесен генә калдырып чыгып йөреп тә керде. Тапшыру-кабул итеп алу актына кул куелгач һәм инде допроска яки туп-туры төрмәгә генә китәсе калгач, күн курткалы кеше Николай Николаевичка аңлашылмастай сүз сөйли башлады:

— Гражданин Вяткин, стачка комитетының башлыгы итеп сез сайланган идегезме? — дип сорады ул.

— Беләсезме... Бездә... ни бит... коллегиаль система кабул ителгән...— диде Николай Николаевич.

— Председатель кем соң?

— Председатель — мин.

— Алайса, сезгә Гадәттән тыш комиссиянең карарын белгертәм,— диде күн курткалы кеше.— Моннан ары без бигрәк тә Наркомпродта бернинди саботажга юл куймаячакбыз. Дусларыгызга әйтегез: әгәр алар иртәгә үк эшкә чыкмасалар, хезмәтләреннән азат ителәчәкләр. Телефоннан шалтыратып әйтегез, я булмаса, извозчик яллап, өйләрен йөреп чыгыгыз... Анысы безнең өчен барыбер, теләсәгез ничек итегез... Эштән чыгарылганда бөтенләйгә чыгарылачаклар, яңадан дәүләт эшенә керү хокукы бирелмәячәк, исемнәре матбугатта игълан ителәчәк. Барысы да аңлашылдымы, гражданин Вяткин?

Гражданин Вяткин куркуыннанмы, әллә мондый сүзнең капыл булуыннанмы, зиһене таралып, җавап бирә алмады.

— Аңлашылса, уңыш телим,— диде күн тужуркалы кеше һәм Николай Николаевичның эчке киеме һәм азык салган саквояжына күз төшереп алды.— Үземнән шунысын да өстәп әйтим: бу — бик җитди карар, сезгә тагын кабат барып йөрергә теләмәс идем мин...

Шуннан соң Дзержинскийның йомышчысы саубуллашып чыгып китте, ә Николай Николаевич, тирән уйларга чумып, әкрен генә Стремянный урамына, үз өенә таба атлады.

Аның өчен уйланырлык нәрсәләр бар иде шул.

Х. ЯХИН тәрҗемәсе.

Шамил Мотыйгуллин

# ЯШЬТӘШЛӘР



Автобуска минем белән Мөнир Фәсхетдинов иптәшләренә сәлам бирде дә тирә-ягына каранып алды һәм урта урыннарның берсенә кереп чумган Барый янына килеп утырды. Сүзсез генә кул кысыштылар.

Машина эче бөркү иде — автобустагылар изүләрен ачып, баш киемнәрен салып җилләнеп утыралар. Мөнир, әле генә күргәндәй, Барыйның шактый гына чаларган чәчләренә карап торды да:

— Әллә инде син, яшьтәш, чынлап олыгаерга исәпләдең? — дип куйды.— Нәкъ карт бүре төсе кереп бара чәчеңә.

— Мин күргәннәрне күр әле, үзеңнеке дә агарыр,— дигән булды Барый. Шаярып башын кашып алды.

— Нәрсә генә күрдең соң син? Матур кызлар турында хыялланып агарса гына инде...

— Мин фронтта сержант булдым, отделение белән командовать иттем, ә син... ефрейтор гына...

— Аның каравы, хәзер син минем кул астында эшлисең...

Бу ике яшьтәш бергә туры килсә, бала-чага кебек гел бер-берсен «чеметкәләргә» керешәләр. Алар хәтта ерак үткәннәргә кайтып гамьсез мәктәп елларын, бергә укыган чакларын исләренә төшереп, сохари тутырган биштәрле капчык асып армиягә киткән көннәрен хәтерләренә алып та үртәшәләр.

— Җәмәгать! Мөнир солдатка киткәндә җиде пар чабата алган иде,— дип көлдерә автобустагыларны Барый.— Ә үзе, җитмәсә, офицер булырга училищега бара!

— Ә Барыйны ни өчен училищега алмадылар дип беләсез? Үзе күтәргән сохари капчыгыннан да тәбәнәгрәк иде. «Үскәч килерсең», дип җибәрделәр.

Барый игътибарны үзеннән читләштерү өчен «һөҗүмне» яңа юнәлештән башлады. Мөнир Фәсхетдинов РСФСР Верховный Советы депутаты. Ул шуңа ишарәләп:

— Карагыз әле, җәмәгать, Мөнир бүген дә депутат значогын тагып килмәгән! — дип гаҗәпләнгән булды. Шуны гына көткән сыман, бораулаучылар әле беренче сессиягә дә барырга өлгермәгән Фәсхетдиновка ябырылдылар:

— Чыннан да, иптәшләр, нигә ул значогын үзенең сайлаучыларыннан яшерә?

— Безне санга сукмый башлавымы Мөнирнең?

— Син халык өчен депутат булсаң да, безнең өчен бит гади бораулаучы! — дип, һәркем үзенчә «үпкә» белдерергә тотынды.

— Әйе. Ленин ордены алгач та буровойга тагып килмәде!

— Юарга кирәк аның значогын, җәмәгать!

Уен-көлкеләр, шаярып сөйләшүләр мастер үзе кергәнчегә кадәр генә барды. Ефрим Долгов автобусның ишегеннән башын тыгып кына исәнләште, кешеләрен барлап чыкты да күңелсезләнеп эчкә узды. Бүген аның тагын бер эшчесе килмәгән иде. Бораулаучы ярдәмчесе Габделбәр Саттаров кичә үзе әйтеп китте. Минә көтмәгез, диде, моннан соң мин буровойныкы түгел, үземә җайлы эш таптым инде, диде.

Аннан алда гына Владимир Потапов бригада белән исәп-хисапны өзде. Эчкән өчен Рим Подрядчиковны кудылар. Кешеләр кими, кешеләр китә, кешеләр тормый... Килеп берничә ай гына эшләп чыккан бораулаучылар да байтак. Бригадада аларның хәзер исемнәрен дә хәтерләмиләр инде.

Автобус Лениногорскидан Азнакай ягына — Көнчыгыш Ромашкино нефть мәйданына юнәлде.

Иртә кояшлы, җылы, матур. Тәрәзәсеннән төрле пейзажлар күрсәтергә теләгәндәй, машина әле ямь-яшел басу яннарыннан, әле купшы куаклы елга буйларыннан узды, әле куе урман эчләреннән, тау араларыннан үтте.

Автобус җилле барды, ләкин эшкә кеше чыкмаудан туган күңелсезлек аңа карап кына басылмады, киресенчә, өкренләп бораулаучыларның йөзләренә, кәефләренә күчте.

— Кайчанга кадәр дәвам итәр бу кеше җитмәү? — дип, үзалдына әйтеп куйды Барый, башын түбән иеп уйланып бара торгач.

Барый җавап эзләми иде. Бу хакта инде сүзләр күп булды. Бригада җыелышы булмасын, конторапыкы яки идарәнеке булмасын, иң күп шау-шу кадрлар мәсьәләсе буенча чыга иде. Әле үткән атнада гына идарәнең профсоюз җыелышы булып үтте. Көн тәртибендә «Социалистик ярыш йомгаклары» дип язылган булса да, җыелыш тиз арада кадрлар мәсьәләсенә салулап кереп китте һәм шул юлыннан чыга да алмады. Социалистик ярыш мәсьәләсе буровойларда эшче көче җитешмәү кебек мөһим фактлардан читтә кала аламы соң! 1971 елны җиде ай эчендә генә дә Лениногорск идарәсе бораулаучылары 15 мең метрдан артык җир тишәргә бурычлы булып калдылар. Бу нефтьчеләргә девон тирәнлегенә җиткән 16 яңа скважина бирен җиткермәү дигән сүз. Бораулау планы үтәлмәү скважинаның бер метрын 4 сумга кыйммәтләтте һәм идарәгә барлыгы 236 мең сум зыян китерде.

Профсоюзның буровой комитеты члены буларак, бик игътибар белән һәм бик борчылып тыңлап утырды Барый отчетның бу өлешен. Егерме ел эчендә бораулауда мондый хәлнең булганы юк иде бит.

Идарәнең кадрлар бүлеге начальнигы Куприяновтан информация сорадылар. Ул 1971 елның беренче яртысында гына да 136 кешенең үз теләге белән эштән киткәнлеген хәбәр итте. Шуларның утыз өче торак булмау сәбәпле, унсигезе эш шартлары авырлыктан, унҗидесе укырга мөмкинлек юктан, уналтысы хезмәт хакы канәгатьләндермәүдән, егерме җидесе семья шартлары аркасында һәм егерме бише һөнәрен алыштыруны сәбәп итеп гариза биргән. Эштән киткәннәрнең күбесе яшьләр, бораулауга яңа кергән кешеләр икән.

— Кайчанга кадәр барыр бу хәл? — диде тагын Барый, үз-үзенә сорау биргәндәй.— Менә, син депутат кеше, я, әйт, берәр чиге булырмы аның?

Мөнир җайлап кына Барыйга таба борылып утырды.

— Син эшче җитмәү дисең, яшьтәш. Эш монда җитмәүдә түгел. Хикмәт — яшьләрнең эш сөймәүләрендә, минемчә. Аксөяк булып тәрбияләнгәннәр — менә ни өчен килмиләр буровойга, менә ни өчен качалар!

— Бәлки белеп кача торганнардыр? Без генә ул синең белән ике тиле «буровой, буровой» дип көлдән таябыз... Чынлап та, уйлап кара әле: көн димисең, төн димисең, тәүлекнең теләсә кай вакытында карчыгыңның җылы куеныннан торып эшкә чыгып китәсең. Аннан 50—60 чакрым доңгыр-доңгыр килеп машинада вәтылып барасың. Буран дими, кар-яңгыр, салкын-эссе дими ачык һавада җир борасың... Я, әйт, нәрсәсе кызык, нәрсәсе рәхәт?

«Әллә моңысы да зарланырга нияте башладымы?» — дип, Мөнир күтәрелеп яшьтәшенә карап куйды. Ләкин уеның-чынын бергә кушып сөйли торган Барыйның йөзеннән нинди дә булса ачык уй-фикерне тотарлык түгел иде.

Барый шактый кыза тешеп һәм мондый чакта гадәтенчә сүзләрен сүзләре өстенә өтләндырып тиз-тиз дәвам итте:

— Үзең ишеттең бит җыелышта яшьләр нәрсә диделәр: давай безгә укырга мөмкинлек, давай культура, кино, танцы, давай с удобством квартира һәм башкалар. Барысын да бир син аларга, тик үзләреннән генә сорама!.. Менә бит ул хәзерге яшьләр кая сикерә... Ә без синең белән эшләгәндә ничек иде? Без яшь чакта нәрсә, суыгы йомшак идеме, кар-бураны рәхимле идеме, әллә бөтен уңайлыклары белән өчәр-дүртәр бүлмәле квартиралар безне көтеп торалар идеме? Буровойларда икешәр-өчәр смена калып эшләдек, карточка белән ипи ашадык, әмма эшләдек бит, ә? — дип, яшьтәшенең сүзен күтәреп алды Мөнир.— Ничек кенә итеп эшләдек әле — Татарстанда бөтен бер нефть диңгезе ачтык!

Барый зур диңгез булып җәелгән нефть мәйданын күз алдына китерергә тырышты. Ләкин ничек кенә итсә дә, нефть чыккан урыннар диңгез булып килеп басмады. Хәтта ул мәйдан булып та күз алдына килми. Газеталарда гына шулай язалар. Алай диңгез кебек шома гына җәелеп ятмады шул нефть. Аны табу өчен разведчиклар таулар, елгалар кичтеләр, чокырлы-чакырлы юллар уздылар, таралып һәм укмашып утырган эреле-ваклы авылларны үттеләр, урманнар-кырлар аша чыктылар. Һәм шунда, кайдадыр басу уртасында яки урман буенда, кукраеп, биек буровой вышкасы гына утырып тора иде. Моңа кадәр күз күрмәгән, колак ишетмәгән якларга барып, шул билгесез җирләрне бораулап йөрделәр алар. Иңе-буе 100 километрга сузылган Ромашкино нефть ятмасының теләсә кайсы почмагына барсаң да, бу ике яшьтәш — Барый Вәлиев белән Мөнир Фәсхетдинов — басмаган урыннар юктыр. Менә шушылай, бер машинада иңгә-иң терәлеп, егерме биш ел бергә эшкә — буровойга йөрделәр бит алар...

Уйлар ерак үткәннәргә кереп китсә, иң әүвәл үзең бораулаган беренче скважинага барып туктый. Барый өчен аннан да истәлеклесе, аннан да якыны юк сыман. Сугыштан кайтып эшли башлаган буровой...

Ул скважина Шөгер янында, Шушма елгасы буенда гына иде. Буровойдан төннәрен яп-якты булып битум заводының зур тәрәзәләре, Шушма аръягына үсеп барган Шөгер эшчеләр поселогы күренеп тора иде. Егет чак. Күңелләрне җилкендереп күпер өстендә яшьләр гармун уйныйлар, кызлар җырлыйлар һәм күпер такталарын дөбердәтеп биеп китәләр.

Әттәгидер генәме,
Гармунчыгыз өйдәме!
Өйдә булса килсен әле,
Биетеп китсен әле.

Бөтен эшне ташлап шулар янына китәсе, алар белән бергә буласы, җырлыйсы, биисе килә иде.

Ә бит җиде ел армиядә булып, фронтларда йөреп, мылтык-автомат тотып куллар да эшкә сусаган. Юк, буровойдан бер генә минутка да аерылып булмый...

Барый эштән кайтканда, арып, еш кына күпер өстендә туктый, аның култыксасына таянып, елгага, су өстендә уйнаган балыкларга озак кына карап тора иде.

— Хәтерлисеңме, яшьтәш, Шөгердә очрашкан көнне? — дип, кинәт кенә сорап куйды Барый. Әйтерсең Мөнир дә аның белән бергә суга карап Шушма аркылы салынган онә шул озын такта күпер өстендә басып тора иде.

Алты-җиде елдан соң булган бу очрашу икесен дә бик нык шатландырган да, гаҗәпләндергән дә иде. Барый үзенең сабакташын, яшьтәшен бораулаучы киеменнән күреп исе китсә, Мөнир Барыйның таза булып буйга үсүенә аптырады. Армиядә чакта Барый солдатлар арасында иң кечкенәсе, иң чандыры иде. Тезелгәндә иң артка, стройның койрыгына бастыра иде аны командир.

— Билләһи, Шөгердә очрашкач мин сине танымый тордым! Миннән бер башка үсеп киткән идең!

— Солдат шулпасы үстерде,— диде Барый, беренче очрашканда әйткән сүзен кабатлап.

Барый белән Мөнир бер авылныкы булмасалар да, бер мәктәптә укыдылар. Мөэмин-Каратай авылыннан Бәкергә — өч чакрым ераклыктан килеп йөри иде Барый.

Укуы белән дә, усаллыгы белән дә әллә ни аерылып тормады ул. Бәкер малайларыннан куркыпмы, дәрестән соң күпер аша чыкмыйча, ниндидер яшерен сукмаклардан, әрәмә эчләреннән өйләренә турыдан гына сызалар иде Каратай укучылары. Ә менә тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлап һөнәр училищесына керергә комиссиягә килгән Мөнир Барыйны күреп гаҗәпләнде дә калды. Барый да гариза биргән икән! Барый булып Барый, чандыр, тәбәнәк Барый да ФЗУга керергә йөри!

Ул чагында һөнәр училищеларының беренче еллары иде. Үсмер егетләр, романтикага бирелеп, ничек кенә булса да шул училищеларның берсенә эләгергә тырышалар. Гаризалар күп, комсомол райкомы һәм врачлар яшьләрне бик тикшереп, сайлап кына алалар. Ул райком ишек төпләрендә, больница ишек алларында ФЗУ га үтмәгән малайларның аһ оруларын, алуны сорап кемнәргәдер ялыну-ялваруларын күрсәң!

Барый комиссиядән авызы колагына җитеп, елмаеп чыкты. Врачлар аның шәрә аркасын чәбәкләп: «Годен»,— дигәннәр!

Барый да алынгач, Мөнир үтә дә үтә инде. Кара син аның төп кебек гәүдәсен, киң күкрәкләрен, кулындагы йодрык булып каткан мускулларын! Һәм комиссиядә әйттеләр: «Яхшы шахтер чыгачак бу егеттән», диделәр. Алдылар!

Юллар ике сабакташны беренче көннән үк аерды. Мөнир Татарстандагы бер төркем яшьләр белән шахта училищесына — Донбасс якларына китте, Барый исә фабрика-завод һөнәр училищесына — Ленинградка таба юл тотты.

Германия сугыш башламаган булса, бәлки бу егетләрнең берсеннән менә дигән шахтер, икенчесеннән оста слесарь чыгар иде. Булмады. Өч еллык программаның бары тик сигез аен гына укып калдылар. Фашист самолетлары Донбасс шахталарын, Ленинград заводларын бомбага тота башлагач, укучыларны өйләренә тараттылар.

Язмыш ике яшьтәшне һич көтмәгәндә тагын очраштырды. Бу юлы инде военкомат ишек төбендә.

— Син кая? — диде Мөнир, сабакташын күрү белән.

— Армиягә. Хәрби училищега.

— Мин дә бит хәрби училищега!

— Димәк, тагын бергә? Алырлар микән?

— Алырлар! Нигә, без кемнән ким?

Тыннары кысылган хәлдә бер-беренә карашып тордылар. Шушы күпме генә вакыт эчендә дә алар ничектер олыгаеп, җитдиләнеп киткәннәр иде. Ябыкканнар да төсле.

Ленинградттан кайткач, Барый слесарь булып Шөгер нефть разведкасында да эшләп алган икән. Мөниргә мактанып сөйли: имеш, ул Татарстанда иң беренче скважинаны бораулауда катнашкан. Ул чагында әле Мөнир «буровой», «скважина» дигән нәрсәләрне күз алдына да китерә алмый иде — яшьтәшенең авыз суларын корытып биек вышкалар, роторлар турында сөйләүләренә игътибар да бирмәде. Күңеле хәрби училищега омтыла. Тизрәк барып керәсе иде дә, командир булып фронтка китәсе иде...

Тик бу юлы аларга бәхет елмаймады. Алмадылар пехота училищесына. «Белемегез сай, русча белүегез чамалы», дип әйтеп бетермәсәләр дә аңлашылды. «Соңга калдыгыз»,— дигән булып кайтарып җибәрделәр.

Күп тә үтми, Шөгер военкоматында яшьтәшләр тагын очраштылар. Бу юлы инде икесен дә «җиде күнлек азык, кружка, кашык» белән чакырганнар. Димәк, фронтка...

Алар Астраханьдагы запас полкка килгәндә, дошманның иң көчле, иң мәкерле чагы иде. Фашистлар инде Белоруссияне, Украинаны басып алдылар, Курск магнит ятмаларын, Донбасс шахталарын оккупацияләделәр, хәзер, бернинди каршылыкларга, югалтуларга карамый, һаман илебезнең эченә — Кырымга, Кавказга, Иделгә омтылалар.

Апрель аенда гына килеп төшкән яшь солдатларны инде фронтка да озаталар. Сталинград куркыныч астында, Сталинград резервлар сорый...

Ә Мөнир белән Барый һаман да бергә. Бер ротада булмасалар да бер полкта, дошманга каршы бергә сугышачаклар...

— Исеңдәме, яшьтәш, өстебезгә беренче мәртәбә бомба төшкән көн? — дип сорады Мөнир. Барый да шул сугыш турында уйлап утырадыр төсле тоелды аңа.

— Кайдан килеп хәтереңә төште әле ул сугыш!

— Менә шул яшьләр турында уйлана торгач. Без күргәннәрне күрсәләр, болай булмаслар иде... Кадерен белерләр иде, мин әйтәм, тыныч хезмәтнең...

Мөнир Астраханьнан пароход белән Сталинградка менгәндә, бомбага эләккән вакытны исенә төшергәндер. Каяндыр яшеренеп килеп чыккан фашист самолетлары чак кына Иделгә батырмый калдылар бит аларны. Бәлки, дошманның Сталинградка килү юлында оборона тотканда булган вакыйганы сөйлидер? Әйе, анда да үлем өстән узып китте. Немецларның егермеләп самолеты шәһәргә таба килә иде. Көчләрен күрсәтергә теләгәндәй, тигез сафларга тезелеп, курыкмыйча, тыныч кына киләләр! Юл уңаенда, эш юктан юанып алу өчен генә дигәндәй, һәрберсе берәр-икешәр бомбасын ташлады да кончыгышка очуын дәвам итте.

— Рота командиры аяктан тартып екмаган булса, белмим, хәзер буровойга барып йөри алыр идем микән? — дип, тирән сулап алды Барый. — Тузан-туфрак эченнән баш калкытсам, янымда гына бияләй кадәр бомба китеге зырылдап әйләнә. Уйлап кара, зәп-зәңгәр корыч кисәге!

— Әйе, кырда дисталәгән мәет калды алар артыннан.

Сугышның шушы беренче чирканчык алган көннәрендә Мөнир белән Барыйның дуслыгы тагын да ныгыды. Бу инде бер көнне тәпәләшеп, икенче көнне татуланышкан малайлык дуслыгы да, больница, военкомат ишек төпләрендә, комиссияләрдә очрашкандагы дуслык та түгел, язмышның кыл өстендә торганда туган чын фронтовиклар дуслыгы иде.

— Исән-сау калсак, киләчәктә ташлашмабыз,— дип ант иткәннәр иде алар сугышта.

Фронтта Барый яраланды. Аны госпитальгә озаттылар. Шуннан соң ике дус яңадан күрешә алмадылар. Сталинградта 330 меңле Паулюс армиясен камалышта калдырып, безнең гаскәрләр көчле һөҗүм белән Дон буйларына, Донбасс якларына юл алдылар. Мөнир күптән түгел үзе укыган Макеевка тирәләрен азат итүдә катнашты, Дон, Днепр елгаларын кичте, Совет Армиясенең туктаусыз ташкынына кушылып, Молдавиягә, Румыниягә барып чыкты.

Ә Барый, дүрт ай госпитальдә дәваланганнан соң, савыгып яңа частька килде һәм Керчь шәһәрен штурмлады. Аннан Белоруссия фронтына күчерелде һәм Брянск өлкәсеннән башланган сугыш аны җиңүләр белән Польшага китерде, Висла, Одер елгаларын кичерде һәм фашистның соңгы оясы Берлинга алып килде.

Барый армиядән кайтканда, яшьтәше Мөнир бораулаучы булып эшли иде инде. Очраштылар. Мондый чакта хәл-әхвәл сорашып буламыни? Әйе, җиде ел армия хезмәте, шуның өч елдан артыгы тоташ фронтларда, сугышта. Кеше дигәнең бу вакыт эчендә ниләр генә күреп бетерми дә, башыннан ниләр генә кичерми!..

«Дан» орденын, биш-алты медален тагып килгән яшел гимнастеркалы дусты белән очрашкач, Мөнир күз кырые белән генә үлчәшеп алды. Барый үскән, ауарданбер башка узып киткән иде. «Ордены да бар, медальләре дә минекеннән күп, җитмәсә сержант» — малайларча эчке бер көнләшү биләп алды Мөнирне.

Армиягә нефть эшеннән киткән булгач, разведкага да бик ансат керде Барый. Ә менә Мөнирне гаризасын тоттырып унбиш көн тилмертеп йөрттеләр: Мөнир кебек демобилизация белән кайтып нефть эшенә керергә теләүчеләр бик күп иде.

Колхоздан ничек китәсе иткәндер. Келәүле станциясенә кайтып төшкәч, солдат капчыгын асып, туган авылы Бәкергә 40 чакрым җәяү атларга булды ул. Машиналар йөрми, ат көтеп торуның мәгънәсе юк, чөнки кешеләр станциягә үзләре арбалар тартып килгәннәр иде...

Әллә армиядә чакта Барыйның буровой, скважина турында сөйләүләре күңелгә кенеп калды, әллә Келәүле белән Спиридоновка авылы арасында шактый күп булып утырган буровой вышкалары үзенә тартты, шул чакта ук нефть эшенә керергә карар кылган иде Мөнир.

Һәм менә алар тагын икәү бергә. Ике сабакташ, яшьтәш, дус һәм фронтовик.

Армиядән ел ярым элек кайткан Мөнир инде бурильщикка күтәрелгән, вахта җитәкчесе исемен алган иде. Барый белә: бу дәрәҗәгә менү өчен кешеләр шактый озак буровой эшчесе булып йөриләр, аннан бораулаучы ярдәмчесе сыйфатында хәтсез генә бораулау станогы янында эшлиләр, шуннан верховой вазифасын алып күпмеләр вышка башында җилләнәләр. Махсус курслар бетермәсә, аннан соң да әле төшеп

идарә пультына баса алмый кеше. Димәк, Мәнир булдыра, димәк, кулы эшкә йога егетнең...

Бергә эшләгән дәвердә Мәнир үзенең уңганлыгын бер түгел, йөз мәртәбәләр раслады. Үткән бишьеллыкта күрсәткән батырлыклары өчен хөкүмәтебезнең иң зур бүләген — Ленин орденын алгач һәм РСФСР Верховный Советына сайлаулар вакытында депутатлыкка кандидат итеп тә күрсәтелгәч, Мәнирнең хезмәтен яңа яклары белән ачкандай булды Барый. «Үз кешебез, иң паеклы бораулаучыбыз»,— дип шатланып тавыш бирделәр аңа бригада членнары.

Барый армиядән кайтканда кайчандыр үзе эшләгән Шөгер мәйданындагы 1 нче номерлы скважина нефть бирә иде инде. Аннан нефть сугыш вакытында, дошман Бакуны басып алырга омтылганда, Кавказга, Грозныйга куркыныч тудырган көннәрдә чыга башлаган. 1 нче скважина тирәсендә тагын 15—20 вышка күтәрелгән. Мәнир шул буровойларның берсендә икән.

Бик күп яңалыклар ишетте ул Мәнирдән. 1948 елның җәендә Шөгердән 35—40 чакрымнар ары — Тимәш авылыннан тагын җир мае тапканнар. Искиткеч күп, тәүлегенә йөз тоннадан артык нефть бирә, ди. Бораулаучылар күптән түгел Зәй-Каратай, Вәли хуторы янында да җир асты байлыгына юлыкканнар. Имеш, «кара алтын» тирәндә зур диңгез булып ята...

Геологлар картасында скважина салынырга тиешле урыннар гади нокталар белән генә билгеләнгән. Мәнир белән Барый ул «нокталарга» ерак юллар, таулар, урманнар, чокырлар үтеп, елгалар кичеп бардылар. Эзләделәр, таптылар ул «нокталарны», бораулადылар һәм нефть чыгарып бирделәр. Күпме сәяхәт итәргә, машакать, җәфа чигәргә туры килде. Шуның белән бергә эшеңнең нәтиҗәсен күреп ничаклы шатлык, куаныч кичерергә, үзеңнең эшче, файдалы кеше икәнлегеңне тоеп, горурлык хисе татырга насыйп булды нефтьчеләргә.

Шөгер битум заводы янындагы скважинаны тәмамлап, 1949 елны, бөтен хуҗалыклары, конторалары белән Ромашкино нефть ятмасына күченгәч, эшкә барып-кайту йөз километрдан артып китте. Җиңел түгел иде, тик сынатмадылар — өч ел буена Чупай, Суркино авылы тирәләрен бораулап йөрделәр. Техника үсте, кешеләрнең тәҗрибәләре үсте. Авыр роторлы станокларны алмаштырып, турбина ысулы белән бораулауга күчтеләр, балчык измәсе урынына җирне арзанлы су белән бораулый башладылар.

1954 елда, Васильевка кырына килеп, 82 нче буровойда эшләделәр, тагын да арырак китеп иң күп продуктлы Миңлебай мәйданын ачтылар. Геологлар картада күрсәткән нокталар чыннан да могҗизалы нокталар булып чыктылар — тишкәне берсе нефть фонтаны булып атты.

Эх, ул заманнар! Ул вакытларда девон батырларының үзләрен күрү, нефтьнең төсен карау, исен иснәү өчен генә дә күпме халык җыела иде бит скважина янына! Шуңа күрә дә һәрнәрсәдән канәгать булып, эшнең ямен, тәмен табып йөрилэр иде бораулаучылар!..

1956 ел бораулаучыларны Ромашкиноның көнчыгышына — ерак Кодаш, Кызыл чишмә якларына алып китте. Барыйның әле булса хәтерендә: бер буровойдан ике көпшә — игезәк скважина салдылар. Тарих өчен монысы да зур яңалык иде. Шушы елны аны үрнәк буровой салу өчен Мәскәүгә җибәрделәр. Ул скважина әле хәзер дә булса килгән кунакларны, чит ил туристларын сокландырып башкаланың үзәгендә, Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә тора.

Мәскәүдән кайткач, тагын Кодаш яклары, яңа ачылган Куакбаш мәйданы... Монда да техника бер урында таптанып тормады. Бораулаучылар авыш скважина тишәргә өйрәнделәр, су белән бораулауны камилләштерделәр, буровойда автомат чайпар, автомат ачкычлар куллана башладылар. Авыр буровой инструментлары урынына нечкә диаметрлы торбалар, җыйнак турбобурлар, камилләштерелгән бораулар килде. Буровой төзүчеләр дә инде кулны тотмый,— вышкаларны тракторлар белән генә тарттырып күчерәләр. Нәтиҗәдә бораулау темплары күзгә күренеп үсте. Элекгәге бер ел-алты ай урынына скважинаны бер айда тәмамлыйлар. Ул рекордлар, бораулау бригадалары исеменә килгән котлаулар, «кара алтын» табучылар исәнлегенә күтәрелгән тостлар!..

Тантана, шатлыкларга уралып, ул елларның авырлыгы ничектер сизелми үткән.

күрәсең — күңелдә буровой тормышының бары тик яхшы яклары гына калган. Татарстан нефтенең күтәрелеш еллары, рекордлар заманы иде бит ул еллар!

Илленче ел башларында беренче тапкыр турбиналы ысул белән мастер Александр Юдин бригадасының станок-айга 1013 метр үткәнен ишетеп гаҗәпләнгәннәр иде, икенче елны яшь мастер Мотаһар Нургалиев бораулау тизлеген 1225 метрга җиткерде.

1952 елда бораулау остасы Мөгаллим Гыймазов буровойны 38 көн эчендә тәмамлап, 1374 метр тизлек белән бораулаучыларның исләрен китәрде. Икенче елны яз көне исә карт мастер Газим Гайфуллин үз буровоен 33 көндә тәмамлады. Күп тә үтмәде, Гыймазов бригадасы тагын өскә калкып чыкты: бораулаучылар скважиналарын 25 тәүлектә тапшырдылар.

Бераздан Гыймазовның рекордын Михаил Белоглазов узып китте. Башта бер буровойны 15 тәүлек эчендә бораулап, аннан 12 көн эчендә 4569 метр тизлек биреп шаккаттырды, соңыннан Белоглазовныкылар девон тирәнлегенә 10 көн эчендә төштеләр.

Күз алдына китерү мөмкин булмаган ифрат кызу темплар иде болар. Тауга карап тау булып булмый инде. Шулай да бу рекордлар заманында кешеләрдән артта калу да килешми иде.

Батырлар артыннан куу ансат булмады. Иярү өчен алар тәҗрибәсен өйрәнү өстенә, шактый көчәнергә дә туры килде. Бораулаучылар икешәр-өчәр вахта рәттән калып эшләделәр, буровойларда куныл яттылар, ялдан, йокыдан, бәйрәмнәрдән ваз кичтеләр... Батырлар рекорды берничә елдан соң барлык бригадалар өчен дә гади норма булып кына калды.

«Боларны яшьләр беләләр микән?» — дигән сыман Барый борылып автобустагыларга карады. Ләкин биредә «яшьләр» дип тотып алып әйтерлек кеше юклыгын ул яхшы белә иде. Йөрәге яңадан сыкранып китте. Яшьләр юк... Нефть табуның беренче авыр елларын гыйбрәт итеп әйтеп калдырырлык һәм, ниһаять, шул чорларның рекордлы, шатлыклы көннәрен горурланып сөйләрлек тә кеше юк бригадада. Шунда Барый, әрнеп, Мөниргә күптән түгел генә булган хәлне сөйләде:

— Бер көнне арып-талып вахтадан кайтып килəм. Өс-баш андый чакта, үзең беләсең, бик күркәм булмый — чалбар да, брезентовка да шактый ук мазутка буялган. Ишек төбендә күрше хатыны, ни өчендер, улын ачуланып тора. Баскычтан менгәндә ишетәм: укы каһәр суккан малай, ди бу, укымасаң әнә Барый абыең кебек майга чумып кара эштә эшләп йөрерсең, дип тирги. Башыма китереп суктыларммыни — куырылып, җыерылып киттем. Үземнең бөтен гомеремне: мохтаҗлыкта узган бала чагымны, сугышта үткән яшьлегемне, буровойда йөреп укый алмауларымны, барысын, барысын каргап бетердем...

— Анысы дөрес,— диде Мөнир, үзе дә Барый сөйләгәннәргә охшашлы кайбер нәрсәләрне исенә төшергәч.— Горурланасы урында кимсенеп тә куясың кай чагында... Соңгы елларда кеше дигәнең башын укуга салды, бәлки, шуңадыр... Ата-аналар да, мәктәп тә балаларны бары тик коры уку белән генә тәрбиялиләр. Эшкә өйрәтү түгел, уку максат итеп алынган. Баланың сәләте, теләге бармы — ата-ана тикшереп тормый, бернәрсә белән исәпләшмичә балаларын ничек булса да институтка, техникумга тыгарга, һич булмаса, «ак эшкә» урнаштырырга тырыша. Нәтиҗәдә балада «кара эшкә» кимсетеп, җирәнеп карау галәмәтләре туа. Мисалга үзебезнең шәһәрне генә алыйк: нефтьче, бораулаучы һөнәренә өйрәтә торган берәр мәктәп яки һөнәр училищесы бармы? Кайсы мәктәпнең кайсы классы нефть ветераннары, атаклы бораулаучылар, танылган разведчиклар белән очрашулар уздырганы, буровойга, промыселларга экскурсия ясаганы, эшче һөнәре белән укучыларны таныштырганы бар? Сүз юк: белем эшчеләрнең квалификациясен күтәрү, аларны культуралы итү өчен нык ярдәм итә. Ләкин шунысы бар: укыганның соңында, диплом белән килеп, яңа вазифа һәм җитәкчелек эше таләп итү гадәте кереп киткән. Аңардан яхшы техник яки инженер чыгармы-юкмы әле...

Менә Мөнир буровойга егерме биш елдан артык йөри, ә автобуста һаман да шул ук кешеләр. Верховой Константин Серыхны яшь дисәк тә ярый инде. Ул нибары өч елдан артык эшли. Верховой. Ләкин Костяга да хәзер утыз тулып килә. Шуның өстенә әле ул да буровойны өнәп бетерми. Бораулаучы ярдәмчесе Николай Савинны да яшь дип йөрткән булабыз. Ул да кырыкның тегe ягына чыккан, ун ел эшли. Тагын

Фазлуллин Әдһәм бар. Яңа килгән кеше булса да, бишенче дистә белән бара. Тагын кемне саныйк яшь дип? Бораулаучы Дмитрий Аброшин яшьрәк. Әмма аның да стажы буровойда унбиш елдан артык. Әнә, бригада электрчысы — Хәниф Баһаветдинов (тагын бер яшьтәш!). Ул 1950 елдан бирле эшли. Аның янәшәсендә — бораулаучы ярдәмчесе Габдрахман Галиев. Аның да чәчләре агарып килә. Ветеран, егерме ел стаж җыйган кеше. Әнә, арткы рәтләрнең берсенә посып утырган верховой Тәүдыйк Хәсәнов. Буровойда икенче дистәне куа...

Мөнир, «тагын кемне санамый калдырдым икән?» дип, автобустагыларга күзен йөртеп чыкты да мастер Долговка килеп тукталды. Гадәтенчә, ул шофер артында, «мастерның персональ креслосында» утырып бара иде. Шактый борчылган, шактый күңелсез Ефим Митрофанович. Бригадасындагы кадрлар турында уйланып барадыр... Яше кырыктан гына узуга карамастан, аның да бит эш стажы егерме биш ел исәпләнә...

Уйлап карасаң, буровойдагы эшчеләрнең яртысыннан күбесенә уртача илле яшь. Алар илле биш яшьтән пенсиягә чыгалар. Димәк, эшче кадрлар тагын да кими дигән сүз. Ә алмаш килми. Мондый күренешләр бер шушы Долгов бригадасында гына булса икән! Ул бөтен буровой идарәләрендә, хәтта «Татнефть» берләшмәсендә дә шулай.

Сер түгел, хәзер идарәләрнең кадрлар бүлеге белдерүләр тактасына кәгазьләр элеп тә, газеталарга язып та, вербовка белән дә үзенә эшче көчләр чакыра...

Без, әлбәттә, эшчеләр җыюның оешкан тәртипләренә каршы түгел. Тик шунысы мәгълүм: былтыр вербовка белән Лениногорск бораулау идарәсенә килгән егерме егетнең бүгенге көндә берсе дә буровойда калмады.

— Нәрсә белән куркыттык соң әле без яшьләрне?

Дөрес, буровойда эшләү кунакта булу түгел. Эш авыр, ул батырлык, кыюлык сорый. Ләкин элеккеге белән чагыштырганда, авырлык икеләтә ким. Илленче еллардагы кебек яртышар тонналы озын-озын торбаларны буровойга кул белән сөйрәп кертәсе юк — аларны механизмнар тарттыра. Шәмнәрне утыртканда да торбаларны кул белән борасы түгел — сүс арканнар, Залкин ачкычлары да модадан төшеп калды — ул эшләрне дә автоматлар башкара. Ә бораулаучылар тарафыннан каһәрләнгән измә хәзерләүләр?..

Һәр скважина саен 150—200 тонна балчык болгатып, кул белән измә хәзерләүләр күптән онытылды инде. Аны да бит хәзер заводтан әзер килеш китерәләр.

Транспорт мәсьәләсе дә зарланырлык түгел. Бораулаучылар эшкә, Барый әйтмешли, киерелеп комфортабельле автобусларда гына баралар. Ә бит нефтьчеләр тегә елларда эшкә кышын-җәен йөк машиналарында йөриләр иде.

Ә эш, көнкүреш шартлары? Бик туңгач, кереп чыгарга кечкенә генә агач будка һәм идән уртасында утын белән ягыла торган тимер мич. Шул будкада ял да итәләр иде, кием-салымнарын да киптерәләр иде, өйдән алып килгән ризыкларын да җылытып ашыйлар иде.

Бүгенге буровойда бөтен уңайлыклары тудырылган махсус вагон. Үзенең зурлыгы, матурлыгы, эшләнеше белән ул тимер юллардагы экспресс вагоннарын хәтерләтә. Бер ягы аның яхшы өстәлләр, утыргычлар, шкафлар, тумбочкалар белән җиһазландырылган. Якты бүлмәдә — телефон, радиоалгыч, телевизор, суыткыч. Ял вакытында газета-журналлар укырга, шашка, шахмат, домино уйнарга мөмкин. Икенче як — йокы бүлмәсе. Йомшак ятакларда — күпереп торган мендәрләр, ак җәймәләр... Тагын бер кечкенә бүлмә кием киптерү шкафы, кайнар су, өйне җылыту һәм аш пешерү өчен газ белән тәэмин ителгән. Хәер, аш пешереп тормасаң да була — аны махсус машинада термослар белән шәһәрдән китерәләр.

— Шулай да нәрсә белән куркыттык соң әле без яшьләрне?

Мастер Долгов та ишетеп алды бу сорауны. Чуваш милләтеннән булса да, татарча яхшы аңлый, шушы якныкы бит ул. Ефрим Митрофанович бу ике дусның моңа кадәр дә еш кына буровойның киләчәге турында борчылып сөйләшкәннәрен ишетә, хәтта кадрлар мәсьәләсендә бәхәсләшеп китканнәрен дә күрә иде. Әңгәмәгә катнашмаса да, ул эченнән алар белән килешеп, Фәсхетдинов белән Вәлиевнең яшьләргә карата булган дәгъваларын хуплап утыра иде... Чөнки Ефрим Митрофанович үзе дә «карт гвардия» исемләгендә йөри, яше 42 дә генә булса да, буровойда инде

чирек гасыр эшли. Буровой тормышының бөтен стадиясен үтте Долгов: буровой эшчесе булды, верховой булды, бораулаучы ярдәмчесе булды, бораулаучы булды. Инде биш ел бораулау мастеры.

Әйе, Мөнир белән Барый дөрес әйтәләр: хәзер яшьләр иркә. Эшкә керешкәнче үк хезмәт хакын сораша, тормыш-көнкүреш шартлары белән кызыксына, культура мәсьәләсен белешә. Ефрим сугыштан соң разведка эшләре белән Куйбышев өлкәсен ермалап чыкты, Татарстанның бөтен көнчыгыш өлешен гизде. Мөнир белән Барый кебек үк ачык машиналарда йөрде, ниндидер таныш булмаган авылларда әби-бабайларда торды, буровойларда кунды, иdәннәрдә йоклады... Кая ул, эш-көнкүреш шартларына бернинди дәгъвасы юк иде Ефримның. Киресенчә, үзен уналты яшь тә тулмас борын эшкә алган буровой конторына, һөнәр өйрәткән, кеше иткән остазларына рәхмәт кенә укый иде. Яшьтән әнисез калып, сугышта әтисен дә югалткан ятим малай, kөтүче малай өчен буровойда эшләү, ипигә тую үзе зур бәхет иде бит!

Күрәсең, олыгаюның бер галәмәтедер — яшәгән, гомер узган саен артка таба ешрак борылып карыйсың икән. Малай чакларыңны, яшьлегеңне искә төшерәсең, нигәдер үзең майтарган һәм майтара алмый калган эшләреңне барлый башлыйсың, ирексездән «элек» белән «хәзер»не чагыштырырга тотынасың. «Элек болай иде, хәзер болай»... «Элек замана начар булса да без әйбәт идек... Хәзер замана әйбәт булса да без начар... Дөресрәге, безне алыштырасы яшь буын начар...»

Мастер Долгов, күптән эзләгән нәрсәсен тапкандай, кинәт талпынып Мөнир белән Барыйга карап куйды. «Моның белән без, үзебез дә сизмичә, үткәннәргә кире кайту морален сукалыйбыз түгелме?»

— Менә син, Барый, хәзерге яшьләрнең таләпчән булуына гаҗәпләнеп утырасың,— дип, әкрен генә сүзен башлап җибәрде Долгов,— бу заманда, тормыш кеннән-көн матурая барган чорда нишләп алар хаклы түгел? Синеңчә, алар буровойда эшлим дип электәгечә йөк машиналарында йөрсеннәрмени? Менә син үзең, мәсәлән, Крупская урамындагы өч бүлмәле, газлы, ванналы квартираңны ташлап элек торган барагыңа чыгар идеңме?

— Юк, чыкмас идем! — дип, кискен генә әйтеп куйды Барый.

— Шул шул менә! Мөнир дә автомат ачкычларын ташлап Залкин ачкычы белән эшләмәс иде!

— Залкин ачкычын кире бирсәләр, билләһи, каравыл кычкырыр идем! У-у, кулдагы сөялләр әле булса да бетми! — Мөнир кулын уып алды.

— Шулай булгач, «Без буровойда кундык, сез дә шулай итегез!» — дип, яшьләрне тиргәп утырасы түгел. Яшьләр таләпне дөрес куялар! Алар «бабайлар ысулы» белән эшләмәсләр хәзер. Җырдагыча: «Сулар үргә акмый!» Безнең идарәдән алты ай эчендә киткән 136 кешене генә алып карыйк. Алар барысы да диярлек яшьләр иде. Берсе дә эшне яратмыйм дип китмәде ич. Утыз өче торак булмаганнан китәргә мәҗбүр булды, унҗиде кеше укырга мөмкинлек тудырылмаганнан гариза бирде, уналтысы хезмәт хакы түбән булганнан эшен ташлады. Гаризаларына «семья хәлләре аркасында», «һөнәрне алыштыру сәбәпле», «эш шартлары авыр булганлыктан», дип язганнарында да әле без белеп бетермәгән күп нәрсәләр яшеренеп ята!

Мәсьәлә шулай тора: эшкә аласың икән, кешегә тормыш шартлары да тудыр!

— «Мин эшкә килдем» дию белән аңа бөтен уңайлыклар булган квартира ачкычы китереп тоттырыргамы? Ай-һай, туган, артык майлы булып китмәсме?

— Ә нәрсәсе начар?

— Без андый квартираларны унбиш ел эшләгәч кенә алдык...

— Әйтәм бит, безнең заман белән бу заманны чагыштырырга ярамый дим... Белəсең килсә, хәзер яшьләр өчен дә квартира салына инде...

Мастер Долгов яшь эшчеләргә шартлар тудыру буенча соңгы вакытларда «Лениногорскбурнефть» идарәсендә нинди чаралар күрелгәнен сөйләп китте.

— Әйе, яшь бораулаучылар өчен бүгенге көндә 120 квартиралы бер йорт салына. Дөрес, квартира бер генә бүлмәле булачак. 18 квадрат метр. Аның караваы, кухнясы, ваннасы, туалеты үзендә. Торып, эшләр өчен армиядән кайтучы яшь солдатларны чакырырга уйлыйлар. Квартира кешенең өйләнү-өйләнмәвенә карамастан бирелачәк. Шуның өстенә, идарә нефть чыгаручылар трестыннан арендага 120 урын алып куйды.

Идарә тагын үз көче белән җитмешәр квартиралы ике йорт төзетә, 140 урынлы балалар бакчасы салдыра. Эшкә киткәндә балаңны калдырыр урын да булачак.

— Шунысы кызганыч, идарә бу эшләрен кешеләрне качырып бетергәч кенә башлаган...

— Әйе, алданрак кирәк иде... Барый картаер дип күз алдына да китермәгәннәр күрәсең,— дип елмаеп алды да Долгов сүзен дәвам итте.— Үзегез беләсез, бездә уку мәсьәләсе бик начар иде бит. Хәзер яше утызга кадәр булган барлык кешеләр исәпкә алынды. Чама белән йөз кырыктан артык кеше урта мәктәпне тәмамламаган. Чакырып сөйләшкәч, шуның алтмыш икесе укырга ризалык биргән. Алар өчен сменадан соң көндезге һәм кичке дәресләр оештырыла.

— Эх, безгә булмады бит шундый мәктәпләр! — дип көрсенеп алдылар Барый белән Мөнир.

Моңа кадәр Лениногорск нефть техникумында бораулаучылар бүлеге юк иде. Нефть министрлыгына үтенеч җибәреп, яңа бүлек ачтырганнар. Аңа урта мәктәпне бетергән ун егет гариза да биргәннәр инде.

Монысына Мөнир белән Барый чын-чынлап көнләшеп куйдылар. Читтән торып бары өч кенә ел укырга икән ләбаса. «Читтән торып» дигәне дә бит аның үз шәһәрендә, өеңнән ике-өч кенә квартал ары. Өч ел укыйсың да, диплом алып, яшь белгеч, техник бораулаучы булып чыгасың. Юк, туры килмәде бит аларның яшьлегенә шундый мөмкинлекләр...

Боларның барысы да яшь буын өчен бик кирәк икәнен белсә дә,ниндидер эчке каршылык Ефрим Митрофановичның үзенен дә күңелен тырнап тора. Артык күп булып китмәсме икән соң бу яшьләр өчен, диң аздырып җибәрмәбез микән аларны, дип шөбһәләнә. Каһәр, һаман шул искелек, консерватизм калдыгы ята эчтә...

Долгов үзе дә зур канәгатьлек белән тагын шуны белдерде: быелдан башлап эшчеләр, озак эшләгәннәре өчен, ел азагында уночыче хезмәт хакын ала башлаячаклар.

— Димәк, элек булып та бетерелгән «за выслугу лет» дигән нәрсә яңадан кайтарыла?

— Әйе. Хәзер, әлбәттә, кешеләр эштән киткәндә стажын югалту турында да уйлап карарлар...

— Күптән кирәк иде мондый кызыксындыру чаралары...

— Шуның өстенә әле, бишьеллык директивалары нигезендә, бораулаучыларның хезмәт хаклары да шактый артачак. Бу бигрәк тә аз һәм уртача хезмәт хакы алучыларга кагыла.

— Тагын яшьләргә?..

— Гадәттә, андый хезмәт хакын кем ала? Стажы аз, разряды түбән булган кешеләр алалар. Димәк, яшьләр...

Лениногорск бораулау идарәсендә күптән түгел җитәкчеләрне, нефть ветераннарын, мастерларны һәм алдынгы эшчеләрне кертеп җиде кешедән Совет төзелде. Ул яшьләр арасында аңлату-тәрбия эшләре алып барачак, аларның эшләре, укулары, ялларны, көнкүрешләре белән кызыксынып торачак. Планда «иң яхшы профессия кешесе» исемен алу өчен ярышлар уздыру, бораулау мастерлары көнен булдыру, коммунистик хезмәт ударниклары слетын үткәрү кебек чаралар каралган. Болар барысы да яшьләрне производствога тартуда, бораулаучыларның бәясен, абруен күтәрүдә, һичшиксез, зур этәргеч булачак.

— Димәк, боз кузгала...

Бу вакытта машина олы юлдан борылып ларга сөрган җир өстендә чайкала-чайкала скважинага таба кереп бара иде инде. Тиздән автобусның алгы тәрәзәсеннән буровой вышкасы да күренә башлады. Һәркем өчен таныш, күңелгә якын буровой... Ул биек манара булып күккә ургылган, гүя килүчеләрне каршы алу өчен муеныи әскә сузган. Яшьләрне, нык, гайрәтле яңа буынны көтә кебек...

# ЯНКА КУПАЛА ҺӘМ АНЫҢ ИҖАДИ ВАРИСЛАРЫ

Бездән өлкәннәр һәм безнең буын кешеләре белорус халык шагыйре Янка Купаланы (Иван Доминикович Луцевичны) Бөек Ватан сугышына хәтле үк яхшы беләләр иде: аның әсәрләре хрестоматияләргә кертелә, рус теленә тәрҗемә ителеп, кат-кат чыгарыла. Купаланың башлангыч иҗатыннан берничә шигырен Максим Горький үзе дә тәрҗемә иткән. Шагыйрьнең гражданлык биографиясе дә, Горькийныкы шикелле үк, шактый катлаулы һәм үз заманы өчен бик гыйбрәтле. Ул 1882 елның 7 июлендә Минск тирәсендәге авылларның берсендә ярлы семьяда туа. Җирле булу өчен алпавыттан алпавытка күчеп йөргән әтисенә ияреп бик күп дөнья гизә, китап укырга омтылганы өчен еш кына кыйнала. Егерме яшендә ул үз хуҗалыгында яши башлый, бераздан исә батраклыкка яллана. Аннары — дәрес бирүче «илгизәр мөгаллим», суд кәгазьләрен күчереп язучы писарь, кече приказчик һәм аракы заводында кара эшче булып эшли. Вильно шәһәрендә китапханәдә хезмәт иткәндә бик тырышып үзлегеннән укый, соңыннан Минскида халык мәктәбе, Петроградта дүрт еллык гомуми белем курсын тәмамлый. Беренче рус революциясе алдыннан «Наша Нива» газетасының баш редакторы булып эшләргә кайта һәм милли изелүгә каршы халык исеменнән, халык тавышы белән протест белдереп җырлаучы шагыйрь булып әдәбият мәйданына килә.

Яшәсәк тә, дуслар, кайгы йотып,  
Тиздән килер безнең көнебез —  
Күкләр булып күкрәр безнең хокук,  
Яшен булып яшьнәр, белегез!

Халыкка ул гади һәм үткен тел белән язылган әнә шундый җырларны ишеттерергә ашыга һәм, халык белән бергә революция утларын кичеп, патриот шагыйрь булып җитлегә, 1925 елда ук халык шагыйре дигән мактаулы исемгә лаек була, 1940 елда дәүләт премиясе ала, Белоруссия һәм Украина Фәннәр академияләренең академигы итеп сайлана...

Мин Янка Купала иҗаты белән Бөек Ватан сугышы елларында аеруча якыннан таныштым. Моның ике сәбәбе бар. Илебезгә немец фашистлары басып кергәч, чик буендагы авыр сугышлардан соң, миңа, партизан булып сугышыр өчен, 1941 елда ук белоруссия урманнарында калырга туры килде. Шул чакны без партизан учаклары янында, көрәш һәм уч алу әлифбаларының берсе итеп, Янка Купала сүзләрен дә укып ятлаган идек. Йөрәккә уелып калган ул сүзләрне искә төшерүе хәзер дә кыен түгел:

— Әгәр дошман безнең бакчаларда пешкән алмаларны өзсә, аның кулында ул алмалар граната булып шартласын.

— Әгәр дошман безнең тук башакларыбызны урып алыр булса, ул башаклардан бөртекләр атылып чыксыннар да илбасар өстенә кургаш яңгыры булып сибелсеннәр.

— Әгәр дошман безнең саф сулы чишмәләребезгә иелсә, аңа су каптырмас өчен, ул чишмәләр кибеп юкка чыксыннар яки аның күзенә агу булып чәчрәсеннәр!..

Халык һәм партия каршындагы бөек антыбызга кушылган шушы поэтик приказны да канат итеп походларда йөргән һәм һөҗүмнәргә кергән еллар хатирәсенең гомергомергә онытыласы юк.

Әшул чакны, 1941 елның октябреннан 1942 елның маена кадәр, шагыйребез Янка Купала исә безнең Казан тирәсендә, конкретрак әйткәндә, Югары Ослан районының Печище тегермәне поселогында торган һәм үзенең яңа әсәрләрен иҗат иткән икән. Ул дошман кулында вакытлыча каласы Минск шәһәреннән семьясы белән китәргә тиеш була һәм безнең якларга килеп төпләнә. Купаланың «Белорус партизаннарына» дигән әсәре шунда языла. Казандагы «Татполиграф» типографиясендә кечкенә форматлы зәңгәр кәгазьгә листовкалар итеп бастырылган ул шигырь безнең отрядларга фронт сызыгы аша самолет белән китерелгән иде. 1962 елда, шагыйрьнең 80 еллык бәйрәменә баргач, ул листовканы мин Минскидагы партизаннар музеенда күрдем. Ә Печищеда Купала торган йортка 1951 елда мемориаль такта куелды. Аны ачкан чакта үткәрелгән митингта без шагыйрьнең хатыны Владислава Францовна, белорус шагыйре Василь Витка, язучы Мозольков һәм профессор Виноградовлар белән бергә катнашкан идек. Ике республика белән ике тугандаш әдәбиятның дуслык биографиясе әнә шулай башланды. Аннан соң бездә Купала шигырьләренең тәрҗемәләре, аның яшьтәше һәм замандашы Якуб Коласның «Юлда» исемле җыентыгы, «Дуслык букеты» сериясендә белорус шигырьләре китабы чыкты, белорус мәкальләре һәм мәзәкләре татар теленә тәрҗемә ителде. Менә хәзер сез Купала шигырьләренең яңа тәрҗемәләрен укырсыз. Шуларга өстәп аның күп санлы иҗади варисларының берсе (Белоруссия язучылары оешмасында хәзер 280 нән артык член бар!), хәзерге яшь буын шагыйрь Иван Колесникның да берничә шигыре тәкъдим ителә. Ул безнең язучыларыбыз белән бергә Мәскәүдә укыды, үткән ел Казанга килгән иде, хәзер безнең поэзия үрнәкләрен белорусчага тәрҗемә итә.

**ЗӘКИ НУРИ**

# Янка Купала

## Минем юл...

Чәчәк белән түшәлмәгән минем юл,
Төшми аңа җылы кояш нурлары.
Караңгы, ярлы кырлардан үтә ул,
Шул кадәр күңелсез ул һәм бормалы!

Үтә минем юл кап-кара төн аша,
Як-ягы караңгылык, куе томан.
Җитәр җирем алдыма килеп баса,
Ирешмәслек әкият я бер төш сыман.

Киртә кора юлга барлык дошманым,
«Көчең беткән, йокла син юлда!» — диләр.
Көчемә һәм киләчәккә иманым
Тик һаман алга барырга өндиләр.

Богаулы берәр туганым очраса,
(Богауларын үзе мескен күрми ул.)
«Юл тотасың кая?» — диеп сораса,
«Арырак!» — дим. Минем бөтен җавап шул.

Буш комлыклар буйлап алга һаман да
Атлармын мин барешми (шул теләгем!),
Алдымда ирек таңы балкыганда,
Тибүеннән тукталганчы йөрәгем!

1911—1913

## Яз көнендә

Нур сибеп җиргә
Якты яз килде.
Җир кышкы төшен
Онытты инде.

Бәхетләр ташый
Йөрәккә ярсып.
Яңгырый җырлар:
«Йокламыйк артык!»

Чаң булып күктә
Шат җырлар гөрли.
Дәртләнеп һәркем
Тормышны зурлый.

Халыклар шаулый
Урманнар кебек.
Бу шауда яңрый
Ирекккә өмет.

Йокылар качкан —
Күз сал бар җиргә...
Йоклыйсың үлеп,
Илем, син нигә?

## Колмагым, кайда кышладың?..

«Колмагым, кайда кышладың,
Ярмыйча яфракларың?
Кайларда, улым, йокладың,
Чишенми аякларың?» —

«Яшәдем бу кышларда мин
Буран бураган җирдә.
Йокладым сугышларда мин
Уклар улаган җирдә».

* * *

«Колмагым, син бөреләндең
Кайсы яңгырсыз җирдә?
Кайда, улым, җәй үткәрдең,
Ризыклар капмый бер дә?» —

«Корыда мин бөреләндем
Эссе җил өргән җирдә.
Җәйләремне мин үткәрдем
Туплар үкергән җирдә».

* * *

«Колмагым, ничек син түздең
Эссе җәй, салкын кышка?
Киттең, улым, нигә үзең
Җыр җырлап ул сугышка?» —

«Бәхетле булды язмышым:
Салкынын һәм эссесен
Кичердем мин җәен, кышын
Сугышып илем өчен!»

1919

## Алеся

Таң ата. Күке кычкыра
Шаулатып Полесьены.
Анасы сөеп тирбәтә
Кызчыгы Алесяны.

Төн җитә. Шаулый наратлар
Полесье урманында.
Җыр җырлап ана утыра
Нәни бишек янында.

«Йокладылар кошлар күптән,
Син дә, чәчкәм, йом күзең.
Әлли-бәлли, әлли-бәлли...
Йокла, якты йолдызым!

Йокла, көч җый рәхәтләнеп,
Тиздән зур кыз булырсың.
Басарсың тиздән аякка,
Иң матур кыз булырсың.

Кышларын, өйдә утырып,
Эрләрсең җепләр төндә.
Язларын бәхет күтәрсең
Капкабыз төпләрендә...»

Таңнарда күке кычкырды
Шаулатып Полесьены.
Анасы ләкин белмәде —
Ни көтә Алесяны?

Өнме бу, әллә төшме бу?
Кызчыгы җитте үсеп
Һәм бер көн күккә менде дә
Еракка китте очып.

Китте очып, кулын болгап
Самолеты эченнән
Ирекле ил күге буйлап,
Туган йорты өстеннән.

Очты карап урманнарга,
Елгаларга, күлләргә.
Аннан, парашютын ачып,
Төште яшел үләнгә.

Кыр өстеннән тагын күккә
Күтәрелде югары,
Корыч канатлары белән
Ярып ак болытларны.

Анасы кояшлы күккә
Карый тәрәздән көн дә,
Күрмәмме Алесямны, дип,
Шул кояш тирәсендә?

Юкка кычкырмаган күке
Урманда көйләп-көйләп.
Юкка җырламаган ана
Кызына бәхет теләп!

1935

ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәләре.

## Теләгем

Халык белән һаман сөйләшергә
Һәм тыңларга халык йөрәген,
Һәм халыкка хаклык өләшергә,—
Шундый минем изге теләгем.

Шатлык җырын, әйдә, көйли бирим,
Һичбер өйгә керми үтмәм мин,—
Мин бәхетнең тик шундыен телим,
Тик шул чакта сагыш йотмам мин.

Тап төшермим халык уйларына,
Тап төшермим халык эшенә,—
Бар өметем минем шунда гына,
Тик шул язлар керә төшемә!

Күгемнән мин һаман кояш күзлим
Һәм халкымны әйдим яктыга,—
Мин бу җирдә тик шул юлны эзлим,
Бүтән юллар бар да ят миңа.

Әгәр үлсәм, илем өчен үлим,—
Көрәшендә җиңеп илемнең,—
Яшәүнең мин тик шундыен телим,
Мин шундыен телим үлемнең.

1912

## Һәр якта җәй

Һәр якта җәй! Болын-кырлар
Нурлы кием кигән.
Тук башакларны басуда
Җилләр җиргә игән.

Иркәм, чык, иркенгә кара,
Таң атканны күр син,
Күркеңне күреп куаныйк,
Безнең белән йөр син.

Аяз күктәге кояштан
Алтын җепләр ал да
Нурлы итеп күлмәк тукы,
Бераз манып алга.

Өз матур зәңгәр чәчәкләр,
Яшел үлән өз син,
Таҗ үргән чакта шуларны
Берәм-берәм тез син.

Энҗе сыман балкып торсын
Синең башта көндез:
Болындагы җем-җем чыклар,
Күкләрдәге йолдыз.

Балкы, иркә, матур булып,
Бул син шундый көчле:
Иң тылсымлы әкиятләрнең
Бер гүзәле төсле.

Күркеңне күрсәт дөньяга,
Йөзең булсын якты...
Ал таң итеп күрсен халык
Синең туган якны!

1913

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре.

Илдус Ахунҗанов

# ҮТКӘНГӘ СӘЯХӘТ

*Лирик репортаж*

Ул көнне мин Казаннан бик иртә кузгалдым. Җитез су трамвае тукталышларга кагыла-кагыла, җәйрәп яткан киң Идел буйлап, без пассажирларны түбәнгә алып төшеп бара. Аның артыннан сузылып калган дулкыннарда ялтырап, кояш нурлары күзләрне чагылдыра. Күк йөзе чип-чиста. һава саф, сулаган саен сулыйсы килеп тора. Якшәмбе иртәсендәге бу рәхәт минутлар хәтергә тагын да ныграк сеңеп калсын дигәндәй, безнең «Москвич»ка каршы килгән өч палубалы мәһабәт теплоходтан, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтеп, таныш музыка — Чайковскийның беренче концерты яңгырый. Безнең трамвайдагы кешеләр, әлеге музыка тәэсиренә бирелеп, тын гына уйланып баралар.

Минем Печищега барыш. Ул авылда Белоруссиянең халык шагыйре Янка Купала үз гомеренең соңгы елын үткәргән. Ниятем — шагыйрь эзләре буйлап йөреп кайту.

Идел киңлекләренең кояшлы манзарасы да, көтелмәгәндә генә Чайковский белән очрашу да бүген миңа яңа тәэсирләр вәгъдә итә шикелле. Кичә Янка Купала шигырьләренең татарчага тәрҗемәләрен укып утырган идем. Аның шигырьләре минем туган телемдә дә, белорус һәм рус телләрендәгечә үк, ачык һәм матур яңгырыйлар икән:

Нужа чиктем — күп тимәде миңа гыйлем,
Мәктәпләргә бик күп йөри алмадым мин.
Халкым уен һәм халкымның туган телен
Әнкәм җырын тыңлап белдем, аңладым мин.

Шигърият һәм музыка! Апа белән сеңел шикелле, алар бер анадан — халык авыз иҗатыннан туган. Янка Купала шигырьләре турында уйлана торгач минә мондый фикергә килдем: аның шигърият чыганагы белорус халык җырларына һәм көйләренә, әкиятләргә барып тоташкан булса кирәк.

Белорус шагыйре Максим Танк сөйләгән бер гаҗәеп легенда искә төште. Борынборын заманда бер белорус егете яшәгән. Жалейка дигән уен коралында уйный икән бу. Шундый матур итеп уйный икән — ул уйнаганда кояш та ныграк яктырта, агачлар да, ботакларын иеп, яфракларын да селкетмичә тыңлап тора, бәлкәгә утыртып куелган көлтәләр дә биешә торган була. Бер вакыт патша үзенең хезмәтчеләренә шул егетне тотып алып килергә боера. Ләкин тегеләр, күпме генә эзләсәләр дә, егетне таба алмыйлар. Кая барсалар да, җырын ишетәләр, әмма егет үзе күренми икән. Патша хезмәтчеләренең берсе, аптырагач, кеше түгелдер бу, җендер, дигән. Икенчесе, юк, үләннәр шулай моңлы итеп шаулый булырга тиеш, ди икән. Алар шулай байтак бәхәсләшкәч, өченчесе әйткән боларга: «Туганнар! — дигән. Белдем мин моның серен: җир үзе шушылай җырлый лабаса!..»

Бу шигъри легенданы ишеткәч, мин, белорус әдәбияты әнә шул легендадан башланмады микән, дип уйлап куйдым.

Белорусларның җыры күп гасырлар кыерсытылып, кысылып килгән. Крепостной Бахрым Павлюкның җыры да кыюсыз гына яңгыраган. Шулай да аның җалейкасын ватканнар, җырын кысрыклаганнар. Янка Лучина һәм Богушевич үз җырларын бераз кыюрак һәм ышанычлырак җырлаганнар. Аларның иҗатлары үз җирләренә бәйле булган. Ләкин белорус әдәбиятының әлеге легендар егетнеке шикелле матур җырлары бөтен дөньяга ишетелсен өчен, Янка Купала һәм Якуб Коласларның дөньяга килүе кирәк булган. Бу шагыйрьләр иҗатында белорус җире, чыннан да, «җырлап җибәрә». Халыкларны һәм аларның җырын азат иткән Бөек Октябрь революциясеннән соң ул җыр аеруча көчәеп китә.

Дусты һәм каләмдәше Якуб Колас Янка Купаланың шигъриятен, белорус җиренең бөтен матурлыгын туплаган чәчәкле гүзәл бакча, дип атаган. Янка Купала шигырьләрен укыганда ул хуш исне һәр даим сизеп торасың һәм, гәрчә сиңа беркайчан да Белоруссиядә булырга туры килмәсә дә, шагыйрь туган җирнең үткәнен дә, хәзергесен дә инде күптән беләсең, күптән яратып йөрисең сыман тоела. Һәм син үзеңә Янка Купала шигырьләренең Габдулла Тукай шигырьләре кебек үк тирән тәэсир итүен ачыграк аңлый башлыйсың. Синең ил турындагы — безнең зур социалистик илебез турындагы — төшенчәңдә бу данлы исемнәр, күрәсең, күптән бирретән урын алган булса кирәк.

Янка Купаланың кыяфәтен күз алдыма ачыграк итеп китерәсем килгән иде. Монда, Печищега барасы булгач, киңәш сорап язучы Гази ага Кашшафның өенә килдем. Ул миңа әле сугышка кадәр үк Янка Купала белән очрашулары турында сөйләде. «Без,— диде ул,— 1939 елда очраштык. Ул елны илебез җәмәгатьчелеге, әрмән халкы белән бергәләп, халык эпосы «Давид Сосунский»ның 1000 еллыгын билгеләп үттеләр. Шул тантана уңае белән барлык республика һәм өлкәләрнең язучыларыннан вәкилләр кояшлы Ереванга җыелды. Чит илләрдән дә кунаклар килгән иде. Татарстаннан шагыйрь Хәсән Туфан белән мин бардым. Тантанада белорус халык шагыйре Янка Купала да бар иде. Туфанның да, минем дә бу атаклы шагыйрь белән сөйләшәсебез бик килә иде. Ләкин бу, дөресен генә әйткәндә, җиңел булмады. Янка Купала һәрвакыт иске дуслары белән сөйләшеп йөри, күзгә артык күренмәскә тырыша. Ә безгә, табигый, аның янына барып, сүз кушу уңайсыз иде.

Шулай да җае чыкты. Бер көнне без ашханәдә утырганда Янка Купала белән Сергей Михалков килеп керделәр. Без аларга үз яныбызда урын тәкъдим иттек. Утырышкач үзара гәпләшеп киттек. Сүз, әлбәттә, әдәбият турында барды. Башта без аларга татар шигърияте турында сөйләдек, русчага тәрҗемә ителгән шигырьләрнең кайберләрен укып күрсәттек. Үзенең шигырьләре дә татарчага тәрҗемә ителгәнен һәм ул шигырьләрне безнең укучылар яратып укыганын әйткәч, Янка Купала аеруча җанланып китте. Нинди шигырьләре тәрҗемә ителүен сорады. Аннары сүз Сергей Михалковның «Дядя Стёпа»сына күчте. Ул чакта бу әсәр дә татарчага тәрҗемә ителгән һәм аны укучыларыбыз аны инде яратып та өлгергәннәр иде. Михалковка шул турыда да әйттек. Купала мөлаем елмаеп, бик зур игътибар белән тыңлады, әмма үзе сүзгә бик аз катнашты. Без аны Казанга чакырдык. Ул Иделдә йөрергә, Ленин укыган, Горький үзенең университетларын узган Казанны күрергә теләвен әйтте һәм килергә вәгъдә итте...

Һәм әлеге сөйләшүдән соң ике ел үткәч, ул, чыннан да, Казанга килде. Ләкин бу очрашу шатлыгын без тиешенчә татый алмадык — илнең кыен көннәр кичергән чагы, Ватан сугышы барган көннәр иде.

Безнең Габдулла Тукай клубы ул чакта эвакуацияләнгән язучылар белән шыгрым тулы. Алар арасында көнбатыш илләреннән килгән антифашист язучылар да байтак иде. Алар барысы да Янка Купаланы хөрмәт иттеләр, аңа бик игътибарлы булдылар. Ләкин мин Купаланың беркемнән бернәрсә сорваганын, нидән булса да зарлануын хәтерләмим. Сугыштагы фаҗигале хәлләрне ул тирәнтен, эченнән генә кичерә иде. Гадәтенчә, һәркайда тыйнак булды һәм күзгә бәрелеп тормаска тырышты. Аннары шәһәрдән авылга — Бөек Идел буендагы Печищега күчеп яши башлады».

Сугыш!

Аның авыр шартлары Янка Купаланы минем илемә — Татарстанга алып килгән. Ә хәзер, шагыйрь исеме белән бәйле Печище поселогына килеп җиткәндә, мин тик бернәрсә турында гына уйлыйм: сугыш елларында шушы поселокта яшәгән Янка Купаланы күреп белгән берәр кешене очрата алырмынмы, шагыйрьнең минем күңелемдәге рәсеменә аз гына булса да яңа сызыклар өстәрлек берәр нәрсә табып булырмы?

Дебаркадердан ярга чыгам. Яр буенда ук диярлек Печище он заводының корпуслары калкып тора. Шулар тирәсендә генә зур торак йорт. Йортның стенасында мемориаль такта. Анда 1941 елның октябреннан алып 1942 елның июненә кадәр бу йортта Белоруссиянең халык шагыйре Янка Купаланың яшәгәнлеге әйтелгән.

Кечерәк кенә ике бүлмәдән торган квартирага керәм. Шагыйрьнең тормыш иптәше Луцевичның язуына караганда, Янка Купала монда бик күп язган. Зур игътибар белән газеталар укыган, географик карталарны караган, радио тыңлаган. Совет солдатларының фронттагы героик көрәше, белоруссия партизаннарының батырлыгы турындагы хәбәрләр аны аеруча нык дулкынландырган. Ул шулар белән рухланып яшәгән. Белоруссия ССР фәннәр академиясе сессиясендә сөйләячәк «Ватан сугышы һәм белорус интеллигенциясе» дигән зур күләмле докладын да Янка Купала шушында язган. 1942 елның 18 январенда белоруссия халкы вәкилләренең Казанда үткәрелгән радиомитингысында сөйләгән речен шулай ук монда әзерләгән. Белоруссия халкының үткән юлын хәтерләп, ул речендә Купала менә болай дип әйткән: «Безгә билгесез һәм билгеле геройлар буыннан-буынга кояшка һәм йолдызларга таба юл сала килгәннәр. Тормышыбызның авыр минутларында без бәла-казаларны һәм кайгыларны батырларча кичердек, ләкин беркайчан да баш иеп, бил бөкмәдек...

һәм, ниһаять, без бәхеткә ирештек. Безнең җиребез бөтен матурлыгы һәм байлыгы белән балкып китте. Белорус чабата һәм тула оектан котылды. Белорус үзенең милли дәүләтендә, бөек совет халыклары семьясында тигез хокуклы хуҗа булып калды».

Тагын бер деталь. Аны Янка Купала иҗатын тикшерүче Евгений Мозольков: «Казан полиграфистлары Янка Купаланың «Белорус партизаннарына» исемле атаклы шигырен бастырып чыгардылар,— ди.— Кечерәк кенә зәңгәр листовка. Шигырь башына кызыл йолдыз ясалган, аның ике ягына «Татарстан хезмәт ияләреннән кызыл партизаннарга» дип язылган. Шагыйрь бу листовканы — белорус һәм татар халыкларының якын дуслыгы билгесен — үзенең китап һәм кульязмалары арасында аеруча кадерләп саклаган». Мозольковның язуына караганда, бу листовкаларны вакытлыча дошман кулында калган белорус җирләренә самолетлардан ташлаганнар. Анда аларны агачларга, коймаларга ябыштырганнар, телдән-телгә сөйләп, кулдан-кулга күчереп язып йөрткәннәр.

Партизаннар, партизаннар,
Белорус егетләре,
Турагыз сез дошманнарны,
Тунагыз сез шакшы җанны —
Кара сугыш этләрен.
...Алыгыз сез туган җирнең,
Янган икмәкнең үчен,
Газиз туганнар өчен,
Куыгыз туган илдән! —
Сәз төбендә булсын гүре:
Җавап канга — тик кан белән,
Үлемгә — үлем белән!

Мин бу юлларны Печищеда Янка Купала яшәгән бүлмәдә искә төшердем. Ләкин мине шагыйрьнең иҗаты гына түгел, аның мондагы тормышы, кемнәр белән аралашканлыгы да кызыксындыра иде. Шул турыда сораша торгач, Алексей Иванович Масленников, Кузьма Алексеевич Антоновларны эзләп таптым. Кузьма Алексеевичны поселок халкы Кузя абый дип йөри икән. Кузьма Алексеевич Янка Купаланы яхшы хәтерли. Тик ул аны Иван Доминикович дип атый. Кузьма Алексеевич Янка Купала белән еш очрашкан: шагыйрь аларның мунчасына юынырга килә торган булган.

— Ул чакта,— ди Кузьма Алексеевич,— заманалар авыр булды. Үзегез дә беләсез, тәмәке һәм шикәр дигән нәрсәләр бик кысан иде. Менә шул чакларда Иван Доминикович күргән саен мине үзләренә чәйгә яки тәмәке тартырга чакырмыйча калмый иде.

Иван Алексеевич Масленников Янка Купаланы шулай ук зур хөрмәт белән искә ала. һәм миңа Сәхап Сәләхетдинов белән сөйләшергә киңәш бирә. Сәхап абзый шул елларда Печище он заводының баш технологы булып эшләгән икән. Ул миңа Янка Купала турында менә нәрсәләр сөйләде: «Янка Купала безгә гаиләсе белән 1941 елның ноябрендә килде. Безнең Печищены ошатты. Ул эшне бик ярата иде. Безнең белән бик еш сөйләшә. Тәүлегенә 12 шәр сәгать эшләп, үзләренә тиешле булган атнага бер көнлек ялдан да баш тарта торган гади кешеләрнең кыюлыгына һәм хезмәттәге батырлыгына соклана торган иде.

Фронтка киткән ирләре, абыйлары-энеләре һәм уллары урынына ул чакта хатын-кызлар эшләде. Алар сынатмадылар, завод үзалдына куелган бурычны уңышлы үтәп барды. Иван Доминикович еш кына завод эшчеләренең җыелышларына килә, анда чыгыш ясап, халыкның рухын күтәрә торган иде. Әле хәзергедәй күз алдымда: 1942 елда безнең завод эшчеләре үз хисапларына танк колоннасы төзү өчен, 200 000 сум акча җыеп тапшырдылар. Аннары завод январь һәм февраль айлары планын да вакытыннан элек үтәде. Менә шул уңышларыбыз белән котлап һәм рәхмәт белдереп, 1942 елның февраль ахырында завод коллективы исеменә хөкүмәт телеграммасы килде. Ул телеграмманы заводта митинг җыеп укыдылар. Митингта Янка Купала да катнашты.

1942 елның май башларында Иван Доминикович мине үзенең машинасы тора торган гаражга чакырды.

— Карап карагыз әле шуны,— диде ул миңа.— Нигәдер чыгымлабрак тора.

Мин аның машинасын бик тиз көйләдем. Радиаторына су салдым да:

— Иван Доминикович, рәхим итеп, утырыгыз! — дидем.

Машинасы шушылай тиз төзәлгәнгә ул гаҗәпләнде һәм бик нык сөенде. Соңыннан без аның бу машинасына утырып, Идел буйларына чыга торган булдык. Машинасын гел миңа йөрттерә иде ул. Иван Доминикович һәрвакыт машинаны Казан яхшырак күренә торган җирдә туктаттыра. Озак-озак шәһәргә карап тора, аның турында миннән дә сораштыра. Шунда сүз арасында Минск шәһәре һәм үзенең туган җире — Полесье хакында да сөйли торган иде...»

Сәхап агайга рәхмәт әйтеп, Идел буендагы текә яр өстенә киләм. Җирле халыкның әйтүенә караганда, Янка Купала нәкъ менә шушы төшкә килеп, уйланып тора торган булган. Ниләр уйлады икән ул монда?

Идел дулкыннарына карап торганда, ул, бәлки, бүтән елганы — Неман ярларын күз алдына китергәндер. һәм беренче рус революциясеннән соңгы кара реакция елларында шул елга ярларында дусты Якуб Колас белән очрашкан вакытларын хәтерләгәндер. Ихтимал, ул заманнарда икесе бергәләп крестьяннарның авыр тормышы өчен кайгырып йөрүләрен, шул хакта җырлар язуларын тагын бер кат күңеленнән кичергәндер. Белорус жалейкасының моңлы һәм кайгылы көйләрен ишеткән сыман булгандыр.

Ә ул заманнарда менә монда, Идел буенда, шундый ук моңлы һәм хәсрәтле көйләрне белоруслярның жалейкасына бик охшаш булган уен коралында — курайда уйнаганнар. Татар халкының моңын, уй-хисләрен чагылдырган ул көйләрне татарның үз шагыйре — Габдулла Тукай тыңлаган.

Янка Купала һәм Габдулла Тукай. Алар замандашлар булган. Бер-берен белмәганнәр. Алар бер юлдан барганнар. Бала чактагы авыр тормышлары да бик нык охшаш, беренче шигырьләренең яңгырашлары да авазташ. Тегендә, Неман буйларында да, монда, Идел тирәләрендә дә, бер үк төрле кайгы — халык кайгысы хөкем сөргән. «Мужик йокысы»н Тукай әнә шул хакта борчылып язган. Янка Купаланың «Мужик» исемле шигыре шундый ук хис белән сугарылган.

Рус халкы белән дуслык темасын Белоруссия поэзиясендә беренче булып Янка Купала күтәреп чыккан булса, татар поэзиясендә шул ук мәсьәләне Габдулла Тукай алга сөрә. Патша ялчылары татар халкын солтан Төркиясенә куган бер вакытта, Тукай бу эшнең мәгънәсезлеген фаш итеп:

**Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:**
**Мондагы ук урынына ул җирдә унбиш шпион.**
**...Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл:**
**Бәйләмеш бу җиргә безне тәңремез (гыйззе вә җәл).**
**Иң боек максат безем: — хөр мәмләкәт, хөр Русия!**
**Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруhе ру сияh! —**

дип язган.

Әйе, Тукай һәм Купала бер-берсен белмәгәннәр. Ләкин аларның иҗатлары ава
даш булган. Шунысы аеруча игътибарга лаек: бу ике шагыйрьнең иҗатын да Горьки
өйбәт белгән һәм аларга зур өмет баглаган. Мәсәлән, ул 1907 елда Янка Купаланы
«А там кто идет?» («Ә анда кем килә?») исемле шигыренә югары бәя бирә һәм, үз
тәрҗемә итеп, ул шигырьне беренче мәртәбә рус телендә бастырып чыгара. Шул у
чорда, шул ук бөек Горький инициативасы белән Габдулла Тукай шигыре дә беренч
тапкыр рус телендә бастырып чыгарыла. Менә шулай итеп, белорус һәм тата
шагыйренең иҗатлары үзара дуслашып, рус халкы каршына килеп басалар.

...Менә монда, Иделнең текә ярында утырганда, Янка Купала, ихтимал, үзене
чордашы һәм каләмдәше Тукайның язмышы турында да уйлагандыр. Әйе, шулайдыр
Чөнки алар, читтән торып кына булса да, танышлар бит: 1939 елны «Давид Сосунский»
ның 1000 еллык юбилее көннәрендә Ереванда очрашкан чакта Хәсән Туфан белә
Гази Кашшаф Тукай турында да сөйләгәннәр аңа. Хәтта шигырьләренең русча тәрже
мәләрен дә укып күрсәткәннәр. Ә Купала ул шигырьләрне бик яратып тыңлаган.

Ул елларда сугышның авырлыгы фронтларда гына түгел, монда — Печищеда д
сизелеп торган. Шул ук вакытта илебез халыкларының ныклыгын, дошманны җиңүг
зур ышанычын да тойган Янка Купала. Шуңа куанып, рухланып яшәгән ул һәм дәртлә
неп иҗат иткән. Бу хакта аның художник Елисеевка сөйләгән сүзләрен искә төшере
үтик: «Бер көнне,— дип сөйләгән ул Елисеевка,— Идел буенда һава сулап йөргәнд
миңа шушы як кешесе, бер татар очрады. Яныма ук килеп, баш иеп исәнләште. Ми
дә исәнләштем һәм үз юлым белән ары киттем. Борылып кайтып килгәндә бу кеше
тагын миңа каршы очрады һәм тагын шулай баш иеп исәнләште. «Гафу итегез,— ди
тегеңә,— без синең белән кайда очрашкан идек соң? Мин һич хәтерли алмыйм». Ә у
миңа әйтә: «Безнең беркайчан да очрашканыбыз юк һәм сез мине белмисез дә. Ә
мин сезне газетада басылып чыккан рәсемегез буенча таныдым. Сез—Янка Купала!»—
ди. «Әйе,— дидем моңа,— мин Янка Купала булам». Менә, күрәсез, мин ялгышмаган
мын,— ди теге кеше.— Мин сезнең белән шуңа дустанә исәнләштем, чөнки шигырьлә
регезне укыганым бар. Сезнең шигырьләрне татарчага тәрҗемә итеп бастырдыла
бит. Шуңа мин сезне үземнең танышым дип саныйм». Шигырьләремне төрле телләр
гә, шул исәптән татар теленә дә, тәрҗемә итүләрен мин, әлбәттә, белә идем. Ләки
татар, үзбәк, әрмән, чуваш һәм башка халыклар мине үз танышлары итеп санаулары
нәкъ әнә шунда, Идел буенда гына аеруча ачык аңладым. Төрле милләт халыклар
минем Белоруссиямне нигә алай нык тырышып яклаганны әнә шунда тагын да тирән
рәк төшендем: бөтен Совет җире — безнең илебез ләбаса! Аның һәр почмагын якла
калу өчен, шуңа безнең теләсә кайсыбыз корбан булырга әзер тора. Безнең көчебе
әнә шунда. Шуңа мин үземнең Белоруссиямне тиздән элеккечә ирекле һәм чәчәк аты
утырган итеп күрәчәгемә ышанам...»

Янка Купаланың бу сүзләрен искә алгач, шагыйрьнең туган илен яклап көрәшкә
курку белмәс татар сугышчылары күз алдыма килде. Белорус җирендә фашистларг
каршы сугышта бик күп татар көрәшчеләре катнашкан. Шуларның берсе — шагыйр
Зәки Нури. Белорус урманнарында сугышкан Заслонов отрядының разведчигы Зәк
Нури бер үк вакытта каләме белән дә дошманга каршы көрәш алып бара. Шул у
1941 елда, Янка Купаланың дошманны тар-мар итәргә өндәп язган «Белорус партизан-
нарына» җавап биргәндәй, Зәки Нури менә болай дип яза:

**Агачларны давыл ексын,**
**Чәчәкләрне — кырыс кышлар.**
**Сине үлем җиңмәс, дустым,**
**Безне пуля алмас, дуслар.**

Ачы булса, кайнар булса,
Кабергә һич кумелмәс уч.
Ярсып торса, ташып торса,
Уттан куркып чигенмәс көч.

Без бу сугышта араның
Иң ерагын иңләүчеләр,
Сакчысы Ватан-ананың,
Һәм шуңа без — үлмәүчеләр!

Ә икенче бер шигырендә зур ышаныч белән:

Бер урында йөзләп шахта,
Йөзләп домна корырбыз.
Изге тынычлыкны саклап,
Сизгер постта торырбыз,—

дип язды.

Авыр сугыш елларында безнең Казан янында, Идел буенда яшәгән Янка Купала да нәкъ шул турыда хыялланган:

Бәйрәм киемнәрен кияр халык,
Сүнәр җирдә сугыш ялкыны,
Совет әләмнәре элеккечә
Безнең кулда торыр талпынып.

Һәм хәзер, утыз елдан соң, нәкъ менә шушы Идел ярында торганда әлеге ике милләт шагыйрьләренең һәм төрле буын шагыйрьләренең фикерләр авaздашлыгын, «заманалар бәйләнешен», бөек традицияләр бәйләнешен һәм илебез халыкларының мәңге какшамас дуслыгын тойдым мин. Бу традицияләрнең тамырлары бик тирәнгә киткән. Алар безнең көннәрдә дә яшиләр һәм бу хәл киләчәктә дә шулай булачак. Халыклар үлемсез булган кебек үк, ул традицияләр дә мәңгелек.

Ул көнне мин Печищедан, иркенләп йөреп, Казанга соңгы рейс белән генә кайттым. Кояш баткан, Идел өстенә кичке эңгер иңгән, табигать тынып калган иде. Ләкин иртән миңа хәерле юл теләп киткән музыка — Чайковскийның гаҗәеп музыкасы тавышы киң Идел өстендә әле һаман яңгырый сыман иде.

## Иван Колесник

●

Күзге кич. Күк томан йоклаган
Саргайган талларны кочаклап.
Күгелҗем урманнар буенда
Тын гына яналар учаклар.

Хуш, сау бул, бала чак, хуш, миңа
Әйләнеп кайтмассың син тагы...
Шып-шыр, буш басуда малайлар
Яндыра бәрәңге сабагы.

Ә күктә торналар авазы
Нигәдер ямансу, кайгылы.
Көз киткән торналар яз җиткәч
Бу якка әйләнеп кайтырмы?

Бер сүнгән учаклар бу җирдә
Яңадан кабынмас бит инде.
Бер киткәч яңадан әйләнеп
Кайтмаган бала чак шикелле.

●

Энҗе-мәрҗәннәр,
Сәйләннәр тагып,
Балкып утыра
Каштаннар тагын.
Яз — мәңгелек җыр,
Йөрәгем, тыңла —
Яшел каштаннар
Кушыла җырга.

Кушылып җырла
Син дә, сөйгәнем —
Онытмыйк кемнәр
Бәхет биргәнен.
Кемнәр дошманга
Каршы басканнар —
Шул хакта җырлый
Яшел каштаннар.

Язмышы шундый
Булган аларның.
Тик бер тапкыр да
Сөйгән ярларын
Үпмәгән килеш
Утта янганнар,—
Туган илләрен
Саклап калганнар.

Онытма, дустым,
Берүк онытма:
Җирдә яз моңы
Тынмасын өчен,
Каштаннар мәңге
Җырласын өчен,
Япь-яшь көенчә
Янганнар утта.

●

Ничәнче кат инде, ничәнче кат
Өй түреннән узам, сизәмсең;
Башка кызлар күптән су буенда,
Ә син чыкмый ничек түзәсең?

Гармунчы да төште гармун сызып,
Алтын юллар суда, күрәмсең;
Ай юлына чия чәчәк сибә,
Ә син чыкмый ничек түзәсең?

Ай юллары буйлап көймәләрдә
Синең белән кила йөзәсем.
Мәхәббәткә сусап тибә йөрәк,
Ә син чыкмый ничек түзәсең?

ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН тәрҗемәләре.

Малик Хәмитов

# ОЧЕРК ГЫЙБРӘТЛЕ БУЛСЫН

Моңарчы күрелмәгән зур төзелеш, XXIV съезд куйган бурычларны тормышка ашыручы замандашларыбыз башкарган гаять зур эшләр әдәбият ишеген торган саен ныграк кага. Халкыбыз алдына куелган яңа бурычлар язучылардан тормышны тагы да киңрәк колач белән, тагы да тирәнрәк итеп чагылдыруны таләп итә. Үзләренә ышанып тапшырылган зур эшләрне заманга лаеклы итеп башкаручы хезмәт кешеләренең язучыларыбыз иҗат иткән әсәрләрдә үзләренә үрнәк булырдай замандашлары образын күрәселәре килә. Бу бик табигый.

Зур әдәбиятның тулы хокуклы бер жанры булган очерк катлаулы тормыш вакыйгаларының килеп ишек шакуын гына көтеп ята алмый.

Очерк жанрын, гадәттә, разведкага тиңлиләр. Ә соңгы вакытларда бу жанрның әһәмиятен, бу жанрның зарурилыгын, аңарга игътибарның көчәйтелергә тиешлеген раслап, аны мәргән мылтыгына охшатучылар да күренә. Димәк, тисә тиенгә, тимәсә ботакка түгел. Очеркның бурычы — сүз чын очерк хакында бара — биография анкетасындагы белешмәләрне теркәп чыгу түгел, аның максаты, тенденциясе булырга тиеш. Бу — мәҗбүри. Бу зур әдәбиятның һәр жанры өчен уртак таләп.

Соңгы вакытта проблема, проблемалы очерк турында сөйләү модага әверелде. Аңлашылмый: проблемасыз әдәби әсәр була аламы икәнни соң?..

Бу сөйләнүләр проблема өчен проблемага кайтып кала башлады!

Калын әдәби журналларда чыккан очеркларны, публицистик мәкаләләрне күзәтеп бару шуны күрсәтә: күп кенә авторлар, «проблема чире» белән мазыгып, игътибарны бары тик бер нәрсәгә юнәлтә башладылар. Фәлән министрлыкның, фәлән главканың, фәлән заводның, фәлән предприятиенең, фәлән авыл хуҗалыгы идарәсенең шундый-шундый кимчелекләре бар. Аларны бетерергә кирәк. Куйган проблемалар күбесенчә шулардан гыйбарәт була.

Бу «проблема»ларны авторлар башлыча өлкә, республика, союз күләмендә үткәрелгән киңәшмәләрдә ясалган докладлардан табалар. Шул фактларны теркәп баралар да, объектларга килеп, докладларда күрсәтелгән кимчелекләргә кагылышлы вакыйгаларны язып кайталар. Менә сиңа проблемалы очерк. Һәм аны журналга тәкъдим итәләр. Басылып та чыга ул. Тик моның файдасы бармы соң?..

Тагын. Әйтик, очеркист объектка килә. Заводкамы, төзелешкәме, авыл хуҗалыгы идарәсенәме — эш анда түгел. Эш шунда: ул, проблема күтәрәм диган булып, һәр төрле кимчелекләрдә казына. Шуларга таянып очерк яза. Басылып та чыга. Файдасы бармы?..

Мондый очракларны дәвам итәргә мөмкин. Үз иҗатына кәсеп итеп караган авторларга мондый мөмкинлекләр күп. Әлбәттә, ул проблема күтәрә торган очеркист булып телгә керә. Ә ул сурәтләгән «кимчелекләр» шул өлкәдә эшләүче һәркемгә билгеле. Белгечләр, җитәкчеләр, эшчеләр, җәмәгать оешмалары шул проблеманы хәл итү өстендә эшлиләр. Тән йокламыйлар, шулар турында кайгыртып, семьяларын, туганнарын, дус-ишләрен онытталар. Болар турында очеркта бер сүз дә юк. (Ә очерк нәкъ әнә шул турыда язылырга тиеш иде!) Үсештә гел була торган каршылыклар шулай итеп бер яклы гына сурәтләнә.

Юк, мин проблемага каршы түгел, әмма ул гыйбрәтле булсын, зарарга булмасын!

Хәзер республикабызда зур төзелешләр бара. КамАЗ төзелешен бөтен дөнья күзәтә. Бу төзелеш, әлбәттә, иң беренче чиратта, очеркларда үз чагылышын табарга тиеш. Үзәктәге газета-журналларда, радио һәм телевидение буенча да, безнең матбугатта да бу төзелеш, анда эшләүче кешеләр, ул кешеләрнең тормышлары, омтылышлары, эчке кичерешләре даими яктыртылып бара.

Кама буенда бу гигант төзелеш башланган көннәрдә үк «Казан утлары» журналында мәрхүм Сәббух Рафиковның автозавод турында зур очеркы басылып чыкты. Бу — төзелеш елъязмасына керерлек әһәмиятле әсәр. Анда автор төзелешнең башлангыч чорын күп төрле кешеләрнең язмышлары белән бәйләп һәм җирле мохиттә, җирле фонда сурәтли. Геннадий Паушкин, Рәхмәй Хисмәтуллин, Тәүфыйк Сәгыйтовларның журналда басылган очеркларын укып карасак, аларда без төзелешнең төрле яклары, төзелешкә бәйләнешле төрле кешеләрнең язмышлары гыйбрәтле итеп, укучы күңеленә ятышлы рәвештә сурәтләнүен күрәбез. Ә Диас Вәлиевнең журналның быелгы 1 санында басылып чыккан «Хәрәкәттә бәрәкәт» очеркында төзелешнең колачы, андагы кешеләрнең язмышлары, омтылышлары, андагы кыенлыклар һәм мөмкинлекләр шулай ук ышандырырлык итеп, тормышчан итеп бирелә. Мондый очерк язу өчен авторга, әлбәттә, бер көн җитәкче машинасында утырып йөрү генә җитми. Андагы кешеләр язмышын үз язмышың итеп тою, аларның уй-теләкләре белән яшәү, катлаулы зур хезмәт кирәк.

Инде килеп, яшь автор Равил Вәлиев очерклары турында. Бу егет, университетта журналистика бүлеген тәмамлаганнан соң, Чаллыга бара да гади ташчы булып төзелешкә эшкә керә. һәм көндәлекләр алып бара. Менә «Казан утлары» журналының 2, 3, 4 саннарында Равил Вәлиевнең «Каурыйлар чыныкканда» исемле очерклар циклы басылып чыкты. Бу очерклар шуның белән характерлы: монда автор гастролер түгел, тегә яки бу җитәкче машинасына утырып төзелештә өстән-өстән күргән очраклы күренешләр турында гына язмый, ул төрле яктан килгән төрле милләт егетләренең һәм кызларының үзара мөнәсәбәтләрен, үз омтылышларын, үз кичерешләрен сурәтли. Төрле кыенлыклар, төрле каршылыклар кичереп, җиде ят кешеләр бер коллектив булып, көчле коллектив булып тупланалар. Бу процесс авторның тирә-юньгә мөнәсәбәте, уй-хисләре, кичерешләре аша бирелә. Шул ук вакытта анда коллектив һәм кеше, шәхес һәм җәмгыять, төзелеш һәм коллектив, производство һәм кеше мөнәсәбәте проблемалары куела. Әмма проблема кую бер нәрсә, ә аны хәл итү — икенче. Ә менә Равил очеркларында проблема куелып кына калмый, коллективның шул проблеманы хәл итүдәге тырышлыгы, шул процессга аның нигезе сурәтләнә. Бу очеркларны яшь авторның җитди уңышы дип әйтәсе килә.

«Казан утлары» журналында узган ел утыз табактан артык очерк һәм публицистик мәкалә басылды. Тематик яктан аларны түбәндәгечә классификацияләргә мөмкин:

**Беренче.** Замандашларыбызның рухи дөньясын, социалистик тормыш тәэсирендә туган яңа сыйфатларны, яңа мөнәсәбәтләрне сурәтләгән очерклар. Журналның узган елгы саннарында мондый характердагы очерклар дистәдән артык. Р. Хисмәтуллинның «Тиреннән чыккан шытымнар», М. Хәснимәрдәновның «Югары нокта», Ә. Рәшитовның «Өченче очрашу», К. Зариповның «Җәлил шәһәре», А. Маловның «Тәвәккәллек», М. Насыйбуллинның «Эзләр кая илтә?» очерклары материалны тирәнтен өйрәнеп, гыйбрәтле итеп язылганнар.

**Икенче.** Фән кешеләре, фән һәм тормыш турында җиде очерк басылган.

**Өченче.** Гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы батырлары, халык бәхете өчен көрәшүчеләрне сурәтләгән очерклар. Мондыйлар сигез очерк. Алар арасында Ш. Маннурның «Һаман да иста» исемле язмалары, С. Хәкимнең «Күңелдән юылмаган эзләр» дигән истәлекләре, Ә. Маликовның «Куриль чәчәкләре», А. Мөслимовның «3309 номерлы мандат», Р. Хәйретдинов белән Г. Кәримовның «Комиссар каны» исемле очерклары аеруча игътибарга лаек.

Әлбәттә, аларның һәрберсендә кеше язмышы сурәтләнә, кеше бүгенге катлаулы техника һәм фән казанышлары фонында бирелә. Аларда замандашыбыз, хәзерге заманның катлаулы техникасына хезмәт күрсәтүче кешеләрнең рухи дөньясы, кеше язмышының ил язмышы белән бәйле этаплары, геройның заманыбызга хас философик фикер йөртүе гәүдәләнә. Очерк

жанрына карата журнал редакциясе тоткан төп юнәлешләр бу очеркларда ачык күренә.

Әлбәттә, очерк жанрының мөмкинлекләре зур. Югарыда телгә алынмаган, әмма укучылар кызыксынып укый торган башка төр материалларны да санап үтәргә мөмкин. Мәсәлән, Рафаэль Мостафинның «Оҗмахка сәяхәт», А. Скрипникның «Могҗизаның сере» исемле язмалары. Аларны да укучылар журналның бер матур сәхифәсе итеп кабул итәләр, кызыксынып укыйлар. Шулай ук журналда укучыларга тәкъдим ителгән кайбер тарихи материалларга да тукталып үтәргә кирәк.

Университет укытучысы, тарихчы Сәвия Латыйпованың узган ел июль санында Ибраһим Хәлфин эшчәнлеге турында эзләнүләре басылып чыкты. Анда халкыбызның күренекле мәгърифәтчесе Ибраһим Хәлфиннең күп кырлы хезмәте шул заманда ук инде Европаның күп кенә галимнәре өчен житди чыганак булып хезмәт итүе яктыртыла. Бу хезмәтләрдән Фридрих Энгельсның да файдалануын автор ышандырырлык итеп исбатлый. Мондый характердагы материалларны журнал битләрендә әледән-әле күрергә була. Мәсәлән, тарихчы Сәлам Алишевның татар полковникларының Пугачев восстаниесендәге батырлыклары турындагы материаллары белән укучылар иң беренче журнал аша таныштылар.

Мондый материаллар язучыларны роман, повесть, поэма кебек киң пландагы әсәрләр язарга илһамландыра.

Очеркны зур әдәбиятның тулы хокуклы жанры дигән идек. Әмма, башка жанрлардан аерым буларак, аның үз кыенлыклары да бар. Очеркист, күп кешеләрдәге аерым сыйфатларны бер геройга туплап, образны типиклаштыра алмый. Ул, киресенчә, замандашларыбыз өчен типик сыйфатларны бер кешедән табарга тиеш. Аның адресы, яшәгән урыны, эшләгән җире конкрет, чынбарлыктагыча булсын. Шуңа карамастан, очерктан да, иң беренче, кешене сурәтләү, аның үзенә генә хас характер сыйфатларын, кешенең социаль мөнәсәбәтләрен, аның тирәсендәге социаль мохитны, кешенең сәләтен, омтылышын, мөмкинлекләрен, әхлагын тасвирлау таләп ителә. Геройны коры сүз белән генә мактау яки яманлау җитми, тормыш вакыйгалары, эчке кичерешләр, аның тирә-як белән мөнәсәбәте аша җанлы итеп сурәтләргә кирәк. Ә аларны очеркта уйлап чыгарып кына язып булмый, ә сайлаган героеңның тормышыннан эзләү таләп ителә. Кыскасы, үз героеңның тормышын, эшчәнлеген, коллективтагы урынын, аның характерына хас уңай сыйфатларны, эчке асылын бәйнә-бәйнә өйрәнми торып, кызыклы, чын-чынлап гыйбрәтле очерк язып булмый. 1971 елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан очерклардан Валентина Гудкованың «Эзләнү азимуты», Нигъмәт Ихсановның «Һәрвакыт юлда», Касыйм Фәсәховның «Сүзе алтын, эше ялкын», Рәхмәй Хисмәтуллинның «Тирәннән чыккан шытымнар», Тәүфыйк Сәгыйтовның «Галимулла аганың истәлекле көне» очеркларын, кайбер кимчелекләре булуга карамастан, әнә шундый житди таләпләрдән чыгып язылган очерклар диясе килә. 9 санда чыккан «Тирәннән чыккан шытымнар» исемле очеркны алып карыйк. Бу очеркында Р. Хисмәтуллин Чаллы районындагы «Гигант» колхозы председателе Зыя ага Закиров тормышындагы берничә вакыйгага тукталa:

Производство идарәсе начальнигы белән конфликт һәм председательнең тормышка, тәҗрибәгә нигезләнгән инициативасының җиңеп чыгуы;

фашистларга каршы сугышып үткән юллар;

артта калган, таркалу хәлендәге күрше колхозы белән берләшү;

колхоз территориясендә гигант автозавод салу.

Кыска гына очеркта менә шул вакыйгалар белән мәнәсәбәттә Зыя Закировка хас характер сыйфатлары да, тирә-юньгә, тормыштагы төрле хәлләргә аның мөнәсәбәте дә, семья хәле дә күз алдына килеп баса.

Югарыда әйткәнемчә, очеркистның төп максаты кара күзлек киеп, чүп-чарда казынуда түгел; теге яки бу кимчелекләрне тискәре күренешләрне эзләүдән бигрәк, ул уңай башлангычны күрә белергә, аның үсеш мөмкинлекләрен, юнәлешен тәсмерләргә тиеш. Очеркның тенденциясе шул уңай башлангычның үсеш процессын, җиңеп чыгуын өйрәнүгә, сурәтләүгә юнәлдерелгән. Ә тискәре күренешләр, тормышның караңгы яклары, кешеләр аңындагы искелек калдыклары белән күбрәк фельетон жанры көрәшсен! Кайбер тәнкыйтьчеләрнең очеркистан суд тикшерүчесе эшен таләп итүләре, әлбәттә, урынсыз. Проблеманы җитәкчеләр ясаган докладлардан гына түгел, урыннардагы объектлардан, төзелешләрдән, завод-фабрика цехларыннан, нефть промыселларыннан, югары уку йортларыннан, фәнни институтлардан, катлаулы табигать шартларында яшәүче, уңдырышсыз җирләрне культура-

лаштырып, иң алдынгы хуҗалыклар дәрәҗәсенә ирешергә омтылучы колхоз һәм совхозлардан эзләргә кирәк. Соңгы елларда партиябез һәм хөкүмәтебезнең авыл хуҗалыгына карата күп кенә мөһим карарлары чыкты. Очеркистларга аерым бер хуҗалык фонында бу карарларның әчтәлеген сөйләү генә җитми, ул карарларны тормышка ашыру процессын, шул процесста туган хезмәт батырларын, аларның рухи дөньясын сурәтләү, шул процесста әледән-әле барлыкка килгән тормыш каршылыкларын, табигать белән көрәш яки аңа яраклашу күренешләрен гәүдәләндерү зарури.

Авыл хуҗалыгы кешеләре белән кызыксынучы очеркистлар төп игътибарларын авыл хуҗалыгында эшләүче кешеләр хезмәтен индустрияләштерүгә, хуҗалыкны үстерүне фәнгә нигезләү проблемасына, авыл кешеләренең культура таләпләрен канәгатьләндерү, культура зәвыкларын үстерү мәсьәләләренә юнәлдерсәләр, тормыш таләпләренә һәм максатка якынрак килерләр иде.

Ә боларны сурәтләү өчен авыл хуҗалыгының һәр өлкәсен, белгечләрнең, механизаторларның эшен, фәнни хезмәтләрне җентекләп өйрәнү кирәк. Төрле хуҗалыклар белән язучыларның элемтәсен ныгытасы бар. Ә бездә соңгы елларда язучыларны авыл хуҗалыгы буенча республика күләмендә үткәрелгән киңәшмәләргә чакыру да бетте. Ә ун еллар элек мондый киңәшмәләргә махсус чакырулар килә иде, югары оешмалар язучыларга конкрет заданиеләр тапшыралар иде. Моны авыл хуҗалыгы буенча гына түгел, КамАЗга карата да, нефть районнарына, башка өлкәләргә карата да үткәрергә мөмкин бит. Танылган язучыларыбызга мондый конкрет заданиеләр күптәннән җыелып килгән фикерләрен туплау, аларны укучыга җиткерү өчен этәргеч булыр иде.

«Казан утлары» журналыннан тыш, «Азат хатын», «Ялкын» журналлары, «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Яшь ленинчы» газеталары да очеркларга, публицистик чыгышларга даими урын биреп киләләр. Язучыларыбыздан Г. Бәширов, Г. Әпсәләмов, Н. Дәүли, Б. Камалов, Ш. Бикчурин, М. Маликова, К. Тимбикова, И. Низамов һ. б. ларның материаллары укучылар күңеленә аеруча ятышлы. «Социалистик Татарстан» газетасы редколлегиясе күптән түгел Р. Хисматуллинның «Якты ташкын», «Назлы җилләр искәндә», М. Рәфыйковның «Килен», «Ашлык фронты Газинурлары», М. Насыйбуллинның «Кан таплары» очеркларын узган елда басылып чыккан иң яхшы материаллар дип билгеләп үтте.

«Татарстан яшьләре» газетасы очеркларга, публицистикага киң урын бирә. Бу газета битләрендә басылып чыккан очеркларда республикабыз яшьләре тормышы, яшь игенчеләрнең һәм терлекчеләрнең, төзүчеләрнең һәм эшчеләрнең, спортчыларның һәм сәхнә осталарының, галимнәрнең һәм укытучыларның, партия-комсомол работникларының эшчәнлеге даими яктыртылып бара. Шунысы куанычлы: «Татарстан яшьләре» аша әдәбиятка, журналистикага аяк баскан күп кенә иптәшләр хәзер дә газета белән дуслыкларын дәвам иттерәләр. Язучы Барлас Камаловның бу газетада актив эшчәнлеген аеруча билгеләп үтәсе килә. Аның республикабыздагы хезмәт фронтының алгы сызыгыннан язган һәр очеркын «Татарстан яшьләре» газетасын укучылар яратып каршы алалар.

КамАЗ төзелешендәге атаклы төзүчеләр бригадасы җитәкчесе Вазих Мәүлихов турында күп язылды инде. Укучылар аны Г. Паушкинның «Чаллы җирендә» китабы буенча да, элек шушы бригадада ташчы булып эшләгән Равил Вәлиевнең «Казан утлары» журналында басылып чыккан очеркларын укып та яхшы беләләр. Җ. Кәлимуллинның «Татарстан яшьләре» газетасында басылып чыккан «Так держать, улым!» очеркы да В. Мәүлихов һәм аның бригадасына багышланган.

Автор материалга үзенчә килгән һәм уңышлы гына очерк иҗат иткән. Очеркны укыганда, без Шәмәрдән станциясендә булабыз, геройның ата-анасы, туганнары белән танышабыз, герой белән бергә Юдино эшчеләр поселогына күчәбез, аның техник училищены бетереп, төзүче булып чыгуын һәм аның катнашында салынган беренче зур йортны күреп, автор белән бергә куанабыз.

Очерк Вазих биографиясендәге фактларны хронологик тәртиптә коры теркәп бару рәвешендә генә язылмаган. Аның эзлекле сюжеты Вазих язмышын гына түгел, бригада коллективының омтылышын, төзелештәге башка бригадалар белән бәйләнешен, мөнәсәбәтен дә, эштәге төрле кыенлыкларны да күз алдына китереп бастыра. Мәүлихов бригадасының төзелештә алдынгы булырга лаек икәнлегенә, бригадирның яңага юл ача белүче, зирәк

акыллы һәм дәртле йөрәкле егет булуына ышанасың.

Республика газета-журналларыннан тыш, узган елда Татарстан китап нәшрияты да дистәгә якын очерклар китабы чыгарды. Аларның иң мөһимнәре: Ф. Мостафинның «Врач язмалары», Рәшит Ибраһимовның «Көмеш канатлар», Абдулла Сәләхетдиновның «Туган җирем Татарстан», Марсель Зарипов белән Рәис Сабировның «Кара алтын чишмәсе», Гариф Ахунов белән Марсель Зариповның «И кадерле туган як» китаплары.

Әгәр дә Фаик Мостафинның врач икәнен, хирург икәнен белмәсәм, мин бу китапның авторын тәҗрибәле журналист икән дип уйлаган булыр идем. Китапка кергән һәр очерк — стиле белән дә, җанлы теле белән дә, авторның кыска гына язмада күп материалны сурәтли алуы белән дә, эзлекле бер сюжетка корылуы белән дә — игътибарга лаек.

«Профессиям турында» дип исемләгән автор кереш сүзен. Чын публицистик ялкын, үз һөнәренә тирән мәхәббәт белән сугарылган тирән эчтәлекле мәкалә ул. «Ач күзеңне, сабый» дигән кыска гына, алты битле очеркта Социалистик Хезмәт Герое Газифә Хәсәншинаның бөтен тормышы, аның үзенә генә хас характер сыйфатлары, чыннан да герой булырга лаек икәнлеге күз алдына килеп баса. Ә «Бәхетле кеше» очеркында Фаик яшь галим, фән докторы, исеме бөтен фән дөньясына билгеле Диләвер Зөбәеров турында йөгерек тел, матур стиль, эчке бер җылылык белән яза. Галимнең эшчәнлеге фән дөньясы белән таныш булмаган кешеләр өчен дә аңлаешлы итеп, популяр формада ачыла. Автор һәр очеркында үз-үзенә таләпчән килгән һәм кызыксынып укырлык файдалы китап чыгарган. Очеркларда авторның һәр мәсьәләгә үз мөнәсәбәте ярылып ята. Укучының дөньяга карашын киңәйтүдә, белемен үстерүдә дә китапның әһәмияте зур.

Рәшит Ибраһимовның «Көмеш канатлар» китабының да танып-белү, тәрбияви әһәмияте зур. Без бу китаптан очучының үз тормыш юлы белән генә түгел, авиация тарихы, Советлар Союзында авиациянең үсеше, атаклы очучылар, очучы хезмәтенең үзенчәлекләре белән дә танышабыз. Бу китап та эзлекле бер сюжетка корылган, җанлы тел белән язылган.

Югарыда телгә алынган китап авторларының исемнәрен без газета-журналларда еш кына күрәбез. Алар икесе дә, үз өлкәләрендә тәҗрибәле белгеч булу белән бергә, оста журналистлар да.

Абдулла Сәләхетдинов, Марсель Зарипов белән Рәис Сабиров, Гариф Ахунов белән Марсель Зарипов китаплары да кызыклы, мавыктыргыч, гыйбрәтле. Аларда республиканың бүгенге казанышлары калку итеп сурәтләнә, ирешелгән уңышларның асылы бөтен тирәнлеге һәм киңлеге белән күз алдына килеп баса.

«Туган җирем Татарстан» китабында Абдулла Сәләхетдинов әкият стиле белән язылган кечкенә-кечкенә новеллалар аша Магнитогорск геройлары, Ярослав Гашекның Татарстандагы маршруты, республика энергетиклары, нефть предприятиеләрендә эшләүчеләр, Бөгелмә галимнәре, Түбән Кама шәһәре, Апас яклары белән таныштыра. Китапка кергән очерклар публицистик пафос белән язылган, җиңел укыла. Әмма промышленность кешеләре турында кызыклы, мавыктыргыч итеп яза белгән автор авыл кешеләрен, бүгенге колхоз казанышларын сурәтләүгә күчкәч, таркаулана, өстән-өстән генә сөйләүгә күчә. Укучы сөрлегә башлый. Димәк, Абдулла Сәләхетдиновның амплуасы — промышленностьта эшләүчеләр. Ә бу өлкәдә эшләүче очеркистлар бездә бик аз. Сәләхетдинов кыюрак язсын, очерклар белән газета-журнал битләрендә ешрак күренсен иде. Гомумән алганда, Сәләхетдиновның бу хезмәте — аның җитди иҗат казанышы.

Г. Ахунов белән М. Зарипов китабы публицистик очеркка булган таләпләрнең барысына да җавап бирә дисәк, ялгышмабыз. Анда портретлар да бар, танып-белү әһәмиятенә ия булган фәнни ачышлар да сурәтләнә, укучы өчен гыйбрәтле булган фәнни һәм техник казанышлар популяр формада күз алдына килеп баса.

Таң алды. Көртлекләр — гаять сак кошлар — скважина тирәсенә җыелышып туй итәләр. Китаптагы бүлекләрнең берсе әнә шундый сирәк очрый торган күренешләрне тасвирлау белән башланып китә.

Нефть турында коры итеп язарга теләмичә, укучыны мавыктыру максаты белән, матур табигать күренешләрен фон итеп сурәтләргә телиләрме әллә авторлар? Юк, аның өчен түгел икән. Элек һәр скважинага дүрт кеше хезмәт күрсәткән, ә хәзер скважиналар тирәсендә кешеләр бөтенләй юк,— анда кертлекләр туй итәләр,— бер кеше 15 скважинага хезмәт күрсәтә. Ә автоматлар кертлекләр өчен куркыныч түгел. Менә шул рәвешчә, Татарстан күренешлә-

ре, республикадагы яңалыклар гади фотография рәвешендә генә түгел, аларның асылы тирән, киң итеп, укучыларның аңына, йөрәгенә кереп урнашырлык итеп сурәтләнә.

Китап бер үк вакытта республикабыз турында фәнни системалаштырылган белешмә ролен дә үти ала — авторлар кызыклы, әһәмиятле документларны, фактларны мул кулланганнар.

Татарстан хезмәт ияләре яулап алган казанышларны, республикабызның атаклы кешеләрен авторлар халыкара хәлләргә, дөньякүләм әһәмиятле тарихи вакыйгаларга бәйләп, аларга капма-каршы яки параллель куеп тасвирлыйлар. Мәсәлән, Камай һәм Розбери, Камай һәм Черчилль;

— яки Мөгаллим һәм Американың нефть җиһазлары җитештерү фирмасы президенты О. Коннор;

— яки Корбан Вәлиев һәм Төмән, Маңгышлак, Белоруссия нефть ятмаларын үзләштерүче белгечләр;

— яки Әлмәт һәм Нобель, Әлмәт һәм Көнбатыш Европа, Америка Кушма Штатлары;

— яки Түбән Кама һәм Аксак Тимер.

Безнең өчен күптән таныш, без гадәтләнеп беткән вакыйгаларның, күренешләрнең һәм безнең тирәдә яшәүче, эшләүче кешеләрнең, шул рәвешчә, яңа мәгънәсе калку булып күз алдына килеп баса, без аларның асылын тирәнрәк аңлыйбыз, авторлар белән бергә горурланабыз.

Авторлар «И кадерле туган як» китабында республикабызның йөзен дә, рухын да, үткәнен дә, киләчәген дә күрсәтерлек калку, мөһим моментларны сурәтләүне максат итеп алганнар һәм аларны, җәүһәрләр кебек итеп, бер җепкә тезеп чыкканнар. Кызыклы һәм файдалы китап килеп чыккан.

Җыелышларда да, матбугатта да очерк жанры артта бара, очерклар аз языла, дип чыгучылар еш очрый. Әмма мондый сүзләр чынбарлыкка туры килми. Киресе, очерклар шактый языла һәм басыла. Аларның әдәби эшләнеш сыйфатлары да начар түгел. Дөрес, очерк язучылар арасында кесәләрендә СССР язучылары союзы билетын йөртүчеләр бармак белән генә санарлык. Моның сәбәбе шунда: әлегә кадәр иҗат оешмаларында да, редакцияләрдә дә, Татарстан китап нәшриятында да очеркларга карата игътибар тиешле югарылыкта булмады.

Журналистларны гына түгел, язучыларны да очерк жанрында актив эшләргә чакыру — иҗат оешмаларының җитди бурычы. Әлбәттә, моның өчен кызыксындыру чараларын да онытмаска кирәк.

Дөрес, «Социалистик Татарстан» газетасы ел саен очеркларга конкурс оештыра. «Казан утлары» журналы басылып чыккан иң яхшы очеркларга бүләк бирүне көн тәртибенә куйды. Документаль әсәрләргә 1972 елдан башлап Хөсәен Ямашев исемендәге премия бирелә башланды. Әлбәттә, бу чаралардан соң, язучылар, журналистлар арасында әдәбиятның иң сугышчан жанры булган очеркларга карата игътибар тамырдан үзгәрер дип ышанасы килә.

Республикабыз хәзер — бөтенсоюз күләмендәге гигант төзелеш фронтының алгы сызыгы. КамАЗ төзелеше меңләгән кешеләрне яңа дәрт, яңа омтылыш белән канатландырды. Алар КамАЗ төзелешен социалистик Ватанга, халыкка хезмәт күрсәтү өчен, тырышлыкларын, омтылышларын, ихтыяр көчләрен максималь файда китерерлек итеп җигү өчен көрәш аренасы итеп сайладылар. Шул максат белән илебезнең төрле почмакларыннан безнең республикага, Чаллыга килделәр.

Илебез тарихында зур этап булган Шатура, Днепрострой, Магнитогорск һ. б. төзелешләрдә дә бик күп кенә якташларыбыз үз исемнәрен бөтен союзга таныттылар. Бетончы Мирсаит Ардуановка Березники шәһәрендә һәйкәл тора. Днепрогэс төзелешендә эшләүчеләрнең өчтән бере безнең Татарстан егетләре һәм кызлары булган. Магнитогорск төзелеше батырлары Галиуллин, Сәгъдиевләрне кемнәр генә белми.

«Батыр яуда сынала»,— диләр. КамАЗ төзелешендә дә аларга тиң хезмәт батырлары күп. Аларның патриотик омтылышларын, фидакарь хезмәт үрнәкләрен киң катлау укучыларга ирештерү, әлбәттә, язучылар эше. Бу гигант төзелешнең Днепрогэс, Магнитогорск, Комсомольск төзелешләре кебек үк киләчәктәге буыннар сагынып сөйләрлек итеп әдәби елъязмасын булдыру, иң беренче чиратта, сугышчан жанр булган очеркларга йөкләнә.

Шуңа күрә бу эшне бары тик очерк язу белән шөгыльләнүче берничә иптәшкә яки журналистларга гына калдырмыйча, шагыйрьләр дә, прозаиклар да, хәтта тәнкыйтьчеләр дә разведчиклар сафына кыюрак бассыннар иде!

# ИҖАТ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН РАСЛАГАНДА...

— Әдәбиятның мәйданы киң, тик талантлы кешеләр генә килсен, үзенчә килсен!

Алтмышынчы еллар азагында Сибгат Хәким тарафыннан әйтелгән бу теләк, кем әйтмешли, изге сәгатькә туры килде булса кирәк. Бүгенге көндә шигъриятебез мәйданына әледән-әле яшь көчләр килә һәм алар үзенчә килә. Шундыйларның берсе — Разил Вәлиев. Менә аның беренче мөстәкыйль китабы — «Зәңгәр кабырчыклар» [1]. Укыйбыз:

Бу дөньяның мин бер кисәкчеге,
Мин кечкенә генә материк.
Таулар да бар миндә, упкыннар да,
Батырлык бар миндә, матурлык...

Кайгыларым җир тетрәве төсле,
Сагышларым — гүя ак томан,
Чишмәләрем — чиста күз яшьләрем,
Ә сүзләрем буран, җил сыман.

Китерелгән юлларга күз салыйк: аларда Кешегә кагылышлы һәр штрих, һәр деталь гүя көч һәм куәт бәркеп тора. «Кайгылар — җир тетрәве төсле, сүзләр — буран, җил сыман». Болар лирик геройның ни дәрәҗәдә тирән һәм көчле хис итә алуы турында сөйлиләр. Дөрес, биредә сорау туарга мөмкин. Әйтик, әлеге детальләр лирик геройны ниндидер өреп тутырылган ясалма затка әйләндермиме? Юк, әйләндерми. Ул — бөтенләе белән җир кешесе. Әгәр дә ул үз бәхетен кояштай якты, шатлыгын айдай нурлы итеп тоя, хис итә белә икән, димәк, бу безнең илдәге социаль-экономик шартлар аның рухи һәм физик сәләтен ачкан, үстергән, камилләштергән дигән сүз. Хис көчен югары «температура»да тәгъбир итү — ул бары тик әнә шул тормыш хакыйкатен чагылдыру, башка һични түгел.

Ләкин Р. Вәлиев шигырендәге Кеше концепциясе болар белән чикләнми әле.

Бу дөньяның мин бер кисәкчеге,
Мин кечкенә генә материк,—

ди автор. Күренә ки, биредә лирик герой, социалистик җәмгыять тудырган социаль тип булу белән берраттән, индивидуаль шәхес тә. Шатлыклары дисеңме, кайгылары, сүзләре, бәхете... дисеңме — боларның һәркайсында әлеге шәхеснең үз төсмере, үз «мөһере» күренеп тора. Нәкъ менә шулар бәрабәренә лирик герой мөстәкыйль, үзенчәлекле шәхес, авторча әйтсәк, «кечкенә генә материк» булып тора.

Әйтергә кирәк, империализмга хезмәт итүче буржуаз язучылар кешегә карата мондый карашны инкарь итәләр. Мәсәлән, Готтфрид Бэн, Стефан Андрес, Г. Носсак кебек Көнбатыш Германия язучылары үз әсәрләрендә әледән-әле бер фикер үткәрәләр: имеш, кеше — үз ихтыяры белән мөстәкыйль эшләр башкарырга сәләтсез. Ул — автомат, робот. Аңарда индивидуаль үзенчәлекләр юк, үзенә генә хас «мин» юк. Бу карашны алар гомумиләштерәләр һәм хәтта социализм илләре кешеләренә карата да кулланырга маташалар. Янәсе, мөстәкыйль шәхес буларак, Кеше биредә дә үлгән.

Менә шушындый карашлар белән бәхәсләшкән кебек, безнең яшь автор үзенең әлеге шигырен болай тәмамлый:

Күпме тырышсаң да булмый мине
Хәят диңгезендә батырып!

Әйе, коммунизм төзүче совет кешесен индивидуаль үзенчәлекләрдән мәхрүм итәргә, аны курчакка, роботка әйләндерергә мөмкин түгел. Чөнки бу җәмгыять

[1] Разил Вәлиев. Зәңгәр кабырчыклар. Казан. 1971 ел.

кешедәге иң күркәм сыйфатларның барлык индивидуаль төсмерләрен тарих күрмәгән үсеш баскычына күтәрүне үзенең изге максаты итеп саный. Ниһаять, «Кеше» исемле шигырь мисалында тагын бер нәрсә ачыклана: совет кешесе образын калку һәм тәэсирле итеп сурәтләү өчен, автор детальләрне табигатьнең үзеннән алган. Мәсәлән, ул «буран, җил» аша сүз көчен ача, «җир тетрәү» белән кайгы тирәнлеген тәгъбир итә һ. б.

Әйтергә кирәк, Разил Вәлиевкә хас сурәтле фикер йөртү үзенчәлегенең бер ягын тәшкил иткән бу алым автор өчен бердәнбер түгел. Аның шигырьләрендә башка чаралар да шактый киң урын алып тора. Мәсәлән, укучыда мәгълүм бер тойгы, хис уяту, омтылыш тудыру нияте белән, ул еш кына төсләр гаммасыннан файдалана. «Диңгез белән саубуллашу» — шундый шигырьләрнең берсе.

Кара балчык — кызлар чәче,
Кызыл балчык — таң кебек,
Сары балчык — сагыну күк,
Ак балчыгым — ак өмет.
Җирдә — шатлык, җирдә — җылы,
Җир — Кояшның сүзе күк!
. . . . . . . . . . .
Ә диңгездә акчарлаклар
Канатлы сагыш кебек.

Беренче карашка бу парча исеменә лаек түгел кебек. Әйтик, кайда биредә саубуллашу? Автор хәтта «сау бул» сүзен генә дә кулланмый ич. Чынлыкта исә алай түгел. Игътибар итик: шигырь ике кисәктән тора. Беренче кисәк укучыда якты тойгыкичерешләр уяту вазифасын үти. Моның өчен автор төсләр сайлый һәм аларны кеше белән мөнәсәбәткә кертә. Кара балчыкта ул, мәсәлән, кызлар чәчен күрә, кызылында — таң, сарысында — сагыну, агында — ак өмет. Күз алдына китерегез: кара чәчле кыз һәм таң! Бу күренештән күңел күтәрелә, хисләр канатлана. Ә сагыну, өмет? Кем генә аларның тылсымлы көчен үзендә татымаган! Төсләрне кешенең рухи дөньясы белән бәйләү аша автор укучыда әнә шундый хисләрне хәрәкәткә китерә. Һәм менә йомгак:

Җирдә — шатлык, җирдә — җылы,
Җир — Кояшның сүзе күк!

Моннан соң бу хис соңгы ике юлда тәгъбир ителгән сагышка каршы куела. Менә шушы ике хиснең бәрелешеннән инде укучының омтылышы ачык юнәлеш ала. Ул хәзер күңеленнән «сау бул, диңгез, исәнме, җир!» дип әйтергә әзер.

Разил Вәлиевкә хас сурәтле фикер үзенчәлеге турында сүзне дәвам итеп, тагын шуны әйтергә кирәк. Үзенең байтак шигырьләрендә автор идея-эстетик эчтәлекне теге яки бу күренеш аша тәгъбир итәргә омтыла. Бу очракта фикер бөтенләе белән тоташ метафорага корыла. Мәсәлән, «Тормыш», «Мәхәббәт», «Алмагачлы әйдәнме син?» һәм башка күп кенә исемсез парчалар шушы алым белән язылганнар. Ләкин бу алым автор тарафыннан әлегә җитәрлек үзләштерелмәгән. Хәзерге хәлендә ул эчтәлекне калку һәм тәэсирле итеп укучыга җиткерү вазифасын үти алмый, киресенчә, аны томан эченә яшерә, башваткычка әйләндерә. Мисалга «Тормыш» исемлесен алыйк. Шигырь диалог рәвешендә язылган, һәм һәр сорау-җавап мөстәкыйль бер күренеш хасыйл итә. Автор кешенең тормыш юлын, үсеш баскычларын сурәтләргә тели.

Менә беренче күренеш:

— Кояш ерып
чыкклы аланда
таңнан нишләп йөрисең?
— Мин бит сабый,
мин урманда адаштым.

Биредә сүз кешенең бала чагы, гомеренең «таңы» турында бара. Бу яшьтә адәм баласы үзенә мөстәкыйль тормыш юлы сайларлык түгел. Ул адашу чорын кичерә. «Мин бит сабый, мин урманда адаштым»ны укучы нәкъ менә шулай аңлый.

Менә икенче күренеш:

— Кояш таптап
чәчәкле аланда
иртән нишләп йөрисең?
— Мин — яшүсмер,
җирне каргыйм:
Ярлы да ул, саран да,
Мин — яшүсмер,
мин урманда юл таптым.

Бусында «мин» инде кеше үсешенең икенче баскычына атлаган — гомернең «иртә»се башланган. Хәзер ул — яшүсмер. Аның дөньяга үз мөнәсәбәте (Җирне каргыйм: ярлы да ул, саран да) бар, үз юлы бар.

Ниһаять, менә өченче күренеш:

— Кояшны онытып
җиләкле аланда
көндез нишләп йөрисең?
— Мин бит гашыйк...
Кояш таптым...
Мин бит гашыйк...
Мин бәхеттә,
мин хәсрәттә адаштым.

Күренә ки, биредә «мин» буйга җиткән егет. Ул — гашыйк. Ләкин бу эчтәлекне укучыга тоташ метафора пәрдәсе артыннан өстерәп чыгарырга туры килә. Әле анда да күп детальләр ачыкланмый калалар. Мәсәлән, беренче күренештәге «кояш ерып», икенчесендәге «кояш таптап», өчен-

чесендәге «кояшны онытып» кебек метафораларны ничек аңларга? Яки: «чыклы аланда», «чәчәкле аланда», «җиләкле аланда». Бу тезмәләрнең мәгънә йөге, эстетик вазифасы нидән гыйбарәт? Бигрәк тә укучыны борчыганы — «кояш».

Мин бит гашыйк...
Кояш таптым,—

ди автор. Болай икърар итүдән чыгып карағанда, «кояш» — сөйгән яр мәгънәсен аңлата шикелле. Ул чагында «кояш ерып, кояш таптап, кояшны онытып»тагы — «кояш» ни белдерә?

Шигырьнең соңгы дүртенче, бишенче күренешләре исә метафора пәрдәсенә шулай төренгәннәр ки, аның артындагы эчтәлекне һич ничек аңлап булмый. Хәер, әйдә, үзегез хөкем итегез:

— Төнгә каршы
сары аланнан
кая болай ашыгасың?
— Кояш артыннан.
— Айны саклап,
кара җирдә,
төнлә нишләп йөрисең?
— Мин — кайтаваз,
җирне зурлыйм:
бик бай да ул, юмарт та!
Мин — кайтаваз,
мин кояшны югалттым.

Кыскасы, авторның тоташ метафорага корылган сурәтләү алымы әлегә тиешле нәтиҗәләр бирерлек түгел.

Аннары, мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әйтик, Р. Вәлиев үзенең әлеге шигырә белән колхоз клубында чыгыш ясый ди. Залда — савымчылар, игенчеләр, механизаторлар, күңелләрдә — коммунизм төзүгә бәйләнешле уйлар, проблемалар... Шушы атмосферада сәхнәдән шагыйрь тавышы яңгырый:

— Айны саклап
кара җирдә
төнлә нишләп йөрисең?

Әйтәсе дә юк, биредә сурәтләнгән дөнья залда утыручылар ихтыяҗыннан никадәрле ерак, заман сулышыннан никадәрле читтә!

Хәлбуки, халык тормышының бүгенге ихтыяҗларына хезмәт итү, коммунизм төзүчеләрне алга, яңа матурлыкларга рухландыру — шагыйрь өчен иң мөкатдәс бурычларның берсе булып тора. Шигърияттә үз юлыңны сайлаганда, моны истән чыгарырга һич мөмкин түгел.

Разил Вәлиев — эзләнүләр чорын кичерүче автор. Аның бер генә үзенчәлеге дә ахырга кадәр кристаллашып, утырып җитмәгән әле. Хәер, андый «утраклык» хәлен автор теләми дә. Ул һаман хәрәкәттә: эзли, таба, яңадан юлга чыга. Әлбәттә, моның һич гаебе юк. Киресенчә, хәрәкәт, эзләну — иҗади эшчәнлекнең мәңгелек юлдашы. Ләкин шунысы бар: даими рәвештә алга омтылып, Р. Вәлиев урыны белән материалны эшкәртүгә җитәрлек игътибар бирми башлый. Нәтиҗәдә, ул нәрсә раслый, нәрсә инкарь итә — болар укучы өчен проблемага әйләнә. Бу хәл бигрәк тә мәхәббәткә багышланган шигырьләрдә сизелә. Алыйк менә бу шигырьне:

Шәп егет тә инде бу Кояш!
Ә мин үзем,
егет кеше була торып,
бер кыз өчен купме яшь коям.
Мәсхәрә һәм оят!

Игътибар итик: егет кешегә бер кыз өчен яшь кою — «мәсхәрә һәм оят»,— ди «мин». Автор бу карашны хуплыймы, әллә гаеплиме? Моңа җавап бирерге мөмкин түгел. Чөнки авторның үз карашы билгесез. Шигырьнең соңгы өлешендә дә ул ачыкланмый.

Житте, йөрәк, житте, шашынма!
Бүгеннән соң һәр кыз белән
кызарынып исәнләшеп,
кызарынып саубуллашырга!
Шәп егет тә инде бу Кояш!

Күрәсез, мәсьәләгә авторның үз карашы, үз позициясе биредә дә ачык түгел. Шуңа күрә дә шигырь ирония белдерәме, әллә сокланумы — безнең өчен сер булып кала.

Разил Вәлиевнең эзләнүләр юлында тагын шундый хәл дә очрый: ул, мәсәлән, тормыш материалын үзенчә эшкәртергә алына, ләкин материал каршылыгын һәр очракта да җиңүгә ирешә алмый. Нәтиҗәдә, автор, каш ясыйсы урынга, күз чыгарып куя. Бу җәһәттән карағанда, «Вәгъдә» исемле шигырь аерата гыйбрәтле.

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...
Бик тар әле чикләрем.
Бар байлыгым — шигырьләрем
Һәм дә кара икмәгем.

Биредә лирик герой уңай кешеме, әллә аны автор хөкем итәме? «Бар байлыгым — шигырьләрем һәм дә кара икмәгем» кебек детальләргә таянып фикер йөрткәндә, безнең алда — уңай кеше кебек. Бу карашны кире кагарлык дәлилләр шигырьнең соңгы өлешендә дә күренми. Ышандык. Ул чагында инде түбәндәге юллар авторның уңай программасы булып чыга:

Оҗмах вәгъдә итмим сиңа...

яки:

Күкне бирә алмыйм сиңа...

яки:

Бәлки, бәхетле булмассын...
Бәхетсез дә итмәмен.
Оҗмах бирәм димим сиңа,
Тәмугка да кертмәмен.

Һ. Такташ, М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким, Ш. Маннур, Н. Арсланов кебек зур талантлар расланган мәхәббәтме бу? Юк. Китерелгән өзекләрдә кол биләүче, яки феодал-хаким авазы яңгырый. Аларда чиксез олы хис — мәхәббәт хуҗа һәм ялчы мөнәсәбәтенә әйләнә.

Хәлбуки, яшь автор мондый нәтиҗәне күздә тотмаган, киресенчә, ул мәхәббәтне хуҗа һәм ялчы мөнәсәбәтенә әйләндерүчеләрне камчыларга уйлаган булса кирәк. Ләкин максатка ирешелмәгән. Чөнки бу очракта автор материал каршылыгын җиңә алмаган. Үз теләгенә капма-каршы булган нәтиҗәгә килү нәкъ менә шул турыда сөйли.

Разил Вәлиев күп очракларда иркен шигырь формасыннан файдалана. Мәгълүм ки, бу форма шигырьне аваз төсмерләренә баета, аның яңгырау куәтен арттыра. Шушы сыйфаты бәрабәренә иркен шигырь сөйләү — декламация вазифасын үз өстенә ала. Әйе, иркен шигырь — ул ялкынлы оратор, темпераментлы агитатор. Аның табигате бүлмә кысымына сыеша алмый. Син аңар мәйдан бир, сәхнә бир. Моның өчен инде ул үзе дә зур эчтәлеккә, югары темпераментлы публицистик пафоска ия булырга тиеш. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Радиф Гатауллин, нәкъ менә шушы сыйфатларны раслау өчен, үзләренең кайбер әсәрләрендә традицион шигырь кыршауларын алып ташлыйлар да. Разил Вәлиев бу юлдан бармый. Аның иркен шигырьләрендә публицистик пафос юк, шулай ук зур эчтәлек тә юк.

Иң беренче
Уйчан булуыңны сөйдем,
аннан — исемеңне.
Аннан — сүзләреңне,
аннан — борыныңны,
күзләреңне,
сөям диюеңне,
минем янга
йөгереп килгән чакта
күкрәкләрең белән бергә
биюеңне.
Хәзер исемеңне сөймим,
бары исемеңне.
Ачуланма,
исемеңне генә алыштырыйм,
исемеңне...

Күрәсез, биредә иркен шигырь формасы иҗтимагый әһәмияте булмаган шәхси кичерешләрне тәгъбир итү өчен файдаланылган. Бу — «шигъри зажигалкалар эшләп чыгару өчен иркен шигырь заводы» ачу кебек түгелме соң? Һәрхәлдә, әлеге шигырь өчен мәйдан кирәк түгел, сәхнә кирәк түгел. Аның урыны — бүлмә.

Разил Вәлиев шигырьләрен укыганда тагын бер нәрсә күзгә ташлана. Атап әйткәндә, ул — шигъри сөйләм чатаклыклары.

Әй, бай идем, шундый бай идем мин...
Бер бөркетем калды читлектә,
Анысын да югалтыр дип уйлап,
Тәрәзә артында соңгы чик кәтә,—

ди автор «Мәхәббәттә алданганнар җыры» исемле парчада. Биредә соңгы ике юл бөтенләй эшләнмәгән. Шигъри сөйләмнән алар ерак, гади сөйләм булырга яраксыз. Беренчесе өчен аларга сәнгатьчә камиллек җитми, икенчесе өчен мәгънәсезлек киртә булып тора. «Анысын да югалтыр дип уйлап»,— ди Р. Вәлиев. Кем болай уйлый? Авторга ышансак, «Тәрәзә артында» кәтеп торучы «соңгы чик» булып чыга. Ләкин, ничек итеп «соңгы чик» уйлый алсын да, ничек итеп ул «Тәрәзә артында» кәтеп торсын икән?

Кыскасы, әлеге юллардан акылга сыярлык реаль мәгънә табарга мөмкин түгел. Алар бары тик «читлектә» сүзенә рифмадаш «чик кәтә»не шигырь үлчәменә урнаштыру өчен генә китерелгәннәр. Шуңа күрә дә бу очракта рифма бар, шигърият юк. Кызганычка каршы, мондый мисаллар җыентыкта аз түгел.

Хәлбуки, шигырь табигате шундый — аның тукымасына аз гына «буш токым», кечкенә генә фальшь кердеме, ул шунда ук түбәнгә тәгәри, үзенең идея-эстетик кыйммәтен югалта. Шуңа күрә дә шагыйрь булу — ул үз эшеңнең иң югары остасы булу дигән сүз.

Билгеле, моның өчен автордан бик күп нәрсә таләп ителә. «Шагыйрьгә» исемле шигырендә Нури Арсланов болай ди:

Булса синдә Әфлатунның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
Телгә оста булсаң Чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлектә Нәүширванныкы гадел,
Юмартлыкта булсаң Хатәм-Тай...
Син әле дә кәмил түгел, шагыйрь!
Җитми әле Хәйям касәсе
Һирдәм тулы шатлык шәрабына!
Бар әле бар күкрәп ашкынасы,
Салават күпере салып күңелләргә,
Койсын бар хисләр ләйсәнен,
Кирәк сиңа Мәҗнүн мәхәббәте
Һәм илһамы гүзәл Ләйләнең...

Әйе, чын шагыйрь булу өчен үзеңдә әнә шундый сыйфатлар тәрбияләргә кирәк. Бу — шигърият мәйданына бердәнбер юл.

**ШӘРӘФ ӘХМӘДУЛЛИН.**

# ТОРМЫШЧАНЛЫК ӨЧЕН

Соңгы елларда хикәяләргә кытлык турында күп сөйләнелә. Язучыларыбыз да, тәнкыйтьчеләребез дә, җыелышларда булсын, матбугат битләрендә булсын, хикәя жанрының үсеше өчен борчылуларын әйтеп торалар. Газета-журналларыбызда да чын сәнгать әсәре югарылыгында язылган хикәяләргә ихтыяҗ зур. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, бу өлкәдә сәләте барлыгын күрсәткән һәр каләм иясе безнең өчен кадерле. Шуңа күрә дә Миргалим Харисовның «Ватан нидән башлана»[1] исемле хикәяләр җыентыгын мин бик кызыксынып кулга алдым.

Китап, әллә ни калын булмаса да, ике бүлектән тора икән. Бер бүлеккә «Хикәяләр» дип, икенчесенә «Юмористик хикәяләр» дип баш куелган. Гадәттә, җыентыкка бер рух белән сугарылган, бер жанрда язылган әсәрләрне туплый торганнар иде. Күләме дүрт табактан артмаган кечкенә китапчык өчен, миңа калса, бу бигрәк тә шулай булырга тиеш иде кебек. Югыйсә, авторның аерым китап итеп җыярга ни лирик хикәяләре, ни юмористик хикәяләре җитмәгән дә, шунлыктан ул, күләм тулсын дип, бар язганын кырып-себереп шушы китапка тутырган төсле тәэсир кала. Ә бит, кагыйдә буларак, китапка язучының иң уңышлы, иң яхшы әсәрләрен туплыйлар.

Ярый, шулай да булсын, ди, авторның төрле жанрларда язылган әсәрләре бер китап итеп чыгарылсын, ди. Моның белән килешергә була. Чөнки, ахыр чиктә, хикмәт хикәяләрнең жанр төрлелегендә түгел, ә бәлки аларның сыйфатында, әдәби кыйммәтендә.

Хикәяләрне укып чыкканнан соң, чыннан да, Миргалим Харисовның каләме өметле икәненә ышанасың. Ул әдәбият теориясен белеп, хикәя кануннарын истә тотып язарга тырышкан. Җыентыктагы күпчелек хикәяләрнең сюжеты оста гына корылган, аларда композиция бөтенлеге бар. Шактый шома яза автор, китапта абынып-сөртенеп торырлык урыннар очраштыргаласа да, алар күп түгел, хикәяләр җиңел укыла. Уңышлы чагыштырулар, оста тасвирлаулар да очрый. Димәк, Миргалим Харисовның яхшы хикәяләр язарга мөмкинлекләре бар, аңа таләпнең зурысын куеп була.

Инде шул зур таләпләрдән чыгып, беренче сорауны бирик: нәрсә турында яза автор? Бу хикәяләре белән нәрсә әйтергә тели? Укучыларны кая өнди?

Беренче карашка, автор бүгенге тормыш, бүгенге кешеләр турында яза кебек. «Ватан нидән башлана» дигән хикәя шушы елларда ил чигендә булып узган хәлләргә ишарә ясый. «Акчарлак» исемлесендә Кама ГЭСы телгә алына. Әмма, кызганычка каршы, заман сулышы шул «телгә алыну» белән чикләнә. Әсәрләрдә хәзерге заман кешесенең тынгысыз тормышы, үй-борчулары, омтылышлары, кичерешләре күренми диярлек. Геройлар — шактый беркатлы, кызыксыз кешеләр. Күп урыннарда автор сөйләгәннәр укучыны ышандырмый, чөнки тормышчанлык җитми. Мисалга «Ватан нидән башлана» исемле хикәяне алыйк. Бирерә сүз чик буенда яшәүче хәрби кешенең гаиләсендәге үзара мөнәсәбәтләр турында бара. Офицер Айдарның хатыны Гөлнар, кулында бик шәп һөнәре булуга карамастан (ул укытучы), яңа урында тиз генә эшкә урнаша алмый. Автор хатынның өйдә «эшсез» утыруы өчен бик көенүе турында яза. Нәни бала карауны, ни сәбәптәндер, автор да, Гөлнар да җаваплы эшкә санамыйлар. Айрат — взвод командиры — кайчакларда көннәр буе өенә кайта алмый. Шундый көннәрнең берсендә: «Чик буенда тынычсыз икән, дигән хәбәрләр дә ишетелә». Ул да булмый, икенче бер офицер хатыны (анысы коеп куйган кире тип) «сугыш башланган» дип коткы тарата. Болай да туган ягын сагынып зарыккан Гөлнарга шул сүз җитә кала, ул, беркем белән сөйләшми-нитми, хәтта күршеләренә дә әйтми, ашык-пошык чемоданына әйбер-карасын тутыра башлый. Ә бу вакыт аның ире Айрат, гадәтенчә, «С чего начинается Родина?» дип җырлый-җырлый һәм «Чынлап та, Ватан нәрсәдән башлана соң?» дип уйлана-уйлана, өенә кайтып килә. Айратның бу уйлары — хикәянең үзеге. Әсәрнең идеясе шунда ачылырга тиеш иде. Бирерә автор совет ке-

[1] Миргалим Харисов. Ватан нидән башлана. Казан. 1971 ел.

шесенең туган иленә булган олы мәхәббәте турында сөйләргә тели. Әлбәттә, Айрат кебек совет офицерларының Ватанны яратуларына бернинди шик юк. Ләкин кеше Ватанны яратуы турында, Миргалим Харисов күрсәткәнчә, беркатлы уйлыймы икән? Беренчедән, «Ватан нәрсәдән башлана?» дигән сорау татарча бөтенләй мәгънәсез яңгырый. Чөнки, гәрчә русчадан сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән булса да, рус телендәге мәгънәсе сакланмаган. Хәер, сөйләшкәндә, димәк, уйланганда да, руслар үзләре дә «С чего начинается Родина?» дип сөйләмиләр, бу җөмлә, бары матур сүз тезмәсе буларак, мәгълүм җыр өчен генә ятыша. Икенчедән, балигъ булган кеше изге хисләре, олы мәхәббәте турында Миргалим Харисов язганча төчеләнеп уйламыйдыр. Ватанны ярату газиз анаңны ярату кебек ул. Халыкның, бу ике төшенчәне берләштереп, Ватан-ана диюе юкка гына түгел. Ә бит «Ана нәрсәдән башлана?» яисә «Ни өчен мин анамны яратам?» дип уйланып йөрү мәгънәсезлек булыр иде! Без, яшь язучылар, геройларыбызны халыкча сөйләтә, табигый уйландыра белмибез.

Айратның бу уйланулары да, аның хатыны белән күрешүен тасвирлаган юллар да ясалма булып, кеше ышанмаслык булып чыккан. Сугыш башлануын ишетеп коты алынган хатын офицер ирен менә ничек каршы ала:

«Гөлнар, Айратның кергәнен сизмәгән иде булса кирәк, сискәнеп артына борылды һәм шунда ук аягүрә басты.

— Китәм мин,— дип пышылдады ул, бераз күзгә-күз карашып торганнан соң.

— Казангамы, Мәскәүгәме, Минзәләгә табамы? — дип шаяртуында булды Айрат.

— Чынлап, Айрат... Зәһрә дә китә... Бөтен кеше китә икән».

Бу эпизодны укыганда, «автор сугышның нәрсә икәнен беләме икән соң?» дигән сорау туа. Хәер, китапка бирелгән аннотациядә: «М. Харисовның бала чагы дәһшәтле сугыш елларына туры килә. Ул сугышның кешеләргә кайгы-хәсрәт, ачлык-ялангачлык алып килүче кара бер көч икәнен тоеп үсә...» — дип язылган. Ул гына да түгел, Миргалим Харисов үзе армиядә ике ел хезмәт иткән икән. Шуңа карамастан, ул бу эпизодны чын сәнгатьчә итеп күрсәтә алмаган.

Офицер хатыны, сугыш башлануын ишеткәч, һәрхәлдә, чемоданы турында гына уйламас. Ул иле өчен дә борчылыр, ире өчен дә ут йотар. Һәм инде шундый киеренке минутта кайтып кергән ирен эчендә җаны бар хатын «китәм» дип каршы алмас.

Гөлнарның, Казанга таба үкчә ялтыратмыйча, чик буенда, офицер ире янында калуын автор бик изге эш, хәтта батырлык итеп күрсәтергә тырыша төсле. Монда нинди изгелек булсын? Сугыш башланмады, хатынга эш табылды, бары да үзеннән-үзе җайланды бит.

Хикәяне укып чыккач, моның белән автор ни әйтергә теләде икән? дип аптырап утырасың. Миргалим Харисов бу әсәрне әйтер сүзе булганга түгел, сан өчен язган кебек тәэсир кала. Ясалмалылык, тормышчан булмау да шул сәбәптән килеп чыга. Мин бу хикәягә төп игътибарны юнәлттем, чөнки ул миңа авторның иң нык эшләнгән хикәясе кебек тоелды.

Максатсызлык, авторның әйтергә теләгән фикере ачык булмау, ясалмалылык җыентыктагы хикәяләрнең байтагына хас. Ләкин арада аеруча эчне пошырганы «Авыртмас башка тимер тарак» исемлесе булды. Анда яңа солдатка алынган ике татар егетенең, якташларның, бер частька эләккәч, бер-берсе артыннан шымчылык кылып, ничек тә булса бер-берсен кеше алдында хур итәргә, бер-берсенә этлек эшләргә тырышып йөрүләре бик тәфсилләп тасвирланган. Авторны бу хәл борчымый, ул укучыларда мондый адәмнәргә нәфрәт уятырга омтылмый.

Материал сайлауда талымсызлык, фикер ярлылыгы юмористик хикәяләрдә дә сизелә. Арада берсе — «Гаҗәеп көн» дигәне сюжет борылышы белән шактый кызыклы, ләкин автор аны тиешенчә эшләп җиткермәгән, ашыккан.

Йомгаклап шуны әйтәсем килә: һәммәбез кебек үк, Миргалим Харисов та яхшы хикәяләр язарга тырыша. Әмма яхшы хикәяләр язу өчен тырышлык кына җитми, күрәсең. Автор, язучы буларак, үзенең максатын, фикерен, тормышка карашын, кешеләргә таләбен ачыкларга тиеш. Шул вакытта гына аның чын мәгънәсендә әдәби әсәрләр иҗат итүенә өмет баглап булачак.

**МӘДИНӘ МАЛИКОВА.**

# ШАГЫЙРЬНЕ МИН ШУЛАЙ АЧТЫМ...

Каләмдәшем Рөстәмне мин беренче шигырьләреннән үк укып барам, яңа китабын[1] да кызыксынып кулга алдым. Бу җыентыктагы шагыйрь дә шул — «Эзләр»дәге егет. («Эзләр». Татарстан китап нәшрияты. 1967 ел.) Тик инде ул дөньяны күбрәк күргән, фикерләрен гадирәк, халыкчанрак итеп әйтә белә башлаган.

Шагыйрь дөньяга гашыйк. Әмма ул «гүзәллеккә сак карый», чын гүзәллек өчен жаны-тәне белән көрәшә. Чөнки яхшы белә: бу гүзәллек җиңел яуланмаган.

Таш дивардай кайгы ауды өстемә,
Әмма күрдең: минем йөздә тынычлык;
Күкрәгемә күнып шатлык талпынды,
Әмма күрдең: үзгәрмәдем, мин — шул ук;
Һәм киттең син минем яннан:
«Жансыз бу.
Кайгы-шатлык белми торган кеше!» — дип.
Моннан зуррак кайгы барын беләм мин,
Моннан зуррак шатлык көтеп яшимен.

(«Беләм»)

Тартып-сузып маташмыйча, күзгә туптуры карап сабыр, ләкин саллы әйтелгән шушы ике строфада тулы бер образ, тулы бер шәхес, шагыйрь үзе. Ул ир-егетләрчә кырыс сөйли, әмма шигырь юлларының нигезендә эчтән бәреп чыгарга торган тыенкы дәрт, кайнар хис, сөенү-көенүләр вулканы ятканын сизү кыен түгел.

Рөстәм, гомумән, үе, гаме зур шагыйрь, борчылып яшәүче шагыйрь. Хәер, чын шагыйрь борчылмыйча яши аламыни?! Ләкин борчылу төрлечә була. Юк-бар шатлыкка очынып китмәгән кебек, Рөстәм кыенлыклар алдында да коелып төшми. Аның уфтануы шәхси мәнфәгатьләрдән өстен. Кешелекнең аерылгысыз бер вәкиле буларак, кешеләр турында, кешелек турында уйлана ул:

Рәхәтләнеп көләп яшәгәндә
Күкрәгемә авыр уй баса:
Бу дөньяда әле бер көлүең —
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң?!

(«Ул шулайдыр әле, уйласаң...»)

Шагыйрь борчыла. Укучысын да битараф калдырмый. Тик аның борчылуында чарасызлык, аптырап-каушап калу тәсмере юк. Кешегә, кешенең гуманлы булуына ышана ул. Шушы ышаныч аны киләчәккә өметле итә, үзен көчле итә. Шуңа күрә дә:

Ак көненне буса төн карасы,
Төнне арттан буып ала таң.
Бу дөньяда әле бер елавың —
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң?! —

ди ул шул ук шигырендә.

Р. Мингалимов шигырьләрендәге драматизм, якты хисләрнең өстенлек алуы аның әсәрләренең тонын билгеләп, форма үзенчәлекләрен китереп чыгара. Бездә Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов кебек шагыйрьләрне алар барысы да бер төсле иҗат итә дип караучылар бар. Тыштан караганда, бу чыннан да шулай кебек. Асылда бу шагыйрьләр — гаҗәп төрлеләр. Аларның уртак яклары исә — фикер поэзиясе тарафдарлары булуларында. Шигърияттең фикер белән хис синтезы икәнен, шуңа ирешкәндә генә укучы белән чын-чынлап аңлаша алуларын яхшы беләләр бу шагыйрьләр. Шуңа омтылалар. Бу нисбәттән Рөстәм кешеләргә якынрак килә, йөрәгеп учка салып сөйләшә белә. Бу аны еш кына иркле шигырьдән традицион алым белән язылган шигырьләргә мөрәҗәгать итүгә китерә. «Алкын су» җыентыгында шул якка таба үзгәреш сизелә. Монда инде образларны киракмәскә катлауландырулар юк диярлек, детальләр төрле яклап ачылганнар. Рөстәмнең фикер һәм хис бердәмлегенә чагыштырмача тизрәк ирешүенә, шагыйрь буларак тизрәк өлгерүенә Әнвәр Давыдов тәҗрибәсе ярдәм итте булса кирәк. Фикерне аһәңле, матур итеп әйтү ягыннан балалар өчен язган шигырьләрендә Рөстәмнең уңышы тагын да зуррак. Минемчә, Рөстәмгә, фәлсәфи тирәнлеген саклаган хәлдә, олылар белән дә шулай җылы итеп, кешелекле итеп сөйләшүгә таба баруын дәвам иттерергә кирәк. Әле хәзергә «Алкын су» җыентыгында фикере булып та, йөрәкне җылытмый торган «Өлеш», «Атом төше хакында», «Туган як кырларына», «Бар» кебек салкын шигырьләр дә очраштыра.

«Җир йөзендә...» шигырендә, мәсәлән, автор болай ди:

---

[1] Рөстәм Мингалимов. Алкын су. Казан. 1971 ел.

Чын бөекләр,
Чын егетләр —
Чын бәркетләр аз, дидегез, кешеләр.
Җирдә чын кеше аз, дисәм —
Миңа ышанмас идегез, кешеләр.

Беләм: «әтисе сугышка киткәндә, Рөстәмнең кайнар беләктә калуын» да, нужа куып, әнисенең «үз яшеннән күпкә картаюын» да, Ватан өчен гомерен биргән, «укылмыйча югалган кыйммәтле хат төсле», әтисен юксынуын да беләм. Авторның кеше үтерүчеләргә карата нәфрәте дә аңлашыла. Әмма бу шигырь күңелдә тирән хисләр уятмый. Ничектер, фәлсәфә артык гомуми, конкрет җирлексез — ышандырмый. Хәер, ышандырмавы әйбәт тә, чөнки автор: «Җирдә чын кеше аз», дип ышандырмакчы була бит. Болай шигырь тәгәл логикага нигезләнгән, югыйсә. «Җир йөзендә чын угрылар да, чын тугрылар да аз... дидегез. Ә бит угрылар да, тугрылар да кешеләр. Димәк, җирдә чын кеше аз булып чыга түгелме соң», димәкче автор. Әмма монда логика законына туры килеп бетмәгән йөрәк законы да бар бит әле. Ә саф йөрәк угрыны тугры белән бер рәткә — Кеше рәтенә куярмы икән соң?! Шигырьнең акыл һәм йөрәк җимеше булуын онытып җибәрү әнә шулай уңышсызлыкка китергән.

Рөстәм Мингалимов, алда әйткәнемчә, фикер поэзиясе тарафдары. Әмма ул хис поэзиясе ягында да. Анык фикер белән хис бердәмлегенә ирешә алган әсәрләренең ишәя баруы шул турыда сөйли.

Бу нисбәттән «Минем дәүләт» поэмасы турында бер-ике сүз. В. И. Ленинның 100 еллыгына багышланган бу әсәр хакында яшьләр иҗатына һәрвакыт илтифатлы Сибгат Хәким: «Рөстәм Мингалимов «Минем дәүләт»емдә ачылды», дигән фикерне әйтте. Әйе, «Минем дәүләт» поэмасында Рөстәмгә хас сыйфатларның күбесе чагыла. Дөнья турында, кешелек турында уйланучы шагыйрьнең идеалы бик табигый рәвештә юлбашчы образына килеп тоташа. Үз шәхесе белән үзенең идеалы арасындагы уртак сыйфатларны таба алуы шигырьне уңышка китергән.

Юлбашчы бөтен кешелек язмышы өчен борчыла, аның өчен җанын аямый. Шагыйрь дә шулай... Шагыйрьнең дә үзенә күрә шәхси дәүләте бар, дәүләт башында ул үзе:

Уйланамын...
Югаламын...
Тагын калкам
Дөньяга:
Бозып торган
Бер тап түгел,

Бизәк булыйм
Дим аңа...

Дөньяда ике идеология яши, бик каты көрәшеп яши. Кешенең зиһене, йөрәге, үзе өчен көрәш бара. Кеше — үзе бер дәүләт, дәүләт — кеше кебек. Кешедә дә «чиста акыл, чиста кул», үткер күз, сизгер йөрәк булырга тиеш. Чөнки «яшьнәп узган заманнар дошманны салкын канлылыкка, хәйләкәрлеккә өйрәтте».

«Кешеләр, уяу булыгыз, бер-берегезгә илтифатлы булыгыз, бер-берегезнең күңелен ялгыш та яраламагыз, чөнки ул ярага, микроб кебек, дошман кереп ояларга, кешене безнең сафтан үз лагерена тартып алырга мөмкин», дип кисәтә безне автор. Бу фикерне ул үз иҗатына хас драматизм, яктылыкның караңгылыкны җиңәчәгенә инану тойгысы белән сугарып бирә. Чөнки аның шәхси дәүләте нигезендә юлбашчы сүзләре, естәлендә — юлбашчы сыны:

Ни соң Ул?
Кем соң Ул?
Ул —
кешенен
иманы

Күрәсез, шагыйрь нинди зур гомумиләштерү ясый!

Поэмада Рөстәм шигырьнең төрле формаларыннан оста файдалана. Бу аңа кешенең күңел хәзинәсен төрле яклап, тулы итеп ачарга мөмкинлек бирә. Поэма ташлардан ташларга сикерә-сикерә шаулап аккан тау елгасын хәтерләтә. Анда лирик уйланулар публицистик күтәренкелек белән аралашып бара. Дөрес, әле Рөстәмнең бу әсәрендә дә фикерен аһәңле итеп әйтеп үк җиткерә алмаган строфалар очраштыргалый. Һәр сүзнең мәгънә йөге булуына, шигъри детальләрнең тәгаллегенә аеруча сизгер игрекле шигырьдә ул кимчелекләр күзгә бигрәк тә тиз чалыналар.

«Минем дәүләт» поэмасының көче авторның заман проблемаларын үткен итеп куюында, шуларны бер фокуска җыеп бирерлек отышлы форма табуында һәм фикерләрен үзенчә әйтеп бирә белүендә.

Рөстәм Мингалимовны, шагыйрь буларак, мин шулай ачтым. Ихтимал, монда объективлыктан читкәрәк тайпылган фикерләр дә очрар. Әмма шунысы бәхәссез: арабызда кызыклы бер шагыйрь яши, борчылып, сөенеп иҗат итә, безнең күңелләрне шигъри ачышлары белән баета. Ә шагыйрьнең үзен һәр укучы үзенчә ачсын...

ШАМИЛ МАННАПОВ.

## Нәби Дәүли

# ТИМӘГЕЗ МИНЕМ ГӨЛЗАДАМА!

хикәя



Бер вакытны мине дустым Гафар белән янәшә бастырып, стена газетасына чәпәделәр. «Ялкау Әмәк белән Шәмәк» дип тозлап, борычлап язганнар иде. Әмәк дигәннәре мин булып чыктым, Шәмәк ул Гафар була, күрәсең.

Газетаны нәкъ идарә каршындагы белдерүләр тактасына ябыштырып куйганнар иде. Узган-барган кеше туктый да эче катып көлә. Вәт, ичмасам, биргәннәр боларның кирәген, диләр. Кеше күзенә күренмәс иттеләр.

Шуның белән генә калса әле түзәр дә идең. Юк шул, район газетасына да язып чыктылар. Бусы инде кыздырган тимер белән тамга баскан кебек булды.

Чыдарлыгым калмады. Тукта, дидем мин үз-үземә, нишләп авыз ачып торам әле? Тотам да үзем дә язам, язам да газетага җибәрәм. Кем турында дисеңме? Һи, авылда кеше беткәнме?

Бер көнне дустым Гафар безгә кергән иде. Мин аңа шул турыда әйтә куйдым. Ә ул исә керосинга ут капкан кебек гөлт итеп кабынып китте.

— Их, парень,— ди,— мин дә бит шул хакта баш ватам. Чыннан да, ди — нигә безгә дә язмаска? Што без грамотный түгелме әллә, кемнән ким җиребез бар? Алып кара әнә хотя бы теге тракторчы Гаязны, ул да каләм тибрәтә, шигырьләр язган була. Ә без, ә без аның кебек кенә язарбызмы соң?..

— Анысы шулай, әлбәттә,— дидем,— каләм балта түгел, кулга сөял чыгармас...

— Шулай шул,— ди Гафар,— нигә куркып торырга? — әйдә, икебез бергә язабыз. Язабыз да конвертка пичәтләп — шалт газетага.

Маркасын да ябыштырып торасы юк. Редакциядә үзләре түләп алырлар. Мәкаләнең ахырына икебез дә имзаларыбызны киртләп куярбыз. Бу алар телендә күмәк корреспондент дип атала икән...

Гафар тәмам адарынып китте. Кулларын уа-уа көлә, күзләре ялт-йолт яна.

— Әйдә, каләм ал, кештердәтә башлыйбыз,— ди.— Даны да булыр, акчасы да кесәне ертмас...

— Ярар,— дидем мин,— башлыйк алайса,— каләмемне карага мандым.

Гафар каршыма ук килеп утырды. Күзләрен түшәмгә текәп нәрсәдер уйлап алды.

— Иң элек мәкаләнең исемен куярга кирәк,— диде.

— Юк әле,— дидем мин,— нәрсә турында язабыз соң? Шуны хәл итик.

— «Нәрсә» турында фәнни журналга гына язалар. Ә без юмор-сатира мәкаләсе язабыз, газетага, белеп тор. Димәк, нәрсә турында түгел, дөресе — кем турында диген.

— Кем турында соң?

Гафар тагын уйга калды.

— Кем турында булсын, давай колхоз председателен каләм очына утыртабыз. Тыпырдап карасын әле бераз. Аны бит гел мактап бозулары да мөмкин. Тәнкыйть — ул теләсә кемгә дә килешә...

— Шулаен ул шулай да,— дидем сузып кына,— председателебез шәп кеше бит — фактлар табып булырмы икән?

— Фактлар дисең син, оныттыңмыни ул ничек безне хур итеп ташлаган иде бер җыенда. Әле дә колаклар кызарып тора. Әмәк белән Шәмәк кебек сельпо бусагасын саклыйлар, эшкә дисәң, эчләре авырта дип, бездән көлгән иде түгелме? Көлгән иде...

— Шулаен ул шулай да,— дидем мин тагын, башымны кашып,— барып чыгармы икән?

— Син нәрсә сөйлисең? — дип кызды Гафар.— Без эштән качабызмы? Кырга чыгарга куша икән — итекләр бирсен, фермага барыгыз ди икән — халат бирергә онытмасын. Урманга барыгыз ди икән, рәхим итеп сухой паек китер! Раз не так, значит уважительный сәбәп. Эзләсәң тырнак астыннан да кер табып була. Давай яз!

— Нәрсә языйм соң?

Гафар тагын түшәмгә карап алды.— «Колхоз председателе эшкә салкын карый» диген. Бу мәкаләнең исеме булыр... Булдымы?

— Булды.

— Хәзер инде санап кара, ничә сүз килеп чыга?

— Монысы нигә?

— Сана, сана...

— Биш сүз,— дидем мин.

— Һәр сүзенә өчәр тиен куйсалар — унбиш тиен! Искечә исәпләгәндә, бер сум илле тиен. Юлда ятмый, энем, бу акча. Шәп, шәп, малай, була бу, әйдә, кештердәт кенә...

— Салкын караш нинди була соң?

— Салкын карашмы? Салкын караш — ул, ул...— дип мыгырданды да Гафар, кинәт кенә тынып калды.

— Я, әйдә, язабыз, әйт, салкын карашны...

— Тукта әле,— диде Гафар.— пожалуй, председательгә тимик. Бәлки әле аның редакциядә әшнәләре дә бардыр. Белеп булмый, дөнья бу!

— Дөрес,— дидем мин,— председательгә тимик. Кемне языйк соң?

Мин каләмемне кара савытына чумырдым. Мәкаләнең исемен ничек куябыз? — дидем.

Гафар күп уйлап тормады.

— Я,— диде һәм шунда ук: «Бал белән майда кем йөзә?» — дип әйтә торды.

— Кем соң? — дип гаҗәпләндем мин.

— Кем булсын,— диде Гафар,— билгеле инде — колхоз завхозы. Келәт ачкычлары аның кулында ич. Кемнең кулында — шуның авызында.

— Аны каян беләбез соң без?

— Каян булсын, үзеннән-үзе килеп чыга. Например, син, яки мин завхоз булдык, ди. Што син, балга бармак тидермәс идеңмени? Майга да исең китмәс идеме, ә? Коры кашык авыз ерта, туганкаем. Сезденме абыеңның тел төбен?

Мин бераз сүзсез тордым.

— Шикләнәсеңме әллә?

— Бу бит вак-төяк.

Гафар идән буйлап арлы-бирле йөреп алды.

— Бүген бармак белән, иртәгә кашык белән, аннан соң үзең беләсең — соскыч белән...

— Факт юк.

— Факт әллә ни зур түгел шул,— диде Гафар тынычландырып,— кемне язабыз соң? Давай бригадирны!

— Кайсысын?

— Теләсә кайсысын. Бөке Харис нигә ярамаган? Валлаһи дип әйтәм, эт итеп сүксәң дә бер нишли алмый. Ул бит мыштым. Бөке дисәң бөке!

— Аны ничек язабыз соң? Эчми, тартмый, чит хатыннарга да күз салмый...

— Аңа тагын чит хатыннар. Үз хатынын кая куярга белми, мескен,— дип, Гафар бүлмәне яңгыратып көлеп җибәрде.

— Әйдә, әйдә яз!

— Юк, Гафар, кулым бармый,— дидем мин,— мыштым булса да, эшне булдыра торган кеше ул Харис.

— Фу,— диде Гафар чыгырыннан чыгып,— алай булгач кемне язабыз соң? Авыл кадәр авылда газетага эләктерерлек бер рәтле кеше юк!

Мин нәрсә дип әйтергә дә белмәдем. Чыннан да, мәкалә язам, дип әйтүе генә җиңел икән. Язып кара. Без инде өнә күпме газапланабыз. Эшнең рәте күренми әле...

— Һәй,— диде кинәт кычкырып Гафар,— бар, малай, бар андый кеше безнең авылда! Таптым тәки...

— Кем ул? — дидем мин,— кем?

— Белмисеңмени?

Гафар миңа мәкерле итеп карады, кем дә булса, бәлки, белми торгандыр, әмма син белергә тиеш, янәсе.

— Юк, белмим,— дидем мин.

— Ферма мөдире Гөлзада! Вәт кем!..

— Гөлзада?

— Нигә исең китте? Әйе, ул үзе — Гөлзада,— дип кабатлады Гафар. Үзе шаркылдап көлә башлады.

Өстемә чиләге белән салкын су сиптеләрмени! Минем Гөлзадамны телгә алды бит бу! Ачуым кабарды.

— Фактлар, фактлар! — дип, мин урынымнан сикереп торып Гафарның якасына килеп ябыштым.

— Кызма, кызма,— диде Гафар,— без бит газетага мәкалә язабыз. Монда мәхәббәтнең ни катнашы бар? Бу җәмгать эше. Раз так...

Йөрәгем ут кебек кабынып китте. Кулларым котырына башлады.

— Раз так,— дидем,— давай фактларыңны, югыйсә, мин сине... дия-дия, Гафарны ишек төбенә үк китереп кысрыкладым.

— Факт дисеңме? Рәхим ит,— диде Гафар,— әйдә яз...

— Язмый торсын, башта әйт!

Гафар агарынды. Бераз шүрләде булса кирәк. Шулай да сүзеннән кире чигенергә теләмәде.

— Гөлзаданы син миннән дә яхшырак беләсең ич, парин,— диде.

— Беләм.

— Ул нинди иде элек?

— Нинди иде соң?

— Кипкән балык төсле иде бит.

— Соң, шуннан?

— Ә хәзер тутырган тавык шикелле булды. Йөзе алсу алма кебек янып тора, күкрәге...

— Булса соң,— дидем мин Гафарны бүлдереп,— анда синең ни эшең бар?

— Как булмасын! Димәк, ул тавык ите белән сыйлана. Әле көн саен дистә-дистә йомырка да эчә торгандыр. Чи йомырка беләсеңме ничек файдалы...

— Юк, факт түгел бу — уйдырма! — дип кычкырдым мин, Гафарның котын алып.

— Уйдырма? Әгәр пример я син, я мин ферма мөдире булсак? Неушто тавыкларның башларыннан гына сыйпап торыр идек, ә?

— Сөйләмә юкны, минем Гөлзадам алтын кыз ул! — дидем мин тагын да көчлерәк кычкырып.

— Синеке, Гөлзада синеке? — дип, Гафар күләргә маташып карады. Аннан соң күзләрен чекерәйтеп миңа текәлде дә:

— Бәлки, ул минекедер,— диде.— Син аны каян беләсең?

Бусы инде артып китте. Минем характерны белгән кеше бу сүзне һич әйтмәс иде. Мин бер аягым белән ишекне тибеп ачтым да икенчесе белән Гафарның арт санына төшереп алдым.

Инде тынычлангач миңа бик якты уйлар килде. Чыннан да, нигә әле мин бу Гафар белән буталып йөрим? Эшләсәм кулларым юкмы? Гөлзада кебек матур кызны сөя алмаслык егетмени мин?

Икенче көнне иртүк Бөке Харис бригадасына эшкә чыктым.

Шул иртәнге сәгатьтә урамнан узып барышлый Гөлзадамны очраттым. Ул миңа бер сүз дә әйтмәде. Әмма күзләренең елмаюы мең сүздән артык иде. Йөрәгем шатлык белән тулды. «Шундый уңган, шундый матур кызны газетага язып әрәм итәләрме соң?» — дип уйлый-уйлый, йөрешләренә сокланып карап тордым. Күгәрчен кебек теп-теп кенә иттереп атлый. Шәп кыз ул! Тимәгез минем Гөлзадама!

## Мәзәкләр

* * *

Беренче класста укучы бер бала мәктәптән өенә кайтып кергә дә бик ачуланып портфелен атып бәргән.

Моны әнисе күреп:

— Нигә болай борчылдың, нәрсә булды? — дип сораган.

Бала:

— Юк, әни, мин инженер да, артист та, художник та бу мыйм,— дигән.

— Кем булырга телисең, кызым?

— Укытучы.

— Ник?

— Укытучы үзе укымый, укыта гына.

* * *

Берәү өченче тапкыр өйләнгәннән соң, дуслары:

— Я, хатыныңнан уңдыңмы? — дип сораганнар.

— Юк,— дигән теге кеше,— хатыным уңды. Чөнки мин аны дуртенче ире булып чыктым.

* * *

Утыз яшьләреннән дә узып киткән бер егеттән күршесе очрага саен:

— Кайчан өйләнәсең инде? — дип сорый икән.

Егет бу бәйләнчектән котылыр өчен бер көнне:

— Әллә синең кызыңа да утыз яшь тулдымы? — дигән.

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Быел да апрель аенда Казанда традицион шигырь бәйрәме үткәрелде. СССР төзелүгә 50 ел тулуга әзерлек шартларында һәм халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукай туган көннәрдә үткәрелгән бу бәйрәм быел аеруча җанлы узды. Башка елларда ул бәйрәм бер генә көн — 26 апрельдә генә була торган иде. Ә бу ел исә 25 апрельдә үк башланды. Ул көнне күп кенә шагыйрьләребез Габдулла Тукай туган якларга — Кырлайга бардылар. Шигырь бәйрәменә быел Мәскәү, Башкортстан һәм Чувашстан шагыйрьләре дә килгән иде.

Республикабыз әдипләре һәм кунаклар Кырлайдагы Тукай музеена автографлары белән үзләренең китапларын бүләк иттеләр, шигъри митингта катнаштылар. Аннары Арча район үзәгендәге китап кибетендә укучылар белән очраштылар, әсәрләрен укыдылар.

Тантананың иң зурысы 26 апрельдә Казанда булды. Башта шигъри бәйрәмгә багышлап Язучылар союзы идарәсенең махсус утырышы үткәрелде, анда Тукай премиясенең яңа лауреатлары — Фатих Хөсни белән Шәүкәт Галиевне котладылар. Аннары язучыларыбыз һәм кунаклар Казандагы В. И. Ленин, А. С. Пушкин, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Г. Тукайның Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры янындагы һәйкәле каршына килеп, зур шигъри митинг үткәрделәр.

Шигырь бәйрәмен үткәрү комиссиясе председателе, М. Горький һәм Г. Тукай исемендәге премияләр лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким ачып җибәргән ул митингта Тукай премиясенең быелгы лауреатлары Фатих Хөсни, Шәүкәт Галиев, Мәскәү шагыйрьләре Михаил Львов, Вадим Кузнецов, Василий Шабанов, башкорт шагыйре Иосыф Гәрәй, чуваш шагыйре Юрий Петров, татар шагыйрьләре Әхмәт Исхак, Гәрәй Рәхим, Ренат Харисов, Мөдәррис Әгъләмов, Рәдиф Гатауллин үзләренең шигырьләрен укыдылар. Нәфис сүз осталары Әзәл Яһудин, Айрат Арсланов Г. Тукай әсәрләрен сөйләделәр. Казан мәктәпләре укучылары Габдулла Тукай шигырьләрен төрле телләрдә укып күрсәттеләр.

Шигырь бәйрәме язучыларның Тукай исемендәге клубында дәвам итте. Анда шагыйрьләребез тамашачыларга үзләренең шигырьләрен укыдылар. Аннары алар, берничә төркемгә бүленеп, Куйбышев исемендәге химия заводында, «Спартак» аяк киемнәре берләшмәсендә, 4 нче тегү фабрикасында эшләүчеләр белән очраштылар.

## ЯШЬ РЕЦЕНЗЕНТЛАР ТҮГӘРӘГЕ

«Казан утлары» журналы редакциясе каршында яшь рецензентлар түгәрәге эшли башлады. Бу түгәрәккә Казан университетының журналистика бүлеге, татар теле һәм әдәбияты бүлеге студентлары һәм Казанның бүтән югары уку йортларында укучы студент яшьләр йөри. Түгәрәк утырышларында татар совет язучыларының яңа китапларына тәнкыйтьчеләр язган рецензияләр укып тикшерелә. Яхшы дип табылганнары республикабыз газета-журналларында бастырып чыгару өчен тәкъдим ителә.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ОЧРАШУЛАР

СССРның төзелүенә 50 ел тулуга хәзерлек унае белән, Татарстан язучылар союзы каршындагы пропаганда бюросы апрель аенда Казан шәһәре культура сарайларында һәм клубларында «Казан язы» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичәләр үткәрде. М. Горький исемендәге клубта, сәүдә хезмәткәрләре, җитен комбинаты һәм төзүчеләр культура сарайларында үткәрелгән ул кичәләрдә язучы һәм шагыйрьләрдән Г. Минский, Г. Ахунов, Б. Камалов, Р. Миңнегалимов, М. Хәбибуллин, В. Нуруллин, Г. Рәхим, Р. Харисов, М. Маликова, драматург С. Шакуров, җырчылардан Г. Рәхимкулов, Ф. Сөләйманова, Р. Ильясов, нәфис сүз остасы М. Шиһапов, баянчы А. Имаев катнаштылар.

* * *

Әдәби кичәләр Алабуга районында да уздырылды. Анда шагыйрьләрдән Г. Латыйп, Р. Гатауллин, Ә. Рәшитов, Р. Әхмәтҗанов, М. Шәймөхәммәтов катнаштылар. Алар Алабуга шәһәрендә һәм авылларда очрашулар уздырдылар, бүгенге татар совет әдәбияты турында сөйләделәр, үз әсәрләрен укыдылар.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СОВЕТЫНЫҢ ПЛЕНУМЫ

Шушы елның апрель ае ахырында пионериянең 50 еллыгына багышлап, СССР язучылар союзы каршындагы балалар әдәбияты советының чираттагы пленумы үткәрелде. «Балалар әдәбияты — пионер-

ларга» дигән тема буенча Мәскәүдә үткәрелгән ул пленумда төрле милләт язучылары вәкилләреннән егермеләп кеше чыгыш ясады. Әлеге советның члены язучы Ләбибә Ихсанова пленумда Татарстан пионерлары тормышы һәм татар балалар әдәбияты турында сөйләде. Ул шулай ук Мәскәү шәһәре китапханәләре мөдирләре белән һәм Мәскәү пионерлар сараенда башкала укучылары белән очрашып, аларны да татар балалар әдәбияты белән таныштырды.

## КОМПОЗИТОР КИЧӘСЕ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге каршындагы сәхнә ветераннары советы соңгы елларда артистлар истәлегенә, аларның иҗатларына багышланган кичәләр уздыруны гамәлгә кертте. Әнә шундый кичәләрнең берсе Татарстанның атказанган артисткасы һәм күп санлы популяр җырларның авторы композитор Сара Садыйкова иҗатына багышланган иде. Ул кичәне Татарстанның атказанган артисты Фәйзи Йосыпов ачты. Аннары Сара Садыйкованың иҗаты һәм тормышы турында филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен һәм музыкант Исмәгыйль Һилалов иптәшләр сөйләде. Кичәнең икенче бүлегендә Сара Садыйкова иҗат иткән җырлар яңгырады. Аларны җырчылардан Ф. Насретдинов, Д. Сираҗетдинова, Җ. Сәләхова, Р. Тимерханова, Р. Нуриева һәм Р. Ильясов башкарды. Баян партияләрен педагогия училищесы укытучысы А. Имаев алып барды, пианинода композитор үзе уйнады.

## ЯҢА БАЛЕТ

Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры коллективы шушы елның апрель аенда «Бакчасарай фонтаны» балетының яңа постановкасын тамашачыларга күрсәтә башлады. А. Пушкин әсәре буенча Борис Асафьев тарафыннан иҗат ителгән бу балет (Н. Волков сценарие) 1934 елдан бирле илебездә һәм чит ил сәхнәләрендә зур уңыш белән бара. Күп кенә театрлар аны Р. Захаров куелышында сәхнәләштерәләр. Татар дәүләт опера һәм балет театры исә тамашачыларга үз вариантын тәкъдим итте. Яңа балетны РСФСРның халык артисты, театрның баш балетмейстеры Н. Юлтыева куйды.

## Ф. ӘМИНОВ КҮРГӘЗМӘСЕ

Шушы елның апрель-май айларында Татарстан сынлы сәнгать музеенда Ленинград художнигы Фәйзерахман Әминов иҗат иткән әсәрләрнең күргәзмәсе булды. Ф. Әминов художниклар арасында яңа исем түгел. Ул инде Бөтенсоюз күргәзмәләрендә



*«Су буе».*

һәм халыкара күргәзмәләрдә катнашкан рәссам. Аның әсәрләрен илебезнең төрле музейларында, атап әйтсәк, Ленинградның дин һәм атеизм тарихы музеенда, Пермь художество галереясында, Ташкентның А. Нәвои исемендәге музеенда һәм Татарстан сынлы сәнгать музеенда күрергә мөмкин.

Ф. Әминов төрле жанрларда иҗат итә. Әмма аның татар фольклорына багышланган әсәрләре аеруча зур осталык белән һәм үзенчәлекле итеп эшләнгән. «Тукай Кырлайда», «Сак-сок», «Шүрәле», «Хуҗа Насретдин» исемле картиналары әнә шундый. Аларны бер күргән кеше гомере буена онытмый.

Ф. Әминов яшьтән үк Габдулла Тукай әсәрләрен яратып укый. Ә үсеп рәссам булгач, шул әсәрләрдәге персонажларның сурәтләрен ясый. Бу җәһәттән аның «Шүрәле»гә ясаган иллюстрацияләре аеруча игътибарга лаек. Сүз дә юк, «Шүрәле»не бик күп рәссамнар ясаган. Киләчәктә дә ясарлар әле. Чөнки Тукайның «Шүрәле»се үлемсез әсәр ул. Ләкин әнә шул бик күп рәссамнарның «Шүрәле»ләре арасында Фәйзерахман Әминов «Шүрәле»ләре югалып калмый гына түгел, алар бөтенләй аерылып, үзенчәлекләре белән күзгә бәрелеп торалар. Ф. Әминовның «Су анасы» исемле картинасы шулай ук Тукайның шул исемдәге әсәренә нигезләнеп эшләнгән һәм бу әсәрендә дә рәссамның татар халкының тормышын якыннан белүе бик ачык күренеп тора.

Казанда үткәрелгән күргәзмәгә рәссамның йөздән артык әсәре куелган иде. Республикабыз тамашачылары аларның барысын да бик яратып карадылар. Фәйзерахман ага Әминовның бу күргәзмәсе зур уңыш белән үтте.



*«Хуҗа Насретдин».*



*«Тукай Кырлайда»*

* * *

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры коллективының бер группасы драматург Хәй Вахитның «Кияүләр» музыкаль комедиясе (композиторлары С. Садыйкова һәм Р. Гобәйдуллин) белән республикабызның Чаллы, Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә, Баулы һәм Лениногорск районнарында гастрольдә булып кайттылар.

## АРХЕОЛОГЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты каршындагы тарих, археология һәм этнография җәмгыяте, СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты һәм Болгар тарих-архитектура заповедникгы хезмәткәрләре бергәләп археология конференциясе уздырдылар. Узган елның җәендә Биләрдә алып барылган казу-тикшеренү эшләренең нәтиҗәләренә багышлап үткәрелгән ул конференциядә тарих фәннәре докторы А. Халиковның «Болгар ханлыгының монголларгача булган башкаласы һәм аны археологик яктан өйрәнү»,

тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдиновның «Биләр шәһәренең топографиясе», Р. Шәрифуллинның «Биләрдәге кәрван сарай», М. Әхметшинның «Кәрван сарай бинасын консервацияләү проекты», Е. Халикованың «Биләр зиратлары», С. Ефимованың «Биләр зиратларының антропологик материаллары», Н. Кокаринаның һәм А. Терехинаның «Биләрдә табылган балчык-чүлмәк әйберләр, савыт-сабалар» турындагы докладлары тыңланды.

Конференция көннәрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан институтлары конференц-залында археология күргәзмәсе оештырылган иде. Анда узган җәйне Биләрдә алып барылган археологик казулар вакытында табылган әйберләр куелган иде. Күргәзмә Казан галимнәрендә зур кызыксыну уятты.

## МӘСКӘҮГӘ — ОТЧЕТ БЕЛӘН

СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән РСФСР Дәүләт планы үз федерациясендәге автономияле республикалар вәкилләренең отчет чыгышларын үткәрде. Шул уңай белән апрель аенда Мәскәүгә Татарстан вәкилләре дә чакырылды. «Татарстан — Россиянең тугандаш халыклары семьясында» дигән девиз астында үткәрелгән һәм республикабызның экономик һәм культура үсеше турында фикер алышуга багышланган ул сөйләшүдә Татарстаннан профессор П. Абрамов, ТАССР Дәүләт планы председателе урынбасары К. Мөхәммәтҗанов, «Теплоконтроль» заводы эшчесе Социалистик Хезмәт Герое Н. Гыйләҗев һәм Язучылар союзы председателе шагыйрь З. Нури иптәшләр катнашты. Алар РСФСР Дәүләт планы хезмәткәрләрен республикабызның экономика һәм культура өлкәсендә ирешкән уңышлар белән таныштырдылар, алда торган бурычлар турында сөйләделәр.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Артистка Вера Минкина күп еллар буена Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында уңышлы эшләп килә. Ул башкарган рольләрне тамашачылар һәрвакыт яратып карыйлар.

Совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, Вера Егоровна Минкинага РСФСР Верховный Советы Президиумы Указы белән **РСФСРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ЧЫГАНАКЛАР ҖЫЕНТЫГЫ ТӨЗЕЛӘЧӘК

СССР Фәннәр академиясенең тарих бүлеге һәм СССР тарихы институты илебез халыклары тормышына кагылышлы борынгы чыганакларның җыелмасын төзү мәсьәләсен тикшерүгә багышланган симпозиум үткәрделәр. Булачак ул җыентык күп томлы ике сериядән торырга тиеш. Беренче серия СССРның Европа өлешендәге халыклар тарихына кагылышлы чыганакларны эченә алачак. Идел буе халыклары тарихына кагылышлы кыйммәтле көнчыгыш истәлекләренә, бигрәк тә классик гарәп-фарсы географиясенә, җыентыкта зур урын биреләчәк.

Җыелманың икенче сериясенә СССР халыкларының хокук истәлекләре теркәлергә тиеш.

Әлеге симпозиумда чыгыш ясаган атаклы тарихчылар, археографлар, борынгы әдәбият белгечләре төзеләчәк җыентыкның күп милләтле совет халыкларының бай тарихын ачыклауда бик кыйммәтле чыганак базасы булачагын әйттеләр.

Симпозиумда Казан тарихчылары исеменнән СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов чыгыш ясады.

## ЮГАРЫ БӘЯ БИРЕЛДЕ

Н. К. Крупская исемендәге Мәскәү өлкә педагогия институтының гыйльми советы утырышында Үзбәкстанда яшәүче яшь галим Исхак Зәбиров диссертация яклады. «Муса Җәлил һәм Моабит төркеме шагыйрьләре» дигән темага якланган бу диссертациягә официаль оппонентлар профессор С. Шешуков, доцент М. Залесский һәм башка иптәшләр югары бәя бирделәр: «Татар әдәбиятын Ташкент галиме Мәскәүдә яклый. Монда Берлин галиме публицист Леон Небенцальнең дә ярдәме булган. Бу хәл бөек Муса Җәлилнең халыкара әһәмияте турында сөйли»,— диделәр алар.

## МУЗЫКАЛЬ КУЛЬТУРА УНИВЕРСИТЕТЫ

Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары булышлыгы белән узган ел Чаллыда культура университеты эшли башлап, анда «Җыр — халыкның җаны», «Борынгы рус романсы», «СССР халык артисты Соловьев-Седой», «Композитор Франц Шуберт» дигән темаларга занятиеләр үткәрелгән иде инде. Апрель аенда университетның тагын бер занятиесе булды һәм анда җырчылардан Р. Әхметов, А. Еланская, Р. Гобәйдуллин, В. Зорин һәм А. Огородников чыгыш ясап, Кама автозаводын төзүчеләр күңелендә җылы тәэсир калдырдылар.

## ДУСЛАР КОНЦЕРТЫ

Шушы елның апрель аенда бер төркем казакъ артистлары республикабызда булып, концертлар биреп киттеләр. Түбән Кама һәм Казан хезмәт ияләре СССРның халык артисты Р. Абдуллин, Казагыстанның халык артисты М. Абдуллин, Казагыстанның атказанган артисты М. Хәмзин чыгышларын бик җылы каршы алдылар.

*Хөрмәтле укучылар!*

Журналыбызның 8 нче санын Әмирхан Еникинең *«Без дә солдатлар идек»* дигән повесте белән ачабыз.

Күренекле татар шагыйре Нури Арслановка 60 яшь тулу уңае белән бу санда аның *«Еллар, язмышлар»* дигән шигъри әсәрен, башкорт шагыйре Наҗар Нәҗми һәм Гөлшат Зәйнашева шигырьләрен урнаштырабыз.

Сәрвәр Әдһәмованың *«Шул биш нарат»*, Гамил Афзалның *«Халык белән очрашу»* дигән хикәяләре, яшь шагыйрьләр иҗаты, Заһирә Гомәрованың балалар өчен язган шигырьләре игътибарыгызны җәлеп итәчәк.

Культурабыз тарихыннан Равил Фәхретдиновның Болгар шәһәрләре турындагы мәкаләсе, Җәүдәт Кәлимуллинның *«Һәрбер теләк — якын киләчәк»*. Җәмит Рәхимовның *«Өченче этап»* дигән очеркларын укырсыз.

СССР төзелүгә илле ел тулу уңае белән Харис Якуповның *«Татарстанның сынлы сәнгате»* дигән мәкаләсе, әдәби тәнкыйтькә караган материаллар, яңа китапларга рецензияләр һ. б. материаллар белән танышырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210